ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

7.2001



# YAZUÇILARIBIZ ÇİT İLLƏRDƏ



**Foat Ġalimullin, Xarras Əyüp, Məsəğit Xəbibullin**. İstanbul şəhəre. *Tərkiə. 2001 yıl.*



Şağır **İldus Ġiləcev** (unda) Kanadada.

**Казан утлары**
**Qazan utları**

2001

# 7

(945)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***редакциянең хезмәт коллективы***

*БАШ МӨХӘРРИРЕ*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов,**
**Зилә Вәлиева,**
**Фоат Галимуллин,**
**Тәлгат Галиуллин,**
**Миркасыйм Госманов,**
**Аяз Гыйләҗев,**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары),*
**Салих Маннапов,**
**Туфан Миңнуллин,**
**Хатип Миңнегулов,**
**Гәрәй Рәхим,**
**Факил Сафин,**
**Ренат Харис,**
**Зиннур Хөснияр,**
**Розалина Шаһиева.**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Камил Кәримов, Мәгъсум Хуҗин, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Альбина Әхмәтова, Гөлзадә Бәйрәмова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәслимә Сибгатуллина, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова, Асия Рәхимова** (баш бухгалтер).

---

✉✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎☎: Баш мөхәррир — 49-36-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 49-36-63,
гамәли хезмәткәрләр — 49-36-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## *Бу санда*

ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР ҺӘМ ШИГЪРИЯТ

Мәдинә МАЛИКОВА. Алтын ятьмә. *Повесть* ..... 5
Фәрит ГАБДЕРӘХИМ. Мирасым бар. *Шигырьләр* ..... 43
Мөхәммәт МИРЗА. Әткән-әнкән фатихасы. *Шигырьләр* ..... 67
Рифә РАХМАН. Юрыйм яхшыга. *Шигырьләр* ..... 72
Әхәт САФИУЛЛИН. Җепнең очы. *Маҗаралы повесть* ..... 92

ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА. Хан һәм шагыйрь. *Тарихи риваять* ..... 47

ГӘРӘЙ РӘХИМГӘ 60 ЯШЬ

Марсель ГАЛИ. «Чын исеме Гөргери...» ..... 75
Gərəy RƏXİM. Dimək. *Şigırlər* ..... 89

ДУСЛАР ҖЫРЫ

Абдулхак ИГЕБАЕВ. Вакыт тулпарын иярләп. *Шигырьләр* ..... 118

ПУБЛИЦИСТИКА

Нурия ИЗМАЙЛОВА. «Океанның аръягында...» ..... 121

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Азат ӘХМӘДУЛЛИН. Әле нокта куймыйбыз ..... 141
Венера МАКАРОВА. «Зур әдип әзер хакыйкать белән яши алмый...» ..... 148

ТАРИХ

Тәлгат НАСЫЙРОВ. Татар мөһаҗирләре матбугаты ..... 152
Ләйсән МИҢНУЛЛИНА. Татар календарьлары тарихыннан ..... 166

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫ

Гаяз ИСХАКЫЙ. Шагыйрь Габдулла Тукай ..... 171

КОРЪӘН ТАТАР ТЕЛЕНДӘ

11—Һуд (Һуд) сүрәсе ..... 176

ФӘН

Ким МИҢНУЛЛИН, Гафур СӨНГАТОВ. Җырның ертыгы юк ..... 184

Бер сорауга—бер җавап ..... 190
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ..... 191

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: повесть М. МАЛИКОВОЙ «Золотая сеть»; детективная повесть А. САФИУЛЛИНА «Сколько веревка не вьется»; стихи Ф. ГАБДЕРАХИМА, М. МИРЗЫ, Р. РАХМАН, А. ИГЕБАЕВА.
«Драматургия»: «Хан и поэт»—историческая быль Р. ЗАЙДУЛЛЫ.
«К 60 - летию Г. Рахима»: статья М. ГАЛИЕВА о творчестве поэта и стихи юбиляра.
«Публицистика»: «По ту сторону океана»—размышления Н. ИЗМАЙЛОВОЙ.
«Литературная критика»: А. АХМАДУЛЛИН. «Еще рано точку ставить...»; статья В. МАКАРОВОЙ посвящена творчеству Хасана Сарьяна.
«История»: Т. НАСЫРОВ. «Печать татарских эмигрантов», статья Л. МИННУЛЛИНОЙ «Из истории татарских календарей».
«История литературы»: статья Г. ИСХАКИ «Поэт Габдулла Тукай».
Коран на татарском языке.
«Искусство»: статья К. МИННУЛЛИНА и Г. СУНГАТОВА «Из песни слов не выкинешь».
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Три луны»—картина художника З. Гимаева; поэтесса Р. Валиева.

## IN OUR ISSUE:

*The magazin edits monthly*

"Prose and Poetry": M. MALIKOVA'S story "The golden net", A. SAFIULLIN'S story; the verses of F. GABDERAKHIM, M. MIRZA, R. RAKHMAN, A. IGEBAEV.
"Dramatics": «Khan and poet» - the historical true story of R. ZAIDULLA.
"Commemorating the 60th Anniversary of G. Rakhim": M. GALIEV'S article about G. Rakhim's creative works.
"Jurnalism": «Over tue ocean» - N. IZMAYLOVA'S refletions.
"Literary criticism": A. AKHMADULLIN'S article "It is early to stop...", V. MAKAROVA'S article about Khazan Sarian's creative works.
"History": T. NASIROV "The Seal of Tatar emigres; L. MINNULINA'S article «From the history of Tatar calendars».
"History of literature": G. ISKHAKI'S article «The poet Gabdulla Tukai».
"Life and religion": Koran in Tartar language.
"Science": K. MINNULLIN'S and G. SUNGATOV'S article.
The diary of social and cultural life.
In our cover: «Three moons»—the picture of painter Z. Gimaeva; poet R. Valieva.

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 49-34-61 телефоны белән басмахәнәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянен компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 20.06.2001 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108¹/₁₆.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 8619 Заказ А-255
Журнал Татарстан Республикасынын Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2001 ел.



## Мәдинә Маликова

# АЛТЫН ЯТЬМӘ

ПОВЕСТЬ

Сихри балкышта яшьләр бии. Ак ефәктән киенгәннәр, күбәләктәй очыналар. Аллы-гөлле нур тасмалары биючеләрнен нәзек-нәфис сыннарына урала, оркестрнын сихри моны күнелнен иң нечкә кылларын тибрәтә. "Безнен балалар чын балет артистларыннан шәбрәк бии түгелме?—дип, куанычын кая куярга белмичә, сәхнә артыннан карап тора Тәслимә.—Кара, ничек остардылар! Мин өйрәттем бит аларны, мин!". Ижат әһелләре, менә шушындый минутларны күрү хакына, очына-очына, шашына-шашына, дөньянын башка төрле куаныч-ләззәтләреннән ваз кичеп, гомере буе тырыша бит. Ярый ла кайчан да булса морадына ирешсәң! Ә менә Тәслимә ун еллык хезмәтенен нәтиҗәсен күреп тора, аннан бәхетле кеше юк бүген! Әнә, биючеләр сәхнә алдына тезелеп бастылар да, бердәм хәрәкәт белән, нәзакәтле итеп баш иделәр.

Ә зал халык белән шыгрым тулы, һәммәсе аягүрә торып алкышлыйлар: "Афәрин! Браво! Тәс—ли—мә! Тәс—ли—мә! Тәс—ли—мә!" Аны чакыралар. Ул чыга. Әнә, бер чибәр апа, галәмәт зур чәчәк бәйләме күтәреп, ана таба килә. Бәй, чәчәк түгел, торт икән ләбаса! Өсте аллы-гөлле чәчкәләр рәвешендә ясалган бик зур торт. "Яртысын биючеләргә бүлеп бирсәм, яртысы гел үземә кала",—дип уйлый Тәслимә һәм ин өстәге татлы алсу чәчкәне иреннәре белән суырып алырга үрелә.

Ул шунда уянып китте. Берни анламыйча, колаклары чынлавын гына ишетеп, карангыда шактый вакыт кыймшанмый ятты. Ниһаять, зиһене ачыла башлады. Башка—авыр уйлар, күнелгә ачы сызлану әйләнеп кайтты. Нинди концерт? Нинди алкышлар? Мәдәният сараен котсыз тынлык, карангылык баскан, анда балалар да, аларнын ата-аналары да,

---

Мәдинә МАЛИКОВА—*язучы, «Кар сулары» (1975), «Янар таулар яктысында» (1980), «Узма, гомер» (1982), «Бер күрүдә яраттым» (1985), «Басып сайрар талы бар» (1987), «Шәфкать» (1990), «Фидая» (1991) һ. б. китаплар авторы. Россиянең һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Ямашев исемендәге премия лауреаты. Казанда яши.*

Тәслимәнең хезмәттәшләре дә күптән күренми бит инде. Штатларны кыскарттылар, түгәрәкләрне күптән тараттылар... Ниткән торт ул тагын! Ак булканы туйганчы кайчан ашаганы да онытылган инде...

Күнел сызлавына ашказаны ачытуы килеп өстәлде. Су эчеп куярга инде әллә? Тәслимә, ирен борчымаска, күрше бүлмәдәге улы белән кызын уятмаска тырышып, яланаяк тавышсыз гына басып, аш бүлмәсенә узды. Ишек ачык иде. Ул ут төймәсенә басты. Өстәл янында чуар трусик кына кигән ун яшьлек улы Самат басып тора, кулында кара ипи телеме. Иртәнге чәй янына, дүртесенә тигез бүлеп ашарга дип исәпләнгән ярты кирпечтән юка итеп кисеп алынган. Малай, әллә уттан куркып, әллә әнисен күрергә теләмичә, күзләрен чытырдатып йомды, иреннәрен кысты. Анын ике янагы бүлтәеп чыккан, күрәсен, ул ипине комсызланып капкан иде. Алар икәү, ана белән бала, бер-берсенен йөрәк тибешен ишетерлек тынлыкта һәм күзләрне ертырлык яктылыкта, шактый вакыт кара-каршы басып тордылар. Малай кыймшанмады, күзен ачмады, тик шәрә инбашлары гына тетрәнә, гүяки китереп органны көтә иде..

Ана улын бу газаплы хәлдә тота алмый, шул ук вакытта нишләргә, нинди сүзләр әйтергә дә белми иде. Ул малайнын сары чәчле башын күкрәгенә кысып: "Улым, балакаем, нинди көнгә калдык бит",—дип сулкылдап елап җибәрүдән көчкә тыелып калды. Калтыранган тавыш белән:

—Бар, балам, кереп ят,—диде. Малай, ипи кисәген култык астына яшерергә тырышып, чәйни башлап, стенага елыша төшеп, әнисе яныннан шуып узды.

Тәслимә йоклый алмады. Әнисен искә төшерде. Берзаман шулай, гаилә белән дүртәүләшеп авылга кайткач, җәйге матур кичтә, көтү кайтыр алдыннан, болдырда сөйләшеп утыралар иде. Киленнәре Нәкыя ишегалды уртасында сыер чиләгенә буханка-буханка ипи ваклый.

—И-и, килде дә мул заманалар!—дип исе киткәндәй башын чайкап куйды әниләре.—Без үскәндә алабута икмәген дә житкерә алмаган чаклар бар иде. "Мич алдында көлгә күмгән бәрәңгеләр ята, шуларнын берсен алып бирегезсәнә!"—дип тилмереп үлгән кешеләр булды. Нинди бәрәнге булсын, кәлҗемәсе дә юк иде. Ул чакта әнкәйнен, элегрәк заманнарда бик мул тора идек, ипи катыларын сыерга ашата торган идек, дип сөйләгәненә хәйран кала идем. Әнә, хәзер, күр инде, ашап туймаслык ипиләрне кирпече-кирпече белән малга турыйлар. Гөнаһ шомлыгы була күрмәсен инде, ходай ачлык күрсәтмәсен! Мул чак белән юк чакнын алышынып килә торган гадәте бар. Алла сакласын!

Менә хәзер Тәслимәнен хәтерендә ул чакта Нәкыя кулында уаланган соры бодай ипиләре аермачык төсмерләнә. Шушы төннән атылып чыгып, моннан алты-җиде ел элек булган җәйге кичкә, авылга очып кына барып төшәр иде дә, ипине Нәкыя кулыннан тартып алып, умырып кабар иде. Әллә теге чакта әнисе әйткән заман—туклыкнын ачлыкка алмашынган чорымы бу? Алай дисән, илдә муллык лабаса, кибетләрдә, базарларда азык-төлекнен, әйбер-каранын исәбе-хисабы юк. Тик алар Тәслимә белән Инсаф гаиләсе өчен түгел. Сигез ай инде заводтан эш хакы түләмиләр. Акчаны айлыклап санап көн күрергә күнеккән кешеләр бит алар! Елга якын эш хакы алмыйча ничек яшәргә кирәк! Инсафнын җан кебек күргән "Жигули"ен сатканнарына да өч ай инде. Кадерләп-тәзәткәләп торганга тыштан ялтырап күренсә дә, күптәнге машина иде, арзанга китте шул. Тәслимә үзен ишексез, тәрәзәсез таш куышта калгандай хис итте, хәтта янында яткан ире дә бу кысынкылыктан коткара алмый, юаныч бирә алмый кебек иде. Хәзерге вакытта күп акча яисә мул ризык кына аны юата алыр, иркен сулыш алырга мөмкинлек бирер иде. Инсаф каян алсын аларны?

Тагын әнисе искә төште. Теге чакта, болдырда сөйләшеп утырганда, Тәслимә:

—Ә шулай да, әни, ачлык килсә, гаиләдә ин беренче кем үлә?—дип сораган иде.

—Ин элек ир кеше бирешә, кызым,—дип җавап бирде әнисе.—Чөнки ул бөтен гаиләгә азык эзләп хәлдән тая. Буш кул белән кайта да, сузылып ятып җан бирә. Намуслы гаиләдә, балаларны кызганып, өлешне тигез бүләләр, ләкин ир-атка җан асрар өчен бала белән тигез өлеш кенә җитми. Ә хатын-кыз казан тирәсендә ялманып та хәл ала.

Бу сүзләр исенә төшкәч, Тәслимәгә кайнар су сиптеләрмени, тәне кызышты: ул да соңгы вакытта, аш пешергәндә, тәмен татуны сылтау итеп, артыграк кабып куймыймы? Димәк, ул да, улы Самат кебек, урлаштыра? Кызы Рәсимәнең дә башкалар күрмәгәндә чемченгәләгәне сизелә бит. Инсафка исә алдына китереп куйганы гына эләгә. Димәк, җитмәүчелек аларның тәнен ябыктыру, хәлсезләндерү генә түгел, җаннарын суыта, вөҗданнарын керләндерә? Үз өйләрендә бер-берсеннән урлашучы карак ясый?.. Нишләргә? Бүгенге көндә аның белеме бер тиен тормый, һөнәре шулай ук, тәҗрибәсе, хезмәте беркемгә дә кирәкми. "Әгәр минем үземне базарга чыгарып сатсалар, әйтик, бик борынгы заманнардагы кебек, кеше сата торган базарлар булса, ничә тәнкә бирерләр иде икән?"—дигән саташулы сорау килде аның кызган башына. Ләкин шундук сискәнеп китте. Әйе, кешеләр хәзер дә сатыла, дип сөйлиләр. Тәннәрен сатуны кәсеп итеп алган хатын-кызлар бар, диләр. Ләкин, беренчедән, утыздан узган хатыннарның ул базарда да бәясе өч тиендер. Аннары аның кулыннан килми бит ул эш. Бик тырышса да булдыра алмаячак ул аны. Башка заманда, бөтенләй бүтән тәрбия алган бит ул. Шунда ул үз-үзенә нәфрәтләнеп куйды: караңгыда саташа башлады, ахрысы. Башына тузга язмаган уйлар килә.

Иртәнге чәй янына утыргач, ул калган икмәкне дүрткә бүлде. Улы белән кызының телемнәргә керфек тә какмый текәлгәнен бүген аеруча нык сизде. Өлешләрнең берсен кечерәк итте ул. Анысын үз чынаягы янына этәрде. Чәйдән соң Рәсимә үзе белән бергә бишенче классны тәмамлаган дус кызы янына, аскы каттагы квартиргә төшеп китте. Ул кызның әти-әнисе икесе дә ит комбинатында эшлиләр, аш өстенә керсә, Рәсимәне дә табын янына утырталар. Самат та каралган кроссовкасын кия башлады.

—Ә син кая?

—Иптәшләрем янына!..

Малай, иелгән килеш, әнисенә астан кистереп карап алды. Салкын тимер төсле күзләрендә җәберсенү, ачу ярылып ята, әнисе сүз әйтсә, кабынып китәчәге күренеп тора иде. Ачның ачуы яман!

Балалар артыннан ишекне бикләп алгач, Тәслимә зур бүлмәгә кереп, совет чорыннан калган "Горизонт" телевизорын кабызды. Мәскәүдән бер олы яшьтәге юан хатын, эшсез, акчасыз калган халыкка вәгазь укып маташа. Бүгенге шартларда һәркем үз көченә генә таянырга тиеш, ди. Әнә, ди, бер карчык, ди, күршеләре көньякка киткәндә, аларның гөлләренә су сибеп, мәчеләрен карап торырга ялланган. Икенче бер карчык челтәр бәйләп, шуны базарда сатып кәсеп итү җаен тапкан. Бер ир-ат ватык тимер-томырдан тормыш кирәк-ярагы әмәлләргә керешкән. "Сөмсерегез коелып, үз-үзегезне кызганып, йомылып өегездә утырмагыз! Хәрәкәтләнегез! Урамга чыгыгыз! Кая да булса барыгыз!"—дип тәмамлады хатын нотыгын.

Тәслимә ачу белән шалт итеп телевизорны сүндерде. Ана калса, бу квартирда иң тынгысыз кеше Самат әнә! Көннәр буе кайларда йөри торгандыр! Башында һаман шулдыр инде аның да—ничек тамак ялгарга! Ә андый гамь юньлегә илтмәс шул—йә группировкага өстерәп кертер, йә токсикоманлыкка (Алла сакласын!) сәбәп булыр, яисә бурлыкка (Ходай күрсәтмәсен!) өйрәтер. Нишләрсең шунда, нихәл итәрсең?

Кая соң әле бу Инсаф үзе? Баксаң, костюм-чалбарын кигән дә, җыймаган урын өстенә сузылып яткан икән. Чыгып китәргә җыенган да кире уйлаган, күрәсең.

—Син нишләп ятасың?

—Күрмисеңмени, тик ятам. Ял итәм! Тагын бер айга түләүсез ялга кудылар безне!

—Шуннан? Көн-төн урын өстендә аунарга дигәнмени?

—Урамда аунарга кушасыңмы әллә?

—Юньле ата булсаң, малаеңны карар идең әнә!..

Инсаф торып утырды да, хатынына астан сөзеп карады. Боздай салкын күз карашы ачу һәм нәфрәт тулы... тагын бер-ике сүз әйтешсәләр, сикереп торып, бәреп җибәрергә дә күп сорамас. Тәслимә тынсыз калды: улы Самат күзләре бит бу! Мондый охшашлык аны салкын су сипкәндәй айнытып җибәрде. Туктарга кирәк. Башка хатыннар, ирем кыйнады, дип зарланса, акыл өйрәтергә бик оста иде бит үзе: "Беркайчан да ирегезне ярсытмагыз! Теләсә нинди чарасын табыгыз, ләкин үзегезгә суктырмагыз! Ирләрнең кулы бер ычкынса, тукмаудан биздереп бул-мый",—ди торган иде.

Иренең аңа сукканы юк, чөнки Тәслимә вакытында чигенә белә. Ана карап сүзе дә аста калмый, тынычлангач, үз теләгәнен җайлап үткәрә. Бу юлы да гадәте җиңде, ни ярсыган булса да, чигенде. Ишекне ябып, алгы бүлмәгә чыкты.

Анын бөтен вөҗүден үпкә, җәберләнү, үз-үзен кызгану хисләре биләп алган иде. Ни өчен иң якын кешеләре аны күрәлмый? Ни гаебе бар анын ире каршында, балалары алдында? Кай җире ким анын башкалардан? Тәслимәнең күзләренә яшь тыгылды.

Ул, үксүен тыярга тырышып, тәрәзә янына килде. Анда, август кояшының чамасыз эссесеннән хәлсезләнеп, җилсез һавада нечкә ботакларын аска салындырган карт каеннар ышыгында, эскәмияләрдә әбисәбиләр тезелеп утыра, ике-өч яшь хатын бала арбасы этеп йөри иде. Малайлар исә күренмәде. Самат кайда йөри соң әле?

Улы өчен борчылу Тәслимәнең үзен кызгану хисен күмеп китте. Ул ашыгып йокы бүлмәсеннән озын итәкле, вак бизәкле күлмәген алып чыкты. Ни дулкынланган булса да, көзге каршына басып, эре дулкынлы коңгырт чәчен җентекләп тарады, лак сипте. Каш-керфекләрен, битен буяды. Күптән күнегелгән бу эшләрне ул уйлап та тормыйча башкарды. Биек үкчәле кызыл туфлиләрен киеп, түгәрәк йөзенә гамьсезлек галәмәте чыгарып, ишекне ачты. Монысы да һөнәре өйрәткән гадәт—эчендәге тышында булса, беркайчан да башкаларны матур биетә алмаячаксың. Урта буйлы гына булса да, биек үкчәләре, тездән югары ерылган озын итәге, нечкә сыны аны башкалардан калку, зифа итеп күрсәтә, урамнардан узганда, күпләрнең карашын үзенә җәлеп итә иде.

Самат урам чатындагы кечкенә базар артында, буш әрҗәләр, катыргы кисәкләре аунап яткан тузанлы мәйданчыкта, үз ишләре белән уйный иде. Киноларда күргән шөгыль белән мәшгульләр, бер-берсенә аякларын чөеп тибенәләр. Әнисен күрүгә, бөтен тәне тартылып туктап калды, каш астыннан янә сагаюлы, салкын караш ташлады. "Өметен өзгән, бер әйбер дә алып бирә алмыйм шул",—дип уйлады Тәслимә кимсенеп. Йомшак кына итеп: "Ерак китмә, улым",—диде.

Өйгә керәсе килми иде, базарга аркасы белән борылып, урам чатына таба китте. Шәһәр үзәгенә илтә торган автобуска утырды.

Барыр җире юк иде, Бауман урамында әрле-бирле йөренде. Кыйбатлы тауар белән тулган затлы кибетләргә, "Макдоналдс" ашханәсендә чират торган яшьләргә, анда да, монда да күтәрелеп-төзелеп килгән биналарга, анда җан-фәрман эшләп яткан төзүчеләргә хәйран калды. Тормыш кайный, кешеләр эшли, ашый, матур киенә, яши. Тик Тәслимәнең генә бу яшәешкә катышы юк, бу дөнья белән бернинди алыш-биреше юк. Ничек алай килеп чыкты соң әле бу? Элек эше дә башыннан ашкан иде, кибетләргә керсә, күзе төшкәнне сатып алырлык чамасы да бар иде. Дөрес, мәдәният сараенда гомергә зур акча түләмәделәр, әмма Инсаф—заводта алтын куллы оста, станокларны көйләүче, бик башлы уйлап табучы да. Читтән торып институт тәмамлады, тик, мин кеше көтүләргә яратмыйм, дип,

житәкче булудан баш тартты. Акчасы да инженерлардан күбрәк килә иде.

* * *

Уйларына батып, кая барганын сизми дә калган, ишегалдына кереп баскан икән. Каршында таныш ишек, Каракүзев дигән эшмәкәрнең эш урыны, заманча әйтсәң, "офисы". Әгәр аяклары Тәслимәне монда китергән икән, гаҗәп түгел: Каракүзевнең кызы бакча яшеннән, ике ел буена бию түгәрәгенә йөрде. Үзе Инсаф белән бер цехта мастер иде, әле машинаны сатканда да ярдәм итеште.

Каракүзев—карачай белән маржадан туган егет—кыяфәте белән, күрәсең, әтисенә тарткандыр, түгәрәк битле, кара чәчле, юантыграк адәм. Тәслимәне ачык чырай белән каршыларга тырышты. Әмма эше тыгыз, борчулары зур иде, күрәсең, зарланырга кереште:

—Берәүнең дә эшлисе килми! Ашарга гына авызларын ачып куйганнар!

Эшлисе килми?! Шаккаткыч иде бу. Эшсез халык белән урам тулган! Бик эшлиселәре килә—юк эш! Тәслимә үзе бик эшләр иде.

Ә Вадим Каракүзев ни рәвешле авыр хәлгә калганын сөйли иде: ул Нижгар заводының машиналарын сату белән шөгыльләнә, хәзергечә әйткәндә, шул заводның дилеры икән. Бу айда эшләр бик кызып киткән, чөнки Нижгардан бер зур кеше Мәскәүгә түрә булып күчкән дә, Рәсәйдәге бөтен житәкчеләргә чит ил машиналары белән йөрүне тыйган. Үз илендәге заводларны эшләтергә, үз эшчеләренә акча түләргә кирәк, ди икән. Шул хакта хөкүмәтнең карарын да чыгарганнар. "Мерседес"ларда, "Гранд-чероки"ларда кыланып йөрүчеләрне жавапка тартачаклар, имеш. Хәзерге вакытта районнардагы түрәләр "Волга"ларга күчеп утырырга ашыгыра. Тик район казналарында акча юк. Машинаны иткә, майга алыштырып алырга туры килә месkennәргә. Менә бүген дә бер районнан атланмай килергә тиеш. Вадимның аны урнаштырып йөрергә вакыты юк, хәзер үк Нижгарга чыгып чабасы бар! Май сатарга кеше табып булмый, каһәр суккыры!

Май. Атланмай. Тәслимә, сиздермәскә тырышып, ялманып куйды. Әллә кайчаннан бирле инде алар өендә атланмайның булганы юк. Маргарины гына керсә дә зур сөенеч. Узган төнне күргән төше хәтеренә килде: теге татлы торт күзгә күренде, иренәнә тимәде бит.

—Мин урнаштырыйммы соң?— диде Тәслимә, май тирәсендә чуалса, бөтенләй буш калмасын уйлап.

Вадимның күзләре кабынып китте:

—Чыннан да, алыгыз, Тәслимә Зиннуровна! Свежий май, заводтан бүген чыкканны төяп яталар анда! Мин сезгә килосын унике меңнән* бирәм. Унбишәр меңнән кулыгыздан тартып алачаклар.

—Күпмедән бирәсез?—дип шаккатып сорады Тәслимә. Алар янындагы кибеттә майның килосы егерме алты мең тора, якындагы базарда егерме меңнән саталар. Ярты бәясенә булып чыга түгелме бу?

—Унике меңнән, Тәслимә Зиннуровна. Колхоз базарында унсигез мең майның бәясе. Кибетләр унбишәр меңнән кулыгыздан тартып алачаклар.

—Күпме соң ул?

—Күп тә түгел! Өч тонна ярым гына.

Өч тонна ярым? Күпме урын кирәк соң аңа? Ләкин Тәслимә берни уйлап өлгермәде, Вадим, мәсьәләне хәл кылынганга санап, урыныннан сикереп торды да ишеккә юнәлде.

—Әйдәгез, бухгалтер белән таныштырам, барысын да аңлатыр, ярдәм итәр,—дип зиһене таралыбрак торган Тәслимәне дуылдатып күрше бүлмәгә

---

* Бәяләр 1996 елгы.

алып кереп китте. Андагы карангы чырайлы арык хатынга:—үзем кебек ышанычлы кеше, майны бүген ул ала, барсын аңлат, ярдәм ит,—дип быдырдады да, чалбар балагына ут капкандай чыгып та чапты—поездга соңга кала икән.

Роза белән,—бухгалтерның исеме шулай иде,—өстәл аша кара-каршы утыргач, аның сөмсере коелган кыяфәтен күргәч, Тәслиманең эчен шик корты нык ук кимерергә тотынды. Гомерендә бер тапкыр да сату-алу белән шөгыльләнеп караганы юк, нишләр?

Ул арада Роза телефонга ябышты, районга шылтыратты.

—Китерегез майны, кабул итәбез,—диде.—Аннары борылып:—Нинди май китерсеннәр—кисәкләнеме, каплынымы?—дип сорады.

—Аның аермасы нидә соң?

Розаның соры күзләре сирәк керфекләре арасыннан атылып чыгардай булып кинәйделәр—ул шул хәтле гаҗәпләнде.

—Май күргәнегез юкмы әллә? Кисәкле май кырыгар килограммлы тартмаларда була, каплысы—ваклап төргәне—икешәр йөз граммлы...

Бизнес дигән өлкәдә Тәслиманең үз өстенә тулы җаваплылык алып кабул иткән беренче карары иде бу. Мәсьәләне дөрес хәл кылганы соңрак ачыкланды. Әгәр шунда кисәклене алган булса, белмим, ерып чыга алыр иде микән?

—Ваклап төргәнен,—диде ул.

—Каплысын,—дип кабатлады Роза телефонга. Аннары трубканы колагыннан алып:—Сәгать өчләргә килеп җитәләр,—диде.—Кайда очрашасыз?

Тәслимә белә: бу бик мөһим мәсьәлә. Балалар белән күп эшләгән кеше, фәлән җирдә, фәлән вакытта җыелабыз, дип бик нык тукыганнан соң да, аңлап житкермиләр, буталалар. Аймылыш булалар. Шуның аркасында чит клубларда, мәктәпләрдә концертларның өзелгән чаклары булды. Ул, телефонны Роза кулыннан алып, үзе сөйләште. Чаллы юлыннан киләчәкләр икән. Димәк, ГАИ постын узгач, андагы күпер астына кергәнче, туктап торсыннар. Шунда очрашырбыз. Машинаның номеры...

Роза җинел сулыш алды. Чырае да яктырып киткәндәй булды хәтта.

—Бөтен шәһәрне майга гарык иткәннәр!—диде.—Ике көн тоташ шылтыратып утырам, ник бер база, ник бер кибет кабул итсен! Һәммәсе май белән шыплап тулган. Аллага шөкер, котылдым.

Бу юлы Тәслиманең күзе акайды. Ничек? Майны сатар урын юкмыни? Роза исә ана карамый, кәгазьләр актару белән мәшгуль иде.

—Кая, бирегез реквизитларыгызны,—диде ул.—Договор төзик.

—Нәрсә соң ул "реквизит"?

Розаның чиктән тыш хәйран калган кыяфәтен тасвирлап бетерү мөмкин түгел иде.

—Сез нәрсә, куктән төштегезме әллә? Предприятиегезнең исеме, адресы, банктагы счеты. Печәтегез үзегез беләнме?

Шуннан соң бу икәүнең, бер-берсен аңламаудан гаҗизләнеп, рәнҗүен һәм ярсуын көчкә тыеп, буталып сөйләшүе китте. Ниһаять, Роза Тәслиманең бу эшкә очраклы рәвештә килеп кергән томана хатын икәнен аңлады. Керфеген дә какмыйча, бүлмәнең почмагына күзен текәп озак кына уйланып утырды да, үзалдына:

—Мина барыбер түгелмени?—диде.—Хуҗа кушканны эшлим дә вәссәлам. Кайткач үзе теләсә нишләр тагын.—Аннары Тәслимәгә:—Менә сезгә договорның без кул куйган нөсхәсе,—диде.—Иртәгә кул куеп, печәт басып китерерсез. Майны кабул итеп алырга доверенность бирәм. Исегездә тотыгыз: без сезгә килосын унике меңнән бирәбез. Акчаны расчетный счет аша күчерергә кирәк булыр. Зинһар, озакка сузмагыз, машина өчен түләргә кирәк.

Ул Тәслимәгә берничә бит кәгазь сузды да, сумкасын алып, урыныннан кузгалды.

—Калганын хужа кайткач сөйләшерсез.Мине налоговыйда көтәләр.

Бүлмәдән чыккач, бухгалтерның күнеле йомшарып китте.

—Хәзер вакыты жайсыз шул,—диде ул баскычтан янәшә төшеп барганда.—Сентябрь башында майны "Суык" комбинатына жыя башлаячаклар. Анда инде май заводларына үзләре теләгәнчә сатарга рөхсәт булмаячак. Шуңа хәзер сатып калырга ашыгалар да. Кайсына акча кирәк, кайсына машина. Житмәсә майны чит илләрдән дә күп китергәннәр. Бераздан хәл жиңеләячәк. "Суык" комбинаты көзгә әзерләнә, сакларга товар кабул итми. Анда барып йөрмәгез. Саклар урын тапсагыз, берәр айдан маегыз егерме меннән китәчәк. Миңа күрерсез. Безгә шул кырык ике миллионны күчереп куйсагыз, сентябрьдә яхшы табыш алачаксыз. Кырык ике миллион әлләни күп акча түгел.

Кырык ике миллион? Күп акча түгел?! Күп дигәне күпме була икән соң ул акчаның?

Бухгалтер, лыбыр-лыбыр килеп, надан юлдашына табыш алу серләрен аңлаткан арада, трамвай тукталышына килеп житкәннәрен сизми дә калдылар. Роза трамвайга утырып китеп барды, Тәслимә әвәрә булып торып калды.

* * *

Сәгатенә карады—унбер тулган иде. Машина килергә нибары дүрт сәгать калган. Шул вакыт эчендә майны бушатырга жайлы урын табарга кирәк. Юкса эш харап булачак.

Ул тукталыштагы эскәмиягә утырды да, сумкасыннан язу кенәгәсен алды. "Бу яшькәчә мәгарәдә ятмадым лабаса, халык арасында көн иттем. Кинәшер кеше табылырга тиеш!"—дип уйлады.

Берәүләр—кәсепкә маһир, икенчеләр ижатка сәләтле була, анарда исә бу ике сыйфат берләшкән иде. Берничә кешене тоташтырып, хәрәкәткә китерүдә ул ижат чалымнары күргәндәй булды, күңелендә рәхәт бер жилкенү тойды, авыз эченнән генә көйли башлады хәтта.

Учындагы язу кенәгәсен актара торгач: "Менә ул!"—дип тукталып калды. Нуретдин Камилев— бер министрлыкта зур гына житәкче. Улы Нурулла биючеләр арасында асылташ иде. Якында гына, трамвайда ике тукталыш кына барасы. Урынында булса гына ярар иде.

Юлы унды. Камилев үзендә икән. Алгы бүлмәдәге компьютер каршында иелебрәк утырган кәттә кызый башта аны карангы чырай белән каршылады. Башын да калкытмыйча, сәламен дә алмыйча гына исемен сорады, телефоннан хужасына шылтыратып, кем килгәнен әйтте. Һәм шундук, алыштырып куйдыларммыни, тураеп утырды, елмаеп жибәрде:

—Нуретдин Исмәгыйлович сезне көтә,—диде.

Ничек "көтә"? Кемне көтә? Бәлки, башка берәү белән бутагандыр?

Әмма секретарьша ялгышмый: Камилев чыннан да аны көтә булып чыкты. Ишекне ачуга, зур бүлмәнең түреннән, ике кулын сузып, каршыга атлады:

—Тәслимә Зиннуровна! Менә бәхет! Сезне борчудан кыенсынып, шылтыратмый тора идем! Рәхмәт килүегезгә!

Селектордан секретарьга дәште:

—Люция! Кофе!

Гажәп иде бу, чөнки, кагыйдә буларак, зур кешеләрне генә шушылай олылап каршы алалар, ни эш урыны, ни берәр төрле байлыгы булмаган буш кесәле бәндәләрне түгел. Әнә, хужа түргә, үзенең иркен кәнәфиенә дә урнашмады, зурлау йөзеннән, ян өстәл кырыена, кунакның каршысына утырды.

Тәслимә Камилевның елмаюдан балкыган ак йөзеннән, сабыйларча эчкерсез зәңгәр күзләреннән үз соравына жавап эзләде. Нилектәндер йомышын әйтергә кыенсынып калган иде ул.

Секретарь кертеп биргән тәмле печеньены кабып, кайнар кофе

эчкән арада, министрлыкның авыр хәле турында сөйләштеләр. Хөкүмәтнең һичнәрсәгә акчасы юк: мәгарифкә дә, мәдәнияткә дә, сәламәтлек саклауга да. Кая барып чыгарбыз болай дәвам итсә.

Тәслимә өзек-төтек җөмләләр белән хуҗаның сүзен хупларга тырыша, эчтән исә үзен ничек тотарга белми аптырый иде. Бу рәвешле әңгәмә кору якын дуслар, яхшы танышлар, бертигез кешеләр арасында була гадәттә. Ләкин бередә алар ничек тигез булсын? Алай гына түгел, хәтта үзеннән югары куя кебек түгелме Нуретдин аны? Тәслимә кояш нурларын бераз йомшартып торган затлы челтәр пәрдәләргә караган, башында: "Мин өемә шундыйларны бирәр заман элә алырмынмы икән?"— дигән көнчелекле уй чагылып уза: "Вакыт үтә бит! Майны кая куярмын!"— дигән борчу аны күнелдән пычак белән уеп алгандай итә иде.

Хуҗа исә сүзне әкренләп мәдәният йортына, бию түгәрәгенә, үзенең Нурулласына күчерде. Ниһаять аңлашыла башлады: улы аркасында хөрмәтле икән ул түгәрәк житәкчесен. Баласының тәрбиячесен кайсы ата ихтирам итмәс? Бигрәк тә тәрбиячесе яхшы булса. Нуретдин исә Тәслимәне тырыш, талантлы, сәнгатькә бирелгән остаз дип белә. Нурулла унберенчегә күчте. Алдагыны хәзердән уйларга кирәк. Мәдәният институтына керсә, бик яхшы булыр иде. Менә шул эштә ярдәме кирәк икән.

Иң элек башка килгән уй шул булды: бигрәк әйбәт! Бәйрәм ашы кара-каршы. Бирәү егетне институтка кертергә ярдәм итә, икенчесе май сатуда булыша. Монда бернинди хилафлык та булмаячак, чөнки Нурулла конкурстан биеп кенә узачак—Ходай аңа сәләтне мул биргән. Ике-өч ел элек алар чит илләргә баргаладылар, Алманиядә, Болгариядә, Венгриядә балаларның биюен бик яраттылар, Нурулланы һәрвакыт аерым алып мактыйлар иде Институтка аны да алмагач, кемне алырлар тагын?

Ләкин.. Ләкин хилафлык бар иде монда. Чөнки сүз янәшә кую мөмкин булмаган, чагыштырып булмый торган нәрсәләр турында барачак иде. Яки, авырлыкларны җиңеп, сайлаган якты юлына тугры каласың, меннәргә жан азыгы бирүгә, аларның тормышын бизәүгә хезмәт итәсең; яки, ул юлдан тайпылып, караңгы ешлыкларда акча аулау кәсебенә бирелэсең. Тәслимәнең май турында сүз башлавын Камилев, мөгаен, менә шулай кабул итәчәк, күнеленнән аны хилафлыкта гына түгел, хәтта хыянәттә гаепләячәк иде. Ләкин каршысында утырган хатынның өстәлдәге кәнфит-прәннекләрне учлап-учлап авызына тутырудан чак кына тыелып калганын беләме соң ул? Балаларын туйганчы ашата алмавына бәгыре ничек телгәләнгәнен беләме? Каян белсен! Хөкүмәт түрәләрне ач тотмый торгандыр, шәт. Ачның хәлен тук белмәс.

Тәслимә төкереген йотты да:

—Минем сезгә бер үтенечем бар иде,—диде.—Май сатарга кирәк миңа. Өч тонна май.

Камилев мингерәп киткәндәй булды. Ул дәүләт эшендәге кеше, Инсаф белән бер токымнан, алып-сату кәсебенә карашы да шундый иде.

Тәслимә аңа бутала-бутала, быдыр-быдыр машиналар, бартер, арзан май турында сөйләргә тотынды. Камилев урыныннан кузгалып, түр өстәл артындагы кәнәфиенә барып утырды. Йөзе сүрелде, карашы өстәлгә текәлде. Ул аптырашта иде, гүяки әле генә аның каршысында биегәеп торган гүзәл сын, кинәт кенә мәрмәр тирәге уалып, җиргә мәтәлеп төште... Аңа ничек карарга? Иякне чөепме, әллә каш астыннанмы?

—Майга урын табылыр анысы,—диде сүрән тавыш белән. Һәм, тирән көрсенеп, телефонга үрелде:—Вәгыйзовка шылтыратыйк. Бер унайдан хәлен дә белешермен.

Танышы белән бер-ике авыз сүз алышкач, ярдәм итүен үтенеп сорады һәм телефон трубкасын Тәслимәнең үзенә сузды.

Сыра заводы янындагы зур базаның директоры булып чыкты ул кеше. Тәслимә, форсаттан файдаланып, бәяне ана арттырыбрак, килосы уналты мең, диде. Гаҗәп, Вәгыйзов мона бик теләп риза булды, ике-өч көн эчендә хакын да түләрбез, акчабыз бар, диде. Камилевның каш

астыннан сынап текәлгән күз карашы астында харап эшем кешесе булып кыланды Тәслимә. Машина килеп житкәнче, база директорының берәр кая чыгып китү ихтималын уйлап, шундук склад мөдире белән тоташтыруын үтенде, аның белән сөйләшеп куйды.

Ул саубуллашып чыгып киткәндә, Камилев урыныннан күтәрелмәде. Күңел түрен нык сыдырды бу, ачыттырды, аннан соң да искә төшеп борчый торган булып калды. Ләкин Тәслимә моны онытырга тырышты. Мәшәкатьләре күп иде: һәммәсен алдан күреп, көйләп куярга кирәк, сәхнәдәге бию кебек, күпләрнең хәрәкәте бер-беренә ярашып, үрелеп барырлык булсын!

Ләкин барыбер көйсезлекләр бер-бер артлы туып кына торды. Башта машина сонарып килде. Эсседә, тузанлы юл читендә бензин сасысы сулап, сәгатьтән артык көтте Тәслимә, әллә күрми калдыммы, әллә бөтенләй килмәскә булганнармы, дип төрлесен уйлап, борчылып, тәмам аптырап бетте.

Ниһаять, бер калтырча "КамАЗ"да көткән саннарны күргәч, үз күзләренә үзе ышанмый торды: шулхәтле иске, пычрак машинага азык салып йөртәләрме? Басуга тирес ташый торганнардыр моның белән!

—Өч тонна ярымга көчкә тутырдык, заводтан чыкканын көтеп торырга туры килде,—диде шофер.

Аннары Казан читендәге котсыз урамнар буйлап шактый буталып йөрделәр—берсенең дә монарчы ул тирәгә барганы юк икән. Склад мөдире, юантык бәдәнле, карлыккан тавышлы Рәйсә ачуланып каршы алды: эш көне бетеп килә, йөк ташучылар да киттеләр инде, диде.

Әмма, майлап җибәргәч, эш җайланды, Рәйсәнең дә тавышы йомшарды, йөк ташучылар да табылды, аскы катка, суыткычка төшерә торган лифт та хәрәкәткә килде. "Менә бит, булдырам!"—дип эченнән куанды, үз-үзеннән бик канәгать иде Тәслимә.

Суыткыч дигән җирдә— идән астында ике градус җылы булып чыкты. Ул сөт-каймак тотарга көйләнгән, май сакларга яраксыз иде. Нихәл итәсең: "Вәгыйзов алам диде, үзе карар",—дип юанырга калды.

Машина әрҗәсенең алгы өлешендә май шактый җебегән, бер тартмасы хәтта нык кына аккан булып чыкты. Анысын складка кабул итмәделәр, Тәслимә үзе белән алып китәргә булды.

Тартмада май егерме дүрт кило иде—күтәреп йөртерлек түгел. Рәйсә икегә бүлеп төрергә, бәйләргә ярдәм итте.

Ике кулына уникешәр кило күтәрүгә сыгылып килде Тәслимә. Чөнки, ире—алтын багана, үзе—иркә хатын, авыр ташудан һәм авыр эштән монарчы азат булды ул. Рәхмәт, Рәйсә бер тартманы алды да капкага юнәлде.

—Атла, атла!— диде.—Бик шәп эшкә тотынгансың, көчен артыр бераздан. Дөнья өйрәтә!.. Без дә синдәй сылу, нәфис идек, туфлиләрнең дә синдәгедәй кәттәләрен киеп кенә, ирләрнең күзен кыздырып, йөрәк очларын чәнчеп-чәнчеп алгандай итеп кенә, чиста асфальтларда тек-тек басып кына йөри идек. Ә хәзер лап-лап, җирне нык-нык таптап барабыз менә гомер буйлап.

Тәслимә аның юан, базык гәүдәсенә, киң кара чалбарына, таушалган кроссовкаларына гаҗәпләнеп карады. Булмас. Мөмкин түгел. Бу хатын туганда ук билсез, тупас булып тугандыр.

Автобустан төшкәч, Тәслимәгә тартмаларны үзенә сөйрәргә калды. Аңа авыр гына түгел, оят та иде, ул үзен шушы хәлендә танышлары күрер, дип курка иде.

Үзләренең ишегалдына ничек кайтып керер, анда очраган таныш хатыннарның күзенә ничек күренер иде—Алла белсен. Язмыш бу юлы да аны кызганды, трамвай юлы аша чак өстерәлеп барганда, чал чәчле бер ир кеше туктатып:

—Нишләвегез бу?—диде.—Балериналарга авыр әйбер күтәрергә ярыймы? Сынарсыз! Кая, бирегез, бир!

Каршы әйткәнне тыңлап та тормыйча, ике тартманы да тартып алды һәм ишек төбенә кадәр китереп куйды.

* * *

Базарда майның кабы өч мең биш йөз сум икән. Тәслимә күршеләренә өчәр меңнән сатты. Нык эрегәнен үзенә калдырды.

Ул көнне өйнең һавасы ук үзгәреп китте.Тәслимә кызы Рәсимә белән базардан ипи- сөт кенә түгел, сыр, колбаса, тундырмалар, кыяр, помидор, алма да алып кerделәр, икәүләшеп майда йөздереп бәрәнге кыздырдылар, коймак пешерделәр. Зал ягында кунак табыны корылды. Тәслимә чәчәкле халаты өстеннән ал альяпкычын бәйләп, ал яулыгын чөеп куйды. Ал төс ана килешә, ә аның бүген бик-бик матур күренәсе килә иде.

Ыгы-зыгы килеп табын әзерләгән арада, ул Инсафка елмаеп— көлеп кенә, җиңеләйтеп, ансатлаштырып кына бу байлыкның каян килгәнен сөйләде: имеш, ул һич көтмәгәндә Каракүзевне урамда очраткан. Вадим бу арада май саткан икән дә, шуның бер тартмасын Тәслимәгә акчасын соңрак түләү шарты белән биргән.

—Машинасы белән ишек төбенә китереп куйды.—дип иренең күзенә карап ялганлады Тәслимә. Шундый ихлас елмаеп сөйләде, хәтта үз әкиятенә үзе ышана язды.— Алдым, ник алмаска! Тирә-күршегә сатып бетерәм мин аны! Саткан өчен һәр кабыннан алтышар йөзе үзебезгә кала. Әчне тишмәс!

Аның шаяруы-шуклануы артистланудан гына түгел, күңеле чыннан да куаныч белән тулган иде. Бу бәхет аңа балаларының йөзе алланудан, иренең күзләренә элекке җылы-йомшак зәңгәрлек иңүдән килә иде.

Аннары шактыйдан онытылып торган гадәтләрен искә төшерделәр. Инсаф кулына баянын алып уйнап җибәрде, Тәслимә пианинога утырды. "Җомга"ны, "Күбәләгем"не җырлап җибәрделәр, Рәсимә гадәтенчә бии башлады, Самат кашыклар алып зыңгылдатты. Аннары Тәслимә үзе дә сикереп торды һәм балалары белән кулга-кул тотынышып сикергәләргә кереште. Ә Инсаф үзе уйный, үзе көлә, үзе хатынын тыйгандай итенә: "Чамаңны бел, абыстай! Артыгын шашма!"—ди.

Ул төнне Тәслимә сөйгәненең кайнар тәненә кинәнеп сарылды, татлы сулышын эчеп исерде, бәхеттән исереп, ләззәттән эреп: "Инсафым, дөньяның ин сафы! Рәхмәт сиңа, рәхмәт, рәхмәт!"—дип пышылдады да пышылдады . Ярының кочагы аның өчен оҗмах, башка берни дә кирәкми иде.

* * *

Әйе, житди сөйләшүне иртәнгә калдырган иде Тәслимә. Чәйдән соң, балалар аш бүлмәсеннән чыгып киткәч, Инсафның күзләренә елмаеп карап, шаяргандай итеп:

—Карале, әтисе, бизнес яхшы нәрсә икән бит,—дип куйды.—Арзанга аласың да кыйбатка сатасың. Әллә без дә бераз җилкенеп алыйкмы?

—Белмәгән эшкә тотынсаң, барып чыгарсың,— диде Инсаф таркау гына. Ул бу сүзнең житдилеген аңламый, үз уйларына чумып утыра иде.—Алып-сату осталары беткәнме әллә шәһәрдә?

Тәслимә тирән итеп көрсенде дә:

—Ә мин өч тонна май саттым инде,—диде.

Инсафның күзләре уныл киткәндәй булды, иреннәре кысылды. Аңа дөресен сөйләми булмый иде. Һәм Тәслимә мөмкин кадәр кыскача аңлатып бирде: тауар базага тапшырылган, акчасын күчерер өчен банкта счет кына кирәк.

—Кире тапшыр,—диде Инсаф катгый итеп.—Йә Каракүзев белән базаны тоташтыр да, үзләре хәл итсеннәр. Сиңа аяк ялы өчен түләсеннәр.

—Аңлыйсыңмы син, юкмы: килосыннан өчәр меңнән, өч тоннага

тугыз миллион акча кулга керәм дип тора бит! Кем шуны ычкындыра? Син аны ел буе эшләп тә ала алмыйсың!

—Эшләмичә алып була дип уйлыйсыңмы әллә! Тоттырырлар, бар! Булмастай эшкә тотынма!

Аңламаган аңламый. Инсаф та дөнья хәлен аңлый алмады.

—Якын бара күрмә, квартирыңны сатып та котыла алмассың,—диде Инсаф курка калып.—Жулик алар!

—Мин дә шуны уйлыйм, чит-ят белән бәйләнергә ярамый, ышанычлы кеше табарга кирәк. Карале, азмы андый оешмалар, предприятиеләр хәзер! Безнең заводта да арадашчылар тулып ята, диләр бит! Завод тирәсендә яңгырдан соң үскән чебен гөмбәләре кебек үрчеделәр, дип зарланалар.

Инсаф көлеп җибәрде, өстәл аша үрелеп, хатынының бармакларын сыйпады:

—Шул-шул менә, агулы гөмбәләр! Эченә ярамас!..

Аның назы, җылы дулкын булып, беләкләр аша бөтен тәнгә тарала, йөрәккә барып ирешеп, хәлне бетерә иде. Тәслимә кискен хәрәкәт белән бармакларын иренең кайнар учыннан суырып алды да сүзен дәвам итте. Теле такылдаганда башына әйбәт фикерләр килә Тәслимәнең. Үзе дә көлеп: "Җил тегермәнен җил эшләтә, минем башны тел эшләтә",—дип куя кайчакта. Бу юлы да шулай булды:

—Карале, теге сезнең Минвәлиев, цехның профкомы, эшсез калган эшчеләрне оештырам, дип йөргән иде бит! Җыелышы яз көне безнең клубта булды. Минем түгәрәккә балаларын китергән ата-аналарны җыеп сөйләште. Туктале, ул берне генә түгел, икене оештырды бугай бит! Әйе шул, мин дә кызыксынып кереп утырган идем. Менә искә төште. Күп балалы гаиләләр өчен аерым счет булдырабыз, "Миһербан" дип атыйбыз, дигән иде. Тагын берсен ничек дип атаганнар иде әле? Хәтерләмисеңме? Минвәлиевтан да ышанычлы кеше юк бит инде! Әйдә, шуның белән сөйләшеп карыйбыз!

Инсаф сикереп торды, артсыз урындыгы шапылдап ауды.

—Мин андый күселәр белән эш итмим! Син дә кысылып йөрмә!

—Китереп биргәннәрен көтеп, кул кушырып утырыйкмы әллә? ..

Тәслимә теленә килгәнне такылдый калды, Инсаф бүлмәдән чыгып китте. Шалтыр-шолтыр чынаякларны юган арада, үз-үзен тынычландырырга тырышты Тәслимә. Ай алла, нәрсәгә дип ызгыш-талаш чыгарды соң әле ул? Минвәлиев белән үзе сөйләшсә ни булган? Сөйләшкән-киңәшкән өчен судка бирмиләр ләбаса. Хәзер менә күршегә керергә дә, телефоннан эзләп табарга кирәк үзен. (Үзләренең телефонын акча түләмәгән өчен өзеп куйганнар иде.) Заводтадыр әле, ерак китмәгәндер. Эшчегә генә сан юк, начальствоны куып чыгара алмаслар.

Дөрес уйлаган булып чыкты. Берәр сәгатьтән Тәслимә Рудольф Минвәлиевичны буш цехның аргы башындагы майга каткан бүлмәдән эзләп тапты. Минвәлиев кечерәк буйлы, төеп тутыргандай нык бәдәнле, бераз бүлтәеп торган корсаклы, нечкә сары мыеклы адәм иде. "Чыннан да күсегә охшаган",—дип уйлады Тәслимә. Бухгалтер Роза биргән договорны җентекләп укып чыкты да Минвәлиев: "Эшне конкрет башкарып чыгуны үз өстегезгә алсагыз, безнең яктан каршылык булмаячак",—дип, кул куеп, портфеленнән мөһер чыгарып, басып та бирде. Тәслимәне иң кызыктырганы шул мөһер булды. Совет заманында бер инженер Италиягә барып эшләп кайткан иде. Шуның, кайткач, андагы хуҗасы турында хәйран калып сөйләгәне истә калган: "Бөтенесен үзе башкарып чыга, мөһере кесәсендә". Ничек инде алай, мөһер бит ул завод директорының сейфында гына саклана торган тылсымлы әйбер! Аны директор үзе дә шапылдатып куеп бирә алмый, аның кушуы буенча секретарь гына куя! Ә монда, тимерчеләр ышкылып йөри торган куышта, күсегә охшаган шушы адәмнең кыршылып беткән портфелендә—мөһер. Шундый мөһере булмау аркасында ире белән ызгышты, кулына керергә торган тугыз миллион сумнан колак кага язды бит Тәслимә. Менә нинди

кодрәтле сихри әйбер бит ул мөһер! Андый нәрсә алтыннан коелган булырга, ялтырап торырга тиеш иде. Ә ул үзе кечкенә, үзе, шул цехта аяк астында аунап яткан тимер кисәкләре кебек, кап- кара иде. Йә алла, нинди юк-бар әйберләргә бәйле була кайчак безнең язмышлар!

Ни булса шул булды, ярты сәгатьтән "Ашкын" дигән оешманың исеме-адресы, банктагы счеты— теге Роза әйткән "реквизитлары" язылган кәгазьләр, мөһер сугылган договорлар Тәслимәнең кулында иде инде. Эшсезләр оешмасына "Ашкын" дип исем кушканнар иде, янәсе, завод хуҗаларының авызына карап, алардан көтеп кенә тормасыннар, үзләре ашкынсыннар, үз тамакларын үзләре туйдыру хасиятен күрсеннәр. Тәслимә шул бик кадерле кәгазьләрне күтәреп, тузанлы троллейбуста әлсерәп, тирләп-пешкән халык арасында кысылып, шәһәрнең бер башыннан икенче башына юнәлде. Юлы ерак, троллейбустан төшкәч, монысыннан да тыгын, иске, дыңгырдык автобуста тагын ярты сәгать барырга кирәк иде әле.

Реквизитларны бирергә дип туп-туры алу-сату бүлегенә юнәлде. Анда, директор сине көтә, диделәр.

Вәгыйзов, илле яшьләрдәге кин җилкәле, шома чәчле кеше, өстәле артында утырмый, тәрәзә турында әрле-бирле йөренә иде. Ул Тәслимәгә утыр дигәнне аңлатып, ишек төбендәге урындыкны тәкъдим итте. Алгы бүлмәдәге секретарына каты итеп:

—Нина Петровнаны чакыр!—дип кычкырды .

Нина Петровна алу-сату бүлеге башлыгы икән. Урта яшьләрдәге җирән чәчле хатын күренүгә, директор бик усал итеп: —Сез ник ул майны кабул иттегез?—дип сорады.

Әмма тегесе бер дә каушап калмады, хуҗасы кебек кычкырып:

—Безгә кичә май кермәде,—диде.—Бездә бернинди договор да, накладной да юк.

—Без сезнең үзегез белән сөйләштек бит—дияргә талпынып карады гаҗәпләнүеннән өнсез калган Тәслимә.. Әмма Вәгыйзов шундук аның авызын томалады:

—Без конкрет сөйләшеп бетермәдек. Мин сезгә әйттем бит, белешербез, уйлашырбыз, киңәшербез, аннары хәл итәрбез, дидем. Ә сез майны китереп тә тыккансыз. Склад мөдирен бик каты кисәттек, чарасын да күрербез. Ул нинди башбаштаклык!..

Тәслимә үз колакларына үзе ышанмады, шаккатып директорның йөзенә текәлде. Мондый икейөзлелекне, әйткән сүздән кире кайтуны, биргән вәгъдәне күз алдында аяк астына салып таптауны һәм, барыннан да бигрәк, моны шул хәтле үз-үзенә ышанып, тамчы да оялмыйча, кыенсынмыйча эшләүне беренче тапкыр күрүе иде. Кара чәчле, кара костюмлы, каты тавышлы бу кеше, тәрәзәдән төшкән кояш яктысын каплап, аның баш өстендә албасты кебек биегәеп тора иде. Тәслимәнең бу хәле бастырылу кебек иде. Ул үзенең котылгысыз һәлакәткә дучар булуын аңлады. Җылы складта май бозылса, Каракүзевкә кырык ике миллион сумны каян алып түләр? Рәйсәне эштән кусалар, ана ничек ярдәм итәр? Бу куркыныч адәмгә каршы каты әйтеп тә булмый, чөнки тауар аның кулында. Тәслимәнең күзләреннән ихтыярсыздан яшь тамчылары ага башлады. Ул кулъяулыгы белән аларны сөртеп өлгерә алмый иде.

Вәгыйзов белән Нина Петровна каршыларында елап утырган хатынны юатырга тиешләр иде, әлбәттә. Елаганны урамдагы узгынчылар да кызгана, ярдәм итәргә тырыша. Ләкин болар узгынчы түгел, эш кешеләре иде. Шуңа күрә алар Тәслимәнең кыланмышларына илтифат бирмәделәр. Андыйны гына күргәнме алар?

—Күпме заказ җыя алдыгыз?—дип сорады директор Нина Петровнадан.

—Унсигезәр меннән биш йөз илле кило җыйдык,—диде тегесе.—Анда кызлар кибетләргә шылтыраталар әле.

—Безгә егерме процент кирәк бит инде. Димәк, килосын уналты

меннән алу турында сүз дә булу мөмкин түгел. Иң күп дигәндә килосына ундүрт меннән договор төзи алабыз.

—Мин риза, риза,—диде мен рәхмәтләр укырга әзер Тәслимә.

—Сез эшне туктатмагыз, заказлар җыегыз,—диде директор Нина Петровнага. Аннары Тәслимәгә борылды:—Менә шул ундүртәр меннән бер тоннасын урнаштырырга тырышырбыз. Калганын, зинһар, алыгыз, озакка сузмагыз. Бозылса, безгә үпкәләрлек булмасын.

Бу минутта ул инде албасты булып түгел, мәрхәмәтле Алып батыр булып күренә иде. Яхшылык кылу Вәгыйзовнын үзенә дә бик ошый иде булса кирәк, базанын авыр хәлен аңлатуны кирәк тапты:

—Күптәннән май белән эш иткәнебез юк инде, он, шикәр белән генә шөгыльләнәбез. Ике-өч тонна товар белән вакланмыйбыз да. Украинадан, Краснодардан вагонлап кына ташыйбыз.

Аңлашылды. Вәгыйзов һич тә начарлык теләмәгән, кичә сөйләшкәндә уйламыйчарак вәгъдә генә биреп ташлаган. Шәһәрнен майга гарык икәнен ул каян белсен? Ә инде эш болай көйсез килеп чыккач, кайсы җитәкче гаепне үз өстенә алсын ди. Димәк, Тәслимәгә ябырылу—җитәкчелек итү ысулы гына икән. Шулай булгач, ничек аңа үпкәлисең?

Тәслимә шуны аңлады: тонналаган май сасыса, гаепне фәкать аның өстенә генә өячәкләр. Яшь урынына кан агызып еласаң да, кызганучы булмас.

Ул складка йөгерде. Рәйсә белән киңәшеп, май тартмаларын салкынрак почмакка, бәс сарган юан торбаларга таба шудырырга керештеләр.

Кичке якта Нижгардан Каракүзев кайтып төште. Майнын кайсы базага тапшырылганын ишеткәч:

—Без алар белән эш йөртмибез,—диде.—Акча түләмиләр алар. Мин берзаман алардан ун тонна онның хакын ала алмыйча чиләнеп беттем. Ярты ел артларыннан йөргәч, көчкә шикәр белән түләделәр. Ул адәмне утыртып та куйганнар, дип ишеткән идем. Чыгарганнар, димәк..

Тәслимәнең авызы кипте. Вәгыйзовның телефоннан биргән тагын бер вәгъдәсе исенә төште.

—Ул мина акча бар, диде. Бер-ике көн эчендә күчерәбез, диде.

—Шулай димәсә, аңа кем тауар бирә? Аның ише базалар таралып бетеп бара. Шуңа күрә теләсә нәрсәгә ябышалар да.

Тәслимәнең эченә тагын ут капты: базада ул акча турында сорарга да оныткан иде.

Ә Каракүзевнен үз хәле хәл. Усал кыяфәтле каратут чырайлы бер ир килеп керде дә, тезләрен аерып утырды һәм Вадимның күзенә текәлеп, сез алдакчы, сез безнен майны үзләштердегез, дип тиргәргә кереште. Минзәләдән үк булып чыкты бу адәм, ике ай элек май китереп биргәннәр икән дә, вәгъдә ителгән "Волга"ны Вадимнан әлегәчә ала алмыйлар икән.

Күрше бүлмәдә бухгалтер Роза да гадәттәгедән дә ныграк кара коелып утыра иде.

—Әллә кайчан әйттем мин Вадимга, салым түләүне сузасын, яхшылыкка илтми ул гадәтен, дидем. Илле миллион түләргә чыгарды тикшерү! Илле миллион! Банктагы счетка кыршау салдылар, хәзер кергән бер акчаны салым өчен сыдырып алып барачаклар.

Тәслимәнең күнеле катмаган иде әле. Районнан килгән адәм тиргәгәндә дә, Розаның зарларын тыңлаганда да ул Вадимны кызганды. Үзе өчен түгел, беренче чиратта аның өчен борчылу ана гайрәт өстәде. Зиһене ачылып киткәндәй булды, план кора башлады. Майны сатар өчен тау күчерергә әзер иде ул.

* * *

Табыннан колбаса, сыр төшмәде, һәр кич итле ризык пешә торган булды. Бурычны түләп, телефонны тоташтырттылар. Ләкин Тәслимә бу муллыкның рәхәтен чигә алмады. Чөнки һәр көн эт булып арып кайтып егыла, төннәрен тыныч йоклый алмый, күпмегәдер онытылып тора да, тагын сискәнеп уяна иде. "Май мүкләнми микән? Тагын кая барып, кемгә тәкъдим итим икән? Каян машина табыйм икән?"—дип өтәләнә, төшләренә дә машина, май керә иде. "Их, ник без машинаны саттык икән?" Бу үкенүле уй Тәслимәнең кызган башыннан китмәде.

Башта майны сумкаларга тутырып, автобус-трамвайларда йөртеп маташты. Ләкин эсседә май каплары тиз җеби, кадере китә, сатар җире калмый иде. Аннары машина яллый торган итте. Кыйбатка төшә, ләкин шунсыз булмый иде.

Үзләренең тугыз катлы йортына, тышкы ишекләргә май сату хакында игълан чыгарып элде. Дүрт-биш капны өеннән сатты. Ләкин ул гына нәрсә!

Май төяп, элек үзе эшләгән мәдәният йортына барды. Оятын яшерергә, битенә битлек кияргә туры килде. Көн буе чабып кайткач, кичләрен телефонда утырды. Түгәрәккә йөргән балаларның ата-аналарына май тәкъдим итте. Гаҗәпләнделәр. Ихтирам кимү сизелде, ләкин һичкайсы тупас сөйләшмәде.

Ә менә базада исә аңа мөнәсәбәт, киресенчә, яхшырды: тырышлыкны күрделәр. Тәслимә көмеш алкаларын базаның баш бухгалтерына бүләк итте. Тәэминат бүлегендә эшләүчеләргә зур торт алып барды. Рәйсәгә янә майдан өлеш чыгарды.

Үзенә калькулятор сатып алды. Кичләрен кайткач язып, санап утыра торган булды. Акчаның шактые машинага китә, ашарга да алмый булмый, телефонга, калькуляторга, бүләк-күчтәнәчләргә. Калганын шундук Розага илтеп тапшырырга кирәк иде. Чөнки,—Вадим хаклы булып чыкты,— база бөлеп килә, майны көн саен кибетләргә озатып торсалар да, баш бухгалтер ни тырышса да, акча "Ашкын"га азлап-азлап кына җибәрелде.

* * *

Ниһаять, тырышлык җинде, май сатылып бетте, Тәслимәнең суыткычы, үзенә дип калдырган ун кап майны санамаганда, бөтенләй бушап калды. "Ашкын"ның бухгалтеры Солтания белән очрашыр алдыннан, калькуляторында шык-шык итеп, санап чыгарды ул. Машина ялларга, бүләкләргә, өйгә тоткан чыгымнардан соң, җиде миллион чиста керем калырга тиеш икән. Димәк, аның җиде миллион сум акчасы банкта "Ашкын"ның счетында ята, дигән сүз. Минвәлиев белән бухгалтерга бераз калдырмый булмас. Ике миллионын алып калсалар да, биш миллионы кесәгә керәчәк бит әле. Алла боерса, бераз вакыт булса да нужасыз, иркенгәеп яшәп калырлар. Балаларны мәктәпкә әзерлисе бар, уку әсбаплары, өс-баш алырга кирәк, һәммәсенә җитәр.

"Ашкын"ның бухгалтеры Солтания чын мәгънәсендә исеменә лаек, мәһабәт кыяфәтле яшь хатын иде. Эре сөякле, нык бәдәнле, куе кара чәчле,—ана һәрнәрсә мул бирелгән . Шәһәр бистәсендә үскән иркә бала, пошмас, кабаланмас, гаҗәеп сөйкемле каратут йөзендә һәрвакыт канәгатьлек хисе чагыла, тырнаклары һәрчак буялган, кара бөдрәләре соңгы мода кушканча тарап, лак белән катырылган. Тәслимәдән тынгысызлык бәркелеп торса, Солтаниядән мөлаем гамьсезлек сирпелә иде. Ул югары белемле инженер, әмма бу заман килгәч югалып калмаган, бухгалтерлар курсында укып чыккан да, "Ашкын" кебек килделе-киттеле биш-алты оешманың акчасын санарга ялланган. Зур оешмаларда эш бик тынгысыз, диләр. Хуҗалар күпләп урлый, аны капларга кирәк, очы барыбер кала, тикшерү килә дә иң элек бухгалтерның якасыннан эләктереп

ала. Алла сакласын. Ә монда акчасы да юк, борчуы да аз. Эш хакы килә тора үзе, дүрт-биш жирдән шактый жыела. Нәфесенне тыя белсән, тыныч яшәргә бик житә.

Үзәктәге бер кечкенә оешмада кысан гына бүлмәсе, сейфы, өстәле, килгән-киткәнне утыртырга ике урындыгы бар икән Солтаниянен. Керделәр, кара-каршы утырыштылар.

—База акчаны күчереп бетерде,—диде Солтания гадәтенчә бик тыныч кына.

Ә Тәсләмәнен күнеленнән куаныч ташый иде. Нәрсә булса булды, тырмашты, чапты, гарьлеген эченә йотты, ире белән бозылышты, әмма ахырда морадына иреште! Менә хәзер Солтания акчаны сумкасыннан чыгарып бирер, банктан алып кайткандыр.

Әмма бухгалтер ашыкмады, сумкасын өстәл тартмасына ук тыгып куйды да, иркенәеп утырды, кәгазь алып, битенә жилпергә кереште. Тәслимә анын хәл алганын көтә иде. Шактыйдан сон гына, тулы иреннәрен назлы тибрәтеп, Солтания:

—Мин расчет ясап, Каракүзевка сонгы суманы күчердем, иртәгә барып житәр, борчылмасыннар,—диде. Анннары урынынннан кузгала башлады:—Мин төшкене ашамаган әле, әйдәгез, барып киләбез.

—Тиз генә исәп-хисап ясыйк. Акчаны алам да китәм мин.

Солтаниянен монлы күзләре гажәпләнүдән зурайды.

—Нинди акча?

—Ну безгә калган керем. Май үндүртәр меннән сатылды, Каракүзевка унике меннән түләдек. Минем санавым буенча, жиде миллион чамасы калырга тиеш анда.

Солтания өстәл тартмасыннан зур калькулятор тартып чыгарды.

—Очын-очка ялгап санамадым әле мин,—диде калькулятор төймәләренә баскалап.— Шулайрак чыгадыр. Минем исәп буенча да шул чама.

Тәслимәнен эченә жылы инде.

—Сезгә мәшәкать өчен күпме кирәк булыр икән?

—Салымнарны түлибез башта.—Бухгалтернын житез бармаклары калькулятор өстендә биешергә тотынды.—НДС майдан егерме процент, юлга нуль өч процент.

—Нинди юлга?

—Ну шундый салым бар. Чиста табыштан утыз биш процент НИОКР. Тузган тораклар өчен. Соц-культ-быт.

Монарчы ишетмәгән ят сүзләрдән Тәслимә аптырап китте.

—Безнен картотека да шактый иде,—дип дәвам итте Солтания саный биреп.

—Анысы нәрсә тагын?

—Түлисе бурычлар. Апрельдән бирле яттылар. Устав язган өчен, регистрация өчен. Кәгазь-каләм алганнын да хакын кайтарасы бар. Күп түгел, бер миллион чамасы гына Аларын банк күчереп тә куйган инде..

Тәслимәнен бугазын кайнар төер кыса башлагандай булды. Алай да үзен тыныч тотарга тырышты: ярый, ике миллионы китсен, тагын биш миллионы кала бит әле!

—Калганын кайчан алып була сон?

—Соцналогларны күчермичә бирмиләр.

—Анысы нәрсә?

—Эш хакыннан салымнар. Пенсия фонды, социаль страхование, медицина кассасы, эшсезлек фонды... Аларына шактый пеня да жыелгандыр әле. Дүрт ай бит инде. Иртәгә салымнарны күчереп бетерәм дә, шундук алырга да була. Пенясы йөз егерме ике көнгә, берәр проценттан йөз егерме ике процент... Ай саен йөз сиксәншәр меннән.

—Нинди йөз сиксән мен сум сон ул?

—Безнен соцналоглар шуннан артмый, зарплата аз бит, президент-

нын өч йөз мең, баш бухгалтерның ике йөз илле мең генә. Апрельдән бирле начисление барды, счетка акча кермәде. Шуннан килеп чыга ул.

—Сез апрель өчен эш хакын мин май саткан акчадан алмакчымыни?

Солтания аңа шаккатып карады.

—Апрельдән алда август өчен эш хакы алып булмый бит инде. Закон рөхсәт итми. Башта апрельгә, аннары майга... Август өчен зарплата сентябрьдә бирелә. Банк белән договорда шулай куелган. Сезне акча ведомостенә кертеп тә булмый әле. Сез бездә эштә саналмыйсыз. Приказ бирелмәгән. Рудольф Минвәлиевич миңа ул хакта берни әйтмәде. Сез сөйләшегез аның белән. Юкса кешене бушка эшләтергә бик остарган.

—Акча кермәгәч, бухгалтерга нинди эш соң ул?

Бу юлы Солтаниянең тирән күз төпләрендә ризасызлык шуып узгандай булды.

—Тик торгызмыйлар,—диде..—Аның кайбер салымнары болай да бара. Милициягә түләү мәҗбүри, мәсәлән.

Тәслимәнең йөзенә карады да, аңлатуны кирәк тапты Солтания:

—Муниципаль милициягә дигән аерым салым бар. Эш хакыннан түләнә. Эш хакын начислять иткәч...

—Сезнең эш хакы алынмаган дидегез бит.

—Алмасак ни, начислять иткәч, налогы да санала. Аны түләргә кирәк. Отчетларны налог испекциясенә биреп барырга кирәк. Рудольф Минвәлиевич үзе дә анда-монда чаптыра. Әле тегендә барып бәреләбез, әле монда, тулыгы гына юк. Авыз ачып йөрсәгез, август өчен зарплатасыз да калырсыз.

—Минме? Шул хәтле акча кертепме?

—Ә каян күренә аны сез керткәне? Документларда сезнең фамилия юк. Анда Рудольф Минвәлиевич белән мин кул куйдык.

"Төшләремә дә кермәде болай буласыларым",—дияргә генә калган иде Тәслимәгә. Кызган баштан бөтен ярсуын бухгалтер өстенә коюдан чак тыелып калды. Шушы арада күргәннәре аны бераз булса да тыелырга өйрәткән иде инде. Шуның өстенә эчке бер тавыш араларны бозарга ярамавын, бу хатынның әле кирәк булачагын кисәтә иде.

Ул тизрәк чыгып китү ягын карады. Минвәлиевнең үзе белән сөйләшергә кирәк. Ни өчен әле аларга биш айлык хезмәт хакын Тәслимә табып бирергә тиеш? Бу акчаны табу өчен нишләделәр алар? Минвәлиев берничә тапкыр кәгазьгә мөһер сукты да, Солтания банкка баргалады. Аларның шул аз-маз хәрәкәтләнүе Тәслимәнең күз яшьләре, кичергәннәре, көн-төн чабуы белән чагыштырырлыкмыни? Ул нинди салымнар тагын? Кеше эшләгәннең бөтенесен ала торган салым була микәнни? Алай булса, эшләгән кеше үз тамагын ничек туйдырсын да, балаларын ничек асрасын?

Ә бит ишеткәне бар иде Тәслимәнең бу хакта. Салымнар эшләгәннең барысын алып бетерә, хәтта артыгын да суыра, дип гәзиттә укыганы да бар иде. Ышанмый иде. Үз башына төшмәгәч, бәгыренә үтмәгәч, каян беләсең?

Минвәлиевне заводтан эзләп йөрергә соң иде инде. Тәслимә аның өенә китте.

Фатир ишеге ямьсез көрәнсу төскә буялган, кырый ярыкларына, кышын җил кермәсен өчен, соры киез тасмалары кагылган иде. "Ишеген дә рәткә кертә алмаган адәмнән ни яхшылык көтәм, нишләп шәһәр буйлап аның артыннан чабып йөрим соң әле?"—дип уйлады Тәслимә.

Ишек ачылып, аның каршында пәйда булган Минвәлиевне бу юлы чын-чынлап күсегә охшатты. Тегенең өстендәге иске күксел спорт костюмы, юан биле, кечкенә күзләренең сагаюлы карашы шулай итә иде. Тәслимә өйгә кереп тә тормады, шыксыз ишек янында, баскыч мәйданчыгында гына сөйләштеләр. Күренеп тора, Минвәлиев бухгалтериядә Тәслимә кебек үк томана, нинди салымнарны күпме түлисен белми иде.

—Без сезгә алдагы айларда да эш көннәре язарбыз, шулай итеп, тиешле акчаны әкренләп түләп бетерербез,—диде ул, бик зур яхшылык

эшләгәндәй, корсагын тагын да бултәйтә төшеп. Ана ни дисен? Апрельдән буе бер тиен акча таба алмаган, алдагы айларда каян тапсын ул?

Ә дөньяда август аенын жылы, жилсез, тузанлы киче иде. Урамнарда халык тулгана, тик берәү дә аңа игътибар итми, бәрелеп узганда да күтәрелеп карамыйлар. Тәслимә үзенең кыяфәтен күз алдына китерде дә, оялып куйды. Әле күптән дә түгел урамнарны балкытып узган хатын шушымы? Соңгы вакытта ул, күп йөрергә, авыр күтәрергә унайлы булсын өчен, күксел футболка белән чалбардан йөри. Аягында Рәсимәнен мәктәптә кия торган сандалие. Чәченең дулкыннары да бетте—шома итеп тарап, баш артына кыстыргыч белән каптырып куя торган итте. Битне жентекләп бизәүнен дә кирәге калмады—сатучыга артистлану-кылану килешмәгәнен белә ... Шулай итеп, ул урам халкы арасында, чүплектә кайнашкан чыпчыкларның берсе кебек, бер иш булды да калды.

Ничек шул хәтле үзгәрде соң әле ул?

Шөгыль! Шөгыль адәм баласын үз калыбына сала. Тәслимәнең үз шөгыле—халыкка бәйрәм ясый торган, бар карашларны үзенә җәлеп итә торган һөнәре бар иде, шуңа хас буларак, анын кыяфәте, рәвеше, йөреш-торышы да башкалардан аерылып тора, очраган кешеләргә бәйрәмнәрен искә төшерә иде. Бүгенге шөгыле исә кешеләрнең көндәлек мәшәкатьләре, житмәүчелек, борчулар белән бәйле, кыяфәте дә шуна ярашкан.

Эчне бушатырга, уйларны уртаклашырга, юаныч табарга кешесе юк иде бу көнне Тәслимәнең. Дус хатыннар дачаларда яталар, бакчаларын-да казыналар. Балалары әле кечкенә, ире исә анын бу борчу-мәшәкать-ләреннән читләшкән иде. Өйне караштырып, ашарга әзерләгәндә һаман уйланды да уйланды Тәслимә.

Моннан бер генә ай элек берәрсе, алып сату кәсебенә керешерсең, дисә, ышанмаган булыр иде. Әле кайчан гына бу кәсеп "спекуляция" дип атала, хурлыклы шөгыль булып санала иде. Караклык белән тиң куела иде ул, анын өчен төрмәгә утырталар иде.

Тәслимәнең туганнан туган бер абыйсы Можгада яши иде, аягына басмаган, артына утырмаган дүрт баласын калдырып, бик иртә үлеп китте. Шул сабыйларның анасы кайчакта Казанга чүпрә сатарга килә, Тәслимәләрдә куныып чыга иде. Хәзер менә жингәсенең, авыр күтәренеп, эт булып арып килеп кергән чакларын исенә төшерде дә, үзалдына кызарынып чыкты Тәслимә: йөзенә бәреп әйтмәсә дә, гаепли иде ул жингәсен, кимсетеп карый иде аңа! Ә бит ул батыр хатын икән! Ул йөзгән агымга Тәслимә бер генә кереп карады, ә ничек шәбәреп чыкты менә! Теге елларда ул эш бигрәк афәтле, бигрәк куркыныч иде, бүгенге авырлыклар өстенә анда милиция дә эзәрлекли иде бит әле! Бирешмәде жингәсе, балаларын ач-ялангач итмәде. Дүрт баланы берүзе! Ә монда Тәслимә белән ире ике баланы мәктәпкә киендерә алмыйлар! Тирәннәнрәк уйлап карасаң, башка күпләргә дә гел яхшылык эшләп йөргән бит ул жинги. Можгада тир түгеп чүпрә ясаган хезмәт кешеләренә гадел эш хакын алырга булышкан, икенче яктан, Казанда яшәүчеләрне чүпрә белән тәэмин иткән. Әгәр ул китереп бирмәсә, Тәслимә дә бәлеш пешерә алмас иде ләбаса, чөнки ул чакта сатуда чүпрә юк иде. Бер танышы Тәслимәдән сорап алып, Магнитогорскидагы әнисенә жибәргән иде хәтта.

"Изге юлда йөргән безнең ак күнелле жингәбез, ә мин аңгыралыгым, тәкәбберлегем аркасында гына ана эчтән каралып торганмын",—дип уйлады ул үкенеп.

Жингәсен искә төшерү Тәслимәнең уйларын бер эзгә салып жибәрде. Аңа менә хәзер нишләргә? Бөтен тырышлыгы жилгә очканны авыз ачып карап торыргамы? Ул тапкан акча банкта ята. Ләкин банкка ул керә алмый, аны кая куйганнарын тикшереп тора алмый. Димәк, акчаны эшлисең икән, ул синең кулда булырга тиеш. Нинди ахмак үз акчасын чит кеше кесәсенә сала? Акча документларына Тәслимә кул куярга тиеш. Мөһер, теге кодрәт тамгасы, шулай ук анын кулында булырга тиеш!

* * *

Минвәлиевнең икенче оешмасы "Миһербан" дип атала, анысының да мөһере бар, анысында да Солтания бухгалтер икән.. "Баш катыргыч кына ул да,—диде Солтания,—бер тиен акча кергәне юк".—"Бигрәк әйбәт",—дип уйлады Тәслимә. Һәм җәмгыять әгъзаларынын исемлеген сорап алды. Арада Каракүзевнын хатыны, сөян агачыннан ясалгандай ак, юка гәүдәле, һәм сүзен кычкырып, туры әйтә торган Лена да бар икән.

Тәслимәгә дәрт керде, ашарга пешергәндә, өй җыештырганда җырлый, хәтта ара-тирә биеп ала торган булып китте. Чөнки ул элекке шөгыле—спектакль кую дәрте белән янды. Анда төп рольнең берсен — үзе, икенчесен Минвәлиев башкарырга тиеш. Спектакльнең исеме — "Алтын мөһер", эчтәлеге— шул мөһерне дию кулыннан тартып алу иде. "Аерылмагыз, аерылмагыз, булса да сәбәпләре,—дип җырлады Тәслимә.— җиткәндер алтын мөһерне кулга алу сәгатьләре". Әйе, җыелыш җыярга да аны спектакльгә әйләндерергә. Шулай итмәсәң, халык алдына чыгып: "Минвәлиев бу эшне булдыра алмый, аны куарга кирәк", —дип дөресен сөйләсәң, морадыңа ирешә алмаячаксың, чөнки завод эшчеләре профсоюз җитәкчесенә каршы чыкмаячак. Димәк, Минвәлиевне бәреп төшерү өчен, аны башта чөеп җибәрергә кирәк. Күккә чөеп мактарга! "Хөрмәтле иптәшләр!—дип үзенә генә мәгълүм көйгә салып мырлады Тәслимә.— Бүгенге җыелышта без Рудольф Минвәлиевичка чын күнелдән зур рәхмәтебезне белдерергә тиешбез". Бу урында озакка сузылган көчле алкышлар бик ярап куяр иде дә бит, җиде-сигез кеше арасында андый ук мәхлуклар булмас шул. Ярый, алкышларсыз гына дәвам итәрбез. " Ул шундый авыр заманда безне, балаларыбызны кайгыртып, берүзе ике оешма оештырды. Ярты ел буе аларның эшен берүзе алып барды. Мин, аңа мактау грамотасы бирергә, бер айлык оклад күләмендә премия белән бүләкләргә тәкъдим итәм. Минвәлиев, талантлы җитәкче буларак, эшне җайга салды. Хәзер дәвам итәргә кирәк. Ике оешманы алып бару аның берүзенә ифрат авыр. Шуңа күрә мин "Ашкын"га президент итеп үз кандидатурамны тәкъдим итәм. Мин инде бу эшкә өлешемне дә керттем, оешмага алты миллион сум акча эшләп бирдем".

Ә Минвәлиев нишләр икән? Акылы булса, ул да Тәслимәне мактарга тиеш. Шуннан соң Минвәлиевне аркасыннан сөеп кенә эшеннән алалар да, президент итеп Тәслимәне сайлап куялар. Спектакль тәмам.

Уку башланган чак, ата-аналар барсы да өйләрендә, кирәкле сигез кеше Тәслимәне беләләр иде. Аларны җыю читен булмады. Каракүзева белән алдан ук сөйләшеп куйды Тәслимә.

Башта һәммәсе аның планы буенча барды. Минвәлиевне мактау чыннан да һәммәсенең күнеленә хуш килде.

Ә менә Минвәлиевнең үзенә акыл җитмәде. Тыелып кала алмады, Тәслимәгә ташланды ул:

—Бу хатын намуслы кеше түгел, аферистка! Әзер оешманы кулына төшереп, акча үзләштерергә маташа!

Анын, төкереген чәчә-чәчә, әле генә үзен күккә күтәреп мактаган кешене хурлавы тынлаучыларга ошамады. Дөрес, дәгъвәгә дә кермәделәр.

—Рудольф Минвәлиевич, сезгә ике оешма бик кирәкме инде?— диде Лена.—Эшләгез берсендә иркенләп!

Шул сүз җитте, Минвәлиевне көйләп-җайлап кына урыныннан алдылар да, Тәслимәне сайлап куйдылар.

Иң кызыгы шул булды: җыелыштан соң Рудольф, аның янына килеп, узган айлар өчен эш хакын бирүен үтенеп сорады.

—Сезгә, әлбәттә, бүгенге көнне дә кертеп эш хакы түләнер һәм бер айлык премия бирелер,—диде Тәслимә.

Ә эченнән: "Юк, мин болай түбәнсенмәс идем",—дип уйлады.

* * *

Менә ул кодрәт тамгасы—мөһер—ниһаять Тәслимәнең учында. Хәзер инде банкка акча керсә, фәкать аның кушуы, аның ризалыгы белән генә тотылачак. Ул һәр тиеннең кая киткәнен белеп торачак.

Әмма бер нәрсә кәефне кырды: мөһергә ияреп акча килмәде. Солтания һәммәсен дөрес санаган булып чыкты. Минвәлиев белән расчет ясагач һәм бухгалтерга да эш хакын түләгәч, Тәслимәнең үзенә алыр нәрсә калмады да диярлек. Рәсимә белән Самат мәктәпкә былтыргы киемнәрен киеп киттеләр.

Тагын май сатарга туры килсә, ничек эш итәргә белер иде инде Тәслимә! База директорыннан да алдатмас, мөһер юклыктан да каза күрмәс иде. Ләкин ярты хакына май сатучы юк иде шул инде. Сентябрь башыннан "Суык" комбинаты эшкә тотынды, заводлардан чыккан барча майны кышка сакларга үзенең очсыз-кырыйсыз бозлы мәгарәләренә йотып кына тора башлады. Районнарга майны үз белдекләре белән сату тыелды. Азык-төлек биреп машина алу шаукымы узды. Вадимның да эше комга барып терәлде.

Тәслимә бераз вакыт кына булса да ашауны кысмыйча яшәп караган иде. Шунлыктан акча кысынкылыгын бу юлы аеруча авыр кабул итте, вакыт-вакыт тәнен нидер богаулый, сулышы кысыла кебек иде хәтта. Фәкыйрьлеккә чыдый алмый торган, аннан котылу өчен чын-чынлап таш актара, жир читенә бара торган кешеләр бар дөньяда. Тәслимә шундыйлардан иде. Аны фәкать бер теләк, теләк кенә түгел ярсып ашкыну биләп алды: бу кыршаулардан ничек тә котылырга! Әнә, базарлар кайнап тора, нинди генә затлы ризыклр, зиннәтле товарлар юк, һәммәсе сатыла. Кемнәр ала? Нигә Тәслимә шул алучылар арасында түгел? Ул кемнән ким?

Май сатканда интеккәннәрен, кимсенгәннәрен уйламый, һәммәсенә риза, тик ике баланы туйганчы ашатырлык, кеше арасында ким-хур булмаслык итеп киендерерлек акча гына булсын!

Ул көннәр буе базарларда йөрде, бихисап ларекларда чит ил кием-салымын күз алдыннан үткәрде һәм аларның шактый зәвыксыз икәнлеген ачыклады. Ул мондый чүпрәк-чапракны очкычларга төяп, жәһәннәмнән ташып йөрмәс, нәрсә алып кайтырга икәнен белер иде! Тик ничек барасың анда?

Тагын Каракүзевка китте. Вадимның янында хәләл жефете Лена утыра иде. Тәслимә, мактанасы килеп, аларга мөһерне күрсәтте.

—Ташлагыз, чүп бит ул,—диде Лена гадәтенчә коры гына.— Вадим ничек котылырга белми, ә сез мөһер, имеш, расчетный счет! Әнә, акыллы кешеләр Төркиядән дөнья кадәр тауар кайтарып саталар, банкка да чапмыйлар, салым инспекциясенә дә сәлам бирмиләр.

—Төркиягә барып житү өчен күпме акча кирәк бит.

—Кәсебенә керешсәң, ныклап тәвәккәлләсәң, акчасы йөри-йөри туплана аның. Әнә мин дә бер тиенсез башлаган идем, Вадимга предприятие ачып, машиналар белән сәүдә итәрлек булды. Бетереп туктады әнә, мөһере генә калды.

Хатынының бу сүзләренә Вадим көлеп, башын чайкап кына куйды.

—Төркиягә барасы булсагыз, Ленадан гына сорагыз,—диде.— һәммәсен өйрәтер, аның белән югалмассыз.

—Бер шарты белән: миңа шундагы бәядән тун алып кайтып бирсәгез,—диде Лена.

Әйтерсең, Тәслимәнең уйларын белеп торганнар, әйтерсең, аны гына көтеп утырганнар.

—Төркия дигәндә мин пас,—диде Вадим,—үзегез сөйләшегез.

Һәм бүлмәдән үк чыгып китте, ике хатын киңәшә калдылар. Эш бик гади икән. Хәзер менә көз, халык тун ала. Таныш-белеш, туган-тумачадан, тунны базардагыдан шактый арзанга алып кайту шарты белән,

заказ җыясың. Базарда сатканнарның чыгымы күп аның: урын өчен түлисе, палаткасын аласы, рэкетирларга бирәсе, салымны да бөтенләй түләми котылып булмый. Димәк, син тунны базардагыдан шактый арзанга сатсаң да, керемен андагыдан ким булмаячак. Алган кеше өчен дә яхшырак—туны башкаларныкы белән бертөрле булмый. Бу—бер. Икенчесе—үзеңнән акча чыгару кирәкми.

—Истанбулда минем бик ышанычлы танышларым бар,—диде Лена.—Син унга-сулга карама, мин әйткән җиргә туры бар.

—Мин төрекчә белмим бит. Ничек аңлашырга?

—Алар русча аңлый! Сиңа бигрәк җиңел, татарча гына сөйләшәсең. Төрек белән татар теле бик якын, диләр. Безнең белән барганнар рәхәтләнеп сөйләшә иде. Татарларга мөнәсәбәт тә яхшырак. Син кайчан китәсең?

Тәслимә аптырап калды:

—Чит ил паспортым да юк бит әле.

—Анысын бер-ике көндә ясап бирәләр. Син заказлар җый. Миннән дә сорашып йөрүчеләр бар. Алайса бүген кич сөйләшәм мин алар белән, иртәгә акчасы булыр. Егерме тун алып кайтсаң... Безнең кызга да яңа кирәк бит! Димәк, миңа икене. Шундагы бәядән.

—Ә миңа ни калыр соң?—дип сорады Тәслимә сагаеп.—Май белән булгандай килеп чыкса?

—Анда син кеше белән бәйләнгәнсең. Акча тирәсенә ятларны якын китерәләрме?

—Үзегез барырга уйламыйсызмы?

—Сумка ташудан гарык,—диде Лена.—Шунда йөри-йөри ике тапкыр корсак төшердем. Бусын саклыйм, табам барыбер. Вадим да, малай алып кайт, дип ялына. Акча убыр кебек ул, вакытында нәфесеңне тыя белмәсәң, чоңгылга алып керә!

—Бер барудан күпме калыр икән?

—Мин әйткәнчә эшләсәң, кырык процент үзеңә калачак. Ун проценты юл чыгымнарына. Утыз процент, дигән сүз. Ну мин бик аз алам. Күбрәк булырга тиеш. Егермене алып кайтсаң, икесе миңа, унсигезне өчкә бүл, димәк, алты тун хакы кесәңдә калырга тиеш. Шунсыз интегеп йөрергә дә кирәкми. Шылтыратышырбыз, мин хәзер тоташ телефонда утырам. Диспетчер булдым. Ике машинабыз бар бит безнен, шуларны йөртәбез. Җанга тынгы юк-югын , тик тәнем тынычта, шунысы кадерле,—дип яссы корсагы турында сары күлмәген сыйпап куйды ул.

* * *

Самолет Казанга кичке якта килеп төште. Һәрберсе билдән биек дүрт сумкасын берәм-берәм сөйрәп азапланганда, Инсафны күреп алды Тәслимә. Йөрәге сулкылдап куйды. Килгән! Җибәрергә риза булмаган иде, үпкәләп калган иде , барыбер каршы аласы иткән! Куаныч хисенең татлы дулкыны бөтен үпкә-сапкаларны юып алгандай итте. Әнә ул каршыга килә, зәңгәр күзләрендә ярату, ак йөзе шатлыктан нур сибә.. Тәслимә аның күптән күнегелгән хуш исле кочагына керде дә, башын күкрәгенә куеп, күзләрен йомды. Йә Алла, бәхет аның сөенечтән балкыган йөзен күрүдә, йөрәк тибешен ишетүдә бит инде!

Әле генә дүрт сумканы дуылдатып йөрткән Тәслимә кинәт көчсезләнде, берсен дә кузгата алмас булды. Һәм кирәкми дә. Бетте ятлар арасында талкыну, бәргәләнү, бетте авыр күтәрү. Инсаф борылып, кемгәдер кул селтәде. Каракүзев! Менә кем әйткән Инсафка, менә кем алып килгән! Икесе сумкаларны дуылдатып алып чыгып та киттеләр, Тәслимәгә алар артыннан теркелдәргә генә калды.

Истанбулның тыгын урамнарыннан, мингерәйткеч базарларыннан, аэропортлардагы ыгы-зыгыдан соң, Казанга илтә торган юл буйлап машинада бару татлы төш кебек иде. Нинди иркенлек, тынычлык, җанга ял бирә торган төсләр! Юл читендә каеннар көзнең алтынына манчылып,

баеп барган кояш яктысында балкып та, ямансулап та торалар, яшел чыршылар исә яшәешнең мәңгелеген раслыйлар кебек иде.

Ә өйдә бәйрәм. Рәсимә белән Самат икесе ике яктан килеп уралдылар. Еракларда бер әйләнеп кайту бик файдалы, аерылышуның жиләс жиле шифалы канаты белән арадагы кер-тузанны сөртеп алгандай итте. Бу кичне ул парына сөекле яр, балаларына газиз ана булу бәхетенә коенды.

Шундук сумкасыннан бүләкләрен алып бирде. Рәсимәгә дубленка, Каракүзев кызы белән пардан. "Минем кызым аларныкыннан кимме әллә?" Саматка да тун. Инсафка күн пинжәк.

Балалар этешә-төртешә көзге каршында бөтерелгәндә, Инсаф бүләкне карамыйча да сумка өстенә куйды.

—Йә, киеп кара инде син дә!—диде Тәслимә.

—Соныннан. Үзенә алдынмы соң?

—Юк әле.

Шулай диде дә Тәслимә, иренең күз карашы үзгәргәнен күреп, сискәнде. "Әле" дигәне ялгыш ычкынды, кирәкми иде. Алдагысына ишарә итәргә ярамый иде бүген.

Тик моны икесе дә шундук үткәреп жибәрделәр. Өйдәгеләр бик матур итеп табын әзерләп куйганнар иде: Инсаф нык борычлап итле бәрәңге пешергән—ул аны "чахохбили" дип атый. Рәсимә ит белән дөгедән "керпе" ясаган. Самат та тик тормаган, помидор белән суган тураган. Торт та алганнар хәтта. Ә анысы каян?

—Эш хакын бирделәр,—диде Инсаф.—Рәсимәгә костюм алдык

—Мина кроссовка!—диде Самат әтисен бүлдереп.

Монысы Тәслимәнең күңелен тырнап узгандай итте. Ни өчендер ул Инсафка акчаны тагын да бераз бирми торуларын тели иде. Шулай кулайрак булачак иде ана. Әмма тыштан елмаерга тырышты, сөенгәндәй итенде:

—Әйбәт булган, котлыйм,—диде.

Әниләре кайту уңаеннан балаларга чын бәйрәм ясау, биеп-жырлап алу тиеш иде. Тик ни сәбәптәндер Инсафның баян уйныйсы килмәде. Радионы тоташтырдылар, аннан бер ир затының, аңлаешсыз чит телдә, тамак төбе белән жикеренгәндәй жырлаганы ишетелде. Самат боргаланырга, тибенгәндәй хәрәкәтләр ясарга кереште, Тәслимә кызын житәкләп анын янына чыкты. Тик озакка түгел, нигәдер тиз туктадылар бу юлы. Диванда монсу кыяфәттә утырган Инсафның житди карашы биюгә дәртне сүрелдерде.

Арага күләгә төшеп, анын әкренләп куера барганын икесе дә сизәләр иде. Икесе дә аны куарга, юк итәргә телиләр иде. Икесе дә бер-берсен югалтудан куркалар иде. Шуңа күрә бу төндә алар бер-берсенә бердәнбер икәнлекләрен аеруча нык тойдылар, беренче кавышкан чакларындагы кебек онытылып, назландылар.

—Карчыгым, матурым! Әйдә, тагын бер малай алып кайтабыз!

—Алып кайтыйк. Малай булсын. Агалы-энеле булырлар. Ике ир туганга яшәү жиңелрәк, диләр.Самат сиңа ошаган. Бу юлы миңа ошаганны алып кайтыйк. Әнисенә ошаган ир бала бәхетле була, диләр. Алып кайтыйк. Хәзер, бу көннәрдә ниятләргә иң унай вакыт.

Тәслимә бәхете тулып елмайды. Ул фәкать Инсаф теләгәнне тели, анын жаны кыйпылчыгын йөрәге астында йөртергә тели, акча да, мал да кирәкми, гомумән дөнья гаме көлке иде аңа!.. Хатыннар нәкъ менә шушындый төннәрдә сәламәт, таза, дәртле улларның анасы булырга беренче адымны ясыйлар да инде.

* * *

Лененың әйткәннәре расланды—туннарны саткач, алтысының акчасы янга калды. Бу әле балаларына, иренә алган бүләкләрне исәпкә алмаганда. Инсаф алып кайткан акча пүчтәк иде моның белән чагыштырганда. Ул

арада танышлары, бер-берсеннән ишетеп, тагын акча китерә башладылар.

Инсаф аны җибәрергә риза түгел иде. Ләкин Тәслимә тыңламады. Соңгы тапкыр барам, диде. Һәм бу сүзе хак иде. Ул табигате белән чын хатын, андыйлар турында, ир заты итәгенә генә орынып үтсә дә буйга уза, диләр. Ире кочагында эреп, тилереп, дөньясын онытып уздырган төннәре болай гына үтмәс, мөгаен. Димәк, акча бик кирәк булачак иде әле.

Тәслимә, ире эштә чакта, өстәлдә язу калдырып, китеп барды.

Самолетка утырыр алдыннан ике сәгатьтән артык аэропортта тулганырга туры килә: әле монда чират торасы, әле тегендә көтеп утырасы. Уйларына мавыккан Тәслимә кемнеңдер аны күзәтеп йөргәнен сизмәде. Ә күзәтүче, сынап караучы булган. Озын төз сынлы, сары мыеклы, утыз бишләр тирәсендәге ир кеше юкка гына чиратта аның артына килеп басмаган һәм аның янәшәсенә эскәмиягә килеп утыруы да очраклы гына булмаган икән. Бу ниндидер ният белән эшләнә, дип уйларлык та түгел иде, чөнки ул адәм үзен бик әдәпле тотты— утырыр алдыннан ике арага, эскәмиягә зур зәңгәр сумкасын куйды. Авыз ачып беренче сораганы да юлдагылар өчен бик гадәти иде:

—Гафу итегез, сезнең дә беренче баруыгызмы?

Тавышы бик йомшак, күңелгә ятышлы иде. Тупас җавап биреп булмый, дәшми калу да яхшы түгел.

—Икенчесе,—диде Тәслимә коры гына, читкә карап. Сүзне озайтасы килмәгәне аңлаган кешегә аңларлык иде. Әмма мыеклы әллә аңламады, әллә аңламамышка салышты. Тирән итеп көрсенде дә, башын аска иеп:

— Ә мин беренче тапкыр барам,—диде. Һәм үзалдына сөйләгәндәй:— Кая барырга, нишләргә, бернәрсә белмим,—дип өстәде.

—Халык кая барса, шунда барырсыз. Ялгышмассыз.

—Сез дә шулай итәсезме?

—Мин дә.

Сүз өзелде. Икесе ике якка карап, дәшми-тынмый утырып тордылар шулай. Әмма самолетка чакыруны ишетү белән, мыеклы сикереп торды да:

—Рөхсәт итегез,—дип Тәслимәнең сумкасын алды. Тарткалашып булмады—мондый чакта ир-атның хатын-кызга ярдәм итүе табигый лабаса. Тәслимәгә сумкасы артыннан тыгыз-тыгыз теркелдәргә генә калды—мыеклының адымнары үрчемле иде. Самолетка алар беренчеләрдән булып керделәр. Бу адәм, стюардесса белән сөйләшеп, Тәслимә белән янәшә утырды.

Юл озын—өч сәгать ярым барасы. Урыннар кысан—ике арага зур сумка кыстырып куярлык түгел. Кыймылдасаң, терсәкләр бәрелешә, кузгалып чыгам, дисәң, тезләрең ышкылып китә. Әнә стюардесса эчәргә су өләшеп йөри, эчтәрәк утырган Тәслимәгә аны күршесе алып бирә. Озакламый поднослар белән ашарга китерделәр— бер-беренә игътибарлы булырга, ярдәмләшергә туры килә. Тәрбияле кеше андый чакта күршесенә төксе карап утырмас. Бер-ике генә авыз булса да сүз алышмый мөмкин түгел. Ә бу адәмнең сөйләшәсе бик килә иде.

Таныштылар. "Алексей",—диде ул башын ия төшеп. Сүзгә сүз ялганып китте. Ул да танышларыннан акча җыеп юлга чыккан икән. Әмма мондый кәсепкә күнеле ятмавын, бу юлга аны зур бер мәҗбүрият кузгатканын сиздерде.

—"Челноклар" арасында очраклы бәндә инде мин, бер барып кайтсам, башка булдыра алмам,—диде акланырга теләгәндәй.

Аның кыенсынуы, яшькелт күзләре белән мөлдерәп каравы Тәслимәнең күңелен йомшартмый калмады. Үзенең дә болай талкынып йөрүе иркле көннән түгел, ул да кыенсына! Аны да бу юлга мохтаҗлык дигән заман зәхмәте өереп алып чыгып китте түгелме?..

Карашларның, кичерешләрнең охшашлыгы тагын да ачылыбрак сөйләшергә җирлек тудырды. Алексейның хәле күпкә авыррак икән әле.

Ул үзе архитектор, хатыны укытучы. Биш яшьлек уллары бар. Моннан өч ай элек хатынында рак чире тапканнар. Операция ясаудан узган, дигәннәр. Хәзер хатыны көннән-көн ябыга, хәлсезләнә икән. Алексей ихлас карашын Тәслимәнең бәгыренә төбәп:

—Мондый хәлне сезгә Ходай күрсәтмәсен,—диде.—Мин аның йөзенә туры карый алмыйм, әйтер сүз таба алмыйм. Ничекләр итеп юатыйм? Врачлар, дәва юк, диләр, без аның сызлануларын гына киметә алабыз, диләр. Мин, ир кеше, ничек инде аның шулай әкренләп сүнә барганын карап тик утырыйм? Әле менә газетадан бер мәкалә табып укыдым. Петрозаводскида рактан янача дәвалый торган үзәк ачканнар. Күпләрне терелткәннәр икән. Бик матур язганнар. Аны укыгач, хатыныма хәл кереп китте. Чыраена нур инде, тамагына ашый башлады. Көчек түгел, чыгарып ташлап булмый! Юньле кеше этен дә ташламый андый чакта. Миллионнан бер шанс кына булса да, кулланып карарга кирәк. Шуны да эшләмәсәң, соныннан үкенеп туймассың. Петрозаводскига шылтыратып белештем, юл чыгымнары белән бергә өч миллион акча кирәк. Менә үзебезнең сабакташлар, танышлар акча җыйдылар, кемгә нәрсә кирәген язып бирделәр. Базардагы торгашларны баетканчы, сиңа ярдәм булсын, барып кайт, диделәр. Ә хатыныма әйттем: мин сиңа тормыш алып кайтачакмын, Ирина, дидем. Моннан кайтуга Петрозаводскига китәргә туры киләчәк. Мин инде анда билет та алып куйдым. Хатынның янындагы өстәлдә ята. Көч бирсен аңа, дидем.

Тәслимә Алексейнның кыйссасын тетрәнеп тыңлады. Менә кайда ул фаҗига! Ярый ла Ирина дигән хатынның ире шушындый фидакарь кеше, аның өчен мең мәшәкать кичерергә әзер тора!..

Соныннан бу очрашуны үз гомерендә ясаган иң аяныч хатасы, иң зур гаебе итеп исенә төшергәндә, Тәслимә аның чыгынкы иягендә, әледән-әле кысылып куя торган юка иреннәрендә, тетрәнгәләп алган борын яфракларында гасабилану, күнел катылыгы ярылып ятканын сизгән кебек була иде. Аның башкалардан өстен булырга, һәрнәрсене үзенчә генә итәргә күнеккән кеше икәнен сизәргә була иде бит! Тукта, тагын нәрсәдер күнелне тырнап узган иде. Аның хатыны турындагы кыйссасын тыңлаганда, кызгану аша ниндидер ризасызлык чагылып узган иде Тәслимә күнелендә. Тик ул моны аңлап житкермәде, башка тәэсоратлар дикъкатьне читкә юнәлтте. Ахырдан гына, кайта-кайта уйланганда, Алексейнның уйчан тавышы гүяки колак төбендә кат-кат кабатлый торган булды: "Көчек түгел, чыгарып ташлап булмый, көчек түгел көчек түгел..." Ул хатынын көчек белән чагыштырды. Димәк, ул хуҗа. Кайгыртучан, миһербанлы, әмма барыбер хуҗа. Хатынының хуҗасы. Ә хатын—аның малы. Ничек моны шул чакта аңламады икән Тәслимә? Хәер, аңлаган булса да, бу хакыйкатьне үз язмышына китереп бәйләргә ни сәбәп бар иде соң әле?

Самолеттан төшкәч, бергә киттеләр. Икесе өчен дә уңай иде бу. Алексейга әйбер-караны арзанга, ышанычлы урыннан алырга кирәк, ә Тәслимәгә ир кеше белән йөрү кулайрак иде. Төрекләр урыс хатын-кызларына ымсынып карыйлар, чөнки үзләрендә фахишәлек закон белән тыелган, Рәсәйдән исә тәнен сатып акча табу кәсебенә керешкән бик күп тәтәйләр килә. Бәгъзеләре кибетчеләрдән товарны шул ысул белән алу җаен карыйлар, диләр. Шунлыктан, кибеткә кергән Рәсәй хатын-кызларын күрүгә, сатучыларның күзе кыза, аларны, яхшы товар күрсәтәбез, дигән сылтау белән арткы бүлмәгә алып кереп, капшаштырырга да күп сорамыйлар.

Янында ир кеше булганда, бу җәбердән котыласың. Хода шаһит, очраклы юлдашы күнеленә ошаганга түгел, фәкать кибетләрдә йөрергә уңай булуын уйлап кына, кояшлы Истанбул урамнары буйлап Алексей белән янәшә китте ул.

Башын югары чөйгән Алексей үзен чын хуҗаларча горур, хәтта шактый ук тәкәббер тота, аның хатынына (ә сатучылар шулай дип аңлады) керфек сирпеп бер караш ташлау да мөмкин түгел иде. Бар нәрсәне

Алексей күтәреп йөри, төрекләрне чаптыра, кибет ишеге төбенә, урамга чыгарып куйган кечкенә өстәл янына җәелеп утырып, сатучы тәкъдим иткән чәйне нечкә билле нәни стаканнан тәмләп эчә. "Сыйлан, рәхәтен күреп кал,—ди Тәслимәгә.—Бездә генә ул сатып алучыга эт кадере дә юк. Ә бирегә килгән акчалы кешеләрнең һәркайсы—кадерле кунак!" Базар кафесына кереп, үзе теләгән ризыкны алды һәм шундыйны ук юлдашына ашатты ул, зур сумкаларны аэропортка илтергә машина яллады. Тәслимәгә мәшәкать бетте, эше җиңеләйде, "ире" артыннан теркелдәргә генә калды. Көчек кебек тагылып йөрергә. Тик моның ахыры ни белән бетәсен һаман аңлап җиткермәде ул. Хәер, аңласа нишләсен? Кит, дип куып җибәрсенме? Аңа ни сәбәп бар иде тагын?

Төн кунарга иң арзан һәм ипсез бүлмәләрне түгел, уртача кунакханәне сайлау яхшы, дип өйрәтеп җибәргән иде Лена. Чит илгә барып, фәкыйрьлегеңне флаг урынына күтәреп йөрергә ярамый, дәрәҗәңне саклау тиеш.

Аскы катта, тышкы ишек төбендә кизү торучы кызыл костюмлы яшь егетләрнең берсе Тәслимәне бормалы баскыч буйлап дүртенче катка озатып куйды. Әйберләрен Алексей күтәреп менгезде.

Кунакханәдә бүлмәләр ифрат кысан, ике ятак арасыннан узарлык кына ара калган, ишекнең бер ягында кечкенә өстәл, икенче ягында тумбочка. Алай да юыну бүлмәсе бар.

Беренче төнен Тәслимә Вологдадан килгән бер хатын белән иде. Икенче төнгә ул ялгызы гына калды. Көн буе базарда йөреп чиксез арылган, иртүк торып, аэропортка китәргә кирәк иде. Тәслимә бүлмәсендә чәй кайнатып эчте дә, юынып алып, тизрәк яту ягын карады.

Ул йокыга киткән генә иде, сак кына ишек шакыдылар. Тәслимә сискәнеп китте— кем шакыганын аңлады. Ишекне ачарга ярамый иде, билгеле.

—Кем анда?..

—Бу мин, Алексей Дару кирәк иде, дару. Дару...

Тәслимә, халатын киеп, өске лампаны кабызды, ишекне ачты да, төнге кунакны кертмәс өчен, аркылы басты.

—Эчем авырта, һич чыдар хәл юк. Бу төрекләрнең ризыгы... Түзәргә тырыштым, үтәр, дидем...

Гаҗәп түгел. Төрекләрнең ногыт борчагы белән зәйтүн җимеше күпчелек урысның эченә килешми. Юлда шуннан да яманы юк инде. Тәслимә үзе белән левомицетин дигән дару йөртә. Ике төймәсен берьюлы капсаң, шундук тынычландыра. Бик ачы ачысын, су белән сиздермичә генә тамактан шудырып җибәрергә кирәк.

Тәслимә коры тавыш белән кыска гына шуларны аңлатты да, яны белән борылып, иелә төшеп, ишек катындагы тумбочкадан сумкасын алырга үрелде. Сагайган иде ул, күңеленә шик күбәләге канатын җилпеп узгандай иткән иде. Ләкин, эче авырткан юлдашыннан бер-ике төймә дару кызганып буламыни? Алай да, бүлмәгә юлны киртәләп тотарга тырышты, сыңар аягын ишек турыннан алмады. Ләкин, янгарак авышкач, гәүдәсенең бер генә мизгелгә тотрыксыз каласын уйлап җиткермәгән икән. Ул ни булганын сизми дә калды, Алексей аны биленнән тотып күтәрде дә, кискен хәрәкәт белән караватка ыргытты. Тәслимәнең башы караватъ агачына бәрелде, күз алдында очкыннар сибелде. Ул арада ут сүнде, ишектәге инглиз йозагы чылт итеп бикләнде. Каты авыртудан һушын югалта язган хатынның сыны каткан иде, каршы торырлык көче булмады. Каны кызган, аны- моны уйлап торудан узган ир аның хәлсез-көчсез чәбәләнүен кылану-кылчыклану дип кенә кабул иткәндер, бәлки.

Кычкырырга кирәк булгандыр, каты тавыш куптарырга. Ләкин хәл калмаган иде. Хәлен булса да, ничек кычкырасың? Ничек гауга күтәрәсең? Аскы катта, ишек төбендә утырган кызыл костюмлы ике төрек егете йөгереп килеп, ишекне каерып ачып керсеннәр, бер-берсенә укмашкан ике Рәсәй кешесен күрсеннәр өченме?

Әйе, күп ирләр, хатын үзе теләмәсә, аны алып булмый, дип

ышандырырга тырыша. Чын ирләр микән алай сөйләүчеләр?

Ә менә бу Алексей дигән адәм самбо буенча беренче разрядлы спортчы булып чыкты. Мингерәгән хатынның тәненә генә хуҗа була белә иде инде ул. Тәслимә кичергән бердәнбер тойгы— сызлану, буылу дәрәҗәсенә житеп тыны кысылу булды. Ирнен авызыннан аракы һәм арзан тәмәке сасысы бөркелә, косасын китерә иде. Бу газапның ахырычиге булмас иде кебек. Ник шунда үлмәде икән Тәслимә, ник газиз жаны чыкмады икән?

Менә, ниһаять, ул сулышы бераз иркенәйгәнен тойды, каты пышылдап әйтелгән сүзләр аңына килеп житте:

—Шешәне алып керергә башка килмәгән. Анда калган иде әле минем. Икебезгә дә ярап куяр иде хәзер.

—Чыгып кит.

—Гафу ит үз-үземне белештермәдем. Ачуланма. Кеше бул. Син ир кешене анларга тиеш. Ничә ай буйдак хәлендә. Мин сәламәт ир кеше ләбаса! Теләсә кем янына бара алмыйм, жирәнәм.

—Зинһар, кит.

—Нәрсә болай кыланасың? Бер бәхетсезне бер төнгә бәхетле итә аласыңмы син? Без табигать балалары лабаса! Адәм баласы бәхетле минутлар кичерү өчен яши. Мең чакрымнар юл йөреп, ат урынына йөк ташу өчен түгел.—Аннары бераз тынып торды да:—Ишекне үзең ачтың ич,—дип өстәде.—Хатыннарның ирләрне төнлә бүлмәләренә ник керткәнен белмисең түгел.

Тәслимә көчкә санын җыеп, урыныннан кузгалды да, юыну бүлмәсенә керде.

Аңа чистарынырга, ничек тә булса тазарынырга кирәк иде. Бик озаклап, сөлгене кат-кат сабынлап тәнен ышкырга кереште. Су тавышы аша ишек ачылып ябылганын ишеткәндәй булды. "Китте... Бүтән күрмәсәм ярар иде..." Шулай дип уйлап та өлгермәде, юыну бүлмәсенең ишеге каерылып ачылды. Су агышы астында торган Тәслимә учлары белән капланырга омтылыш ясады. Ишектә Алексей тора, кулында тулы стакан иде.

—Эч,—диде. Тәслимәнең чәченнән умырып башын артка каерды да авызына сыекчаны койды.—Эч, җинел булыр. Моннан яхшы даруның булганы юк. Тәнгә дә, җанга да.

Тәслимә тончыга язып йотты да йотты. Тамагы, бугазы көйде.

—Менә шулай,—диде Алексей, ниһаять, аның башын ычкындырып. Аннары стаканда калганны голт-голт үзе эчте. Тәслимә исә укшуын тыярга тырышып, өстән коелган суны учлап-учлап капты. Әкренләп тәненә хәлсезлек җәелгәнен, йөрәк ярсуы басылганын, уйлары буталганын тойды. Күнеле тулды, таш диварга капланып үкси башлады. Алексей су агымы астына кереп, аны кочагына алды:

—Син нәрсә? Гыйффәтле кыз түгел ләбаса. Шушы яшеңә житеп, бу заманда. Кайда яшәдең соң син?.. Бу кадәр беркатлы дип кем уйлар.

Ул онытылып-шашып Тәслимәнең бөтен тәнен үбә башлады.

—Ела, Тася, ела. Елаганда син тагын да гүзәл.

Күз яшьләре Тәслимәнең бөтен хәлен алган, көчле, каты кулларда аның тәне чүпрәк булып калган иде.

* * *

Казан аэропортына кайтып төшүгә, Тәслимә халык арасыннан ирен эзләде. Үзе як-ягына карангаланды, үзе: "Килмәгән булса ярар иде",—дип уйлады. Аны каршы алучы юк иде, шөкер. Алексей машина табып, сумкаларын урнаштырышты. "Мин шылтыратырмын",—дип хуҗаларча каты куллары белән аны үзенә тартып, яңагыннан үпте.

Көн кичкә авышкан, яңгыр сибәләп тора, юл читендәге каеннарның күбесе инде шәрәләнеп калган, яфракларын салмаганнарының да төсе

тоныкланган, конгыртланып бозылган иде. Йә Алла, әле кайчан гына дөнья да, Тәслимә дә бөтенләй башка, якты төсмерле, саф иделәр бит! Каеннар да ачы җилләрдән кыйналган, алар да керләнгән. Ул да. Ничек итеп күренер ул иренең, балаларының күзенә?

Ишек ачып кергәндә, хәле-төсе юк иде. Рәсимә белән Самат икесе ике яктан кочаклап алдылар, Инсаф читтәнрәк текәлеп карады.

—Ни булды? Авырыйсыңмы әллә?

—Егылдым. Башым бәрелде.

Инсаф шундук бөтен үпкәләрен онытты.

—Кайда? Ничек?

—Төркиядә үк инде. Кунакханәдә. Ялгыш басып, баскычтан егылдым. Баскычлары тар, текә. Алай зарарлы сыман түгел иде. Үзем торып киттем.

—Врачка күрендеңме? Ник шылтыратмадың? Каршы алган булыр идек. Врач чакырырга кирәк!

—Туктале, кичкә таба нинди врач.

Инсаф анын курткасын, кроссовкаларын салдырды, җитәкләп эчке бүлмәгә алып керде, халатын алып бирде. Шундук ваннага су коярга, урын-җирне рәтләргә тотынды, Рәсимәгә чәй куярга кушты.

Ә балалар, рәхмәт яусын аларның гамьсезлегенә, сумкаларның ачылганын түземсезлек белән көтәләр иде. Кроссовкаларны, спорт костюмнарын, свитерларны күргәч, күзләрендә очкыннар кабынды, көзге каршында этешә-төртешә бөтерелә, сикерешә башладылар. Ана өчен балалардан да шифалырак җан дәвасы бармы? Берничә минутка булса да онытылды Тәслимә, елмаймыйча булдыра алмады. Бигрәк тә Рәсимәсе:

—Әнием, рәхмәт, мондый костюм безнең класстагы бер кызда да юк!—дип аңа сарылгач, җаны эреде.

Ләкин ире каршында ул сырхау иде. Юынып, дарулар эчеп, урын өстенә барып ятты да, йокыга киткәнгә сабышты. Бар курыкканы—иренең орынуы иде. Ул чакта нишләр? Аны кабул итү мөмкин түгел, этеп җибәрү шулай ук. Нишләргә? Ярый, бәхеткә Инсаф аны чыннан да авыру һәм бик арган дип белде. Борчымаска тырышты, караватның кырынарак шуышты. Ярый читләште, югыйсә ул хатынының ут эчендә ятканын, аның тәне кызышып, сулышыннан эссе бөркелгәнен тоймый калмас иде.

Төн буе эчтән дә, тыштан да кызышып чыкты Тәслимә. Ул хыянәтче. Хыянәтче ирenә, антына хыянәт итте. Аңа беркайчан да ярлыкау булмаячак. Инсаф аны менә шушы минутта бәреп үтерсә дә хаклы булачак. Законда да бу каралган: хыянәтче хатыннарын үтергән ирләрне утыртмыйлар да бугай. Миен ялкын теле белән өткәндәй тагын бер уй бәреп керде: Алексейдан берәр начар чир алып кайткан булса? Ул кешенең кайларда, ни рәвешле себерелеп йөргәнен кем белә?

Инсаф тагын бер малай булуын тели иде. Тәслимә аңа вәгъдә биргән иде. Менә алып кайтты... Ләкин ул гаепле түгел бит! Әгәр берәр бандит аны имгәтеп ыргыткан булса, кем аны гаепләр иде? Имгәттеләр бит аны, тәнен генә түгел, җанын имгәтеп ыргыттылар. Башка берәүне гарипләсәләр, җинаятьчене тотып төрмәгә утыртырлар иде. Ә монда бөтен газабы Тәслимәгә...

* * *

Шул рәвешле җанның кыйналуы белән үтте ул төн. Иртән Инсаф балаларны мәктәпкә әзерләп озатты, Тәслимәнең, яхшы йокладым, бүген хәлем әйбәт, дигән сүзләренә бик ышанып ук җитмәсә дә, сүзне озакка сузмады. Заводта яртышар көн генә эшлиләр икән, озак тормам, дип китеп барды.

Дөнья куунын үз чирләренә үз дәвасы да бар. Ул дәва—тынгысызлык. Сузылып яту мөмкин түгел иде. Алып кайткан әйберләрне ияләренә тапшырып, исәп-хисап ясыйсы, калганнарын базардагы сатучылар ашамы, таныш-белешкәме сатасы. Рәсимә кул арасына керсә дә, өй мәшәкатьлә-

реннән дә бөтенләй бушанып булмый: базарга чыгып кирәсе, ашарга пешерәсе, юасы, үтүклисе бар.

Ленага шылтыратты—ул тагын бер тун белән күн курткага заказ биреп җибәргән иде. Тапшырырга кирәк.

—Гафу ит, Вадим сине каршы ала алмады бу юлы,—диде Лена кабаланып.—Сина Инсаф әйткәндер бит, без сезне кунакка көтәбез бүген.

—Юк, әйтмәде.

—Ну вот! Вадимның туган көне, утыз өч яшь тула. Әйттем бит мин Инсафка, баянын белән килерсен, дидем. Җиденче яртыда Вадим килеп җитәр машинасы белән, әзер торыгыз.

Авырыйм, дияргә кирәк булгандыр. Кунакка йөрерлекме сон? Ләкин Инсаф вәгъдә биргән бит инде. Шулай булгач, бармау яхшы түгел.

Ул Солтаниягә шылтыратты—ана да тун алып кайткан иде. Анысы, төштән сон үзем кереп чыгармын, диде.

Эч пошканда өйдә тик ятудан да яманы юк. Үз-үзенне яканнан өстерәгәндәй итеп булса да урамга, иркенгә, халык арасына алып чыгып китәргә кирәк. "Тор хәзер үк!—диде Тәслимә үз-үзенә.—Ки өстенә. Тот сумканны. Ач ишекне! Чык!"

Кибет ишек төбендә гәзит-журнал саталар. Үзе дә анлап житкермичә, ул шунда, витрина янына барып басты. Монарчы беркайчан да алар янында тукталганы юк иде, күз салуга кире борыла иде. Чөнки ул журнал-гәзитләрдә ярым- шәрә хатыннарнын, авызын ерган ялангач ирләрнен сурәтләре ясалган. Узгынчыларнын өлкәнрәкләре ул тарафка күз сирпергә дә ояла, кайсылары сукранып куя. Тәслимә дә шулар кавеменнән, бу өлкәдә "бик тә артта калган"нарнын берсе иде. Оялудан да бигрәк, кызыксынуы юк иде.

Бүген исә, нилектән икәнен үзе дә анламыйча шулар янына тартылды. Озаклап карап торды. Әлбәттә инде, бөтенләй үк томана түгел, сирәк-мирәк булса да кулында тотканы бар. Культура сараенда бер-берсеннән алып торалар, укыйлар, көләләр, аптырыйлар, гаеплиләр иде.

Ләкин бу юлы ул аларга бөтенләй башкача карады. Ә нишләп әдәпсез? Нишләп пычрак? Бу гәзитләрне миллионлаган кешеләр ала, укый, аларнын һәммәсен пычрак дип санарга ни хокукы бар анын? Бәлки, менә бүген, үзенә җавапны Тәслимә шулардан табар?

Ул "Спид-инфо" гәзитенен берничәсен сатып алды.

Өйгә кергәч, диванга сузылып ятты да актара башлады.

Авыл мохитында тәрбияләнгән, Әпсәләмов, Ибраһимов, Ахунов, Ибрай Гази әсәрләрен укып үскән бала буларак, үсә төшкәчрәк Тургенев, Пушкин, Толстой, Айтматов китапларын йотылып укыган студент буларак, мәхәббәткә, гаиләгә, биргән антына карашы ачык, үз-үзенә таләпләре бик каттый иде анын.

Ә менә бу гәзитләрдә хатыннарнын, ирләрнен чит кешеләр белән уйнашлык итүе хыянәт дип аталмый, бер шаярып алу гына дип тасвирлана иде. Ул гынамы! Кайнана белән киявенен, оныгы белән бабасынын женси мөнәсәбәтләргә керүләре, Тын океандагы утрауларда, кайсыдыр кабиләләрдә "күмәкләшеп кавышу йолалары" турында тәфсилләп язганнар.

Менә бер яшь, чибәр кыз сурәте. Кыяфәтенә караганда, саф, гөнаһсыз бала. Озын күлмәк кигән дә, тезләрен кочаклап, уйланып утыра. Ялан аягы очында ике бәллүр чәркә, ике алма салынган тәлинкә һәм язу: "Яна партнерны көткәндә". Күпләрне күргән кызый, димәк, чираттагыны көтеп утыра. Һәм шуны уйлый:: "Мин чишенгәч, ана ошармын микән? Ул ялангач калгач, ни төсле икән? Ләззәтне тулысынча алып булырмы?" Карасана, ирләрне бер-бер артлы алыштырып торучыларнын да эче буш түгел, аларнын да гамьнәре бар икән! Кара син, болай итеп монланып көтеп утыру үзе бер матурлык, үзе бер хозурлык икән ләбаса!

Менә бит ул ничек. Табигать адәм баласын "полигамный" итеп, ягъни төрле кеше белән женси мөнәсәбәткә керә торган итеп яраткан.

Бәс шулай булгач, бер-берсенә тугры калган гомерлек парлар табигатькә каршы килә, дигән сүз. Әгәр Инсаф башка берәүгә карасa, моның өчен ана рәнжергә кирәкми. Аңларга кирәк, гафу итәргә һәм Тәслимә гафу итәр беленсә. Белмәвең исә яхшырак икән. Инсафның да белмәве әйбәт. Белдермәскә, сиздермәскә генә кирәк. Иреннең күнелен китмәскә... Анысын да өйрәткәннәр, аларын да укыды Тәслимә.

Ә чир-чор? Булмаган нәрсә белән ник баш катырырга! Алексей— гаилә кешесе, чистадыр, мөгаен.

Тәслимә, теге "яшь гүзәлгә" карап, алдагы кичтә ничек тә булса үз иренең күнелен күрү турында уйлады. Хыянәтеңне онытырга кирәк. Элеккечә булырга. Спектакль куя белә ләбаса, монда да спектакль уйнарга кирәк!

Мавыгып киткән иде ул... Җаны да сызланудан тынып торган иде шикелле. Кинәт зыңгылдаган ишек кыңгыравы тавышыннан сискәнеп китте, гәзитләрне кабаланып диван астына шудырды.

Солтания икән. Гадәттәгечә салмак, пошмас хәрәкәтләр, битараф, тыныч тавыш. Бу юлы Тәслимә аны бохар мәчесенә охшатты. Мәчеләр хуҗаларының җанын тынычландыра, авырткан җиргә терәлеп ятса, тәнгә дә сихәт бирә, диләр. Солтаниянең дә шундый дәвасы бардыр шикелле.

Замша белән күн тасмаларын аралаштырып тегелгән озын көрән тунны киеп карады. Мондыйлар Казанда әлегә сирәк күренә. Тун Солтаниягә ифрат килешә, затлы-зыялы кыяфәт бирә иде. "Әгәр минем хәлдә калса, әгәр аны тотып көчләсәләр, нишләр иде икән?—дип уйлады Тәслимә.— Иренә сөйләр идеме, эченә йотар идеме?.. Юк, ул берсен дә эшләмәс иде",—диде аннары үз-үзенә. Чөнки аның йөргән юлларында беркайчан да Алексейлар очрамаячак. Очраса да якын килә алмаячак. Якын килсә дә, Алексейга дигән дару анда булмаячак һәм шуңа күрә тәнлә аның ишеге ачылмаячак. Чөнки тыныч кеше Солтания, уйлап эшли торган кеше, Тәслимәдәге тынгысызлык аны борчымый, беркатлы ышанучанлык шөбһәле хәлләргә куймый. Шулай уйлады Тәслимә һәм үзалдына кимсенде.

Инде тунны әйбәтләп төреп, полиэтилен капчыгына тыгып куйдылар. Инде исәп-хисапны ясадылар. Инде ишек төбенә барып бастылар. Ә Солтания элгечтән күн курткасын алырга ашыкмады, тукталып калды. Тәслимә, чәй белән сыйлаганны көтәдер, дип уйлап куйды.

Аш бүлмәсенә кереп утырдылар.Чәйнек кайнап чыккан арада Солтания ияген учына куеп, моңлы күз карашын тәрәзәгә төбәде дә:

—Безнең "Ашкын" нәрсә хисабына финансланыр икән?—дип сорады.

Ә-ә, менә нәрсәдә икән хикмәт! "Ашкын"да житәкче бит әле Тәслимә! Мөһере бар бит аның. Ашкынып, тырышып, спектакльләр ясап алган мөһере. Каядыр шкафта ята.

—Анда безнең тагын картотека җыела башлады,—диде Солтания.— Салымнар түлисе бар. Мин монда акча түләү документларын басып алып килдем. Мөһер сугып бирегез дә, банкка илтеп тапшырам.

—Нинди акча түләү? Акчабыз юктыр ла безнең?

—Булмаса да, салым түләү кәгазьләрен банкка вакытында илтеп тапшырырга кирәк. Югыйсә безгә бик каты штраф салачаклар. Ә болай ул кәгазьләрне банк картотекага куя, счетка акча керү белән, җибәрә.

—Ул нинди бетмәгән салым?

—Эш хакы начислять итәргә кирәк бит. Бухгалтерга. Президентка.

—Нинди президентка?

—Сезгә соң!..

Ерак юлларда кешелектән чыгып тапкан акчаны салымга бирергәме әллә тагын?

—Аны кире Минвәлиевкә тапшырырга кирәк,—диде Тәслимә.

—Ул үзе сезгә әйтергә кушкан иде әле, "Миһербан"ны да алмас микән, дип. Район администрациясенә эшкә чакыралар икән, андагыларга бизнес белән шөгыльләнергә ярамый.

—Ябарга кирәк алайса.

—Ябу да зур мәшәкать. Аның өчен бөтен салымнарны, эш хакы буенча бурычларны түләп бетерергә кирәк башта. Шуннан соң артыннан шактый йөрисе. Анысына тагын кем бушка чабар икән?

Кара син аны, бер каптырып алсалар, котылу да җинел түгел икән. Алтын мөһер дигәне корыч кармак булып чыкты түгелме?.. Солтания белән саубуллашканда, Тәслимә чарасын күрергә вәгъдә итеп калды.

Ничек тә хәл итәргә кирәк иде моны. Авыр уйлары арткарак чигенде, чөнки, мөгаен, яна спектакль куярга кирәк булачак иде. Теге вакытта, мөһерне кулга төшергәндәге кебек. Тагын бер кат шулай уйнарга да, "Ашкын"ны берәрсенә сылап куярга. Ике айлык салымнарны, бухгалтерга һәм ана—Тәслимәгә ике айлык эш хакын түләрлек итеп. Әнә, ул үзе ай ярым элек кенә дүрт айлык салымнарны, эш хакларын түләде бит. Тагын шундый берәр тиле табылмасмы? Ул шунда, анына килеп, башын чайкап куйды: ай-һай, андый ачык авыз булырмы тагын? Ә шулай да, нинди бәхетле булган ул! Акчасы югалу берни түгел, җаны тыныч, тәне чиста булган!.. Аннан зур бәхет бармы? Шул чактагы үзен сагынудан Тәслимәнең күзләреннән яшь чәчрәп чыкты.

Ярый әле, Леналарга кунакка барасы булды. Тагын хәрәкәт, ә хәрәкәттә, мәгълүм булганча, бәрәкәт. Матурлап киенү, бер-беренне сыйпаштыру, кибеткә кереп чәчәк алу—бүләген Төркиядән кайткан товар арасыннан алып бардылар—һәммәсе бер-беренә якынайта иде.

Каракүзевлар яна районда квартир сатып алганнар. Ишектән барып керүгә затлылык күзгә бәрелде: стеналарга кыйммәтле обойлар ябыштырылган, идәндә—паркет, ишекләр имәннән, юыну бүлмәләре чит ил плиткалары белән эчләнгән, краннары, юынгычлары—һәммәсе ялтырап тора. Кул юарга дип кергән Тәслимә берничә минутка онытылып торды—бу чисталыкка, байлыкка, матурлыкка кызыкмый мөмкин түгел иде. Хәзерге заманда үзен-үзе ихтирам иткән кешеләр өр-яна квартирга да "евроремонт" ясамый кермиләр шул. "Унган кешенең торган җире менә шушындый була икән",—дип уйлады Тәслимә.

Кунаклар күп түгел, һәммәсе парлылар иде. Арада берничәсе—таныш, ятсынып торасы булмады.

Беренче котлау сүзе әйтелгәч, Тәслимә шампан шәрабы тулы бокалны төбенәчә бушатты. Аннары тагын берне, тагын берне. Сусаган иде, нәкъ менә шәрабка сусаган иде, иренең карашын тойса да, тыела алмады. Рәхәт, җинел булып китте. Ә нәрсәгә эчне пошырырга? Ни булган әле? Юк ул Алексей дигән адәм! Төркиясе дә юк! Менә елмаепкөлеп, бер-берсен макташып утырган кунаклар, менә аның ире, менә татлы шәраб, тәмле ризык...

Тәслимә табын күркенә әверелде: Инсаф баян уйнаганда , бөтенесен җырлатты; мондый чакта һәммәсенең җырлыйсы килә, тик күбесе сүзләрен белми. Ә менә Тәслимә җырларга да, җырлатырга да маһир. Пианинода да уйнап алды, ә биюне әйткән дә юк.

Бөтенесен булдыра, һәммәсенә көче житә иде шикелле. Аш бүлмәсендә савыт-саба юышканда, "Ашкын" белән аның мөһере хакында да бер-ике авыз сүз алыштылар.

—Сат син ул фирманы,—диде Лена гадәтенчә катгый итеп.— Егерме процентын бирсән, алучы табам мин сина.

—Аны сатып та буламыни?

—Яна фирма ачу өчен күпме чабасы да күпме акча туздырасы? Сатып алу җайлырак. Тиз дә, арзан да. Ике миллион чамасына ычкындырырга булыр. Уставынны китер, карап чыгарбыз.

Һәммәсен бик ансат хәл итә, баш ватып тормый Лена. Әнә, акчаны да өеннән чыкмый гына таба. Ике машиналарына ике шофер яллаганнар, шулар белән йөк ташыйлар. Гәзиттә игълан бастыралар, кирәк кеше шуннан карый да шылтырата. Диспетчер булып алган Лена. Бала табарга җыена үзе. Пычрандым дип үз тәненнән җирәнәсе дә, иренен күзенә

туры карарга куркасы да юк. Нинди бәхетле! Ә менә Тәслимә буйга узган булса?!

Шампан шәрабының сөреме башка тиз бәрә, тиз чыга да. Кайтып кергәндә, яхшы гына айныган иде инде Тәслимә. Эчкә тагын сагыш саркый башлады. Уйнарга кирәк, теге гәзит өйрәткәнчә кыланырга, урын өстендә спектакль куярга!..

Акыл шулай диде. Әмма тән тамырларының үз хәтере бар. Тән куркып калган, ир заты якын килүгә, тартышып килә иде. Хәтта сөйгәненең татлы сулышын да тоя алмады Тәслимә. Үз ирен, үз ярын элеккечә кинәнеп, онытылып, ләззәт дингезендә тирбәлеп кабул итә алмады.

—Ашыктык, ахрысы,—диде Инсаф бераздан аның башын сыйпап. —Бигрәк нык күпкән шул, кайчан төзәлер. Врачка бармый булмас.

Тәслимәнең исә күңелендә бер теләк, бер омтылыш янды: тизрәк өйдән чыгып китәргә. Аэропортлардагы, базарлардагы ыгы-зыгыда уйларынны адаштырырга, меңләгән халык арасына кереп югалырга. Инсафның күз карашыннан, назларыннан, сүзләреннән котылып торырга.

* * *

Ял көнне идән юганда Рәсимә диван астыннан гәзитләр тартып чыгарган да, ишек янындагы тумбочкага куйган. Юыну бүлмәсендә кер чайкап азапланган Тәслимә күрми калды. Инсаф кибеткә чыккан иде, кайтып керүгә:

—Кем куйды боларны?—дип сорады.

—Мин,—диде бүлмәдән башын сузып, аны-моны аңламаган Рәсимә.

—Син? Каян алдың? Кем бирде?

Тәслимә су тавышы беләң ишетми торды, ул чыкканда ата белән кыз коридорда кара-каршы басып торалар, Инсаф ачулы, Рәсимә исә кызарынган-бүртенгән иде. Ул әнисенә өмет һәм ялвару белән карады:

—Менә, диван астыннан килеп чыкты,—диде әтисе кулындагы гәзитләргә ымлап.

—Кем куйды икән соң аларны?—диде Тәслимә гаҗәпләнгәндәй кыланып. Ах, әгәр ул шунда кызының бәгырьгә кадалган карашын күрмәгән булса иде. Әнисенең бу беренче тапкыр ялганлавын Рәсимә онытмаячак иде. Әрнүдән, оялудан нишләргә белмәгән Тәслимә иренә ябырылды:

—Нәрсә син юк белән баланың башын катырасың? Үзең тыгып куйгансыңдыр да оныткансыңдыр әле!.

Инсаф аңа кистереп карады, дәшмәде. Әйе, иренә юл бирә торган зирәк хатын түгел иде инде бу! Тавышы бөереннән чыга. Сыйпаштырып та карады, ачыктан-ачык сөйләшергә омтылган чаклары да булды Инсафның, тик аралар җайланмады.

Инсаф моны үзенчә, хатыны акчаны күп тапканга азына, дип аңлады. Гадәттә, тормышны мин алып барам, иремне мин туйдырам, дип уйлаган хатыннар шушындый явыз, башбирмәскә әверелә. Шулай уйлый иде Инсаф һәм кимсенә иде.

Хәлбуки сәбәп бөтенләй башкада—Тәслимә йөкле иде. Кем баласын йөртә ул карынында? Теге чакта фаҗигасен яшерде, хәзер инде бу хакта ире белән сүз кузгату мөмкин түгел иде. Яшереп кенә больницага кереп чыгарга кирәк, Тәслимә әлеге дә баягы шул Лена аша күндәм врач эзли. Түләү бәрабәренә эшен башкарсын да көнендә кайтарып җибәрсен, больницага салып азапламасын. Тик бу гамәлнең дә табигать куйган үз вакыты бар, бер-ике атна сабыр итәргә кирәк. Тәслимәнең исә күңеле болгана. Хәзер генә юлга да чыгып китә алмый.

Бу хәлендә ул һәммәсенә ирен гаепли башлады. Әгәр дә Инсаф шул заводына ябышып ятмаса, гаилә башлыгы буларак, балаларын тәэмин итү җаен тапса, сумка тотып җәһәннәм тишегенә чыгып китәр идемени ул? Мондый газапларга дучар булыр идемени? Әнә, Тәслимәнең әнкәе

нәрсә сөйләгән иде бит: ачлык вакытында әти кеше балаларына ризык эзләп чыгып китә, бөтен авырлыкны үз өстенә ала, дигән иде. Ә Инсаф нишләде? Баласы бер сынык ипи урлар чиккә житкән, ә ул сузылып ята, йә гармун уйнап утыра иде! Тапкан! Әнә, шундый аталарның балалары мәктәпләрдә ачтан һушын югалтып авалар да инде. Самат укый торган класста да булган андый хәл. Әгәр Тәслимә акча тапмаса, иң беренче егылган бала башка берәү дә түгел, Самат булыр иде! Әйе-әйе, афәтле юлларга чыгарга Инсаф мәжбүр итте аны, ул, ул гына! Ул юлларга ялгыз чыккан хатын-кызның башы ни күрмәс? Чын ир булса, моны уйларга тиеш иде ул: "Барма, барма!"—дип кенә түгел, үзе мал табып, хатынын бу куркынычтан араларга тиеш иде. Хәзер әнә ниндидер гәзитләр өчен гауга куптарып маташкан була тагын. Табылган бер тәкъвә! Шуның тәкъвәлеге белән юанып, эт куышында яшә менә!

Каракүзевләрдә булып кайтканнан соң, Тәслимә үзенең тормышын бик фәкыйрь итеп күрә башлады. Акшарланган түшәм, ак ишекләр, "Зөя" суыткычы, иске заманда алынган, күптән модасы чыккан шкафлар. Элек Минвәлиевнең тышкы ишегенә булдыксызлык билгесе дип караган иде. Каракүзев кебек кешеләр бу фатирга килеп керсә, хужалар турында ни уйлый инде? "Эт куышында яши икән болар",—диярләр. Һаман шул Инсафның булдыксызлыгы аркасында!

Шулай уйлады Тәслимә, шул рәвешле үз намусы каршында акланырга тырышты. Балаларын бал-майда гына йөздерүен, ал-гөлгә генә киендерүен уйлап үз-үзен аклады, тагын-тагын юлга чыгып китәчәген уйлап юанды.

Шул рәвешле бер утларда янып, бер суларга чумып йөргән көннәрнең берендә Алексей шылтыратты. Теге чакта, Казан аэропортында салкын гына саубуллашканнан соң, ул икеме-өчме тапкыр шылтыратып караган иде, ләкин Тәслимә бик коры сөйләшкәч һәм бүтән борчымаска кушкач, дөньяда барлыгын сиздерми иде.

Һәм менә кинәт анын тавышы. Бу юлы Тәслимә телефон трубкасын ташламады. Исәнләштеләр.

—Мин кичә хатынымны жирләдем,—диде ул.

Юату сүзләре әйтергә кирәк иде. "Урыны жәннәттә булсын" ничек була соң әле русча? Тәслимәнең зиһене таралып китте.

—Пусть земля будет пухом,—диде исенә төшереп.—Кайгыңны уртаклашам.

—Ә син күземә карап уртаклаша алмыйсыңмы минем кайгымны?

—Вакытым юк.

—Нәрсә, әллә тагын шунда барасыңмы?

—Анда да барылыр. Челночница ич мин.

—Алайса бигрәк тә... Без очрашырга тиеш..

—Мин алай дип санамыйм.

—Әгәр үлсәм, бәхилләшергә дә килмәс идеңме?

Тәслимә югалып калды. Барыр иде микән? Бәхил бул, дияр иде микән? Ә бит барырга тиеш булыр иде. Чөнки Алексей аңа чит түгел. Ул, бәлки, Тәслимәнең иң якын кешеседер бу дөньяда. Әгәр дә аның йөрәге астында яралган тормыш кыйпылчыгы Алексей каныннан булса.

Ул очрашудан баш тарта алмады.

Автобус тукталышка килеп житкәнче үк, тәрәзәдән күреп алды: соры халык төркеме эченнән ул буе белән дә, муенындагы керсез ак кашнесы белән дә аерылып тора иде.

Эш буенча очрашкан кешеләрдәй бик ачылып китмичә генә исәнләштеләр. Күрше паркка кереп, шәрә каеннар төбендәге эскәмиягә утырдылар. Араларында бераз урын калды, аннан салкын, дымлы жил исеп торды, күңелне гүяки салынкы болытларның авырлыгы изә иде.

—Ә син үзгәргәнсең,— диде Алексей.

Тәслимә дәшмәде. Ни дисең, үзгәргәнен үзе дә белә бит. Ә менә ул үзгәрмәгән кебек. Хәер, барыбер түгелмени.

—Минем сиңа үтенечем бар,—диде Алексей бераз тынып торгач. —

Миңа бик күп уйланырга туры килде. Бик күп. Барысын да төзәтеп була. Үлемне генә төзәтү мөмкин түгел. Әгәр ул исән булса, әгәр терелтеп булса, һәммәсен төзәтеп булыр иде. Барма син, Тася, Төркиягә. Базар тирәләрендә йөрмә. Мин бер генә бардым. Башка ул юлга чыкмаячакмын.

—Рәхмәт киңәшенә,—диде Тәслимә читкә карап.—Ләкин мин бармый кала алмыйм.

—Бер-береңнең кадерен белергә кирәк исән чакта. Бер-береңянындарак булырга кирәк. Ахырдан үкенәсең, соң була.

—Кызганыч, теге чакта әйтмәдең. Шул чакта, беренче күргәч үк, үгетләп, Казан аэропортыннан кире кайтарып җибәргән булсаң...

—Тыңлаган булыр идеңме?

—Син теге чакта Петрозаводскига бардыңмы?—дип сүзне икенчегә борды Тәслимә.

—Бардым. Ике олы сумка дару алып кайттым. Һәммәсен кулландык.

—Шарлатаннар үлем хәлендә яткан кешеләрне дә талау җаен табалар, ә? Дарулары кыйммәттер әле.

—Ә мин аларга рәнҗемим. Врачлар алдан ук әйттеләр, барып йөрмә, алар мошенниклар, диделәр. Ә мин, сез нәрсә тәкъдим итәсез соң, дип сорадым. Алар чарасыз иде. Ә Петрозаводскига Ерак Көнчыгыштан килүчеләр бар хәтта. Газиз кешеләре өчен тырышалар. Ә мин үз хатыным өчен алардан кимрәк тырышыйммыни? Мин ана өмет чаткысы алып кайттым. Беразга гына булса да юаныч бирдем. Шуна күрә син "шарлатан" дигән кешеләрне гаепләмим. Рәхмәт кенә әйтәм.

Тәслимә башын иеп тыңлап утырды. Нинди сәер бу дөнья! Берәү, башкаларның бәхетсезлегеннән файдаланып, алдап-йолдап акча җыеп яткан аферистларга рәхмәт укый, ә үзе икенче берәүнең тормышын җимереп ташлаганын сизми дә. Ә бәлки, әйтергәдер? Хәер, хатын-кызның мондый хәлен ир заты аңлыймы? Син генә түгел, барыгызда да бер хәл, аннан котылу проблема түгел, дип кенә җибәрер. Инде килеп, аңласа да, кызганса да, аннан ни файда? Тәслимә аның үзенә орынып башыннан сыйпавын теләми. Теләми!

Телефоннан сөйләшкәндә бер-берсенә якынрак кебекләр иде. Күзгә-күз очрашкач, араларында упкын тирәнлеге аерымачык күренде. Алар бер-берсен юата да алмыйлар иде.

* * *

Сөләйман патшаның балдагында иң бөек хакыйкатьне аңлаткан сүзләр язып куелган, имеш. "Бар да үтә. Монысы да үтәр". Ләкин Тәслимә өчен үтмәде. Дөрес булып чыкмады Сөләйман патшаның гакыллы сүзләре. Алексей да шундыйрак сүзләр әйткән иде бит: "Исән чакта, барысын да төзәтеп була",—дигән иде. Шулайдыр. Төзәтеп буладыр. Әгәр исән-сау булсаң. Ләкин Тәслимә исән-сау түгел иде шул. Миллионлаган хатыннарның башыннан кичкән хәлләр, миллион кешеләрне чирләткән кизү кебек: берәүләр терелә дә оныта, бик сирәкләре үлеп китә, ә кайсылары имгәнеп кала. Тәслимә дә менә шундый кайсыларыннан. Ул эчтән имгәнеп калды.

Ул бит совет чорында үскән кеше. Күбрәк сәхнә түрендә әйләнде, тормышның караңгы якларын күрергә туры килмәде: студент чакта ук Инсаф белән танышты, өч ел очрашып йөрделәр дә өйләнештеләр. Башка егетләр белән мавыгырга вакыты булмады. Шулай итеп, балачактан булдырылган таза үзәге тормыш итә башлагач ныгыган гына иде.

Хәзер ул менә шушы үзәге сынганны белә.. Моны сиздермәс өчен ул битлек кияргә, икейөзләнергә мәҗбүр. Тик синең битлегеңне читләр чын йөзең дип кабул итсә дә, гомер иткән парыңны алдап булмый.

Баштанаяк эш-мәшәкатькә күмелергә тырышты Тәслимә. Лена ярдәмендә "Ашкын"ны сатты. Акчасы салымнар түләргә дә, Солтаниягә эш хакы бирергә дә җитте. Хәтта бераз үзенә дә калды. Иренә белдерми

генә йөгеннән котылды. Юлларны ярата башлады ул. Бетмәс тынгысызлык, үзгәреп торган мохит, очраклы танышлар, алар белән эч бушатып алулар —һәммәсе хәрәкәткә мәҗбүр итә, бәгырь үзәгендә көйрәгән утлы кисәүне сүрелдереп тора, ардырып, хәлдән тайдырып, төннәрен изрәтеп йоклата иде.

Акча кайгысы бетте. Рәсимә — аэробикага, Самат каратэга йөриләр. Түгәрәк өчен күпме кирәк—түлиләр, спорт костюмнарынын бүтәннәрдә югын кияләр. Инсаф каршы килүгә карамастан, Тәслимә өйдәге ишекләрне, ванна-юынгычларны алыштыртты, йокы бүлмәсенә яна жиһаз алып куйды. Квартирны алыштырырга план кора башлады. Әмма мона Инсаф каршы иде.

Заводта да акча биргәлиләр, тик мул тормышта ул сумнарнын кайтканы-кайтмаганы сизелерлек түгел иде. Ир белән хатын бик аз, балаларга кагылышлы нәрсәләр турында гына сүз алышкалыйлар иде. Инсаф буйдак кебек яши башлады: үз киемнәрен үзе юа, ризыкны үз акчасына алып кайтырга тырыша. Зал ягындагы диванны жәеп, улы белән йоклый торган итте. Рәсимә исә әнисе янына, йокы бүлмәсенә күчте.

Тәслимә эшнең жаен алды: Төркиядән тауарны үзе сөйрәп йөрми. Андагы таныш кибетләрне рәттән йөреп кенә чыга, тегене, моны фәлән-фәлән хәтле төрегез дә озатыгыз, дип акчасын гына түли. Төрекләр үзләре самолетка төяп жибәрәләр. Йөкне Казан аэропортыннан гына барып аласы.

Әйберләрне сатар өчен базардан башта бер, аннары ике, аннары өч урын алырга, сатучылар ялларга кирәк булды. Иртә белән аларга тауарны таратырга, кичкә таба жыеп алырга кирәк. Баштарак машина яллап эш итте Тәслимә, ләкин санап карагач, үз машинаң белән йөрү арзанракка төшәсен аңлады. Күнел түрендә ул, Инсаф машина ярата, шул уңайдан араны төзәтеп булмасмы, дип өметләнгән иде. Ләкин Инсаф хатын акчасына алган машинада йөрергә дә, сату эшләрендә аның ялчысы булырга да теләмәде. Горур иде, чын ир иде чөнки.

—Синең акча, син ал,—гына диде.

Ярый ла дөнья жилләре бөдрә чәчеңне тарап, башың сыйпап кына исә торган булса. Кайчак давыллары, туфаннары куба шул аның. Андыйлары сыгылмаганны сындыра. Инсаф моны аңлый алмады, бөгелергә теләмәде. Төз каласы килде. Әмма кесәң такыр булганда, бай хатынын янында тураеп калкынып торып буламы?

Ә менә Тәслимә исә мал табарга остарганнан остара барды. Аның кул астында өч сатучы эшли иде инде—берсе элекке медсестра, берсе укытучы, берсе инженер. Инде килеп машина алырга ниятләгәч, шофер кирәк булды. Анысын табарга сатучы-медсестра Гөлнар ярдәм итте.

Тәслимә әйбер-кара сакларга шәһәр үзәгендәге иске бер йортның аскы катында арендага бүлмә алган иде. Шофер белән шунда, базардан әйберләрне алып кайтып урнаштырганнан соң, очрашырга булдылар.

Көн кичкә авышып килә, бүлмәнең жир белән тигез кечкенә тәрәзәсеннән төшкән яктылык бик чамалы иде. Шунлыктан, күрәсең, ишектән килеп кергән егет бик яшь күренде. Юк икән, егерме жидесен тутырган икән инде. Альмир, почмакка караган килеш, кыюсыз гына үзе турында сөйләде. Арча районында туып үскән. Армиягә киткәнче үк шоферлыкка укыган, жиңел машиналарда эшләгән. Хәзерге вакытта Савин бистәсендәге абыйларында яши, әлегә өйләнмәгән.

Егетне эшкә алганда Тәслимә аның тәжрибәсе булуын, абыйсының ишегалдында машинаны тоту мөмкинлеген, Савин бистәсенең үз өенә якынлыгын исәпкә алды—трамвайда нибары бер тукталыш, кирәк чакта йөгереп барып житәргә була. Ә калганы... кешенең кемлеген бер күрүдә белеп буламыни?

Беренче көннәрдә үк, базарда машина сайлап алганда, ГАИ юлларында йөргәндә , тиз якынаеп киттеләр. Мона бер кызык әйбер—ак төлке койрыгы

да сәбәп булды. Хикмәт шунда, машина алу белән, алдагы кечкенә көзге астына озын, йөнтәс койрык асып куйды шофер һәм, сез ничек карарсыз икән, дигән кебек, аксыл кашы астыннан Тәслимәгә балаларча шаян елмаеп карады. Соңыннан анлашылды: егет Себердә хезмәт иткән, шунда ауга йөргәләгән, аучылар белән дуслашкан һәм истәлеккә Себер төлкесенең койрыгын алып кайткан. "Бөти урынына, афәттән сакларга",—диде ул. Машинага койрык асып йөргәнне монарчы күргәне юк иде Тәслимәнең, алай да каршы әйтмәде. Шулай итеп, аларның ике арасында койрык болганып йөри торган булды. Игътибарны җәлеп итә иде бу, нәрсәгәдер ишарә кебек тә иде. Тик моны анлап җиткермәде Тәслимә.

Базарда, ГАИ да бу икәүне, табигый, ирле-хатынлы дип кабул иттеләр. Егетнең ак йөзе баштарак алланып чыга, Тәслимә дә читенсенә иде, әмма тора-бара моны шаяруга сабыштыра торган булдылар.. Бәхеткә, егет бик житез, хәрәкәтчән икән. Тиз арада эшнең күбесен үзе генә башкарып чыга торган булды. Иртән сигезгә Тәслимәнең өе янына килә, бергәләп складка баралар. Тауарны исә шофер базарга үзе генә илтә, кич үзе алып кайта.

Язгы көн кичкә авышып килә иде. Альмир базардан әйберләрне алып кайтып, складка ташыды да чыгып китте. Тәслимә өстәле янына утырып, иртәгә кайсы сатучыга нәрсә чыгарырга икәнен язарга тотынды. Шул чакта ачык тәрәзәдән бер ир-атның:

—Альмир, кил әле!—дип кычкырганы ишетелде. Тәслимә күтәрелеп тәрәзәгә карады. Һәм сулышы киселеп киткәндәй булды. Тәрәзә турыннан Альмир узып бара иде. Ул аякларын аерып, җиргә ничектер рәхәт итеп, һәр адымыннан тәм табып атлый, ак йөзендә елмаю балкый. Бөтен йөреш-торышыннан, һәр хәрәкәтеннән самимилек, эчкерсезлек, гамьсезлек агыла иде. Аның өчен җирдә яшәү, сулау, атлау, көлү, сөйләшү генә дә үзе зур бәхет кебек иде. Аның сыгылмалы, ваемсыз хәрәкәтләре кыргый җәнлек балаларын, аларның тук чагын, кояшлы аланда шукланып шаярганын хәтерләтте. Күптән инде җан тынычлыгы белмәгән Тәслимәгә бу күренеш нык тәэсир итте. Кызыктырды, сокландырды.

Ул ишегалдына чыкканда егет машинаның тәрәзәсен сөртеп азаплана иде.

—Альмир!

—Ә-ә-ү-ү!—диде ул сузып һәм тураеп Тәслимәгә елмайды. Аның тавышында куаныч, күнел күтәренкелеге янгырады, күзләреннән наз бөркелде. Тәслимәгә күптән, бик күптән инде мондый иркә тавыш белән, аны күрүгә чын күнелдән сөенеп, иркәләп "ә-ә-ү-ү" дип дәшкәннәре юк иде. Кечкенә чакта әнисе шулай җавап бирә торган иде. Күнеленә бәреп кергән назлы дулкыннан сүзсез калды Тәслимә. Һәм Альмирнын сөрмәле күзләрендә соклану, якын итү,чакыру күргәндәй булды. Алар буйга бер чама, күзләренә туры караган хәлдә шактый тордылар бугай. Болай ярамый иде, яхшы түгел иде, Тәслимә ашыгып машинага кереп утырды.

Бу вәсвәсәдән үз вакытында котылырга кирәклеген белми идемени ул? Белми димени, анламый димени. Эштән куарга кирәк шоферны. Тик бу Тәслимәнен көченнән килмәде. Бу егет аның кара төнгә әверелгән күнел түрендә тулган ай булып күтәрелә башлаган иде шул инде. Ул үзен шул айның яктысыннан, "ә-ә-ү-ү!" дигән сүзне ишетүдән, егетнең ак йөзе белән балкып: "Рәхәт сезнең белән, Тәслимә апа-ай!"—дигәнен тынлаудан мәхрүм итә алмады. Үзе дә теләмәстән, аның белән машинада күбрәк йөрергә сылтау эзли башлады..

Хәер, жаен эзлисе дә юк, андый чакта ул үзе килеп чыга. Складта сатылмый калган әйбер-кара шактый күп җыелды. Кием-салымның модасы тиз уза, вакытында котылмасаң, аннары алмыйлар.Тәслимә танышлары аша Азнакайдагы бер сәүдәгәр белән килешеп, анда кайткалап йөри торган итте.

Азнакайга илтә торган юллар озын, бормалы, урманлы. Май аеның дәртле яшеллегенә төренгән агачлар ешлыгыннан ак чәчәккә күмелгән шомырт агачлары сирәк-мирәк узган машиналарга сәлам биреп кала иде.

—Альмир!

—Әү-ү!

— Туктале, бер-ике сабак чәчкә өзик әле.

Машинадан төшкәч, ана иярмәде, юк, ул бөтенләй юлның икенче ягына чыгып, икенче агачларгә юнәлде. Көн салкынча, болытлы, тыныч, жанга шундый рәхәт иде. Менә Тәслимә ак чәчәк тәлгәшләре авырлыгыннан бөгелә төшкән шомырт агачы янында тора, хуш исле саф һаваны күкрәген тутырып сулый, яшь үләннең сыгылмалы йомшаклыгы аша жирнең ныклыгын тоя. Күкрәп яшәргән, биеклеккә ашкынган каеннарга, наратларга карап туя алмый... Баш очында яшәү бәхетеннән онытылып кошлар сайрый. Йә Алла, нигә кирәк үкенүләр, әрнүләр, рәнжүләр? Гомер үзе менә шушындый мизгелләрдән тора лабаса! Тәслимә дә шушы яшәешнең, табигатьнең бер кисәкчегe бит! Нигә ана да үзен бәхетле тоймаска, нигә шушы агачлар, кошлар кебек ваемсыз, тыныч, канәгать булмаска?

Юк бернинди үткән гомер! Юк киләчәк-күрәчәк! Менә шушы мизгел генә бар һәм ул гүзәл, татлы!

Машина эче шомырт исе белән тулды. Ерак юлга Тәслимә термос, азык-төлек ала, бу юлы да чәй эчтеләр. Альмир жыр ярата торган булып чыкты, бигрәк тә хәзерге яшьләр башкаруында татар жырларын. Аның күнеле булсын дип, Тәслимә кыйбатлы магнитола да алып куйган иде. Соңгы вакытта танылып киткән жырчыларның шундыйлары бар, алар турында күңел кылларын тибрәтәләр, дип әйтеп булмый. Аларның тавышы-моңы тән тамырларына бәреп керә, канны кузгата, уйната шикелле.

"Күзләремә бер каравың житә, бөтен кайгыларым югала,
Әл дә син бар әле бәхетемә, әл дә син бар әле дөньяда".

Машина эче нәни ресторан кебек, кайнар чәе, тәмле ризыгы, күнелгә хуш музыкасы, чәчәкләре—һәммәсе бар; шул ук вакытта рестораннан яхшырак, чөнки биредә ятлар юк. Альмирның сөрмәле күзләре Тәслимәгә үз итеп, сокланып карыйлар, әмма аларда бернинди бүтән ишарә юк шикелле.

Яшәешнең язгы янарышын тыелгысыз тантана белән кичергән табигатьнең саф кисәкчекләре иде алар бу минутларда.

Ул кичне Тәслимәнең исәбе Чаллыга кайтып куну иде. Азнакайда тоткарланырга туры килде, кайтыр юлга соңарып чыктылар, караңгыга калдылар. Кичкә таба яңгыр сибәли башлады. Юлдагы чокырларга су жыелган, тәрәзәләргә пычрак чәчри иде.

Урманнан чыгып житмәделәр, машина кинәт туктап калды. Үткән-сүткән күренми, кемнәндер ярдәм көтеп булмый. Альмир яңгыр астына чыкты да, капотны ачып, кечкенә лампочка яктысында казынырга тотынды. Шунда Тәслимәнең күңел түрендә: "Төзәтә алмаса ярар иде..."—дигән теләк туды. Һәм бу уеннан сискәнеп китте. Юк-юк, алай була күрмәсен, монда, яңгыр астында, машина эчендәге кысанлыкта икәүдән-икәү төн уздырырга туры килсә... Юк, бу мөмкин түгел!.. Тәслимә коты очып курыкты һәм шушы каршылыклы теләкләр бәрелешеннән бер янып, бер туңып, хәлен юлдашына сиздермәскә тырышып, тынын да чыгармыйча көтте дә көтте. Ә Альмир бер капот астында казынып, бер эчтән машинасын кабызырга маташып, озак азапланды. Менә, ниһаять, кереп утырды, тирән көрсенеп: "Булмый,—диде. —Су кергән. Кипкәнен көтәргә кирәк".—"Озакмы?"—"Кем белә, бәлки, бер сәгать, бәлки берничә сәгать". Егетнең тавышы карлыгып киткән иде. Туңганнандыр. Тәслимә аның иненә орынды—курткасы манма су. "Кайнар чәй эчеп куйсаң, комачауламас иде. Шактый нык үтте бу яңгыр..."—диде егет. Тавышында эчтән калтырану сизелде. Ләкин термос буш, Чаллыга нибары ике генә сәгатьлек юл, шуңа күрә Тәслимә Азнакайда чәйнең яңасын салып тормаган иде. "Суык тимәсен тагын,—диде ул. Һәм багажнигында аракы барын исенә төшерде.—Әнә, бер илле грамм аракы йотсаң гына. Сагыз бар, исен бетерер..." Берaз ык-мык килде егет, ялындыргандай итте. Әмма ахырда килешми булдыра алмады.

Суынып өлгергән машина эчендә, караңгыда ыгы-зыгы китте. Кирәк әйберләр багажникта иде—арткы утыргычка күчеп утырырга туры килде. Альмир курткасын салып, җәймәгә төренде. Шешәне табарга, капшанып стаканга салырга... Бер-берсенә ихтыярсыздан орындылар—егетнең бармаклары боздай, ә Тәслимәнең куллары кайнар иде.

"Үзем генә эчмим",—диде егет. "Мин яратмыйм".—Ә мин яраткан-нан эчәмме? Сез бер йотмасагыз, эчмим",—диде ул иркәләнеп. Киек жанварларда гына була торган табигый сизгерлеге белән Тәслимәнен күңел йомшаклыгын тоеп алган иде инде.

Әйе, бу юлы аракыны Тәслимәнең авызына көчләп коярга туры килмәде—үзе эчте. Күңеле нык алгысаган иде, шуны басарга теләпме, үзе куйган чиктән—бер йотымнан арттырыбрак та җибәрде.

Хәмер пары акылны томалады. Калганын табигать үзе эшләде. Ул фәкать буйсынды гына, каршы гына тора алмады. Егет мондый очракта да житез, хәрәкәтчән, көчле булып чыкты. Берәү туңган иде, икенчене тәне кайнар иде. Берәүне жылытырга кирәк иде, икенченең жылытасы килде. Тәслимәнең зиһенендә фәкать: "Без табигать балалары бит, табигать балалары",—дигән сүзләр генә кабатланды. Бу сүзләрне беренче тапкыр кемнән ишеткәнен ул инде хәтерләми, фәкать алар бу минутта аны аклый иде шикелле.

Бераздан егет алга сузылып, бардачокны ачты да, тәмәке алып, көйрәтеп җибәрде. Шул хәтле рәхәт итеп, тавышланып суырды, иркенәеп, башын артка ташлап утырды ки, Тәслимә кызыгып куйды.

—Бир әле миңа да,—диде.

—Бәй. Ник аны әллә кайчан әйтмисең? Мә суыр, мондый чакта бигрәк тәмле.

Тәслимә суырды. Машина судагы көймә кебек тирбәлә башлаган кебек булды, ә каршыда, болытлы төннең чак сизелерлек аксыллыгында, кап-кара булып төлке койрыгы болгана иде.

* * *

Шул юлдан әйләнеп кайтканнан соң мөнәсәбәтләр нык үзгәрде. Тәслимә бу белемсез, гамьсез егеткә нык бәйле булып калганын тиз сизде. Альмирның елмаюында инде беркатлы соклану гына түгел, түбәнсетү дә сизелә, "әү-ү!" дип дәшкән тавышында назлау гына түгел, баласыту да ишетелә иде. Ул машина эчендә җәелебрәк утыра, иртәнге якта соңаргалап та килә, сорап-нитеп тормыйча, машина белән авылга китеп бара иде. Машинага хикмәтле фаралар, япмалар, шампуньнар—кәттә егетләр телендә "прибамбасы" дип атала торган күп нәрсәләр алынды. Тәслимә ул сораган акчаны бирми кала алмый иде, өстәвенә егет әле авылга кучтәнәчкә, әле яна курткага акча сорап тора, ай ахырында эш хакын санаганда, аларны басып калып булмый, чөнки ул чакта шофер бөтенләй получкасыз калачак иде.

Тәслимә үзенең томана, зәвыксыз бер бәндә тозагына эләккәнен акылы белән аңлый иде инде, ләкин бу мөнәсәбәтләрне өзәргә үз-үзенә мең тапкыр ант итсә дә, Альмир учын аның тезенә куюга эреп төшә, зиһене чуала, ул ни дисә шуңа буйсына иде. Назга сусаган, кайнар, гөнаһлы тәне акылга буйсынмый, үз ихтыяры белән йөртә иде аны. Табигать баласы иде шул ул!

Бу хурлыклы бәйләныш күпмегә сузылган булыр иде, бер вакыйга чик куйды.

Дүшәмбедә базарлар эшләми, сатучылар ял итә. Шундый бер көнне районнан бер эшмәкәр килеп төште дә Тәслимәгә шылтыратты. Яшь, уңган бу егет Ләззәт исемле икән, кибетләре, складлары, рестораны бар. Казанда да тамыр җибәрергә омтыла. Кемдер Тәслимәне тәкъдим иткән. Складта очрашырга килештеләр.

Икесе дә шактый кыйналган, дөньяның рәтен беләләр, бухгалтерияне аңлыйлар икән. Эш кешеләре буларак, бер-берсен тиз аңладылар, ошатып киттеләр хәтта.

Шулай көлешә-көлешә сөйләшеп утыралар иде, кинәт ишек ачылып Альмир килеп керде.

Мондый очрашуларны спектакльләрдә "сүзсез күренеш" дип атыйлар. Менә алар өчәү бер-берсенә карап калдылар. Альмир сәлам дә бирмәде бугай, һәрхәлдә Тәслимә колаклары чыңлавы аша аның тавышын ишетмәде.

Ләззәт сүзне тизрәк төгәлләп чыгып китәргә ашыга, шуна күрә вакытсыз килеп кергән кешегә сабырсыз, канәгатьсез караш белән текәлде. Тәслимәнен исә күнел төбендә көйрәгән ризасызлыгы йөзенә бәреп чыкты, анда горурлык хисе уянды: ничек әле бу манка малай ана хужа була алды? Кем ул? Нишләп ул үз урынын, Тәслимәнен ялчысы гына икәнен, анын кулыннан ашаганын оныта?

Әйе, надан иде Альмир, ләкин анда табигать биргән кыргый җәнлек сиземләве көчле иде. Ул һәммәсен анлады, бәлки әле артыгын да уйлагандыр. Юка иреннәре күгәреп чыкты, йөзенә көл төсе керде, күз бәбәкләре кара бәрхет төсен алды.

—Ни булды?—дип сорады Тәслимә коры гына. Ул егетләрне таныштырмады, бу үзе үк шоферны читләтү, аны урынына— хезмәтче итеп кую иде. Ә хезмәтчеләр берәр тапкыр хужа белән үзен тин итеп хис кылса, кире үз урыннарына төшергәнне беркайчан гафу итми. Аларнын үче ачы була.

—Машинанын радиаторыннан су ага,—диде Альмир төксе генә. Ләззәт сораштырып алды: нинди радиатор, кай жире тишелгән. Төбендәге краны пластмассадан ясалган икән. Шул ярылган.

—Аны ямап булмый,—диде Ләззәт.—Яна радиатор алырга кирәк..

Башка чакта андый кыйбатлы запчастьләрне базардан икәү барып алалар иде. Әмма бу юлы Тәслимә сумкасыннан акча алды да Альмирга сузды. Ләззәт алдында үз дәрәҗәсен саклау өчен, сөяркәсенә беренче мәртәбә үзенен өстенлеген, аннан бәйсезлеген сиздерү өчен шулай кирәк, дип санады.

...Сишәмбе көн иртән Альмир аны алырга килмәде. Савиндагы туганнары, авылга китте, әле килеп житмәде, диделәр. Чәршәмбедә дә машина ялларга мәжбүр булды Тәслимә. Ике көн узгач, иртән складка килүенә, урам себерүче хатын:

—Шоферыгыз килгән иде, мин эштән китәм, эзләп йөрмәсен, дип әйтергә кушты,—дип Тәслимәгә машинанын ачкычын һәм документларын тапшырды.

"Жигули" ишегалдында тора иде. Тәслимә аны чак таныды. Машина пычракка баткан, тәгәрмәчләре алыштырылган, кайсыберләренен, бүсере чыккандай, эчтәге резинасы бүлтәеп тора, кыйммәтле магнитола да, затлы япмалар да, термос та, сумка да, чит илдә эшләнгән инструментлар тартмасы да—барлык "прибамбас"лар, хәтта машина алдында акаеп торган сары фаралар да юк иде. Фәкать алгы көзгегә эленгән төлке койрыгы гына асылынып тора, ни сәбәптәндер аны алмаган иде Альмир.

Беренче омтылыш, тизрәк машина яллап авылга бару, анлашырга, анлатырга тырышу, ничек кенә булса да Альмирны кире кайтару иде. Тәслимә, әлбәттә, шулай эшләячәк иде. Егетнен табигать баласы икәнен анлый бит ул, дәртен кузгата белә, ихтыярын сындыра ала. Минутлык үпкәләвен генә оныттыра ала!.. Очрашырга, орынырга гына кирәк!

Башка берәүнен машинасы белән базарда сатучыларга тауар өләшкәндә, ул һаман шуны уйлады, егетнен үпкәле йөзенә ничек карасын, нинди сүзләр әйтәсен күз алдына китерде, анын назлы кулларына орынасын уйлап, тәне кызышты.

Тәслимә югында әйберләрне складка Гөлнар кайтара торган иде. Бу юлы да ана сүз кушты Тәслимә.

—Ярар,—диде Гөлнар.—Тик мин үзем дә иртәгә сорап китмәкче идем әле. Авылга кайтып киләсе бар. Чәкчәк пешерергә чакыралар. Туйга әзерләнәбез бит.

—Кемегез өйләнә? Әллә берәрсен кияүгә бирәсезме?

—Альмир әйтмәдемени? Якшәмбедә туйлары була бит!—Тәслимәнен йөзе үзгәрде, ахрысы, Гөлнар керфеген дә какмый текәлеп карады.—Эштән ник китәм, диде сон? Ну бу яшьләр, бигрәк мәнсез! Мәнсез булмасалар, бу көнгә кадәр сузмаслар да иде инде. Кәләшнен корсагы борынына терәлергә тора, туй күлмәге киярга оят... Авылга кайтсам, елап килә, аптыраткан иде инде. Жаным тынар ичмасам...

Ә нәрсә көткән иде Тәслимә? Ни өмет иткән иде? Ул табигать баласы булганны, башкалар табигать балалары түгелме әллә?

—Машинада койрыгын онытып киткән,—диде.—Кайтарып бир, эзләп килмәсен.

* * *

Андый очракларда "яхшылык теләүчеләр" табылып тора, Инсафка хатынының "мәхәббәт кыйссасы" барып иреште, билгеле. Әмма ире бу хакта сүз кузгатуга, Тәслимә иренең авызын томалады:

—Сина барыбер түгелмени? Асылда без аерылышкан бит инде. Судка бир әнә, хатыным хыянәт итте, дисәң, шундук аералар.. Квартир өчен борчылма, мин сина бер бүлмәлене алып бирермен.

Соңгысын Инсаф бик зур мыскыллау дип кабул итте.

—Минем квартирым бар,—дип кырт кисте ул. Әйе, квартирны завод аңа биргән иде шул.

Тәслимәгә аерылу кәгазе нигә, бу арада гына кияүгә чыгасы юк. Инсафның исә балалар белән бергә буласы килә, шуңа күрә аерылышырга ашыкмый, чыгып китәргә уйламый иде.

Алар шулай, икесе бер елгада, икесе ике ятьмәгә эләккән балыклар кебек, бер бәргәләнеп, бер хәлдән таеп, яши бирделәр. Инсаф яңа заманны аңлый алмады, кабул итмәде. Хатынының кәсебен ул "спекуляция" дип кенә белә, алып кайткан акчасын, малын хәрәмгә саный һәм аны ашауны үзе өчен гөнаһ дип исәпли иде. Хәтта үз хатынына сатылырга да сәләтсез булып чыкты ул. Заманында Совет иле башка мәмләкәтләрдән "тимер пәрдә" белән капланып яшәгән булса, ул пәрдә череп коелгач, Инсаф кебекләр дүрт якны кыйбла ясаган яңа заманнан үзләрен аерып куйдылар, гүяки тимер ятьмәгә төренгәндәй булдылар.

Ә Тәслимә исә үзенә аерым ятьмәгә кереп уралган иде. Тик ятьмәсе башка—алтыннан иде аның. Мөмкинлек булса да, аннан чыкмаячак, элекке эшенә кире кайтмаячак иде инде, жан асрарлык хезмәт хакына биеп йөрергә риза булмаячак иде. Чөнки акчаны санамый туздырырга, ялланган шофер белән машинада үзе теләгәнчә йөрергә, берничә кешенең—сатучыларның гына булса да язмышын кулында тотарга күнеккән иде ул, ә мондый гадәтләрдән бизү бик авыр, күпләр өчен мөмкин түгел хәтта.

Көн саен ул базарны әйләнеп, тауарларны карап, хакларын белешеп чыга. Ларекларда элекке укытучылар, галимнәр, экономистлар, инженерлар, офицер хатыннары әйбер сата. Ниләр кичергәннәр, ниләр уйлыйлар—Алла белә. Күбесе тәмәке тартырга өйрәнгән, бәгъзеләренең салып алганы да сизелә. Салкын вакытларда бигрәк тә. Эсседә дә, суыкта да, янгырда да, жилдә дә котсыз тар куышларда, чүпрәк-чапрак, вак-төяк арасында кысылып басып торалар шулай. Арада карты-яше, чибәре-ямьсезе бар, әмма йөзләрендәге яшерен сагыш, монсу уйчанлык, эчке бер сызлану барысын бертөсле итә. Озаграк монда эшләгәннәре больница юлын таптарга керешә—салкын тиюдән, аяклары шешүдән зарлана.

Баштарак Тәслимә сатучыларны кызгана, күбрәк түләргә тырыша иде. Ләкин аларны һаман кызганса, үзенең кызганыч хәлгә каласын аңлады. Хәзер башкалар белән бер чама—жан асрарлык кына бирә. Чөнки акча үзенә бик кирәк—шәһәр уртасында зур кибет ачу турында хыяллана ул.

Эше бик тыгыз, тын алырга да вакыты юк, башы саннар, товарлар, планнар, хәйләләр белән тулы Тәслимәнең.

Барысы да әйбәт. Төннәрен генә нигәдер бәгырьне сагыш талый. Яшьли сөйгән ярының татлы сулышыннан эрегән чаклары исенә төшә. Нурга күмелгән сәхнә, биюче балалар төшенә кереп, үзәген өзә.



# Фәрит Габдерәхим

## МИРАСЫМ БАР

—Әллә соң син гөнаһларың өчен
Юлыктыңмы каһәр-җәзага.
«Халкым!» дисең гелән—аңа атап
Күпме мөмкин шигырь язарга?!

—Татар кебек тоташ җәберләнгән
Халыкларның, әйтче, кайсысы?!
Юк, аз язам: мең шигырьгә сыймас
Фаҗигасе аның, кайгысы.

## Ә шулай да...

Шигырьләрем... Утырамын барлап:
Шифалысы бармы сүзләремнең?
Минем якты теләкләргә карап,
Якты якка дөнья үзгәрдеме?

Үзгәрмәде... Сүзләремнән минем
Төннәребез әйләнмәде көнгә.
Ә шулай да, шөкер әле, димен,
Көннәребез әйләнмәде төнгә.

---

Фәрит ГАБДЕРӘХИМ (*1930*) — *Башкортстанда яшәүче татар шагыйре. Башкорт һәм татар телләрендә дистәгә якын китап авторы.*

Динамитсыз сүзләр... Исән әнә
Бу дөньяның сират күперләре.
Үлгәннәрне терелтмәде—әмма
Исәннәрне сүзем үтермәде.

## Яшиселәр килә

Никтер мине егерменче гасыр
Бигрәкләр дә инде яратты:
Ташлап китмәсен дип, өзгәләде
Җилкәннәрен минем корабның...

Яшермимен: җибәрмәскә теләп,
Хәмер күлләренә чумдырды.
Кышкы чилләләрдә яндырды да
Җәйге чилләләрдә туңдырды.

Куштаннары мактый: «Иң шәп гасыр!»
Нинди көләч, имеш, битлеге.
Сандугачлар хәтта көнләшерлек:
Саф алтыннан, имеш, читлеге.

Чибәрләрнең кочагына салды,
Кочаклары кайнар—түз генә!
Йә булмаса тупларыннан атты,
Калдырмакчы булып үзендә.

Егерме бер—явыз гасыр, имеш,
Мондый гасыр килә меңгә бер.
Газраилгә ришвәт биреп карый,
Ә тегесе алмый нигәдер.

Упмак булган, йотмак булган иде
Егерменче гасыр кабере,
Саклап калды—бу гасырга мине
Алып чыкты Тәңрем әмере.

Битлекләре, алтын читлекләре—
Егермедә калсын барсы да.
Яшиселәр килә битлекләрсез,
Читлекләрсез Яңа гасырда.

## Мирасым бар

Кем калдыра мирас итеп
Тиенләп җыйган акчасын,
Кем калдыра машинасын,
Кем калдыра йорт-дачасын.

Мин ни-нәрсә калдырырмын?!
Юк акчам да, машинам да.
Арбам бар иде—ватылды
Коммун йөге ташыганда.

Мирасым бар! Бар мирасым!
Үзем белән китмәм алып.
Әрәм-шәрәм булмас микән,
Кадерсез кулларга калып?!

Мирас итәм каргышларын
Безнең аутан кальгаларның;
Халкым түккән күз яшенең
Түләнмичә калганнарын.

Мирас итәм милләтемнең
Җавап көткән сорауларын;
Өзелмәгән зынҗырларын—
Ватылмаган богауларын.

Уйлап ятам төннәр буе,
Тынгы бирми ошбу уем:
Бу мирасны үз итәрме,
Баш тартмасмы туар буын?

## Кемнеке

Кемнеке бу Заман?
Дәшми—көлә Яман.
Кемнең таңы атты?
Кара япты акны.
Мәхбүс милләтләрнең
Көн-төн каны акты.
Җәллад күкрәгенә
Янә калай такты.
Яман үз-үзенә
Бирде иң зур хакны.
Кинме, тармы Заман?
Яманга тап-таман.

## Сукбай эт белән сөйләшү

Кил әле, кил—ял итик бер, дускай!
Очрашулар безнең сирәк бит.
Чолгауларны юып элдем әнә,
Сиңа рәхәт: чолгау кирәкми.

Син иркле! Шуны гына әйтим,
Сөйләп тормыйм әле башкасын:
Син бит миннән мең кат бәхетлерәк:
Чылбырларын өзеп качкансың.

Үз иркеңдә—йоклау-йокламаулар,
Үз иркеңдә—өрмәү-өрүләр.
Бәйрәм бит ул иркен далаларда
Үз ишләрең белән йөрүләр.

Чү! Кем килә? Эт аулаучы—җәллад!
Өрмә, сукбай, өрмә—түз инде.
Пос артыма тизрәк! Богауланган
Җаным белән каплыйм үзеңне...

## Ничек күчим?!

Өзгәләнә нәни кошчык:
Давыл йоткан оясын.
Синекедәй сызлый җаным,
Җанны кая куясы?

Җиде ятлар ят чанада
Алып китте аръякка.
Ничек күчим «тройка»дан
Үзебезнең «пар ат»ка?!

## Гаҗиз калдык

Гомер буе читтә яшәде ул,
Юк язмыштан узмыш—нишлисең.
Дәрәҗәләр, даннар яуласа да,
Булып калды авыл кешесе.

«Авыл зиратында җирләгез» дип
Васыятендә язган сүзеннән
Гаҗиз калдык: үлгән икән авылы
Алданрак аның үзеннән.

*Зәки Зәйнуллага*

Зәкиләр күп. Мин шуларның
Дүртесен әйбәт беләм.
Бер-берсенә охшаганнар
Буй-сын вә холык белән.

Дүртесе дә туры сүзле,
Битлек-мазар кимиләр.
Зилзиләләр купканда да
Горур башны имиләр.

Беренчесе—фән докторы,
Икенчесе—полковник.
Өченчесе—шәп язучы,
Рәхәтләнеп мактарлык.

Дүртенчесе—милләтпәрвәр,
Татар өчен җан атар;
Татарыма ирек даулап
Көрәшүче чын татар.

Нинди киртә корсалар да,
Китмәс алар борылып.
...Дүртәү түгел, Зәки—берәү,
Әмма дүрткә торырлык!



**Ркаил Зәйдулла**

# ХАН ҺӘМ ШАГЫЙРЬ

ТАРИХИ РИВАЯТЬ

**Катнашалар:**

Хан
Шагыйрь
Ханикә—ханның хатыны
Тогай-Туглы—ханның әнисе
Карачы
Казый
Диван бәге
Саружа
Танышбәк
Асук—дәрвиш шагыйрь
Әндри, Ибан—ярлык алырга йөрүче урыслар
Кызлар, шагыйрьләр, хезмәтчеләр, урыслар, ике шыгаул.

## Беренче бүлек

**Алтын таш—хан сарае. Келәмнәр эленгән диварлар кырындагы көрсиләргә асылташлар тулы алтын-көмеш табаклар куелган. Бүлмә уртасында тәхеттә Бирдебәк хан утыра. Янәшәдә алтын агач, аңа төрле җимешләр рәвешендә асылташлар эленгән. Зур ишекнең ике ягында ялангач кылыч тоткан шыгауллар басып тора. Ханның каршысында—олуг карачы.**

---

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА *(1962)—шагыйрь, прозаик, публицист. «Урыс кышын озату», «Ил» һ.б. китаплар авторы. Драма әсәрләре дә яза. Казанда яши.*

Хан. Йә, олысларга атчабарлар жибәрдеңме? Нинди хәбәрләр бар?

Карачы. Киләсе ай башына чирү жыелып бетәчәк, тәкъсир.

Хан. Хуп. Бөтен чирү белән ябырылсак, без илханның нөгәрләрен сытып үтәрбез. Кем биләмәсенә үрелгәнен белсен! Каф тавы артын Чыңгыз бабай Жучи оланнарына бүлеп биргән.

Карачы. Хак сүз, солтаным.

Хан. Мин анда калгай булып торганда Һулагу әнчекләре борын сузарга да өркеп торалар иде. Атам Жанибәкнең каты авырганын ишеткәч, Сарайга ашыктым шул. Аның фатихасын алмый калырмын дип курыктым. Ширванда минем алтын жеп белән тегелгән, зөбәржәтләр белән бизәлгән халатым калды!

Карачы. Без аны сатлык әмирдән әллә ничә мәртәбә сораттык. Илчеләрнең йөзенә карап көлгән.

Хан. Мөртәт! Елыйсы көннәре алда әле.

Карачы. Синең халатны киеп тәхеттә утыра икән.

Хан. Аһ, эттән туган. Тузанын коярмын мин ул сасыкның. Ат койрыгына тактырырмын *(тәхеттән ук сикереп тора)* Ширванга! Ширванга!

Карачы. Бәкләр башта Арранны алырга кирәк диләр. Шул чагында гына Ширванны чолгап алырга жайлы булыр.

Хан. Юк! Башта Ширванга! Анда минем алтын халатым!

Карачы. Арранны алгач, без Ширван әмиренең чигенер юлын кисәчәкбез. Алтын халат бездән качмас. Аннары Арран бик бай бит. Затлы келәмнәр, коллар, кәнизәкләр, бихисап алтын-көмеш. Бәкләр яуга ыргыла, тәкъсир. Тик менә...

Хан. Нәрсә? Әйт сүзеңне!

Карачы. Болгар әмире икелемикеле жавап биргән. Аның калаларына урыс ушкуйниклары һөжүм итә икән. Гаскәремне яуга алып китсәм, алар илемне харап итәчәкләр, диеп әйтә ди.

Хан. Шул урыс-улактан куркып яудан баш тартамы? Сыныкка сылтау таба. Арт санын кузгата алмый торса, дар агачы аны тиз жинеләйтер.

Карачы. Ушкуйникларның да тәмам ояты качты, тәкъсир.

Хан. Урыс кенәзенә хәбәр жибәр: угрыларын тыймаса, баскагымны көтсен. Мономах бүрегенә солы тутырып кирмән тышына чыга торсын, баскакның аты озын сәфәрдә ачыккан булыр...

Карачы. Житкерермен, тәкъсир. Тик урыс кенәзе бик каты авырып ята, диләр. Әжәле житә, күрәсең. Шуңа ул үз угрыларын тыя алмый да...

Хан. Алар бит үз жирләрен таламый. Болгарга киләләр. Ираннан кайткач, мин аларны да акылга утыртырмын.

Карачы. Син безнең ышанычыбыз, солтаным. Жанибәк хан үлгәннән соң караңгылык баскан күнелебездә син йолдыз булып кабындың. Чыңгыздан соң мондый ханны йорт күрмәгән иде әле.

Хан. Авызыңа бал да май *(тәхеткә утыра)*. Ханның урыны—ат өстендә.

Карачы. Чыңгыз ханның буынчы дөнья өстендә озак жилфердәр.

Хан. Амин *(ике кулы белән битен сыпыра: бу—сүз тәмам дигәнне аңлата, карачы башын ия-ия арты белән чигенәчигенә чыгып китә)*. Тыштан ялагай, эчтән үзен дөнья тоткасы итеп тоя, көчек... Илханны тез чүктергәч, сезгә тотынам әле мин. Үзләре мине мактый, үзләре һаман атам Жанибәк ханны сагына. Сагынасыз икән, тиздән аның белән кавышырсыз!

**Ишек ачылып китә. Сарай эченә тавыш яңгырый:**

—Бисмиллаһи, сәййидүнә вә мәүләнә, казыйул—көззай вәл-хөккем, мобәйинул-фәтава вәл-әхкем, бисмиллаһи! Бәдретдин әс-Суари![1]

**Бер аягын авыр гына өстерәп Сарай шәһәренең казые килеп керә. Ханга баш ия, хозурына килеп йөгенмәкче булганда артына чак кына авып китми. Аннары якындагы тәбәнәк тәңгәлгә килеп утыра, дога кылырга диеп ике кулын йөзе алдына жәя.**

Хан *(тиз генә битен сыпыра да, усал елмая)*. Житәр, аксак! Соңгы вакытта бик тәкъва булып киттең әле. Әллә теге дөнья чабудан тартамы?

Казый. Иртәме-соңмы барыбыз да анда булабыз.

Хан. Алай да бик ашыкмыйсың әле. Син бит Үзбәк бабай вакытында

[1]Алла исеме белән, безнен хужабыз һәм әфәндебез, казыйларның һәм хакимнәрнең казые, дини кануннарны һәм хөкемнәрне аңлатып бирүче Алла исеме белән!

ук казый иден бугай.

Казый. Аллага шөкер, Мөхәммәд Үзбәк хан Чыңгыз йортының алтын баганасы иде. Ходай ана рәхмәтләрен әйләсен, гүрен нурлы итсен. Ул мине Сарай шәһәренә казый итте. Хөкемем гадел булды, монарчы беркемнен миннән зарланганы юк, әлхәмделилла...

Хан. Син хөкем иткәннәр зарлана алмый инде, казый. Аллаһы Тәгаләгә зарлансалар гына... Йә, сөйлә, ни йомышың бар?

Казый. Тәкъсир! Калада бер шагыйрь пәйда булган!

Хан. Бу яналыкмы? Ул дәрвишләр, суфилар, шагыйрь-шогаралар бөтен каланы басып алды инде. Кая тәкермә, берәр шагыйрьгә эләгә. Әрәмтамаклар!

Казый. Аларның төрлесе бар. Ханны, илне-көнне мактап мәдхия язалар икән, без бәясеннән тормыйбыз. Туруннарга синең турыда яхшы сүз барып җитсен. Иранда әнә илхан сараенда көтү-көтү шагыйрь асрыйлар. Ә бу—Әхмәд Болгари—Болгардан килгән бер сукбай дәрвиш, базарда төрле сүзләр сөйләп халыкны болгата. Ил белән ничек идарә итү кирәклеген сөйли.

Хан *(тәхеттән калкынып куя)*. Салкын ташка![1]

Казый. Сак астына алдык без аны.

Хан. Син мондый чакта икеләнеп тормый идең. Нигә сузасың, әйтеп бетер.

Казый. Тагын бер сәбәп бар, шуңа синең хозурга киллем, тәкъсир.

Хан. Ни?

Казый. Ул нәкъ сиңа охшаган.

Хан. Ни дисең?

Казый. Суйган да каплаган инде менә. *(Пауза)*

Хан *(көлеп җибәрә)* Ханга беркем дә охшый алмый!

Казый. Әлбәттә, күктә—Алла, җирдә—хан. Алланың кодрәте зур, ниндидер йолкышка да хан кыяфәте бирә ала. Мин аның мәйданда башын өздерә алам, әмма...

Хан. Әмма?

Казый. Синең ихтыярдан башка моңа җөрьәт итә алмадым. Бигрәкләр дә охшаган, игезәкләр кебек.

Хан *(кулын селти)*. Бире китерегез, багыйм.

[1]Сарайда җәза урыны.

**Казый титаклый-титаклый чыгып китә.**

Хан *(тәхетеннән торып әрле-бирле йөренә башлый, узалдына сөйләнә)*. Һе, суйган да каплаган, диме? Чыңгыз ханның орлыгы бер дингездән бер дингезгә кадәр чәчелде шул. Әллә бабайларның каны караларда уянып, безне шулай кызык итәме? Кеше кешегә ничек ике тамчы су кебек охшый ала?

**Ишек ачыла да берәүне эчкә этеп җибәрәләр. Керүче, тигезлеген тота алмыйча, ханның аяк астына ук китеп йөзтүбән егыла.**

Хан *(йөзтүбән ятучының шәрә башына итек очы белән төртә)*. Тор!

Шагыйрь *(авыр гына күтәрелә)*. Әссәламәгаләйкүм!

**Хан шашып калгандай була. Каршыда ул үзе—Бирдебәк басып тора! Шул ук гәүдә, шул ук җирән сакаллы йөз, зәңгәр күзләрендә мыскыллы очкыннар биешә.**

Шагыйрь *(шаркылдап көлеп җибәрә)*. Син миңа охшагансың икән, Бирдебәк!

Хан. Хан үз-үзенә генә охшый ала, бичарам! *(Ул, шагыйрь белән икәүдән-икәү генә каласы килеп, шыгаулларга чыгып торырга ымлый)*. Мәйданнарда халыкны болгатып ниләр сөйләнеп йөрисең?..

Шагыйрь. Мин гаделлек турында сөйлим.

Хан. Гаделлек... *(тәхетенә утыра)*. Ни беләсең син гаделлек турында? Еш кына гаделсезлек тә гаделлеккә әверелә.

Шагыйрь. Хан гадел хөкем итәргә тиеш. Ул салымнарны халык күтәрәлгәнчә салырга, угры түрәләрне җәзаларга, илбасар сугышлар ачмаска тиеш.

Хан. Тукта, юләр шагыйрь! Миңа син гаделлек турында сафсата сатып халыкны болгатасың. Ахмак кешеләр, синең сүзенә карап, гаделлек табабыз дип фетнәгә кузгала. Бераздан минем ясаулларым аларны чебен урынына сыта. Ком җыелып таш булмас, кол җыелып баш булмас. Димәк, гаделлек турында сөйләп, син үзенә ияргәннәргә гаделсезлек эшлисең. Шуңа күрә мин афәт чыкканчы ук синең башны чабарга боерам. Сиңа карата бу

гаделсезлек булыр, чөнки син дә адәм баласы, сине дә Алла яраткан, әмма синең сафсатаңа иярәчәк беркатлы бәндәләр өчен бу гаделлек булачак. Мин шулай күбрәк кешенең гомерен саклап калам.

Шагыйрь. Хан гадел хөкем иткәндә бернинди дә фетнә чыгалмый.

Хан. Кемгәдер гаделлек булып тоелган нәрсә кем өчендер гаделсезлек. Һәркемгә беркайчан да ярап бетә алмыйсың. Ә угры түрәләрне җәзалауның мәгънәсе юк. Түрә урлый, ришвәт ала, бу мәңге шулай булачак! Тик чаманы гына югалтмасын. Аннары бит алар салган сарайларын үзләре белән алып китә алмый. Мал монда, илдә кала.

Шагыйрь. Син урамга чыгып кара. Почмак саен күпме теләнче утыра. Халыкны чарасыз калдырсаң, ул ерткычка әйләнә, илдә каласы сарайларыңны җир белән тигезли. Бездән соң бер алачык та калмаячак.

Хан. Чыңгыз йорты—мәңгелек! *(Йодрыгын йомарлый)* Менә күрәсеңме? Көч... Шул илне җыеп тора. Көч булганда, бернинди фетнә дә куркыныч түгел.

Шагыйрь. Көч белән тоткан илнең киләчәге юк!

Хан. Син Болгардан бит әле? Узындыгыз сез. Ясакны вакытында түләмисез, әмирегез гаскәр җыярга да ашыкмый.

Шагыйрь. Җучи олысы ямаулыклардан тегелгән юрган кебек. Һәр ямаулык үзе ил-көн. Һәр ил-көн үз көнен үзе күрергә тиеш. Нигә әле Болгар халкы әллә кайдагы Каф тавы артына яу чапсын?

Хан *(сакалы дерелдәп ала)*. Син кайдан ишеттең бу турыда?

Шагыйрь *(сүрән генә)*. Сүз иясе белән йөрми.

**Хан тәхетеннән төшеп, тагын арыбире йөри башлый. Ул ярсыган.**

Хан. Сүз тормый. Бәкләр кайтып бичәләренә сөйлиләр, тегеләре ахирәтләренә. Ә Сарай үзе шымчылар белән мыжлап тора.

Шагыйрь. Син мине исән калдырмассың инде?

Хан. Салкын ташка эләккән кешенең юлы берәү генә... Аннары сиңа бу кыяфәт белән көн күзендә йөрергә дә ярамый. Шуңа күрә уеңдагы телеңдә булсын. Сүзеңне үзең белән алып китмә. Бу гомергә бер бирелә торган форсат.

Шагыйрь. Ни калган безгә Иранда? Син башта үз йортыңда тәртип урнаштырырга тиеш. Әнә Мәскәү көчәя. Аларның чиркәүләре, монастырьләре, иксез-чиксез җирләр биләсә дә, казнага бер тиен ясак түләми. Үзбәк ханның әмере. Әгәр берәр попка кыек сүз әйтсәң, ясауллар башыңны чаба. Хан шулай кушкан. Ярый рәхмәт укып гыйбадәт кылып ятсалар. Алар бит безгә каршы коткы тарата. Монахлар көне-төне безне кыргый дип атап китаплар яза, денсезләр дип безгә каршы яуга өнди.

Хан. Хи, урыс беркайчан да безгә каршы чыгарга базнат итмәс. Алар бит корал тота белми торган мәңге исерек халык.

Шагыйрь. Эт симерсә, иясен тешли.

Хан. Тешләмәс. Хуҗаның кулы нык, бау кыска. Муенчак бик тиз элмәккә әйләнә ала.

Шагыйрь. Син һәммәсен алдан күрә белергә тиеш.

Хан *(ярсу)* Тиеш?! Сез шагыйрьләргә акыл сатуы җиңел. Әмирләргә яу кирәк! Аларның байлыгы, малы артсын өчен хан гаскәрне чит илләргә юнәлтергә тиеш. Аларның хатыннарына ефәк кирәк, асылташлар, алтын беләзекләр, балдак, муенсалар, үзләренә кәнизәкләр кирәк! Менә мин ни тиеш! Алар кулында гаскәр. Даладагы морзаларга Сарайдан борынын да чыгармаган хан кирәк түгел. Мин нишли алам? Тәкиядә, байларның сәдакасын көтеп утырганда, акыллы булып кылану җиңел ул. Ә син менә бу тәхеттә түрәлек итеп кара!

Шагыйрь. Әйдә соң... Алмашыйк урыннарны. Без бер-беребезгә охшаганбыз, беркем дә аера алмаячак.

Хан. Кызык... *(тәхетенә менә)*. Бер атна, бер атна гына мескен җилән киеп, тәкиянең салкын диварына арканы терәп, бу дөньяның фанилыгы турында уйланып утырасы килә килүен.

Шагыйрь. Һәр кешедән шикләнеп, сарай эчендәге һәр ым-шымга колак салып, тәхет өчен калтырап утырудан туймадыңмыни, хан?

Хан. Анысы шулай. Ләкин түрәлек искиткеч ләззәт бирә шул... Хатын-

кыз куены, атның биле, тәхет... Ират өчен башкаларны буйсындырудан да зур бәхет тагын бар микән? Күктә—Тәңре, җирдә—хан!

Шагыйрь. Һарун-әр-Рәшид тә хәерче киеменә төренеп Багдад урамнарында кемсәләрнен ни турында сөйләшеп йөрүен тыңларга яраткан. Илнең ни белән сулаганын шымчылар аша гына белеп бетереп булмый.

Хан. Хуп. Ләкин онытма—минем бармакта Бату ханнан калган тамга.

Шагыйрь. Ком—таш, кол—баш булмас, дисең бит.

Хан. Әйдә бер атна минем тәхеттә утырып кара. Күрербез, ничек сайрарсың икән.

Шагыйрь. Борчылма, Бирдебәк. Шагыйрь хан була ала, хан шагыйрь була алмый.

Хан *(чишенә башлый)*. Шагыйрьләрнең бушкуык икәнен мин күптән беләм.

**Шагыйрьнең ямалган, җөйләнгән тузанлы иске җиләне, төкәнгән кеше гомере кебек, идәнгә шуып төшә. Бирдебәк шул җиләнгә төренеп ишеккә атлый. Шагыйрь киенеп-ясанып тәхеткә менә.**

Хан. Онытма, бер атнага... *(чыга)*.

**Әзмәвердәй ике шыгаул янә ишек катына баса.**

Шагыйрь. Ah! *(бармакларын уа, кычкыра)*. Йөзегемне урлаган, йөзе кара! *(шыгаулларга кул селти)* Барыгыз, йөзегемне кире кайтарыгыз. Угърының хәзер үк башын чабыгыз!

**Шыгауллар бер булып ишеккә ташлана. Теге якта ыгы-зыгы ишетелә, «шык» итеп нидер таш идәнгә килеп төшә. Бераздан шыгаулларның берсе тез белән шуыша-шуыша тәхеткә якынлаша. Учында Батудан калган көмеш йөзек.**

## Икенче бүлек

**Хан сараеның Ханикә биләгән ягы. Түрдә челтәр ябылдыклы киң ятак. Келәмнәр өстендә Ханикә ахирәт кызлары, кәнизәкләре белән энҗе арчып утыра. Шау-шу, көлеш.**

Беренче кыз. Ахирәт, илем дә илем, дисең. Сөйлә әле нинди соң ул һиндиләр иле?

Икенче кыз. Анда ел әйләнәсендә җәй. Карны мин монда килгәч кенә күрдем.

Беренче кыз. Анда тун да, бүрек тә кирәкмидер инде.

Өченче кыз. Анадан тума йөрүчеләр дә бар.

Беренче кыз. Хи-хи-хи... Алдыйсындыр әле. Казый тотып камчыларга кушмыймы?

Икенче кыз. Ул үзе дә шәрә. Оят җирен генә чүпрәк белән каплаган да... *(Кызлар шаркылдап көлешәләр.)*

Беренче кыз. Бер сүз әйтимме?

Кызлар. Әйт әле, әйт...

Беренче кыз. Әй лә, әйтмим.

Икенче кыз. Әйтәм дигәч, әйт инде. Сер мәллә? *(Кызлар колакларын кызга якын китерәләр)*

Беренче кыз. Юк, әйтмим.

Өченче кыз. Алайса әйтмә *(үпкәләгән булып кызлар читкә борыла)*.

Беренче кыз. Әйтәм, әйтәм. Иртән ишек төбендә мине казый тотып алды. Итәгеңне бир әле, дип, итәккә бер уч чикләвек салмакчы була.

Өченче кыз. *(Хи-хи-хи)*. Шул чатан пәриме?

Икенче кыз. Бирдеңме соң? Казый чикләвеге тәмледер ул... *(көлешәләр)*.

Өченче кыз. Итәгеңне бирсәң, ул чикләвек кенә салмас.

Беренче кыз. *(Чатанлап атлап китә, казый булып сөйли.)* Әй, кызлар солтаны... Бәрәкалла, бигрәк сылу икәнсең. Кая, кая, бир әле итәгеңне, салыйм әле чикләвек, рәхәтләнеп аша әле шуны *(урынына барып утыра)*. Тотмакчы, капшамакчы була, карт шайтан.

Икенче кыз. Алдыңмы соң чикләвеген?

Беренче кыз. Нишләп алыйм... Алсаң, әллә нәрсә уйлар... Мин андый кыз түгел, әлхәмделилла шөкер...

Өченче кыз. Иртән чыбылдык эчендә нәрсә ярып маташа идең соң алайса? *(көләләр)*

Беренче кыз *(торсая)*. И-и,

юкны сөйләп утырма сана... Тәнә генә Каф тавы егете белән үзең авызга-авыз ни сөйләштең соң?

Өченче кыз. Сөйләшермен дә... Мине аңарга кияүгә бирәләр. Шулай бит, Ханикә солтаным?

Ханикә. Әйе, алар ярәшелгән инде. Тиздән шаулатып туй үткәрәбез, Алла боерса.

Икенче кыз. И ахирәтемҗаным. Бәхетең бар икән. Егете нинди бит: үзе мут, күзе ут, борыны кылыч!

Ханикә. Син дә кайгырма. Теге ясаул сиңа бик күз салып йөри бит. Ханнан да синең белән ярәштерүне сораган.

Икенче кыз. Теге урысмы? Әбәү, кыяфәтсез—сап-сары ич ул...

Ханикә *(бармак яный)* Аны күргәч, үзеңнең дә күзләрең уйный башлый...

Беренче кыз. Филләреңне сагынырсың әле, урыс үз иленә алып китсә... Анда җәй бөтенләй булмый, имеш.

Икенче кыз. Җәйсез ничек яшиләр икән соң алар? Кеше ышанмастай сүзне, чын булса да сөйләмә син, ахирәт.

Беренче кыз. Тиреләргә төренеп аю кебек яшиләр. *(Аю булып сикереп күрсәтә)*. У-у, у-у... Ярты гомерең ялангач үткән, ярты гомерең тире эчендә үтәчәк.

Икенче кыз. Әй лә, алайса мин аңа бармыйм.

Ханикә. Юри генә ирештерә бит ул сине, юләр.

Өченче кыз. Көнләшә ул синнән. Сиңа урыс биргән теге кеш тиресе йокысын алды аның. Нинди елкылдап тора бит. Чыланмый да, су шуып кына төшә үзеннән.

Икенче кыз. Бет тә әллә кая кача аңардан...

Беренче кыз. Әйтәм, соңгы арада кашынмый башладың.

Икенче кыз *(ахирәтенең өстенә килә)* Мин сине...

Ханикә. Җитте сезгә!

**Кызлар урыннарына утыралар.**

Өченче кыз. Бүген Сарайга урыслар килде әле. Кенәзләре үлгән икән. Абыйсы белән улы килгән. Икесе дә ханнан ярлык алмак келе. Олау-олау кеш тиреләре, ас тиреләре китергәннәр, тәпән-тәпән бал... Икесе дә, бер-берсе белән ярышып, морзаларга мал өләшә. Ханны кайсы үз ягына аударыр.

Беренче кыз. Ханикә солтаным, син аларның кайсысын яклыйсың?

Ханикә. Аларның йоласы буенча, үлгән кенәзнең абыйсы ярлык алырга тиеш.

Өченче кыз. Карачы да аның абыйсына ачык чырай күрсәтә, диләр.

Икенче кыз. Хан нәрсә әйтер бит әле. Ул үзе йола.

Беренче кыз *(тавышын әкренәйтә)* Бүген хан янына бер дәрвиш шагыйрьне алып кергәннәр. Тач ханга охшаган ди, җаным. Суйган да каплаган ди инде менә.

Ханикә. Хан нинди хөкем чыгарган?

Өченче кыз. Шул арада ханның йөзеген урлаган. Башын чапканнар бичараның.

Икенче кыз. Дәрвишләр дә карак була микәнни?

Өченче кыз. Бармактан йөзек урларлык булгач, гади карак кына түгел инде ул. Күз буучы түгел микән?

Ханикә. Дәрвишләр күз буа белә, диләр бит. Алар арасында әллә нинди сихерчеләр бар, имеш.

Өченче кыз. Сихерче булса, башын чаптырып торыр микән соң ул?

Ханикә. Йәгез, буш сүз сөйләп утырмагыз. Ханның килер вакыты җитә, кабырчыкларны җыя башлагыз.

**Кинәт теге яктан чиелдап кычкырган тавыш ишетелә. Аннан бер кыз йөгереп керә.**

Дүртенче кыз *(еламсырап)* Ханикә-солтан, хан имиемнән тотты-ы...

Кызлар *(барысы бергә)*. Нәрсәә...

Ханикә. И Ходаем. Булмаганны... Җен алыштырган мәллә.

**Шул чакта бераз чайкалып хан килеп керә.**

Хан *(ишек төбендә туктап кала)*. Ханикә! Кара озын сачләреңне аяк белән тиң яраткан... (алга атлый).

Ханикә *(борылып)* Ни булды сиңа, солтаным?

**Кызлар чыркылдашып тиз арада чыгып китәләр, Беренче кыз гына кала, ул ханны юындырырга дип комганга барып тотына.**

Хан. Мәхәббәтле булсын диеп бит очына мин яраткан... *(барып кулынбитен юа, аннары ятакка килеп утыра).* Шәраб!

**Беренче кыз Ханикә кулындагы сабага шәраб агыза. Сабаны ханга сузганда хатынның беләкләре ачылып китә. Хан йотлыга-йотлыга шәраб эчә.**

Хан. ...күңеленне киң яраткан...

Ханикә. Бүген әллә нинди сәер әле син...

Хан *(Беренче кызга чыгып китәргә кушып кулын селки).* Мин җиденче кат күктә, гарештә *(аякларын сузып җибәрә).*

**Ханикә иелеп аның читекләрен салдыра башлый. Ләкин итекләр кысан, хатын мышнап чыга, гаҗизләнеп аптыраулы карашын ханга күчерә.**

Ханикә. Итек тә утыра мәллә, ходаем.

Хан *(тәкате калмыйча хатынны кочаклап ала).* Соңыннан, соңыннан...

**Бүлмә караңгылана. Музыка. Бераздан хатынның читкә тайпылганы күренә. Яктыра.**

Ханикә. Син Бирдебәк түгел!

Хан. Мин—мин түгел? Тилерденме әллә? Кем инде мин, синенчә?

Ханикә. Ул мондый түгел иде.

Хан. Нинди—мондый?

Ханикә *(бераз икеләнеп)* Шундый... Дәртле...

Хан. Сагындым...

Ханикә. Кичә генә миндә булган иден ич әле...

Хан. Мин көн дә синең янда булырга риза, бүтән хатыннарны күрәсем дә килми...

Ханикә *(сикереп тора, әрфия япма белән имиләрен каплый).* Юк! Юк! Син Бирдебәк түгел, син башка кеше!

Хан *(сикереп тора да хатынның иңбашыннан умырып тота)* Кычкырма, ахмак! Мине хан түгел дисәләр, ят кеше белән йоклаган өчен синең дә башынны чабачаклар. Чапмасалар да, син инде хан хатыны булмыйсың.

**Ханикә түшәккә йөзтүбән ятып, сулкылдый-сулкылдый елый башлый. Елап туйгач, торып утыра. Керфекләрендәге сөрмә күз яше белән агып йөзен буяп бетергән.**

Ханикә. Кем син? Дәрвиш шагыйрьме?

Хан. Мин—Бирдебәк. Син мине аңладыңмы?

Ханикә *(пышылдап)* Аңладым.

## Өченче бүлек

**Беренче бүлектәге күренеш. Тәхеттә—хан. Ул, янәшәдәге бәллүр савыттан әфлисун алып, әрчи башлый. Яртылаш әрчегәч, җимешне янә савытка куя.**

Хан *(үзалдына)* Тып-тын, шомлы тынлык...

**Ишектән диван бәге килеп керә.**

Диван бәге *(башын ия).* Әссәләмәгаләйкүм, солтаным. Кәефең юк бугай. Шагыйрьләр, җыручыларны китердем, алар ишек катында. Боерасыңмы?

Хан. Керсеннәр.

Диван бәге. Бүген Асук чичән дә килде. Көтелмәгән хәл. Аның элек сарайга аяк басканы юк иде. Сарай шагыйрьләреннән күләп җырулар чыгара иде. Бүген атаклы Асук үзе килгән.

Хан. Асук? Ни калган аңа монда? Ул бит үзен гидайлар, сукбайлар җыручысы дип атый. Хан хозурында ни эзли? Билне бөгәргә мәҗбүр иткән дөньядыр...

**Ишек ачылып китә дә аннан биш шагыйрь килеп керә. Бишесе дә саз тоткан. Алар башларын иеп ханны сәламлиләр.**

Беренче шагыйрь. Ханнар ханы! Солтаннар солтаны! Галәм чатырын тотып торучы алтын багана! Исемеңне ишетүгә дошман кан калтырап тора. Күктә кояш торганда синең исемеңә шагыйрьләр дан җырлар. Төн житкәч күк йөзенә сибелгән йолдызлар, синең шөһрәтеңнән көнләшеп, бер-берсе белән серләшерләр...

Хан. Тукта! *(Көлемсерәп.)* Көнчел йолдызларны себереп төшерәсем килә. Мин моны булдыра аламмы?

**Шагыйрьләр ни әйтергә дә белмичә аптырап калалар.**

Асук. Ә син себереп карадыңмы соң?

Хан. Карадым.

Асук. Себереп төшердеңме?

Хан. Буем житмәде. Йолдызлар минем ихтыярыма буйсынмый. Мин шуңа кайгылы бүген.

Асук. Бу вакытлыча хәл. Тиздән алар да синә сәждәгә егылыр.

Хан *(көлә).* Ә син ханнарга мәдхия укырга өйрәнгәнсең, Асук!

Асук. Дөнья өйрәтә, солтаным. бу тарих—ханнар, солтаннар тарихы икән.

Хан. Йә, кайсыгыз башлый? Тик алдан ук әйтеп куям—кемнең мәдхиясе ошамый, шунда ук башын чаптырырга боерам.

**Куркып калган шагыйрьләр бер-берсе белән чыш-пыш сөйләшеп алалар. Берсе дә мәдхия җырлый башларга җөрьәт итми.**

Беренче шагыйрь. Асук Сарайга беренче килә. Аңардан башлыйктыр...

Хан. Юк инде. Ул иң соңыннан җырлар. Әйдә, синнән башлыйк.

Беренче шагыйрь. Бигайбә, солтаным *(сазының кылларын чиртеп ала).* Күк йөзендә кояш кеби якты нурын сибә, имди...

Хан. Булды, булды... *(шыгаулларга)* Алып китегез үзен *(Шыгауллар якынайгач, Беренче шагыйрь буыннары йомшап, идәнгә тезләнә).* Туктагыз, калсын. Башкаларны да тынласын инде, теге дөньяга китәр алдыннан. Әйдә, икенчең... *(Кулын чәбәкләп куя).*

Икенче шагыйрь *(тавышы калтырана).* Даладагы шоңкар кеби...

Хан. Булды, тукта. Тапталган сүзләрне кабатлыйсыз. Шундый йоны коелган сүзләр өчен сезне ризыкландырып ятаргамы? Теге дөньяда фәрештәләр тәңрегә бертуктаусыз мәдхия укый, ди. Шулардан өйрәнеп кайтырсыз.

**Шагыйрьләр барысы да тезләнәләр. Асук кына басып кала.**

Өченче шагыйрь. Ярлыка гөнаһлы шагыйрьләреңне, солтаным. Без инде бернигә ярамыйбыз. Безнең күкрәгебездә сандугач түгел, карга утыра.

Хан. Менә бу чагыштыруың миңа ошады. Шуның өчен генә әллә ярлыкаргамы сезне?

Шагыйрьләр *(беравыздан)* Ярлыкагыл, ярлыкагыл.

Хан. Беркайчан да мондый җырулар чыгармаска сүз бирегез!

Шагыйрьләр. Сүз бирәбез, сүз бирәбез.

Хан *(диван бәгенә).* Боларны далага ку. Көтү көтсеннәр, илгә файдалары булыр. Ә син, Асук, кал. Шыгауллар, сез дә чыгыгыз, Асукның җыруын ялгызым тыңлыйсым килә.

*(Диван бәге шагыйрьләрне алып чыга.)*

**Хан Асук белән күзгә-күз кала.**

Таныдыңмы?

Асук. Таныдым.

Хан. Тәкия элеккечәме? Салкынча, аулак...

Асук *(җавап бирмичә)* Арзанлы мәдхияләргә алданмыйсың син.

Хан. Шагыйрь алдында сүзнең бер дәрәҗәсе юк. Чын уйларын яшерер өчен ул аларны кызганып тормый.

Асук. Арзанлы сүзләр астында да хакыйкать яшеренеп ята.

Хан. Купшы, көяз чәчәкләр агымсулар өстенә сибелә, аста ләмгә баткан кара таш кымшанып та карамый, аның тирәсендә вак балыклар уйный, әкәм-төкәмнәр рәхәт чигә. Кара таш серен зирәкләр генә күрә. Җете чәчәкләргә кызыгып сузылган кешене агымсулар алып китә, чоңгылларга илтеп ташлый.

Асук. Тәхеттә дә шагыйрьлегең бөтенләй жуелмаган икән әле. Шулай да бу кәмит нигә кирәк булды?

Хан. А-а, күптәнге хыялымны тормышка ашырдым мин. Тәхет тирәсенә елышкан, шагыйрь исемен күтәреп күкрәкләреннән карга очыручылар көтү көтәргә генә ярыйлар. Миңа шагыйрьләрнең тажы Асук үзе мәдхия укырга тиеш!

Асук. Син үзгәрмәгәнсең икән...

Хан. Юк, мин бик нык үзгәрдем. Мин хәзер сүзләрне түгел, дөньяны вәзенгә салам.

Асук. Ханнар килә, китә, ә шагыйрь даны мәңгелек.

Хан. Син шуңа күрә төннәр буе кара сулардан энҗе эзлисеңме? Дан хакына?

Асук. Кыска гына гомердә мәңгелеккә орыну бәхет түгелмени?

Хан. Тәхете юклар гына коры сүздән бәхет таба. Кара син сарай шагыйрьләренә—төнлә олуг әшьялар

турында, Галәм турында язалар, көндез ханның рәхимле күз карашын аулыйлар.

Асук. Тәхеттә искиткеч тарту көче бар. Шул тарту көчен жингән кеше генә яшәү мәгънәсенә ирешә.

Хан. Халык—көтү. Һәркем шул көтүнең күз унында булырга тели, ишләренең уйлары белән идарә итәсе килә. Сәләмә кәжә бәтие дә, мәтәлчек атып, көтүнең исен китәрергә маташа!

Асук. Без шул ахмак шамакайлыктан качып, дөнья малыннан ваз кичеп, вак мәшәкатьләрне ташлап дәрвиш булып киттек ич инде.

Хан. Бу үзе үк кешеләр күңелендә аерым урын эзләү түгелмени? Жылы сүз көтеп тәкиягә килүче булмаса, робагыйларыбызны тыңларга башка дәрвишләр жыелмаса, гасабилана идек бит!

Асук. Димәк, син анда да жаныңтәнең белән Аллага якынаерга тырышмаган, ә үзең кебек мәхлукларның рухында түрәлек кылырга омтылган. Дөнья мәшәкатьләреннән ваз кичеп, ялангач, ачлы-туклы яшәвең белән син үзеңнең бүтән кешеләрдән аерылып торуыңны күрсәткәнсең...

Хан. Халык көтү икән, кемдер аның көтүчесе булырга тиеш. Мин борынгы болгар бәкләре нәселеннән. Олуг каланы яулап алгач, Бату хан, үзенә каршы сугышкан өчен, нәселебезне кырып бетерергә кушкан. Безнең тармак кына ниндидер могжиза белән котылган. Биләмәсез калгач, без муллamунтагай булып, дәрвишлеккә китеп көн күрергә дучар ителдек. Бату балаларына минем ыру үчем дә бар. Үч алу! Иң зур ләззәт шул түгелмени? Илһам өчен монда мәйдан зур...

Асук. Син кылыч йөзеннән йөрисен...

Хан. Бу дөнья киселгән тырнакка тормый. Шуңа күрә булган бөтен ләззәтне татырга, булмаганын уйлап табарга кирәк. Ләззәт уйлап табу үзе дә ләззәт бирә! Ә менә тәхетле булганда гына ирешеп була.

Асук. Бирдебәкне үтереп тәхеткә менүең турында Сарайда сүзләр йөри инде. Мин сине кисәтергә килдем. Сине үтерәчәкләр!

Хан. Үлем беркайчан да вакытыннан элек килми. Уйлаганың юкмы, Асук: үлем яшәүнең иң соңгы ләззәте түгел микән?

Асук. Нигәдер бу турыда беркемнең дә кайтып әйткәне юк. Мин шуны гына беләм—үлем шәрабының махмыры булмый *(чыга)*.

**Диван бәге керә.**

Диван бәге. Тәкъсир, синең хозурга казый килгән. Боерасыңмы?

Хан. Йомышы ни?

Диван бәге *(аптырап)*. Һәрвакыттагыча, тәкъсир...

Хан. Керсен.

**Диван бәге чыга, ишектән казый керә.**

Казый. Әссәләмәгәләйкүм, тәкъсир *(тәбәнәк таңгалга утыра, дога кыла)*

Хан. Вәгаләйкүм әссәлам. Йә, йомышың ни?

**Казый сүзне нидән башларга белмичә угалана, үз хәбәреннән үзе үк шүрли, ахрысы.**

Хан. Телеңне йоттыңмы әллә? Телсез калуың өстенә чукрак та, сукыр да булсаң, Сарайда күпме кеше иркен сулыш алыр иде. Ә, Бәдретдин әс-Суари?!

Казый. Аллага шөкер, дүрт ягым да төгәл әле. Күктә ноктага әверелгән карчыганы да күрәм, комның шуышканын да ишетәм. Мин—синең колагың, мин—синең күзең.

Хан. Йә, комнар ни пышылдый инде?

Казый. Сарайда яман сүзләр йөри, олуг хан. *(Пауза)*. Сине хан түгел, ә мәкер белән тәхеткә менгән э... э... шагыйрь дип гайбәт тараталар.

Хан. Нинди мәкер?

Казый. Имеш, төс-кыяфәтең охшашлыгыннан файдаланып, бер йолкыш шагыйрь синең тәхеткә менеп утырган.

**Хан ярсып тәхеттән төшә, янәшәдәге алтыннан ясалган агачка ялгыш чабуы тиеп, ботакларга жимешләр кебек беркетелгән асылташлар жил искәндәге сыман тибрәнеп алалар, бер якут өзелеп идәнгә төшә, келәм өстендә кан тамчысы кебек алсу-кызыл төсләр белән уйнап ала.**

Хан. Ханның һәр жирдә күзколагы барын һәммә кеше белә. Беләләр, шулай бит?

Казый. Беләләр, тәкъсир...

Хан. Әмма гайбәт тараталар, ниндидер ният коралар. Димәк, курыкмыйлар!

Казый. Тел ни сөйләмәс...

Хан. Кемнәр тарата мондый коткыны?

Казый. Туганнарың. Бигрәк тә Танышбәк. Хан үз-үзенә охшамаган, диләр.

Хан. Бу сүзләрне ничек чикләргә?

Казый. Башларын чаптырырга... бетте-китте, вәссәлам. Муеннан аерылган башта тел тик тора.

Хан. Юк, бик гади була бу. Таныклык кылдырырга кирәк. Анамнан, хатынымнан...

Казый *(шикләнеп)*. Ә алар таныклык кылырлармы соң?

Хан. Ничек таныклык итмәсеннәр? Ана үзе тапкан улын танымыймы, хатын үз куенында яткан ирне танымыймы?

Казый. Хатын-кызга ышаныч юк.

Хан *(чыгарга ымлый)*. Иртәгә барысы да ачыкланыр.

**Казый чыга. Диван бәге керә.**

Иртәгә барлык ир туганнарымны, анамны, хатыным Ханикәне сарайга чакыр. Мәҗлес җыям, табынны мул әзерләгез!

**Диван бәге чыга. Хан беравык тәхеттә уйланып утыра. Тынлык эчендә почмак якта тычканның кетер-кетер нидер кимерүе ишетелә. Хан чүгеген салып шул якка томыра.**

Хан. Хан сараемы, гидай алачыгымы—тычканга барыбер *(кычкыра)*. Ә мәче уянды!

*Пәрдә.*

## Дүртенче бүлек

**Шул ук күренеш. Идәндә табын әзерләнгән. Хан әрле-бирле йөри. Бераздан ишек ачыла да, хан чирүенең башлыгы Саруҗа керә, башын ия.**

Саруҗа. Чакыргансың икән, олуг хан!

Хан. Тиздән минем ир туганнарым мәҗлескә җыела. Син беләсең, аларның һәрберсе юрганын үзенә таба тарта. Ә Җучи олысы бер йодрыкта булырга тиеш. Шул чакта гына без дошманны җиңә алабыз. Каф тавы артын яңадан кул астына кайтарыр вакыт җитте. Һулагу огланнары бер-берсе белән орышып дәүләтне харап иттеләр. Үзбәк хан туруннары да үзара кылыч күтәрсә, олысыбыз өстендә Чыңгыз байрагы авып төшәчәк. Ил иминлеге өчен огланнарның Тәңре янына китүе кирәк. Гаделлек шунда!

Саруҗа. Төшендем, олуг хан...

Хан. Үткән ау вакытында Танышбәк синең энеңне чабып үтергән бугай...

Саруҗа. Яшьләр кызу канлы. Энемдә дә гаеп булгандыр. Танышбәк аның өчен күп алтын түләде инде...

Хан. Аны кан белән генә түләп була. Син нөгәрләреңне әзерлә. Мәҗлес кызгач, мин ым кагуга, алар огланнарны бабаларыбыз янына җибәрергә тиеш.

Саруҗа. Кунакларга кылыч күтәрү...

Хан. Алар дошман! Яу чыгар алдыннан безгә бер йодрыкка тупланырга кирәк.

Саруҗа. Төшендем, олуг хан...

Хан. Болгар әмиреннән бер хәбәр дә юк. Үз чирүен безгә кушасы килми бугай. Иртәгә үк анда кузгалырсың, мин сине Болгар әмире итеп түрә кылам. Каршылык күрсәтүчене гөрзиең белән сыт!

Саруҗа. Баш өсте, олуг хан...

Хан. Яуга чыккач, уң канат синең кул астында булыр. Әйттем!

Саруҗа. Минем бер үтенечем дә бар иде, олуг хан.

Хан. Әйт.

Саруҗа. Агаларым инде ничәнче ел тарханлык сорыйлар.

Хан. Беләм агаларыңны. Мәҗлестән соң ярлык язарга боерырмын.

Саруҗа. Тәңре сиңа озын гомер бирсен, тәхетеңне нык итсен.

Хан. Огланнарны юк иткәч, нәүбәт ыру бәкләренә җитәр. Һәр ыру үз ягын каерганда, илдә иминлек булмый. Аларны Чыңгыз хан кебек болгатып, бутап бетерергә кирәк. Җучи олысында бер ыру гына калырга тиеш. Бер ыру, бер йола, бер тел. Бер ил-көн! *(Чыгарга ымлап кулын селки.)*

**Саружа чыга. Бераздан кунаклар керә башлый. Һәрберсе, ханны сәламләгәннән соң, үзенә тиеш урынга утыра. Ишек ягыннан тавыш ишетелә:**

—Мәрхүм Җанибәк ханнын хатыны, Бирдебәк ханнын анасы Тогай-туглы!

**Ишектән йөзе акшарланган юан карчык килеп керә. Ул вәкарь белән акрын гына атлый, арттан озын күлмәк итәген унлап кәнизәк күтәреп бара. Хан, тәхетеннән төшеп, аны каршыларга китә, кулыннан җитәкләп килеп үзенең уң ягына утырта. Карчык кара төртмә күзе белән аны тишеп ала да, йөзенә битарафлык чыгарып, авыз эченнән генә ниндидер дога укый. Амин итәләр.**

—Бирдебәк ханның хатыны Ханикә!

**Хан Ханикәне дә аягүрә каршылый, ишек төбеннән үк алып килә, үзенең сул ягына утырта. Барысы да бергә дога кылалар.**

**Танышбәк тәхеттән ерак түгел уң якка урнашкан, мендәргә таянып кырын ята.**

**Зур күн капчыкларда елкы ите кертә башлыйлар, кымыз ташыйлар. Табын җиләк-җимеш белән тулы. Көмеш табаклар өстендә бавырчыларның пычаклары елык-елык уйный. Анасы ханга кымыз салып бирә. Хан, кымызны уртлап алгач, саркытын * Танышбәккә суза. Ханның мондый хөрмәтенә гаҗәпләнгән огланның касәне алганда кулы җиңелчә дерелдәп куя.**

**Бавырчылар һәр кунак алдына савыт белән ит куялар. Кыстау тавышлары ишетелә: «Җитешегез! Боерыгыз! Монысыннан авыз ит...» Кымыз бераздан телләрне яздыра—шыбыр-шыбыр сөйләшү, ара-тирә көлү авазлары яңгырый. Пыяла чүлмәкләрдәге шәраб, батып барган көньяк кояшы кебек, моңсу нурларын табын өстенә сирпи. Борынгы йола буенча шәраб тулы касәне кулына алган кеше җыру әйтергә тиеш. Танышбәк ханга карап җырлый:**

Далаларда кылганнар шаулый,
Кызыл төлке казгышлар аулый,
Каурыйларын җилләр тик каулый,
Аучы егет чыга өеннән...

Хан. Ай, Танышбәк! Егетләр солтаны! Яхшы җыру җырладың, күңелләр әллә нишләде. Аучы! Ә мин кем соң? Кызыл төлкеме, казгышмы?

*(Танышбәк дәшми, башын аска иеп тора.)*

Йә, нигә дәшмисең?

Танышбәк. Син хан... диләр...

Хан *(уң кулын күтәрә).* Тыңлагыз! Сарайда минем турыда төрле сүзләр йөри икән. Имеш, мин—мин түгел. Янәсе, тәхеттә мин-Бирдебәк утырмыйм, ә миңа охшаган ниндидер йолкыш шагыйрь утыра. Мин бу ялага колак та салмаган булыр идем. Хан төрле гайбәтләрдән өстен! Тик туганнарымның минем артта шундый сүз таратуын рәнҗетте.

*(Мәҗлес тып-тын булып кала.)*

Йә, кайсыгыз мине хан түгел, ди? Кайсыгыз? Танышбәк, синме?

Танышбәк. Минем алай дигәнем юк. Тәхеттә утыргач, хан буласыңдыр инде...

Хан *(торып баса)* Менә уң ягымда анам утыра. Мин аның бәгыреннән өзелеп төшкән. Кайсы ана үз баласын ятлар белән буташтырыр? *(Тогай-Туглыга борыла).* Анам! Әйт бу адашкан огланнарга, әйт минем кем икәнне!

**Карчык борсаланып ала, кара төймәдәй эчкә баткан күзләре янә ханны тишеп үтә. Бу караштан бернәрсәне дә яшереп булмый.**

Тогай-Туглы. Син—улым Бирдебәк...

Хан. Сул ягымда газиз хатыным утыра. Мин аның белән ничә төнне бер юрган астында үткәрдем. Кайсы хатын үз ирен ятлар белән бутый ала? *(Хатынына борыла).* Хатыным! Әйт бу адашкан огланнарга, әйт минем кем икәнне.

Ханикә *(башын күтәрә төшеп табындагыларга күз йөртеп чыга. Аннан өзеп әйтә).* Син—ирем...

Хан. Ишеттегезме барыгыз да?

**«Ишеттек, ишеттек»,—дигән тавышлар яңгырый.**

Сезнең күңелдә шик-шөбһәгә урын калырга тиеш түгел. Диван бәге! Корьән алып керегез! Анам да, хатыным да сүзләрен раслап Корьән тотып ант итсеннәр!

**Диван бәге яшел тышына алтын хәрефләр төшкән Корьән-Кәримне алып керә. Изге китапны күргәч, Ханикә үзе**

Саркыт—Хан эчкәннән соң касә төбендә калган эчемлек. Хан хөрмәте, ул аны иң ышанычлы кешесенә генә бирә.

**дә сизмәстән артка тартылып куя, бер мизгелгә кулын ямереп ала.**

Тогай-Туглы *(тиз генә алтын балдаклар белән бизәлгән кулын Корьән өстеннән шудырып ала).* Ант...

Ханикә *(нәфис бармакларын Корьәнгә тидерә)* Ант...

Хан. Моннан соң итәк астыннан сүз йөртмәссез. Минем күз күпне күрә, колак күпне ишетә. Ә хәзер ашагыз, эчегез, сыйланыгыз. Бер-беребезгә мәрхәмәтле булыйк.

Диван бәге. Олуг хан! Син ярлык алырга килгән урысларны тыңлармын, дигән идең.

Хан. Керсеннәр.

**Ишектән кенәз ярлыгына дәгъва итүче ике урыс—Әндри белән Ибан керә. Аларның яраннары ханга, аның якыннарына бүләкләр—йоннары җемелдәп торган тиреләр алып керәләр.**

Диван бәге. Олуг хан! Менә монысы—мәрхүм кенәзнең абыйсы—Әндри. Монысы—мәрхүм кенәзнең улы—Ибан. Алар ярлык алырга килгән. Һәркайсы ярлык үзенә тиеш дип саный. Ярлыкны кемгә бирү—синең иркеңдә.

Хан. Сөйләсеннәр.

Әндри. Олуг хан! Сиңа Аллаһы Тәгалә озын гомерләр бирсен. Син булганда урыс җире дә яшәр, дошманнар аңа кагылырга җөрьәт итмәс *(янындагы яраныннан кеш тиресе алып, хан алдына барып тезләнә).* Шушы кечкенә генә бүләгемне кабул ит. Шушы җәнлек тиресе кебек синең патшалыгың да еракtан җемелдәп торсын, төрле бөҗәкләр аңа үрмәли күрмәсен *(бүләген ханга суза).*

Хан. Син дә озак яшә, Әндри. Казнаң бай икән, ишеттек.

Әндри. Моннан бер ай элек кенәзебез үлеп китте. Авыр туфрагы җинел булсын.

Хан. Авыр туфрагы җинел булсын *(дога кыла. Урыслардан кала бүтәннәр дә аңа кушыла).*

Әндри. Безнең бабайлардан калган йола буенча, аның урынына мин утырырга тиеш. Ләкин мәрхүмнең улы Ибан, шул йоланы санга сукмыйча, тәхеткә үзе менәргә маташа. Яшь әле ул, аның башын тирәсендәге байарлар бутый. Ханнар гомер бакый безнең йолаларны санга сукты, син дә үз сүзенне әйт, олуг хан!

Ибан *(абыйсына кычкыра).* Мине байарлар бутамый, минем үз сүзем сүз!

Әндри. Тик кенә тор, көчек.

Ибан. Кем көчек? Кем? Ах, син, карт кәҗә *(кизәнә).*

**Урыслар төрткәләшеп ала.**

Хан. Туктагыз! Карачы, син ни әйтерсең?

Карачы. Без Бату хан заманыннан ук урысларның йоласына тыкшынмадык. Алар үз диннәрен тотты, үзләренчә яшәде. Безгә үз вакытында ясакларын түләп барсалар, шул җиткән. Әгәр аларның йолалары буенча Әндри кенәзлек итәргә тиеш икән, аңа бир ярлыкны.

Хан. Диван бәге! Син ни диярсең!

Диван бәге. Әндринең казнасы нигә бай? Ул, ханга җибәрәсе бар дип, халыкларыннан ясакны ике-өч өлеш күбрәк җыя! Үзе череп байый, ә халык безне кургалмый.

Казый. Алар күптән ачтан үлеп бетәрләр иде дә, әле ярый урыс җирендә шалкан белән керән яхшы уңа.

Диван бәге. Шалкан ашмыйни инде ул...

Саружа. «Җил җибәргәннәр» ашы...

Диван бәге. Шуңа аларның ушкуйниклары болгар сәүдәгәрләренең икмәк тулы корабларын талыйлар да инде.

Әндри. Безнең халык хәерче, җиребез уңдырышсыз—сазлык та урман. Сезгә дигән ясакны да халыктан көчкә җыеп алам.

Хан. Мәрхүм кенәзнең васыяте нинди соң?

Әндри. Ул васыять язарга өлгерми калды. Болай да билгеле бит инде—кенәз үлсә, аның урынын бертуганы били.

Ибан. Ялганлый ул! Әтинең васыяте булган! Әндринең кешеләре аны юк иткәннәр.

Әндри *(ханга)* Менә шундый ул. Олылардан узып алга сикереп чыга.

Ибан. Олуг хан! Ышанма син аңа. Ул монда гына юашланып маташа, үзебездә халыкны сиңа каршы котырта. Кайчакка хәтле басурманнарга ясак түләрбез, ди.

Әндри. Ангыра бәрән! Телең ни сөйләгәнне колагың ишетми.

Хан. Без анда кемнең ни кылганын

көне-сәгате белән белеп торабыз.

Ибан. Олуг хан! Безнең борынгыдан килгән йола буенча тәхеткә чыннан да әтиемнең абыйсы менәргә тиеш. Ләкин бит йола да мәңгелек түгел. Бер йола үлә, икенчесе туа. Әндри әллә кайчан туфрак булган бабайлар сүзенә караса, мин синең күзеңә карыйм. Без синең иркеңдә! Син ничек әйтсәң, шулай булыр. Менә минем йола!

*(Табындагылар шаулашып ала. «Шәп әйтте! Егет!» дигән сүзләр ишетелә).*

Танышбәк. Нигә күп сөйләшеп торырга? Әндрине ат койрыгына тагып далага җибәрергә, җыйган казнасын Сарайга алып кайтырга кирәк.

Карачы. Ибан әле яшь, кенәз булырга өлгерер. Безгә урысның йоласына тиеп, халыкның күңелен кайтарырга ярамый.

Хан. Син үз сүзенне әйттең инде.

Саружа. Әндридән яхшы ук тамган моңа.

Танышбәк. Күрмисеңмени, урыс күлмәге киеп утырган.

Карачы. Синең якаңдагы ас тиресе кайдан килгән?

Хан *(кулын күтәрә).* Тыңлагыз. Тәхет атадан угылга күчә. Кенәз ярлыгын Ибан исеменә язарга боерам. Моннан соң йола шундый булыр. Әйттем!

Ибан *(шатланып кычкыра).* Мең яшә, олуг хан!

Әндри *(башын иеп).* Ни кылсаң да, иркең бар, падишаһыбыз...

Хан. Ибан кенәз атланган атны Әндри үз чатырыгызга кадәр җитәкләп барсын. Кенәз өчен чураларның олысы-кечесе юк.

Әндри *(тагын баш ия)* Тыңлыйм вә буйсынам, падишаһым.

Ибан *(абзыйсын ишеккә этеп җибәрә)* Бар, атның тышавын салдыр...

**Чыгалар.**

Казый. Бик тә акыллы, зирәк әмер булды бу, тәкъсир.

Диван бәге. Бер-берсе белән тәхет бүлешеп, талашып ятсыннар.

Саружа. Безгә ясак килеп торса, шул җитә.

Хан. Син ни әйтерсең, Карачы?

Карачы. Син хаклы, олуг хан. Тик алар белән сак эш итәргә кирәк. Юлдашың урыс булса, билеңдә балта булсын, диләр бит.

Саружа. Безнең билдә кылыч, беркем дә тынын чыгара алмас.

Танышбәк. Урыс нәрсә ул? Бер җикерсәң, алар ун ел урманнан борыннарын чыгармый. Кырымдагы җәнәүзләрнең арт сабагын укытырга кирәк менә. Тамга бәясе бигрәк арзан. Алар анда череп баеган. Үз куеныбызда елан җылытып ятабыз.

Карачы. Кырым яһүдләре акча бирмәсә, без Иранга яу чаба алмас идек.

Казый. Әйе, аларга тияргә ярамый.

Хан. Әйдәгез, сыйланыгыз, кадерле кунаклар.

Тогай-Туглы. Сез сыйланыгыз, без китик инде, улым. Мин дә алҗыдым, Ханикәнең дә әнә күзләре йомылып китә *(урыныннан тора).*

Хан. Олы башыгызны кече итеп улыгыз хозурына килгән өчен Тәңренең игелеген күрегез, анам. Таянган җирең һәрвакыт йомшак булсын, Ханикә *(хатыннарны озата чыга).*

Танышбәк *(исерә төшкән).* Җәнәүзләрне узындырасыз. Мин аларны акылга утыртыр идем.

Диван бәге. Сәүдә итү ул кылыч болгау түгел. Аңа баш кирәк.

Танышбәк, Мине башсыз димәкче буласыңмы әллә, көтүче!

Диван бәге. Башлы, башлы. Әнә ич муеныңда тырпаеп утыра, күреп торам. Әлегә...

Хан *(тәхетенә утыра).* Җырлашып утырыгыз, кунаклар. Җырусыз табын йөгәнсез ат сыман ул.

Танышбәк *(диван бәгенә).* Чыккач сөйләшеп бетерербез.

Казый. Тәкъсир! Мин инде олы кеше. Кайтып түшәккә башымны куйыйм.

Карачы. Миңа да китәргә рөхсәт ит, солтаным.

Хан. Хәерле сәгатьтә! Килешеп житмәгән төшебез булса, гаепләп китмәгез, кырын сүзләр әйтелсә, үткәреп җибәрегез.

Карачы. Табын бик мул, кешеләр яхшы, нинди гаепләү инде...

Казый. Тагын шулай бергә-бергә кәефләнеп утырырга язсын.

**Чыгалар.**

Танышбәк. Яуда мине маңгайга куй син, хан! Мин ул кызылбашларны, у-у... Башта Арранга бәреп керәбез...

Хан. Башта Ширванны алабыз.

Т а н ы ш б ә к. Арранны алсак, алар Ширваннан чигенә алмаячак.

Х а н. Анда минем алтын халатым калды. Шуны ябынмыйча минем жаным тынычланмас.

Т а н ы ш б ә к. Халат, халат. Иранда халат беткәнмени... Мин булсам...

Х а н. Син булсаң... Булсаң шул менә. Тик инде син булмыйсың. Син яуга да бармыйсың. Танышбәк...

Т а н ы ш б ә к. Н-ни өчен?..

Х а н. Син инде бүтән шәраб та эчә алмыйсың, сылу кызлар да коча алмыйсың...

Т а н ы ш б ә к *(тора башлый)* Син, син...

Х а н *(Саружага ым кага)* Бабаларыгыз янына, бабаларыгыз янына китәсез, Танышбәк...

**Бүлмә эче караңгылана. Ишектән нөгәрләр кереп тула. Кунак огланнар өстенә үлем арысланнары ташлана, еландай сызгырып кылычлар баш күтәрә, төлкегә ташланган ау лачыны сыман хәнҗәрләр корбаннарына үтеп керә. Диван бәге Танышбәкнең башын чабып өзә.**

Д и в а н б ә г е. Менә хәзер башсыз калдың, Танышбәк!

**Канлы туйда кияү булып утырган хан, эченә тулышкан тантанага чыдый алмыйча сикереп тора да, Танышбәкнең өзелгән башын ишеккә таба тибеп җибәрә.**

Хан. Буш ул, буш!

## Бишенче бүлек

**Хан сараеның Ханикә ягы. Ханикә ятакка утырган. Беренче кыз аның озын кара чәчләрен тарап тора.**

Б е р е н ч е к ы з. Сарай тып-тын калды. Беркем беркем белән сөйләшми. Үлек чыккан йорт кебек.

Х а н и к ә. Үлек чыккач, җанда нинди дер җиңеллек була. Кеше үз-үзенә дә белгертергә теләмәгән җиңеллек. Бушанып калу. Ә монда безне ниндидер авырлык изеп тора. Һәркем нидер көтә.

Б е р е н ч е к ы з. Ниндидер күз күрмәгән, колак ишетмәгән афәт килер кебек.

Х а н и к ә *(тыңланып тора)*. Давыл алды тынлыгы.

Б е р е н ч е к ы з *(еламсырап)* Мин куркам, Ханикәм...

Х а н и к ә. Нидән куркырга? Барысы да без туганчы ук мангайга язылып куелган.

Б е р е н ч е к ы з. Беләсе иде, нәрсәләр язылган икән анда. Мин кайчан кияүгә чыгам икән?

Х а н и к ә. Синең һаман бер уй. Күзең төшкән егетең бармы соң? Иртәгә үк яраштерәм.

Б е р е н ч е к ы з. Күзем төшкәне бар да... Әгәр ул мине яратмаса?

Х а н и к ә. Алар бит безгә охшамаган. Без генә ул яратсак, башка нәрсә турында уйлый алмыйбыз. Ирләрнең «яратам» дигәндә дә, башыннан дөнья мәшәкате чыкмый. Бер серле караш ташласаң, җылы сүз әйтсәң, ир сиңа тагыла инде ул. Әллә син алар безне сайлый дип уйлыйсыңмы? Юк, җанкисәгем, без сайлыйбыз аларны. Шундый итеп сайлыйбыз, ирләр мескеннәр үзләре дә сизмәстән безнең җәтмәгә килеп каба, әле «үзебез сайлаган язмыш», дип сөенә-сөенә кабалар.

Б е р е н ч е к ы з. Фатыйма да үзе сайладымы? Әллә кайдагы эссе Һинди якларыннан килеп, зәмһәрир суык урыс җирләренә китеп бар инде.

Х а н и к ә. Аның ире Ибан кенәзгә ияртүне сораган бит. Хан каршы килмәгән. Туңып үлмәс әле Фатыйма, кайнарлыгы җитәрлек. Анда да кешеләр яши.

Б е р е н ч е к ы з. Бөтенләй кыргый ди бит алар. Тирегә төренеп йөриләр икән.

Х а н и к ә. Кем белә, бәлки без дә аларга кыргый күренәбездер. Һәр халык үзенчә яши. Үзенә охшамаганнарга «кыргый» тамгасы суга.

Б е р е н ч е к ы з *(тавышын әкренәйтә)*. Мәҗлестәге бөтен огланнарны үтереп бетергәннәрме? Ханның үз туганнарына ничек кулы күтәрелде икән, ә?

Ханикә. Үзең аңламаган нәрсәләр турында уйлама. Тәхет тирәсендә туганлык юк анда.

Беренче кыз. Нәрсә булыр, нәрсә булыр?

Ханикә. Таң атар да кич булыр. Кояш беркемнең әмеренә буйсынмый, калка да бата, бата да калка.

Беренче кыз. Хан бүген кырыңа килер микән?

Ханикә. Нигә килмәсен, килер...

Беренче кыз. Башка хатыннары янына барганы да юк диләр...

Ханикә. Анысы инде аның үз эше.

Беренче кыз. Үзең дә бик яратасың ахрысы аны.

Ханикә *(кызны җиңелчә этеп җибәрә)* Үз иремне ничек яратмыйм ди инде...

Беренче кыз. Ә мин аңардан куркам. Күргәч үк эчке калтырау ала.

Ханикә. Сиңа нигә куркырга? Ул кызларга тими.

Беренче кыз. Тимәсен дә беләм. Тик бүре күргән киек кебек буыннар йомшый, кузгалып китә алмый торам.

Ханикә. Әллә ханга гашыйк булгансың инде син, кызый?

Беренче кыз *(кызара)* Юк ла, Ханикәм, Алла сакласын. Үз бикәмнең иренә гашыйк булырга минем башка ат типмәгән әле.

Ханикә. Ул бит хан. Аңа гашыйк булсаң да бер гаебе юк. Хатын-кыз көчле, бай ирләрне ярата. Тик алар көчле күренәләр генә. Һәркайсының эчендә сабый ята. Сабыйлар кебек үчләшәләр, бер-берсенә тияләр, ә үзләре бу дөньядан башларын яшерергә итәк эзлиләр.

Беренче кыз. Яуга кайчан кузгалалар икән?

Ханикә *(уйчан)*. Кем белә, бәлки кузгалмаслар да әле...

**Дүртенче кыз йөгереп керә.**

Дүртенче кыз. Хан килә!

Беренче кыз *(тиз генә урыныннан сикереп тора)*. Мин чыгыйм инде.

**Кызлар чыгып китә. Хан керә. Керүгә Ханикәне кочаклап ала.**

Хан. Чәчләрең нинди матур. Куе. Керәп адашасы килә шунда. Мондагы сатлык, комсыз, мәкерле кешеләрдән шунда гына котылып буладыр...

Ханикә. Кешеләрне яратмыйсын син...

Хан. Ә аларны ни өчен яратырга? Мин бит аларны үтәли күрәм. Яратырлык бер генә матур сыйфат та юк аларда...

Ханикә. Ханнар ярату бәхетеннән мәхрүмдер шул.

Хан. Әйе, хан тойгылардан азат булырга тиеш. Нинди күнелсез сүз— ярату... Хыялыйлар бәлки ярата алалардыр—яратыр өчен бит кешене хыялда гәүдәләндерергә кирәк. Анарда булмаган гүзәл сыйфатларны уйлап чыгарырга...

Ханикә *(әкрен)* Шагыйрьләр хыялга бай булалар. Алар менә чынлап яраталардыр...

Хан *(сискәнеп)* Нәрсә?!. Ә-ә, шагыйрьләр... Алар үз сүзләренә үзләре ышаналар микән соң? Уен, барысы да уен...

Ханикә. Уенның да матуры була, ямьсезе...

Хан. Болар барысы да сүзләр генә... Нәрсә матур, нәрсә ямьсез— кем әйтеп бирә ала? Уен комарлы, үзенә бөтереп ала, җибәрми. Ахыры ни белән бетәсен дә беләсең, тик уеннан чыгарга кодрәтең җитми. Бу уенның ахырын син дә беләсең бит, әйеме?

Ханикә. Берни дә белмим. Мин уйламыйм, яшим.

Хан. Хатын-кыз шулай чынлап уйнарга ярата. Әйтимме уенның ахырын? Син йөгереп килеп минем янга тезләнәсең дә кочаклап кычкырып җибәрәсең: «Ире-ем, Бирдебәгем! Без бергә... бергә...» *(Ханикәне кочаклап ала)* Без бергә, бергә!

Ханикә. Монда да уйнап утырмасана!

Хан. Юк, мин шаяртмыйм. Нәкъ шулай булачак. Син мине яратасың, яратасың, шулай бит?

Ханикә. Яратам, яратам.

Хан. Хет бер яктылык бар... Кемнеңдер үзеңне яратуын белү барыбер рәхәт. Баксаң, шул ук үз-үзеңне сөю бит инде бу, кем өчендер газиз булуыңа кинәнү...

Ханикә. Нигә һәр нәрсәнең төбенә тоз коясың? Минем янда уйларыңнан арынып тора аласыңмы син?

Хан. Юк. Алар изә мине. Башым кыршау кидерелгән кебек *(пышылдый)*. Инде минем бер атна йоклаганым юк.

Ханикә *(ханның башыннан кочаклый)* И, бичарам...

Хан. Тәхет бәхет китерә дип уйлый идем. Уен башы—син! Кузналы уенында сөякләрне төрлечә ыргытып була. Баксаң, кемнеңдер уенында мин үзем кузна, үзем бер сөяк икән...

Ханикә. Ял ит, ял ит...

Хан. Синнән ниндидер татлы ис бөркелә. Нинди ис—һич исемә төшерә алмыйм.

Ханикә *(көлә)* Ислемай исе ул. Аны Бизан сәүдәгәрләре алып килгән иде. Гарәпләр жирендә генә үсүче ниндидер үсемлектән ясыйлар икән.

Хан. Синең янда гына бераз жиңеллек алам мин. Әле дә менә тәхет бүлмәсеннән качып килдем. Диван бәге, Карачы, Казый, Саруҗа... Туйдым барысыннан да... Ялагай тук чырайларыннан, комсызлыкларыннан... Хәзер менә тагын үзләренә яңа биләмәләр өметләнәләр. Огланнарны үтерделәр бит! Ә үзләре эчтән мине куралмый. Беләләр минем кем икәнне, беләләр... Кара әле, син дә эчтән мине куралмыйсыңмы?

Ханикә. Син бит кешеләрне үтәли күрәсең. Үзең әйт—куралмыйммы сине?

Хан *(хатынга төбәлеп карап тора)*. Юк, хатын-кызның жаны карурман... Хатын-кызны үтәли күреп булмый.

Ханикә. Син өлгеррәк булмасаң, Танышбәк үзе сине үтергән булыр иде.

Хан. Танышбәк үтермәс иде. Үтерүче күп сөйләми ул. Танышбәк үз теле аркасында харап булды. Диван бәге ничек сөенеп ташланды аңа... Менә аларны гаепләргә кирәк. Чыңгыз нәселенә кул күтәргән кешеләрне рәхимсез җәза көтә... Мин әле уйлыйм, моңарчы булмаган нинди җәза бар?

Ханикә. Моңарчы булмаган җәзаны көтү—иң зур җәза.

Хан. Дөрес! Сездерергә, сездерергә кирәк аларга әкрен генә: җәза янәшәдә... Уен тәмамланып килә... *(Урыныннан тора)* Ау урынын карап кайтасым бар. Яуга чыкканчы чирүләрне ауда сынап карарга кирәк. Кайткач, мин синең янга килермен. *(Ишеккә таба бара, бусагага җиткәч, Ханикәгә борыла)*. Синнән килгән исне исемә төшердем. Өметсезлек исе ул. Өметсезлек шулай аңкый *(чыга)*.

## Алтынчы бүлек

**Тәхет бүлмәсе. Карачы, Казый, Диван бәге, Саруҗа.**

Диван бәге. Хан ау урынын карарга китте, ул кайтканчы сөйләшеп алыйк.

Карачы. Кайтуга ук кадап үтерергә кирәк, чыдар әмәл калмады. Коңратлар аны якламаячак. Минем ун төмәнем кылыч күтәрергә әзер тора. Бер ым житә.

Казый. Бер хәчтерүш дәрвиштән кан калтырап торырга күпме мөмкин! Әллә без үзебезнең кем икәнебезне оныттыкмы? Бабаларыбызның каны суга әйләндеме? Ул мине кичә тәрәт чүлмәгенә утырган килеш кабул итте! *(Калганнар авызларын каплап көлешеп алалар.)* Нигә көләсез, сакалсыз калгырлары! Сарайдагы барлык шагыйрьләрне, дәрвишләрне көтүче итеп далага куды, күрдегезме? Чират хәзер әмирләргә житә. Ике морзаны ат койрыгына тактырды инде.

Диван бәге. Чыңгыз нәселенә кул күтәрү җинаять, ди. Огланнарның үлемен безгә сылтап калдырачак. Күрербез шунда күрмәгәнне.

Казый. Огланнарны үтерүдә минем катнашым булмады. Әнә Саруҗаның башы авыртсын...

Карачы. Саруҗа! Син безнең беләнме? Ул бит сиңа Болгар әмирлеген вәгъдә итте, яуда уң канат башына куям, диде.

Саруҗа. Сезнең белән. Йолкыш бер дәрвишнең мин тәхеттә утыруын теләмим. Минем ерак бабам Чыңгыз белән дөнья яулаган!

Казый. Мондый мыскылга татар чыдармы?

Диван бәге. Татар чыдам ул. Бу эштә ашыкмаска кирәк. Син, ка-

зый, Ханикә белән Тогай-Туглы хатын янына барырга тиеш идең. Ничек булды?

Казый. Ханикә аны чын Бирдебәк ди... Ә кәмпер, әгәр дә ханны богаулый алсак, аның Бирдебәк түгеллегенә таныклык бирергә риза.

Саружа. Һе, анасын эт ялагыры. Ир астында калгач, аңы бетә хатын-кызның.

Диван бәге. Хикмәт анда гына түгел. Ханикә—акыллы хатын. Ул аны Бирдебәгем, дип Коръән тотып ант итте. Сүзеннән кайтса, аны мөслимә дип кем санга сугар? Икенчедән, бер бичара дәрвиш белән йоклаган хан хатынына сарайда гына түгел, җир йөзендә дә урын калмаячак. Өченчедән, Бирдебәк үтерелсә, ул ханбикәлектән колак кагачак. Ана артка чигенергә юл юк. Ә инде Җанибәк хатынының эчкерле, икейөзле, кансыз икәнен барыбыз да белә.

Казый. Тотып богауласак, безгә ул карчыкның таныклыгы нигә?

Саружа. Кадыйбыз да үтерәбез. Кыз-хатын бүген алай, иртәгә тегеләй... Үлгәч Бирдебәге дә, дәрвише дә бер була инде. Үләксә!

Казый. Ә тәхеткә кемне күтәрәбез?

Диван бәге *(казыйны тыңламыйча)* Аннары... Безгә аны гап-гади дәрвиш дип игълан итү дә ярамый. Чыңгыз канлы огланнар, затлы бәкморзалар бер хәчтерүшкә буйсынып торган, дип бөтен дөнья бездән көләчәк. Без нәкъ менә Җанибәк углы Бирдебәкне, илгә золым салучы кансыз Бирдебәкне үтерергә тиеш.

Карачы. Миңа тәхеттә кем утырса да барыбер. Тик минем кышлауларга, җәйләүләргә генә кагылмасын. Ә бу, анасын ат ниткере, утыз авылымны Кырымга күчереп утыртты.

Диван бәге. Әйе, безнең сүздән чыкмаса, дәрвиш түгел, әллә кем булсын иде. Тик бу безне бит тишек бер тиенгә дә куймый башлады. Кичә «сиңа кайчан сакал чыга инде»,—дип, сакалымны тарта *(өч-дүрт бөртек сакалын сыпырып куя)*. Минем ыруның яртысын аерып алып, найманнар жиренә күчерәм, ди...

Карачы. Үзе ырусыз булгач, башка ыруларны да корытырга уйлый ул.

Казый. Ә кемне тәхеткә күтәрәбез? Бату хан туруннарыннан берәү дә калмады бит.

Саружа. Барысын да кырдыры. Ни—ни, кулы каты аның.

Карачы. Иртәгә үзен ни көткәнен беркем дә белми. Хан Тәңренең эшенә тыкшына башлады.

Саружа. Бәлки яуга чыкканчы сабыр итәргәдер. Яуда аңардан арыну жиңелрәк булыр.

Диван бәге. Яуга кадәр ул безнең башка житәчәк.

Карачы. Яуга чыгабызмы әле, юкмы... Мангытларның чирүе күренми, табыннар һаман кузгалмаган. Аның хан түгеллеген озын колак бөтен далага тараткан инде.

Казый. Тәхеткә кемне күтәрәбез соң?

Диван бәге. Аюны әле үтермәгән, тунамаган, ә син инде аның итен өләшә башладың. Тәхет буш тормас.

Казый. Анысы шулай. Үзара бола чыга күрмәсен, дим.

Диван бәге. Әнә Азак буенда Килдебәк жәйли. Аны Үзбәк ханның турыны дип сөйлиләр.

Карачы *(көлеп жибәрә)*. Чыңгыз нәселеннән дип теләсә нинди көтүчене тәхеткә мендерергә була. Инде безнең тәжрибә бар.

Диван бәге. Ханны аугa чыгар алдыннан кадап үтерербез. Һәрберебез кадар. Аны аерым кеше үтерергә тиеш түгел. Амин *(дога кылалар)*.

**Шул вакыт тышта урам ташларына бәрелеп тояк тавышы яңгырый.**

Карачы. Кемдер безне тыңлап торган, ахрысы...

Казый *(югалып кала, титаклап бер урында әйләнә)*. Мин бер сүз дә әйтмәдем... әйтмәдем... әйтмәдем...

**Саружа аңга килеп ишеккә ташлана, тышта аның «куып житәргә!»—дигән боерыгы яңгырый.**

Диван бәге. Артка юл юк. Ходай ярдәм бирсен.

Карачы. Амин. *(тиз-тиз чыгалар)*.

## Җиденче бүлек

**Ишектән тиз-тиз атлап хан килеп керә. Аңа Диван бәге ияргән.**

Диван бәге. Ауга чыгарга барысы да әзер, солтаным.

**Хан тәрәзәгә килә**

Хан. Елкычлыар арбалары янында, чатырчылар киергеләрне, уыкларны барлый, аучылар коралларны яный, кошчылар турагачларны җилкәгә салган...

Диван бәге. Ау уң булыр, Аллаһы боерса...

Хан *(көлә)* Зур ерткычны алырга уйлыйсың, бәк!

**Диван бәге сискәнеп китә, әмма бик тиз үзен кулга ала—йөзе таш кебек салкын, анда бер сызык та селкенми.**

Хан. Кулың калтырамасын...

Диван бәге. Минем бу кадәр тыныч булганым юк иде әле.

Хан. Олыслардан нинди хәбәрләр бар?

Диван бәге. Мангытлар чирүе килеп житте, солтаным. Болгарлар да килде.

Хан. Әйе, анда Саруҗаның барып торуы кирәк булмады.

Диван бәге. Ул инде үзен Болгар бәге дип уйлый башлаган иде.

Хан. Шуңа үпкәләдеме? Яуда ул уң канатта барачак. Аннан кайткач, Болгарга китәр. Мин үз сүземдә торам.

Диван бәге. Хәзер ул ауга ыргыла.

Хан. Танышбәк ничек җырлаган иде әле? *(Әкрен генә көйли).*

Далаларда кылганнар шаулый,
Кызыл төлке казгышлар аулый,
Каурыйларын жилләр тик каулый,
Аучы егет чыга өеннән...

Дөнья шундый, бәк, кем казгыш, кем кызыл төлке, кем аучы икәнен тәгаен генә беркем дә әйтә алмый.

Диван бәге. Төлке казгышны буа, аучы төлкене куа... Бу дөньяда һәркемнең үз урыны, солтаным. Урыннар алмашынса, дөнья бутала.

Хан. Без бит кешеләр. Аллаһы тәгалә һәр кешене тигез яраттым, дигән. Ә, бәк? Ялгыша ул, шулай бит?

Диван бәге. Аллаһы хөкеменә керә алмыйм. Тик аучылар аз, казгышлар күп икәнен генә беләм. Кыр тычканы күпме генә талпынса да, аңа канат үсми, ул шоңкар була алмый.

Хан. Әйе, еллар буе кыр тычканы булып өндә ятканчы, бер сәгать шоңкар булып күкне иңләвең яхшы.

Диван бәге. Быргыларны кайчан уйнатырга боерасын?

Хан. Урыс илчеләре тагын нигә килгән?

Диван бәге. Тогай морзаның мишәр җирләрен үзләренә бирүне үтенәләр. Ясакны үзебез җыеп сезгә тапшырыр идек, диләр.

Хан. Син ни уйлыйсың?

Диван бәге. Анда бит ат үтә алмаслык куе урманнар, сазлыклар. Ул җирләрдән инде ничә еллар ясак җыйганыбыз юк. Тогай морза үлгәч, балалары талашып, бүлешеп беттеләр. Мәскәү хәзер ныгып килә. Җыйсын безнең өчен ясакны...

Хан. Син безнең ерак бабабыз Мәдә хан турында ишеткәнең бармы?

Диван бәге. Юк.

Хан. Көн чыгышында зур дәүләт тоткан ул. Башта алар бик көчсез булган. Бервакыт күршеләре аның сөлек кебек атын сорап килгәннәр. Мәдә үзенең киңәшчеләрен җыйган. «Бирәбезме атны, юкмы?»—дип сораган. «Бирмәскә!—дигән күбесе,—шундый затлы атны ягага биреп җибәрергә без бөтенләй хәлдән таймаган әле». «Алар белән орышырга әлегә безнең көчебез юк,—дигән Мәдә хан.—Бер атны бирүдән дөнья бетмәс». Ә бирмәскә дигән киңәшчеләрнең башын чаптырган. Бераздан күршеләр Мәдәнең чибәр хатынын сорап килгәннәр. Мәдә тагын киңәшчеләрен җыйган. «Бирмәскә!—дигән күбесе.—Бу нинди хурлык, ягага кем газиз хатынын биреп җибәрә?» «Безнең әле көчебез аз,—дигән Мәдә.—Бер хатынны биреп җибәрүдән дөнья җимерелмәс». Һәм бирмәскә дигәннәрнең башын чаптырган. Күпмедер вакыт үткәч, күршеләр чик буендагы буш җирне сорап килгәннәр. «Ул җирнең безгә барыбер файдасы юк, бирергә кирәк»,—дигән киңәшчеләр. «Юк инде,—дигән Мәдә.—Җир—дәүләтнең нигезе! Аның өчен без соңгы канга кадәр сугышачакбыз».

Шулай дигән дә бирергә дигән кинәшчеләрнең башын чаптырган. Тик, кызганыч, Мәдәнең туруннары бу сабакны үтәмәгәннәр.

Диван бәге. Гыйбрәтле риваять... Мин илчеләргә шулай дип җавап та бирермен.

Хан. Тик дөньяда берни дә мәңгелек түгел шул. Дәүләтләр дә юкка чыга... Ничәдер йөз елдан бу җирнең безнеке булуын бәлки беркем дә белмәс...

Диван бәге. Сарай—мәңгелек. Мондый гүзәл шәһәр эзсез югала алмый.

Хан. Мәңгелек... Нигә кеше мәңгелеккә дәгъва кыла? Үлгәннән соң да әле ул бөтенләй юкка чыгарга теләми, теге дөньяда яшәргә, хур кызларын кочарга өметләнә. Сиңа кыска гына гомер бирелгән, син шуны кешечә яшәп ал!

Диван бәге. Үлем булмаса да бик күңелсез булыр иде.

Хан. Аллаһы Тәгалә, кешеләрне тигез яраттым дигәндә, нәкъ шул үлемне күздә тоткандыр да. Үлем һәркемне тигезли.

Диван бәге. Тигезләп бетерәме икән? Ханнар кабере өстендә төрбәләр утыра, мөҗавирлар алар рухына көн дә дога кыла, ә бер юлбасарның, сукбайның кабере дә булмый—кипкән сөякләре генә далада агарып ята.

Хан. Иске киемеңне салып калдыргач, аның кайда ятуы синең өчен мөһиммени?

Диван бәге. Хәтер бар бит әле, кеше хәтере. Кемне яхшы сүз белән яд итәләр, кемне каһәрләп...

Хан. Кеше хәтере кыска. Ул явызлыкны гына озаграк истә тота. Кансыз, дәһшәтле хөкемдарларның исемен авыз суын корытып кабатлый. Чыңгызлар, Батулар шаны искермәс, ә олыска ислам нурын иңдергән, кылыч тотмый гына ил-көнне туплап тоткан, тынычлыкны барыннан да өстен куйган Бәркә ханны кем хәтерли?

Диван бәге. Ә бәлки Чыңгызлар, Батулар да Тәңре каршында алай ук явыз түгелләрдер. Алар аркасында күпме кеше шәһид киткән, оҗмахка тиенгән.

Хан. Язмышың маңгаеңа язылган булгач, без гамәлләребез өчен җавап бирергә тиешме соң? Туганда ук газапка дучар ителгәнсең икән, дәрвиш тәкиясендәме син, хан тәхетендәме, барыбер анардан котыла алмыйсың.

Диван бәге. Син төн буе йөреп чыгасың... Ни газаплый сине?

Хан. Аны аңлап, аңлатып буламыни? Тыңла әле *(якын килә, акрын)*. Минем кайчагында Тәңре буласым килә.

Диван бәге *(гаҗәпләнеп)*. Тәңре?

Хан. Тик Тәңре булсаң да берни үзгәрмәс иде. Шушы мескен дөньяны яратуы өчен ул да газаплана бит!

Диван бәге. Газаптан ничек котылып була соң?

Хан. Аның бер генә юлы бар, бәк... Һәм син аны беләсең.

Диван бәге *(әйтергәме-әйтмәскәме дип икеләнә)*. Бүген Карачы, Казый, Саруҗа...

Хан *(бүлдереп)*. Ә синең хатының чибәр, бәк...

Диван бәге *(тәмам аптырый)*. Хатыным?

Хан. Кичә төнлә ул минем чатырга килгән иде. Уң имие өстендә ясмык кадәр миңе бар, әйеме?

Диван бәге *(шашып калгандай)*. Нигә синең янга килде ул?

Хан. Кыз-хатын нигә төнлә ир янына килә?

Диван бәге *(кычкырып)*. Алдыйсың!

Хан *(көлә)*. Син үз ханыңа хатыныңны артыксынасыңмы? Тар күңелле булма, бәк! Гомер бит бер генә килә...

Диван бәге *(башын тота)*. У-у...

Хан. Ханга кычкырган өчен синең башыңны чабарга тиешләр. Тик мин сине ярлыкыйм. Өйләнгән елны егетләр юмарт була. Сезнең өчен гомердән дә татлы ни бар тагын? Җыйган алтынга сокланып, хатынны саклап утыруны чын тормыш дип уйлыйсыз сез. Ә алар менә (учына өрә) тузан, чүп. Кеше үлемен күргәндә генә яшәү татлы булып тоела. Син моны белергә тиеш идең, бәк...

Диван бәге. Моннан соң белермен, хан...

Хан. Ә хәзер кит.

**Диван бәге чыга. Асук керә.**

Асук. Олуг ханга сәламәтлек телим.

Хан *(үзалдына)* Сәламәтлек кирәк, үлгәндә дә сәламәт булуың яхшы. *(Асукка)* Нигә килдең?

Асук *(аптырап)*. Сине күрәсем килгән иде.

Хан. Минем беркемне дә күрәсем килми.

Асук. Мин синнән ярдәм сорап килдем.

Хан. Ханнан да, түрәләрдән дә беркайчан ярдәм сорама, мәрхәмәт көтмә. Беркемнән дә ярдәм сорама. Яшәве жиңелрәк була. Чөнки бераздан ярдәм иткән кешене кыралмый башлыйсың. Ул синең аңа булган бурычыңны искә төшереп тора.

Асук. Без бит дуслар идек.

Хан *(көлә)*. Дуслык... Ханның дуслары булмый!

Асук. Без бит ничә еллар бергә тузанлы юллардан үттек, тәкия иднәнәрендә бер жилән ябынып йокладык.

Хан. Нигә этләр бүреләрне аерата күралмый? Алар да бит кайчандыр бүре булган! Шагыйрьләрне минем женем сөйми...

Асук. Ярдәмне бит үзем өчен сорамыйм. Син халыкның хәлен беләсенме соң? Ясак түләр өчен алар балаларын яһүд сәүдәгәрләренә сата!

Хан. Халык һәрвакыт интеккән, һәрвакыт интегәчәк. Идарә итү ул халыкны талау дигән сүз.

Асук. Мин сине танымыйм!

Хан *(Асукка якын килеп, кулын җилкәсенә сала. Арган тавыш белән)*. Син белгән Әхмәд Болгари күптән юк инде ул... Эзләмә син аны, Асук. Аның башы түгел, йөрәге сарай идәненә тәгәрәде...

**Асукны ишеккә этә.**

Бар, бар... Һавага чык...

**Асук чыга. Титаклый-титаклый Казый керә. Сулышы капкан.**

Казый. Олуг хан! Солтаным!

Хан. Ни бар? Янгын чыккан мәллә?

Казый. Хәбәр... Яман хәбәр...

Хан *(битараф кына кулын селти)* Сөйлә...

Казый *(фаҗигале тавыш белән)* Фетнә, олуг хан! Диван бәге, Карачы, Саружа сине үтерергә телиләр!

Хан. Шул гынамы? *(мыскыллы елмая)* Шундый вак-төяк белән минем хозурга керергә ничек жөрьәт иттең, көчек?!

Казый. Ни—ичек?

Хан. Син дә шулар белән идең бит. Хан аркасына дүрт пычак... Вакыты житкәч шыр жибәрденме?

Казый. Синең өчен гомерем жәл түгел!

Хан. Буш вәгъдәләр бирмә. Гомер—комарлы уен. Сезнең кебекләрнең аннан бер дә аерыласы килми. Миңа... Миңа, димәк, үлем шигырен язарга вакыт житкән. Ә мин шигырьләрне начар язмый идем!

**Ул үз уйларына бирелеп, беравык тын утыра.**

Син күпме кешенең жанын кыйдың, үлем исеннән исердең. Бервакытта да шул үлемне үзең татып карыйсың килмәдеме? Әллә син арый белмисеңме? Кеше башы таудагы таш кебек, берсе кузгалса, үзе артыннан башкаларны да иярттә *(чыгарга ымлый)*.

**Казый чыга.**

*(үзалдына)* Гомеремне соңгы ноктасына кадәр үзем язам дип уйладым. Баксаң, аны әллә кайчан кемдер язып куйган икән... Менә хәзер аны берничек башка юлга борып булмый. *(кычкырып)* Шыгауллар кайда? *(Акрын)* Алар бүген көне буе булмады түгелме соң?

**Еракта шау-шу, кылыч чыңлаган тавышлар ишетелә. Алар һаман якыная бара.**

Хан. Берүзем, берүзем... Кеше туганда да берүзе туа, үлгәндә дә берүзе...

**Ишек шәрран ачылып китә дә аннан Карачы, Диван бәге, Саружа, титаклап Казый килеп керә. Аларга кораллы нөгәрләр ияргән.**

Хан. Ау башланды!

**Керүчеләр ханга ташланалар. Һәрберсе аңа пычак белән кадый. Кычкырган, сүгенгән авазлар ишетелә. Хан бер-ике адым читкә атлый.**

Хан. Бүтән уятмагыз... *(Егыла)*.

**Саружа аягы белән ханның гәүдәсен этеп карый.**

Саружа. Бетте...

Диван бәге. Ау тәмам!

**Шул вакыт ишектән чәче-башы тузган Ханикә йөгереп керә, тезләнеп ханны кочаклап ала.**

Ханикә. Ире-ем! Бирдебәгем... *(сулкылдый)*. Без бергә... бергә!

*Пәрдә*



## Мөхәммәт Мирза

### ӘТКӘҢ-ӘНКӘҢ ФАТИХАСЫ

Күңелемнең шик-тапларын
кырып аласым килә.
Биләүдәге нарасыйдай
саф-пакь каласым килә.

Көтмәгәндә күкләр күкри,
Көтмәгәндә җир тетри.
Көтеп-көтеп син килмәсәң...
Җаным тетри һәм күкри!

Заман җилләре исә лә,
маңгайны эзләр кисә...
Җанкаеңны кем җылытыр
челләдә кырау тисә?..

Мөнбәрдә исәп-хисапчы:
—Без әйбәт,—ди,—гел алда!

Мөхәммәт МИРЗА *(1953)—шагыйрь, «Турайгыр» исемле китап авторы. Актанышта яши.*

**Шулай күренәсең килсә,**
**Күз дә йомма, гел алда!..**

**Кояшта да таплар бар,—диләр,**
**бәндә ничек булсын тамгасыз?**
**Уң битемдә нокта-миң—бәлки,**
**күңелем күзенең бер алмасы?**

**Мин ярлардан, ахры, ерагаям**
**Җилкәнемне җилләр куа кая?..**
**Җир читенә җиткән җете комач**
**Сүнеп, бетеп бара—байый торгач...**

**Йөксез поезд кебек шакылдап тик,**
**үтеп китеп барды шигырьсез көн.**
**Кызарып каралды офык чите,**
**әллә болыт купты, әллә төтен?..**

**Йөрәгемә дәштем:—Түз!—дидем,**
**газапларың бер көн чигенер.**
**Ак сөлгедәй ап-ак көн килер:**
**илһам нуры белән чигелер.**

**Еракларга китеп кара, диләр,**
**Үз хәлеңне анык белергә.**
**Китмичә дә беләм, хәйран калам:**
**—Ничек мөмкин шулай бөлергә?!**

**Атылды йолдыз—**
**янды кем җаны?**
**Сөреме каплый**
**ярты дөньяны...**

**Тарих тамырыннан**
**төртеп чыкты курпы:**
**куркып калды дөнья:**
**—Тартар, татар, ургы...**

«Бисмиллаһиррахман иррахим»—
фатихасын сорау Ходаның.
Оныттырыр өчен шул җөмләне
Иблис һәрчак уяу торадыр...

Талгын җил йөземә ягылды,
пышылдап: «—Боекмачы,—диде,
Җил түгел, син икән, син икән
юатмакчы буласың мине...

—Дусларың шәпләрме?—дисең,
дуслар шундый төстәрәк:
—Берсе суга тез астына,
берсе үрелә өскәрәк...

Тышта кырлач—бүрәнәләр
шартлап ярыла...
Уйда Сабантуйлар... Җәйне
күңел сагына...

Сорыйм шигем калмасынга:
—Кайсы ялганың, чының?
Утырдың кем арбасына,
Җырлыйсың кемнең җырын?..

Шүрәле бармагы сыман
кысылды көн
Күк белән Җир арасына:
Җирдә мәңге чарасызлык
Адәм-Хава баласына.

Фани дөнья сынар өчен дан, мал бирер,
Әмма чиксез—бары вакыт үзе генә.
Югалту һәм табу чиратлашып килер:
Рәхәтенә, хәсрәтенә син түз генә.
...Аллана, баллана алма тик көз генә.

Ялкынына ураласым килде,
Ташкынында килде агасым.

**Уралыплар актым—бәхетемне таптым**
**Инде**
**Күзалмаңда килә каласым!..**

**Шөгыльсез үтмәде көнем—**
**сугардым гөлләремне.**
**Шигырьсез үтмәде төнем—**
**Җаныма елышып, гөлләр**
**күкләргә үрләде гел...**

**Кем чигеп үргән читән бу,**
**Кем йөреп салган сукмак?**
**Яр ярылып аерылган—**
**Ишелми калган туктап:**
**Өзелмәгән бер тамырдан**
**Тал үсеп килә, сутлап...**

**Үргә аккан чишмә-суны**
**Күреп хәйран калганым бар,**
**Үргә аккан инеш-суга**
**Карап күзем талганы бар...**
**...Табигатьнең без белмәгән**
**Илаһи бер ялганы бар...**

**Нидер язмак булып утырам да...**
**Исемеңне язып куямын...**
**Ак бит тула синең исем белән,**
**Бүлмәм тула синең исең белән,**
**Үзеңне дә янда тоямын...**
**Син бер үзең—шигъри дөньямы?**

**Сынды җәй—**
**Сарылды**
**Сарылык...**
**Сулды гөл:**
**Сабырлык,**
**Сабырлык...**

## Шифаханәдә

**Палата—буш;**
**Таракан—мыж;**
**Күршеләр—«чуж»;**
**Барсы да—гыж;**

Урамда—кыш;...
Бүлмәдә—тыш...
Бу, әйт, кай төш?..

Гөл-чәчәкләр арасыннан
Әзлим сиңа охшаганын...
—Охшаган,—дип ышанамын...

... Мин бар кыйммәтләрне
Шигырь бизмәненә
Салып үлчим хәзер...

...Иртәсе, иртәсе!
Энҗегә төрелгән
Җир—күкләр иркәсе!..

Ычкынды гомер йомгагым,
белмим кая тәгәрәсен:
—Бармы юрар мәгънәсе?!.

Әткәң-әнкәң фатихасы
Имин итәр ил-көнеңне,—
Рухлары нурга коенсын!..

Үткелләрне үткәндә дә,
Зилзиләләр искәндә дә
Куллары җылысын тоерсың...

Әткәң-әнкәң фатихасы—
Һәрчак шуңарга сыен Син!..

Ак болыт кичте Иделне
Табанын да чылатмый.
Йомшак җил үтте йөгереп,
бер дулкын да чыгартмый.
Торналар очып үттеләр,
аккошлар, кыр казлары:
хәтеренә чорный Идел
төсләрен, авазларын...



# Рифә Рахман

## ЮРЫЙМ ЯХШЫГА

Керфекләрне ябыштыра уйлар,
Кашларымны җыя бер турга.
Нәрсә көтә бездән килер заман?
Ул заманны юрыйм яхшыга.

Хәрабәләр калмасын ла, димен,
Безнең сугыш уйнап йөргәннән.
Киләчәкнең уенчыгы нинди?
Уйнармы ул, атлар йөгәнләп?

Уйнармы ул? Тугай-болыннарда
Ясармы ул әйлән-бәйләнле төн?
Сөйгәннәрнең күзләрендә генә
Серле нурлар сирпеп сүнәрме көн?

Агармы төн көймә өсләрендә,
Җырлар җырлап, таң атканга кадәр?
Әй Киләчәк! Син ишетсәң мине,
Төбәп карап торам, бир, хәбәр!

Нәрсә көтә мине офыгымда?
Куллар болгыймы ул, тизләтеп?
Син, Киләчәк, абынганны безнең
Торасыңмы, тыныч күзәтеп?

Керфекләрне әнә шундый уйлар
Җыеп куя минем бер турга.
Безне ничек бәяләрләр, димен...
Ул заманны юрап яхшыга.

---

Рифә РАХМАН—*шагыйрә. «Шук алма, моңсу алма» , «Күзләрең төймәләнсә», «Төнге кояш» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

## Сихерләнгән ай

Әле таң да уянмаган,
Әле көн дә—йокыда.
Су буенда чегән кызы
Чәчен тарап утыра.

Иткән күзгә зәңгәр күлне,
Тон җилен иткән тарак.
Ай селкенми—сихерләнгән,
Чегән кызына карап.

Һич аннан күзен алалмый,
Кымшатмый иреннәрен—
Шаккаткан, суга керде, дип,
Салмыйча киемнәрен.

Юеш тәненә тараткан
Толымнары чем-кара!
Ай йолдызларны оныткан,
Чегән кызына карап.

Әле таң да уянмаган,
Әле көн дә—йокыда.
Чегән кызы ай нурыннан
Чигү чигеп утыра.

Ай селкенми, сихерләнгән,
Чегән кызына карап.
Башыннан алып кадар күк
Чәченә алтын тарак!

## Хәерлегә булсын!

Хәерлегә булсын бу күтүем.
Хәерлегә булсын өметләр.
Кемлегеңне ничек аңларга соң?
Кемлегеңне әйтми болытлар.

Безнең яктан син бик ерак шул—
Ак болытлар агып барырлар.
Йә кайтырлар, миңа сәлам алып,
Йә янында синең калырлар.

Авырайса, алар шунда калыр,
Минем барлыгымны онытып.
Хәерлегә булсын, болытларны
Озатканда калдым ут йотып.

*

Яшел җәйгә, артык эссе җәйгә,
Кит, дип әйтү авыр тиктомал.
Ул бит, китмәс өчен, бакчабызның
Коймасына килеп тотынган!

Бәпкә-чеби үсеп беткән юкса,
Бозау-бәрән кергән абзарга.
Яшел җәйнең нигъмәтләрен күрсәң,
Ис-акылың китә базарда.

Кайдадыр көз ул киткәнне көтә,
Эшләр көтә безне, сагынып.
Алай икән, нигә әле төндә
Елыйм, ял иткәнне сагынып?

Ирнем белән яфрак өзгән булам,
Агач асларында утырган...
Яфракларда җәй тәмнәре тора!
Ул—агачка килеп тотынган!

Син шаярып кына әйткәнсеңдер,
Ә мин менә никтер алдым чынга:
Сары яфрак куып йөргән җилнең,
Аяк чалдым, чыгып каршысына.

Ул өзмәсә, төшми торыр яфрак.
Агачлар да куркып саргаймаслар.
Яфрак куган җилгә охшаш бит син,—
Сөям!—диеп, миңа хат язмаслар!

Шаярып та миңа хат язмаслар,
Яфрак өзеп аткан кебек кенә.
Сөям, дигән сүзең тамыр җәйде,
Йөрәгемнән атчы өзеп кенә.

Син өзмәсәң, һаман ныгый барыр,
Аннан шытар, яшел яфрак ярыр...
Булмый синңа, булмый, аяк чалып...
Җил күк юкса яфрак куган чагың.

## Хыял очы

Мин ярата алмам инде Сезне,
Яратмагыз, дип тә үтенмәм.
Сезнең хыял чиген белмим шул мин,
Үземнеке инде сүтелгән.

Очын тарткан аның бәгырьсезләр,
Йөрәккә юл шуннан үткәнгә.
Мин оялып кечерәеп киттем,
Сез шуның җеп очын үпкәндә.

Кыенсынам, хыял буйлап түгел,
Үтсәгез дә минем җиң аша.
Сезнең теләк чиген белмим шул мин,
Үземнеке җанга тоташа.

Ярата да алам, яратмый да...
Яшәсәм дә ничек, үкенмәм.
Сыпыла җан, Сез кагылган саен...
Ә хыялым тәмам сүтелгән...

Кешеләр бу җиргә берәмләп күмелгән.
Гомерләр кайвакыт тау булып өелгән.
Күзәтә фәләкләр, күкләрдән текәлеп,
Күзендә—атылган йолдызлар меңләгән!

Күзендә кабыныр, яначак йолдыз да
Аз түгел, ә бит ул барыбер сүнәчәк...
Сүнгәч тә, кемгәдер пар булып, бар булып,
Көн саен төшенә җемелдәп керәчәк.

Кешеләр бу җирдә тау булып өелгән,
Һични юк кадерсез кешедән, гомердән!
Хыялый күңелләр, куркусыз йөрәкләр
Сөңгеләр очында күкләргә чөелгән.

Фәләкләр күзендә йолдызлар меңләгән,—
Булмаска!—хыяллар сибелгән, вакланып!
Йөрәген кулына ут итеп тотканнар
Яшәми язмышның утыннан сакланып...

*Гәрәй Рәхимгә 60 яшь*

**Марсель Галиев**

## “ЧЫН ИСЕМЕ—ГӨРГӨРИ...”

Кайда син—кылганлы тау кашагасыннан йөгергән, жәядән йолдызлы күккә каратып ук аткан, бәрәңге төбе өйгәндә китмән белән аяк бармагын канаткан, сусап, жиләктән кайтканда, арба эзенә ятып, тонык суга төшкән бер уч ак болыт шәүләсен эчкән Гөргөри атлы малай, кайларда син?

Офыклардан кул изәп чакырасың да... әрекмәнле таллыклар арасыннан, әйдәкләп, аланнарга алып чыгасың да... Инде куып житеп, салпы колагыңны борам дигәндә генә... жил шәүләсенә әверелеп, Колмаксар әрәмәләренә кереп югаласың.

Шагыйрь, балачак иленең чик сызыгында туктап, хатирәләргә бирелә.

Ятим калган туган нигез...

Киселгән агач төбе ...

Алтмыш тапкыр бөтерелгән еллар божрасы—Шагыйрь гомере...

Менә колакка хөсетсез жил пышылдый, бүтән беркем дә бу дөньялыкта алай ук жылы итеп әйтмәячәк сүзне пышылдый: у—лым... Әнкәсе Пикыла тавышы. Ул бит аның әнисе—Үркәй Пикыласы (Арина Фекласы) жил телендә, улына дәшә, үткәннәрне исенә төшерә. Дәһшәтле 1941 елда, сабан туе көнне, ире Үкчей Бәчкәсен (Аксинья Василиен) бүтән хатын-кызлар ирен озата барган кебек үк авыл башына кадәр озата бара алмаган шул. Хәер, моның өчен ире үпкәләмәгәндер, хатынының карынында туачак баласының йөрәк тибешен учында тойгандыр һәм шул бер уч кодрәт аны Берлинга кадәр хәвеф-хәтәрдән саклап озата баргандыр. Шулай итеп, ирен яу кырына озатып калганнан соң, өч көн үткәч, Пикыла бу жиһанга, яшәү даулап, үжәт аваз салган ир бала тудыра. Бу сабыйның уң жилкәсенә утырып, кылган изге гамәлләрен исәпләп барасы фәрештә “Шагыйрь” дип язып куйгандыр.

Ваемсыз үтәсе балачак күгенә сөремле сугыш шәүләсе төшкән.

Атаклы Шандор тауларын, жилдә тибрәнгән вышкаларны, кара алтын фонтаннарын күреп үскәнгә күрә, чабаталы якларда туып-үскәннәрдән уй-хыялы белән бер башка югары торган егет, ниһаять, Казанга килә. Университетның мәһабәт ак колонналары арасында кайчандыр Толстой, Аксаков, Ульяновларның башыннан сыйпап искән жил, борынгы учы белән, керәшен егетенең дә маңгаена кагылып үтә: “Миннән сиңа фатиха...”

Егетнең букчасында үтә күренмәле хисләрдән торган самими шигырьләр...

Үзе белән ияреп килгән туган як табигате—тыйнак таулары, Колмаксар каеннары белән ул колонналар арасыннан сыеп керә алмыйча, бер мәлгә каушап-куркып-икеләнеп, олуг белем сарае каршында басып тора.

Кырыс шәһәр кабул итә риясыз егетне. Аннары инде башлана...

Танышулар.. һәр килеп кергән яшь каләм иясен сындырып сыный торган иҗат Галәменә башны иеп керүләр.

Рәсми кәгазьләрдә гомере буе Григорий Родионов булып каласы егет, олуг шагыйребез Хәсән Туфан киңәше белән, иҗатта төрки-мөселманча—Гәрәй Рәхим дигән исемгә әверелеп китә. Күп еллардан соң, шаян холыклы Шагыйрь, үзеннән көлеп, болай дип язар:

Родионов чакларда
Сикереп мендем атларга.
Сикереп мендем, егылып төштем
Гәрәй Рәхим чакларда.

Онытылырлыкмыни узган гасырның алтмышынчы еллар шаукымы! Илдә—рухи күтәренкелек. Мәскәүдә шигърият дөньясы кайный. Булат Окуджава, Евгений Евтушенко, Белла Ахмадуллина, Андрей Вознесенский, Роберт Рождественскийлар шигъри сүз егәре белән мәйданнарны, стадионнарны алалар.

Кызыктыра каһәрләр...

Империя учыннан төшкән бу шагыйрьләр сәләт һәм мөмкинлек ягыннан чагыштырусыз өстенлеккә ия булсалар да, боларга кызыгу шаукымы Казанның да яшьләрен бер тирәгә туплый. Чәчелеп калмыйча, бүгенгегә килеп җиткән чордашлардан: Гәрәй Рәхим, Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Рөстәм Мингалим, Рәдиф Гаташлар бүген дә шигъриятнең дулкынында, сүз егәрен кулда тоталар.

... Ул гөнаһсыз чакның хатирәләре... Танышулар, сынашулар башы... Һәммәсенең үз туфрагы, үз чишмәсе, үз нәсел агачы—холык-фигыльләрен шулар чарлаган. Тел коелары да төрле тирәнлектә... Болар, Сабан туе мәйданына чыгасы көрәшчеләр кебек, бер-берсенең ихтыяр көчен, торыш-кыяфәтен, беләк-тән ныклыгын, фикри егәрен, күз карашы үткенлеген сынашалар (күңелгә ятышмаганнар читкә тибәрелә).

Ә эчтә—хыял даласында пегас-айгыр үрә баскан, яңгыратып кешнәве җанны кытыклый, араннарны сикереп чыгып, шигърият мәйданына ыргып, йөрәгенне тояклары белән кага... Моны һәммәсе аерым-аерым гына белә. Бу—тирәндәге кодрәт күз карашыңа, йөз кыяфәтеңә, йөрешеңә, иреннәрең кысылуына, җилдән чәчләрең кайнап-тузгып алуына—бөтен вөҗүдеңә күчеп тигез таралган. Һәм ул бер кәлимә сүз белән аңлатыла—я ш ь л е к...

Алтмышынчы еллар... Күндәм халыкларның кан тибешенә күчкән Сталин исемен дә тетрәтеп куйган, саркып кына булса да, зинданнар төбеннән хакыйкатьнең кояшка чыгу дәвере... Аяусыз цензура балтасының үтмәсләнебрәк калган бу чорында әле генә исемнәрен атаган шагыйрьләр төркеме кыюрак фикерләргә дә кармак салалар:

Йөрәкләр турында язасы бар әле,
Атылган йөрәкләр,
Ватылган йөрәкләр,
Сатылган йөрәкләр турында.
(Атылган йөрәкләр күптәннән кабердә,
Сатылган йөрәкләр исәннәр хәзер дә.) —

дип яза Гәрәй Рәхим. Бу әле Шагыйрьнең сиземләве аша хәбәр биреп куюы гына. Тирән катламнарны ачасы өмет-омтылышлар дәвамы алда, хәтәррәге алда булачак әле... Әмма, озак та үтмәс, хакыйкать капкалары кабат ябылып, җәмгыятьнең кеше гомере белән уйнаган астыртын эш-гамәлләре, мәкерле алымнары хакындагы дәреслек тыюлык зонасында калыр. Янадан чирек гасыр үтеп, сүз ирege килгәндә исә яшьлектәге күнелнең кайнар тояклы ялкыннары инде сүрелеп, көл белән өртелгән күмергә әверелгән булыр. Еллар аша эчке сыкрану хисе Шагыйрьнең мондый юлларына күчәр:

Дөрләп-дөрләп ала
Уйдык-уйдык уйлар...

* * *

Шаянлык—анын калканы.

Үзеннән дә көлә белү—анын саклану чарасы түгелме?!

Юк, моны ул ан-зиһен аша үткәреп, бүтәннәргә ошар өчен эшләми, жор күнеллеге анын табигый рәвештә, эчтән, нәсел тамырларыннан ургылып чыга. Тапкыр-уенчак сүзгә күчеп ул үз күнеленә дә шифа бирә, үзен сыгылып-сынып калудан коткара һәм, көлү яктысын бүтәннәргә дә мул өләшеп, үзен яраттыра белә.

Кайчакларда ул еламас өчен көләдер шикелле...

Татарның империя тоткан дәверле чагы хәтерендә сүнеп бетмәгән әле, юк-юк та бер канында уйнаклап ала; бу анын әче телендә, кинаяле әйтемнәрендә чагыла. Кешенен берәр ошамаган сыйфатын кире яктан бәяләп, мукшы ... чирмеш... чуаш... керәшен... мишәр... диеп, шул кавемгә хас сыйфатны купайтып, мыскыллы кушаматка әверелдерә. Гомумән, империя хужасы саналган милләткә аяусызлык, үзен өстен кую, тәкәбберлек хас. Инде күптән дәүләтен жуеп, үзе дә буйсынучы кавемгә әйләнгән татарда бу сыйфатлар гасырлар юшкыны астында калган югыйсә, әмма кайчакларда йокымсыраган песинен төшендә үзен арыслан итеп күрүе кебек, зәгыйфь кенә тәкәбберлек хисе өскә калка да теленә чәнечкеле сүз булып күчә.

Әгәр һәрдаим "керәшен" дип тукып-искәртеп торганга Гәрәй Рәхим үпкәләп, кимсенеп йөрсә, тагын да әрсезләнебрәк анын жанына тоз салып гажиз итәрләр иде. Мондый чакларда аны йомры сүз—юмор коткара. Ә инде фәлсәфи уйлар эчтә, тирәндә кала...

Табынган манаран очы хач белән тәмамланамы, табынган манаран ярымай белән күккә тоташамы—ата-бабаларын сайлаган язмышны бүгенге ихтыярга буйсындыра алмыйсын, давыллы чорларны кичеп чыкканнар шул алар. Христиан дине дә, мөселман дине дә бөтенләй бүтән кинлектә, бүтән шартларда гомер сөргән семит халыкларыннан кергән безгә. Табынган аллабыз—Тәнре булган, динебез—мәжүсилек, ягъни табигать белән бер жан, бер тән, бер рухта яшәү рәвеше булган, дип саный Гәрәй Рәхим.

Бер йодрык булып төйнәлә алмаган халык язмышы да борчый аны. Төрле исемнәргә бүлеп, эчтән үз-үзен таркатырга адарынган милләткә Шагыйрь, ачынып, болай ди:

Әй татар, татар гынам,
Татар гынам, тар гынам.

* * *

Кәефе нинди чагы булмасын, Гәрәй Рәхим борчу-гамьнәрен иненнән кагып төшереп, бусага артында калдырып керә белә. Нинди даирәгә килеп кушыла ул—редакцияме, "кофер почмагы"мы, мәжлесме—кайда гына булмасын, уенчак дилбегәне үз кулына алыр да...сөйләсә—батырып сөйләр, жырласа—өздереп жырлар, көлсә—рәхәт чигеп көләр... Таралу-хушлашу мизгелендә, аны якыннан белмәгәннәр: "Кара инде, бу Гәрәйнен бер генә борчуы да юк икән", дип калырлар. Ул чыгып киткәч, мәжлеснен "пары" суына башлый, илһамлы сүз дәрте сүрыга, утырдашларнын кызыгы бетә.

Шагыйрьне исә бусага артында зарыгып көткән гамь-борчулар култыклап ала. Менә ул, уйларын иненә салып, төнге дөнья уртасыннан үз-үзенә кайтып бара.

Ялгызлык—жанга сихәт алу халәте.

Ялгызлык—үзенне чыбыркылый алырдай гадел хөкем мөнбәре.

Ялгызлык—күнелнен ялангач асылы.

Үз теләге белән кергән ялгызлык халәтен Шагыйрь "аулак" дигән серле мәгънәгә төрелгән сүз белән билгели: "Ни өчендер мин гомерем буе аулак урыннарны яраттым".

Аулак кояш,
Аулак Ай, йолдызлар.
Аулак Марс,
Аулак Венера...
... Мин алардан аулаграк бугай,
Фикри япа-ялгыз мин торам.

Чордашлар, каләмдәшләр, көндәшләр, аркадашлар арасында үткен сүз кисеше, елгыр фикер бәйгесенә тиң гәп-бәхәсле, кайнар әңгәмәле табыннардан соң күнеленә савылып моңсулык инә, шау-кайтавазлары тынган җанында тик бер үзең генә тойган сулкылдау-әрнү таралган упкын хасил була. Мондый чакларда болгавыр, кырыс Казанны ташлап китә дә Шагыйрь туган төбәгенә—"Шөгер" белән "йөгер"не рифмалаштырган якларына, садә балачагы узган нигезенә кайтып, аулак урынга чыга да... рәхәтләнеп бер түгелә....

Елыймын мин ялгыз рәхәтлектән.
Сабый чаклар хатирәсеннән.
Каралтылар белән бергә елыйм,
Үксеп-үксеп елыйм һәм көләм.

Үзем уйлыйм: ярый әле димен,
Еракта мин шәһәр, дуслардан.
Мескен хисләр, диеп, юкса, алар
Көләр иде минем елаудан.

Шагыйрьнең болай шик белдерүендә хаклык юк димә. Бүгенгедәй күз алдымда: сәхнәдә—Гәрәй Рәхим. Мул сакал-мыеклы, нәселле борынлы, рәссам кыю, эре сызыклар белән ясардай йөз—кыяфәт. Менә ул сәхнәдә аякларын аерыбрак, нык басып "Каралтылар белән бергә елыйм" дигән әлеге шигырен сөйли. Килешеп тә бетми кебек ир-егеткә. Ул чакта бу шигырь мәзәгрәк тоелган иде миңа. Яшьрәк булганмын шул. Казанның таш салкыны күңелемә күчәргә өлгермәгән яшьрәк үсенте булганмын ул чакларда. Намус, тугрылык дигән төшенчәләрнең хәлиткеч мизгелдә төшеп уаласын, дус дип йөргән затларның астыртын-мәкерле гамәлләренә тарасымны белүдән хали булганмын икән. Үземнең дә шулай, туган нигеземә кайтып, ихатаның аулак бер почмагында, төнге күккә карап, йолдызларны күз яше белән юып, үпкә-әрнүләрдән бер чистарынып кайтасымны күз алдыма китермәгәнмен. Андый чакларда бу шигырь юллары искә төшәр, ялган каһарманлык рухы белән сугарылган, "барабанлы шигырьләр"дән күпкә өстен, чын, риясыз хисләр белән өртелгән юлларны мин күңелемнән пышылдармын һәм Шагыйрьгә рәхмәтле калырмын.

Гәрәй Рәхим үзенең хәсетсез күңелен бу шигырендә тагын да ачарак төшә:

Шунда мине әнкәй табып ала.
—Таң ата,—ди—кереп ят, улым.
Көлә-көлә сөеп юата ул
Утыз яшьлек карт бер сабыен.

Мин әнкәйгә үкси-үкси сөйлим
Шәһәрдәге дуслар турында:
—Алар, әнкәй, шундый әйбәтләр,—дим,—
Кечесе дә,—димен,—зуры да.

Менә бит ул: туган нигез,әнкә нигезе аны ничекләр юатты, шәһәр корымын тәненнән дә, җаныннан да кагып төшерде. Хәзер инде ул беркемгә рәнҗеми, һәммәсен дә үзе кебек якты, күләгәсез итеп күрәсе килә. Ул тагын Казанга ашкына, ул тагын матур итеп алданырга әзер...

Бәхетсезлегемдә бәхет күреп
Яши торган мәхлук мин җирдә.

* * *

Казаннан ерак түгел "Волга" халыкара лагерында узган гасырның 70-80 елларында яшь иҗат көчләренең семинарлары була торган иде. Монда язучылар, рәссамнар, артистлар, музыкантлар катнаша. Яна әсәрләр уку, лекцияләр тыңлау, күргәзмәләр карау, кичләрен танцы, ял итү, гашыйк булулар, Иделдә көймәдә йөзү, төнге учак янында таңга кадәр җырлашып утырулар дисеңме—бу истәлекләрнең сүнә барган кайтавазы гына күңелдә хәзер.

Бер елны, гадәттәгечә, май аенда барып төштек берничә автобуска төялешеп. Бөтен җирне ялт итеп буяганнар, кая карама, анда—"Осторожно, окрашено!" дигән язулар тора. Кәефе килгәндә һәмма нәрсәдән мәзәк табарга яратучан Илдар Юзеев карап торды да:

—Һи—ии, монда Гәрәй Рәхимне генә beләләр икән...—ди куйды. Тел төбен аңламыйча, аптырабрак калуыбызны искәреп:

—Күрмисезмени, бөтен җиргә "Осторожно, о крашен!" дип язып куйганнар,—диде. Шулчак безнең дәррәү көлү тавышыннан нарат урманы сискәнеп куйды. Әлбәттә, безнең бердәм авазларны күмеп, Гәрәйнең хахылдавы шәбрәк яңгырады.

Монда кояш—җил—су кочагында истирәхәт кылып берничә көн яшәп алган дәвердә бер-беренне якыннан белү, аралашу өчен сукмаклар такыр. Еллар үткәч, бер-берсе белән мәңге аралашмаячак төркемнәргә бүленүләр әле шәйләнә генә...

Гәрәй Рәхим үз чордашларына караганда үзгәрәк иде: киеме, үз-үзен тотышы, шигырьләре дә бик гади. Артык гадилекне женем сөймәгәнгә күрә, мин аны башта бик үк өнәп тә бетермәдем шикелле. Гадилекне санга санау кая... үзең дә аңламаслык шигырьләр язарга кызыгып йөргән чаклар бит ул. Шакмаклы такмаклардан туйганбыз, ак ясисә ирекле дип йөртелгән алама сурәтле шигырьләр генә безне кызыктыра иде. Ауропаның яһүди шагыйрьләре кузгаткан бу жимергеч дулкын татарга Такташлар чорында килеп керә һәм, алтмышынчы елларда Әнвәр Давыдов, Шамил Анаклар моны кабаттан яңартып, яшь шагыйрьләргә йоктырган иделәр. Гәрәй Рәхимнең баштагы чор иҗатына бу шаукым канат очы белән, йомшак кына кагылып алды. Гаҗәеп моңга бай, тел хасиятенең үтә нечкә кылларын тибрәткән, төрки-шәрык шигъриятенең гүзәл үрнәкләрен, хисләрнең мәҗүси садәлеген саклаган керәшен җырлары тәэсирендә үскән егет өчен бу шаукым ят иде.

Шулай итеп, күпме еллар дәвамында таланып, имгәтелгәнен аңлап, үз асылына, Шәрыкка соңлап әйләнеп кайтучылар язмышы аңа тимичә узды. Ярсулы хис, галәми фикер белән мавыккалап алса да, Шагыйрь, башын күтәреп карагач (йолдызларны кем дә күрә...), көзге урманның үз халәтенә тиң бер күренешенә тап була:

> Ботактагы буш ояда
> Бер уч җылы посып тора.

Бер уч җылы... Шагыйрь бәгырендә ул—кайнар йомгак, күкрәктән суырып алуга суына да, кешеләр күңеленә күчәсе бер уч җылыга әверелә. Ул йомгак очы ата-бабалар рухына күзгә күренмәс җеп очлары белән тоташкан.

Бер уч җылы... җаны суына барган чакта, инде яшәүгә өметен өзгән мәлдә Тәңре ут тергезгән шул бер уч җылы коткарып калгандыр аны...

Маңгаена Газраил салкын кулын куйган мизгелне Гәрәй Рәхим утыз дүрт яшендә кичерде. 1975 ел кышы. Казан яны, Каменка санаторие. Сынар тәрәзәле аерым палата. Тәрәзә каршында урман шаулый. Шомлы төннәр өметкә сусаган көннәр—дисбе төймәләре кебек тезелеп айларны хасил итә. Шагыйрь кан төкерә. Табиплар әллә нинди дарулар биреп сыныйлар, тикшерәләр, профессорлар чакыртып киңәшәләр. Үпкәдән кан килүе тукталмый. Алда ни көтә Шагыйрьне? Сүнеп барамы гомер шәме? Өметсезләнеп, түшәмгә карап кына ятсаң, хәлсезләнә барган тәнең мәкерле чир-сырхау ихтыярына отыры бирешәчәк түгелме?

Ниһаять, Гәрәй Рәхим дүрт стена белән чикләнгән кысан палатада бәргәләнеп, өметсез-хәвефле уйлар чолганышыннан котылу юлын эзләп, кулына каләм-кәгазь ала, үз-үзенә читтән карап яза башлый:

**"... Кызык, монда ул бары тик узган гомере турында гына уйлый ала. Ә киләчәк турында... Юк, ул монда киләчәк турында уйлый алмый иде".**

Күрәсез, киләчәккә аның күнел тәрәзәләре ябык. Ул, үзе дә сизмичә, бу дөнья белән бәхилләшергә җыена. Үткән гомерен барлап, андагы хыялларын (тормышка ашкан яисә ашмаганнарын) тәртипкә китереп, үлемне җиңеп үләргә ниятли. Юк, шигырь кысаларына кереп, бер көйгә тирбәлергә аның түземлеге җитми, җаны тарыга. Ишелеп килгән уйларына киңлек, иркенлек, хөрлек кирәк; менә алдында яткан ак кәгазь кыլганлы далага әверелә. Япан дала уртасыннан барган эзләр үткән көннәргә, үткәннәргә таба йөгерә. Тизрәк, тизрәк, дип пышылдый йөрәк кагышы. Кинәт уйлар агышы сөртенеп китә... Карлы кыр аклыгында ахактай кан тамчылары пәйда була—яралы җәнлек эзләреме? Юктыр, ул бит үз гомерендә бер генә җан иясен дә кыерсытмады, бер генә бөҗәкнең дә гомерен кыймады... Карлы кыр тарая, тарая бара һәм ютәлено буылган Шагыйрь алдында кан чәчрәгән кәгазь яктысы торып кала.

Хәл җыеп, ул янадан каләмгә тотына. Бу—сонгы әсәрем, дип, үзе генә белгән догалар укып, күк катларыннан мәрхәмәтле вакыт сорый; көнне төнгә ялгап яза да яза, шулай итеп рухын савыктырып хәл ала, әмма күзгә күренмәс тырнаклары белән үпкәне кысып алган чир бирешергә теләми, тәндәге егәрне суыра бара.

Гомер шәме, нәзберек күбәләк кебек, менә сүнәм, менә сүнәм дип тырпылдый...

Көннәр язга авышкач (Гәрәй Рәхимнең монда язган проза әсәре шулай атала) аны Ялта шәһәренә алып китәләр. Шушында аның үпкәсенә хәтәр операция ясала (сыңар үпкә урынында күкрәк читлегендә бушлык кала).

Аннары ... Алупка (Алып) санаторие. Үлеп терелгәннән соң, Кырым кояшы астында тагын айлар уза. Яшәү дигән бөек очраклылыкның яңа мәгънәләрен табып, сират күперен чыкканда кичергән җан тетрәве аша бу тормышның татлы да, газаплы да серен ачарга омтылу—әдипне тагын кулына кәгазь-каләм алып язарга ихтыярлый.

"Саргаймагыз әле, каштаннар"—язылачак әсәрнең исеме алдан ук туа. Йөзе суырылып, саргаеп калган Гәрәй Рәхим Кырым манзарасын яратып, көз урыны-урыны белән зәгъфран сарысы сирпеп үткән табигатьне юата: "Саргаймагыз әле...".

Элеккечә, һәммә нәрсәдән кызык табып, яшисе дә яшисе иде бит!

Гәрәй Рәхим, хәлен белергә, Казаннан килгән каләмдәшләренә Кырымда гына үсә торган могҗизаи агачларны, үз матурлыгын чак күтәреп торган



*Азнакайда әдәбият атналыгында. Сулдан—Р. Ишморатова, М. Галиев, җырчы Ж. Сәлахова, Г. Рәхим, М. Хәсәнов. 1975 ел.*

чәчәкләрне, дингез дулкыннары тетрәткәнгә изрәп оеган кыя-ташларны күрсәтеп йөри. Ике тапкыр Советлар Союзы Герое, легендар очучы Әмәтхан Солтан һәйкәленә чәчәк салырга алып бара. Кырым татарлары хакында искә төшерергә дә ярамаган бер чорда, онытылырга дучар ителгән һәйкәлгә барып баш ору—заманы өчен үзе бер батырлык түгелмени!

Кырымнан Казанга шундый хәбәр кайта: Гәрәй шаярта башлаган, димәк яши! Татарга бер үпкә житә икән, ике үпкә булса, үзара килешмәскә мөмкиннәр...—дип шаярткан, имеш, Пикыла Гөргөрие.

Тәнре анын гомер капусын ачып карап, бу жир йөзендә олы гөнаһлар кылмаган өчен ярлыкагандыр һәм ан-зиһенен фәһемле эшләргә генә юнәтеп, ана озын гомер юлы индергәндер.

Сынала...

Сыналу ызаннарын кичә инсан гомере ...

Шаянлык пәрдәсен ачып жибәрсән, Гәрәй Рәхимнен иртә олыгайган шәхес икәнен төшенеп аласын. Кырык бердә туган күпләрнен уртак михнәтле язмышы...: “Азык юктан бармак суырганмын—бик читләтеп үткән исәнлек”.

Студент чагында әтисе Василийнын хәвефле үлеме... Үзе авырып ятканда әнисе Фекланы сонгы юлга озатканнарын белү үкенече ...—болар, эчке сыкрау булып, каләм очыннан күз яшенә манылып тамгандыр: “Әткәм—әнкәм булып тик син калдын, ятим итмә мине, Шигърият”.

Сабырлык—Гәрәйнен ин күркәм сыйфатыдыр мөгаен. Юк ла, тешне кысып түзү сабырлыгы түгел, ә табигый чыдамлык, кичерә белү олылыгы сыйган гадел сабырлык анарда. Вакыт белән бергә-бер калырга дучар ителгән әдип нәкъ менә шул сабырлык хасиятеннән үзенә көч-дәрман алып, әдәбиятнен ин төп һәм олуг жанры—прозада үзенчәлекле өслүбтә яза белгән саллы каләм иясе икәнен раслады.

Каштаннар матурлыгыннан туйгач, тал-өянкеләр күркәмлеге житерәк күренә икән шул. Туган якка кайтып төшкәч, Гәрәй Рәхимнен беренче ачышы шул булгандыр.

Янадан туып кайткач...

Кырым кояшыннан бер уч жылы алып...

* * *

Тәгәрмәчләргә чакрымнарны урап үткәргән көннәр—язучы кавеме өчен елга сирәк килә торган мәшәкатьле бәхет иде. Ул командировка дип атала, ягъни, син гаилә тозагыннан котылып, беразга үз-үзенә командир буласын. Мона—яна жирләр белән танышу да, халык белән очрашу киеренкелеге дә, үзара уйнап-көлеп, мәзәкләр чыгарып йөрү ваемсызлыгы да керә.

Менә без Азнакай якларына (1975 елнын кыш башы), аз да түгел, күп тә түгел—бишәү килеп төштек Казаннан. Олы яшьтә булуына карамастан, жилкенеп, каядыр чыгып китәргә һәрвакыт атлыгып торган Рәисә ханым Ишморатова, жиз тутлы йөзенә сирәк елмаю чыгарган Рөстәм Мингалим, жырлап бетереп, сәхнә артына чыккач, башка артистлар кебек сүгенә белми торган зыялы ханым Жәваһирә Сәлахова, боларны оештырып алып чыгучы—мин һәм... шушы чуар төркемнен жаны—Гәрәй Рәхим. Барыбыз бергә—шау килеп безне каршы алган Мәхмүт Хәсәновнын калын инсәләренә кунган чыпчыклар кебек чыркылдашабыз.

Клубларда халык шыгрым. Гәрәй Рәхим юка гына китабын залга күрсәтә дә:

—Бу минем беренче китабым—“Чәчәк сатучы малай” дип атала. Бәясе өч тиен,—ди. “Өч тиен” дигән сүздән Шагыйрьгә хөрмәт йөзеннәнме, халык аптырабрак кала, тыенкы гына елмаючылар да берән-сәрән генә күренә.

—Шушы китабым чыккач,—дип дәвам итә Гәрәй,—бик тә әче телле Мөдәррис Әгъләмов дигән шагыйребез мондый эпиграмма язган:

Рәхимсез Гәрәй Рәхим бу
Чын исеме Гөргери.
Өч тиенлек китабы бар,
И пычагым кергери.

Шул мәлдә зал шартлый. Кул чаба-чаба көләргә тотына һәм Гәрәй Рәхимне бер сулыштан яратып өлгерә.

Инде бу очрашулардан соң ничә еллар үткән югыйсә, Азнакайга кайтсам, "Теге ... өч тиенлек китап язган Гөргери нишләп йөри?" дип әле дә сагынып искә алалар үзен.

Азнакайда үтәсе көннәребез минутынача бүленеп куелган иде. Борчылу-кабалануга урын юк. Йөгерек юллар. Кунакчыл йөзләр. Тулы заллар. Мул табыннар. Әшен дә эшлибез, иртәдән алып төн урталарына кадәр, мәзәк табып, сулышка капканчы көлешәбез дә. Хәтта, ни житди Рәисә ханыбыз бүрәнә ярыгыннан да көләргә торган чытлык кызчыкка әверелеп калды. Мингалимнең дә жиз-төмсә йөзеннән елмаю китми башлады.

Соңгы көнне Мәхмүт ага Хәсәнов өендә мәжлескә жыелдык. Бер ягына хатыны—Мәрьям ханымны, икенче ягына Жәваһирә ханымны утырткан Мәхмүт ага өстәл башында бәхет тәхетендә, хан кебек рәхәт чигеп утырды. Табынны алып баручы—аның вәзире сыйфатында Гәрәй Рәхим иде.

Мәрьям ханым, ризык хәстәрен күрергә дип, кухня ягында югалып торгалый, Мәхмүт ага исә, бинихая гәүдәсен йомарлап, Жәваһирә ханымның куенына ук кереп беткән. Әрсезлеккә сәбәп калдырмыйча, күз карашы белән итагатьле генә читкә "этеп" куя белгән Жәваһирә ханымга да нидер булды: йөзеннән тигез тешләрен балкыткан елмаю китми, көч-куәте ташып торган ир заты янәшәсендә ул, мамыкка әверелеп, яшьлегенә кайтып бара иде бугай...

Бервакыт, Мәрьям ханымның күптән инде чыгып утырганын искәреп, Гәрәй Рәхим әйтә куйды:

—Мәхмүт ага, Мәрьям апа ягына да күз салып ал бераз...

Гашыйклык аллыгыннан парланган йөзле Мәхмүт ага, каерылып борылып карады да:

—И—и, карчык, син дә мондамыни!—дип, саллы кулы белән Мәрьям ханымның иңеннән шапылдатып сөеп куйган булды. Табын дәррәү кубып көләргә тотынды. Иренең канәгатьлегеннән кинәнү ала белгән Мәрьям ханымның да йөзенә эчкерсез елмаю жәелде.

Әнә шулай, гомернең Азнакайдагы биш көне, бер мизгелдә туып, шул мизгелдә үлә барган юморга, кытыклы-жор сүзгә, тузга язмаган тапкыр мәзәккә бай көннәребез, көлү мәрәкәсендә гөрләп, бүтән мәңге кабатланмаска дип үтеп тә китте. Казанлыларны озаткач, форсаттан файдаланып, мин туган авылыма, шимбә—якшәмбене үткәрергә дип әти—әни янына кайтып аудым. Аудым, дию, һич тә чынбарлыкка хилафлык китермәс. Күңелдә ямансу бушлык, ике тәүлек буе, Тукай әйтмешли: "буш шешә сыман аунап" түшәмгә карап яттым. Сулыш алулары да кыен, тамактан ризык та үтми, тәмәке тартырга да хәл юк—бөтен эч мускулларына кан сауган. Әни өзгәләнә:

—Кайсы төшең авырта соң, улым,—ди, өстәлгә төрле тәм-томнар китереп карый. Артык нык көлүдән авырыйм, дип әйтеп булмый бит инде әнигә. Чынлап та, чама белми көлүдән үлеп китүең дә бар икән бит... Түшәмдәге ботак сурәтенә карап, Гәрәй Рәхимне битәрләп ятам, әгәр ул булмаса, бу кадәр үк көләр идекмени, вәт керәшен шүрәлесе!

Гәрәй белән күрәселәр әле алда булган икән...

1982 елда мин Максим Горький исемендәге Әдәбият институтының Югары курсларына укырга кердем. Гәрәй Рәхим ул чорда Мәскәүдә яши, фатирлы, машиналы—тулы хокуклы башкала кешесе иде. Аның киңәшен тотып, институтның Добролюбов урамындагы тулай торакның жиденче катыннан "татарлар" бүлмәсенә урнаштым. Безгә кадәр укып киткән Туфан Миңнуллин, Гәрәй Рәхим, Ризван Хәмидләрдән мирас булып күпме савыт-саба, кирәк-

ярак калган, хәтта суыткычы да бар. Нәкъ тәрәзә каршында—Останкино манарасы.

—Ава-нитә калса, дип курыкма, мин ике араны адымлап үлчәп чыктым,—ди Гәрәй Рәхим шаяртып.—Ауган сурәттә, Останкинонык очы тәрәзәнең тышкы өлгесен ватып, жиде миллиметр гына керәчәк, зыян салалмый.

Гәрәй Рәхим бу чорда Сергей Михалков кул астында, РСФСР язучылар союзының төрки халыклар әдәбияты буенча әдәби консультант булып эшли иде. Институтта дәресләр беткәч, мин аның эшенә барам. Казан сагындыра. Гәрәйнең юмартлыгыннан файдаланып, казна хисабына, телефон кызганчы сөйләшеп, Казандагы дус-ишләрне бер селкетеп алам. (Соңыннан Гәрәй: "ике ел эчендә бер машиналык сөйләштең син телефоннан, шул кирәк урыс акчасына",—диде).

Эштән кайткан чагында без аның белән кайчандыр Муса Җәлил яшәгән Столешников тыкрыгына сугылабыз. Жир астына төшә торган баскычта бераз чират торганнан соң, Мәскәүнең ул чакта иң шәп саналган сыра барына эләгәсең. Монда бокалларга тир бәрдереп чыгарган салкын сыраны, егерме тиенлек көмеш салып, автоматлардан агызып аласың. Тәлинкә тутырып креветка, кара уылдык, кыздырылган бифштексмы китертәсең—һәммәсе дә илле тиен бәһадә. Гитлерның дөньяны яулау фикерләре сыра барында туган, диләр, безнең дә әдәбиятта бөек әсәр язып шаккаттырасы уйлар шушында килә.

Мин яшәгән тулай торак янында самолетлар куя торган ангар чаклы сыра бары бар иде. Анда берьюлы йөзләрчә кеше сыйгандыр. Бервакыт Мәскәүдә китап чыгару нияте белән килгән Мөхәммәт ага Мәһдиевне шунда алып киттек. Сыраны яратып, тәмен тәненә ләззәтле таратып, чамасын белеп кенә, сәнгатьле итеп эчә белә иде ул. Менә без кайнар буы чыгып торган биниһая олы чаннардан чатлы—ботлы зур-зур крабларны алдырып, бөтен килеш кенә үлчәтәбез (килосы биш тәңкә). Утын агачы сыман сындырып, эченнән савылып чыккан ап-ак, мәмрәп торган итне тел өстенә салып, салкын сыраны уртлап, Мөхәммәт аганың әсәрендәрә торган мажаралы хикәятләрен тынлый-тынлый... юк, моны бүгенге кимәлдән сурәтләп бирергә галиҗәнаб каләм көчсез...

—Их, егетләр, дөнья рәхәте бит бу, ә!—ди Мөхәммәт ага—Шушылай, беләк юанлыгы крабларны сындырып кабып кына сыра эчәрмен дип кем уйлаган. Гомердә бер генә була бу! Испаниянең Балеар утрауларының берсенә—Мальоркага тукталгач, эчкән идем шулай, анда краб итен мыскаллап кына, чемченерлек итеп кенә биргәннәр иде. Монда, күр инде син, күсәбәсе белән...

Остазның мәмнүн булуыннан без дә канәгать идек.

Бер көнне, Гәрәйнең өендә кунак булып утырганда, Вахит Юныс телефоннан шылтырата:

—Егетләр, миндә аулагый, хатын Мароккода командировкада, улымны Каһирәгә, алты айга практикага озаттым. Бер ялгызым гармунда уйнап, җылап утырам, хәзер ук килеп житегез,—ди. Без, әҗәкә ягып кыздырылган тавыкны кайнар килеш сөлгегә төреп, машина белән юлга чыгабыз. Вахит абыйга кадәрге ара илле чакрымнар булыр. Гәрәй, байлар төсе кергән чыраен күреп шикләнмәсеннәр дип, рульне кыю тотып, Кремль тирәсеннән, дәүләт житәкчеләре машиналары йөри торган урамнардан алып бара. Ниһаять, хәвеф-хәтәрсез генә барып житәбез, баянын иңенә аскан Вахит абый безне ишек төбендә каршы ала. Алдан сөйләшкәнчә, буйдак хуҗаның өстәленә зурлап, сюрприз итеп чыгарабыз дип тавыкны сиздермичә генә, алгы бүлмәгә яшереп керәбез. Керсәк, карасак ... залдагы озын өстәл өстенә алма төшәрлек тә түгел, ни генә юк: дөньяның кайсы кыйтгаларында житлеккән чикләвекләр дисеңме, семга, палтус балыклары, сары, кара, кызыл уылдыклар дисеңме, эчендә төрле төсләр яшьнәп торган фужерлар, пычак-чәнечкеләрнең шаһ-корольләр өстәленә генә халыкара тәртиптә тезелеп куелуы дисеңме—болар бар да ашау симфониясенә югары зәвык белән әзерләнгән увертюра иде. Ярый әле тавыкны ашыгып чыгармадык, бу ниґъмәтләр арасында тавыгыбыз

Парижга эләккән көтүче хәлендә кала иде, дип пышылдыйм, Гәрәйгә төртеп.

—Егетләр, әйтүгә килеп життегез, шулкадәр рәхмәт сезгә,—дип, Вахит Юныс безне кабат-кабат кочаклап аркадан сөя, күзләрендә шатлык яше...— Хәзер сезгә гажәеп бер блюдо өлгертәм, мин аны күп еллар элек Тайваньда, генераллиссимус Чанкайши банкетында күреп кайткан идем...

Егермеләп илдә күп еллар эшләгән, инглиз, гарәп, корея телләрен белгән Вахит агада таңга кадәр кунак булдык. Ауропача бизәлгән өй жиһазлары ул төндә керәшен жырларын тәүге тапкыр кинәнеп тыңладылар.

Эш урынында Гәрәй Рәхим Чабаксар, Казан, Уфа язучылары, сәнгать әһелләре өчен үзе бер илче иде. Китап чыгару нияте белән килгәнсең икән, ул сине нәшриятлар буйлап йөртә, кирәкле кешесен табып сөйләшә, кунакханәгә урнаштыра, ижат йортына урын табып бирә, ижади командировкаларны юллап куя. (Чукоткага, Командор утрауларына барам дисән дә ул елларда Мәскәү оешмасы акчаны мулдан түли иде)—кыскасы, һәммә кешегә яхшылык кылып, үзенә савап алу кебек олы жанлылыкка ирешкән Алла бәндәсе иде ул.

Олы форумнарга, юбилейларга ул Михалков кебек исемле шәхесләрне Казанга, Уфага яисә Чабаксарга алып кайта, үзе дә шома йөзле партия әһелләре белән янәшә президиумда утыра иде. Халыкның мең күзле карашыннан кадакланып президиум кысаларында утыру аңа килешеп тә бетми шикелле, жор күңелле табигый халәтеннән мәхрүм калып, артык житди булырга тырышудан яңак мускуллары кысыла, болай да ассиметрик чырае ямьшәеп, төмсәләнеп кала. Андый чакларда Гәрәйне интегүле киеренкелектән коткарасы килә иде.

Киеренке эш сәгате беткән мәлләрдә Гәрәйнең машинасына утырып Мәскәү буйлап чыгып китәбез.

—Син машинаны улатып кузгатма, әнә Мөсәгыйт Хәбибуллинның мотор тавышы да ишетелми,—дим аңа.

—Нәрсә, ул кабызмыйча гына йөримени?!—ди Гәрәй.—Ул бит тумыштан шофер.

Авылда, бәләкәй өстәлдә, тимер шарлы бильярдта уйнап өйрәнгәннәр зур шарлы бильярдта да шәп уйныйлар. Ә инде капылт кына зур шарлы бильярдта өйрәнгәннәр, барыбер остарып житә алмыйлар, "ана сөте белән кермәгәне" күренеп тора. Машина да шулай ахрысы, аңа бәләкәйдән үк ябышып үсәргә кирәктер.



*Чувашстанда узган (оештыручысы Г. Рәхим, алгы рәттә, сулдан икенче) татар, башкорт, чуваш яшь шагыйрьләре семинарында. 1985 ел.*

—Хәтсез акча да эшлим инде югыйсә, гонорарлар да алам—баеп булмый. Шушы "Жигули" ашап бара. Ике машиналык акча чыкты инде үзенә,—ди Гәрәй.—Йә мин бәрдерәм, йә мине бәрдереп китәләр, тәзәттерү кыйбат бит. Житмәсә, көн аралаш, штраф түлим. Дөрес тә барам, кагыйдәне дә бозмыйм кебек, юк, барыбер тоталар.

Шулай сөйләшә-сөйләшә алты рәтле гажәеп киң урамнан жилдерәбез. Эреле-ваклы машиналар дәрьясыннан йөзеп кенә барасың шикелле. Бар да тыныч иде кебек... Кинәт, юл кырыеннан, асфальттан яралган шикелле, ГАИ хезмәткәре калыкты да, йөзләрчә машина арасыннан Гәрәйнекен табып алып, бармагын изәп чакыра башлады.

—Менә, тагын мин икәнен күреп алды инде,—дип Гәрәй, теш арасыннан "с" авазын кысып, имгәтеп чыгарды. Бу аның үзенчә сүгенү рәвеше иде. Яктылыкны каплауны женем сөйми, дип алдагы йөк машинасын өнәмичә, икенче сызыкка чыккан иде ул, шул ярамаган икән. Гәрәйнен бумажнигын тагын унбиш тәңкәгә ябыктырып, ары кузгалабыз. Мин аны үземчә юаткан булам.

—Авылда хәтерлисеңдер, берәүнең сөтне күп бирә торган шәп сыеры була. Шуны икенче берәү сатып ала—сыер кинәттән генә сөт бирми башлый. Килешмәде, диләр андый очракта. Сиңа да, Гәрәй, килешми бу машина. Сатарга кирәк моны, тәмам бөлдереп бетергәнче,—дим.

—Шулай итим микән...

Кызык бит ул дөнья дигәнең: эт жәнлеген үз алдында мыскыллап көлсәң, беркайчан да онытмый, кайчан да булса бер тешләп, үчен кайтара икәненә мин үз тәжрибәмдә төшенгән идем, ә менә машинаның да үзен кимсетүне кичермәвен, үч ала икәнен мин әле белми идем. Һәм ул моны озак көттермәде...

Шолохов үлгән көн иде (1984 елның феврале). Радиолар сагышлы музыка бирә башлады, кайгылы хәбәр әле икенче көнне генә илгә таралачак, мәскәүлеләргә инде миллион колактан таралып өлгергән.

"Москва" кунакханәсендә Туфан Миңнуллинның болын чаклы люкс номерында гәпләшеп утырабыз. Гариф Ахунов "Тын Дон"ның яшьлегендә үзе тәржемә иткән кайбер өзекләрен, дулкынланып, яттан сөйли. Прозаны яттан белү—сирәк була торган хәл.

Шул көннәрдә генә "Литературная газета"да Шолоховның соңгы интервьюсы басылып чыккан иде. Анда ул "Тын Дон"ның баштагы нөсхәсен тел ягыннан нык эшкәртеп, шивә сүзләрдән арындыруын әйтә. Шивә дигәне татардан кергән сүзләр булган икән...

—Казакларның төп өлеше татардан чыккан инде. Романында "хутор Татарский" дип тиккә атамагандыр Шолохов,—ди Туфан Миңнуллин,—яңгыравык тавышын бүлмә киңлекләренә таратып.

—Казаклар шул ук керәшен татарлары инде, —ди Гәрәй Рәхим, шаяртып. Аннары, житдиләнеп, өстәп куя,—"Тегеләр" радиосыннан тыңлаганым бар: большевиклар, гражданнар сугышы чорында, Казанский дигән станциада биш йөз ир-атны тезеп куеп, берьюлы атып үтергәннәр. Бу да юкка түгелдер.

—Кайбер авылларда, бәлки, тел, гореф-гадәтләр сакланып калгандыр. Университет студентларын фольклор жыярга шул якларга жибәреп кайтарырга иде, —дим мин.

—Бер буында—тел, икенче буында—моң, өченче буында—хәтер бетә. Аларның кыпчак икәнен православие дине оныттырган инде,—ди Туфан Миңнуллин.—Кушаматлары да мишәрдән кергән бит югыйсә: каңак, качак, казак...

Гариф Ахунов, гадәтенчә, уен уйдырып, тирән керүне өнәми: Шолоховны якыннан күрүе хакында хатирәләргә бирелә.

Төнге сәгать берләр тирәсе житкәч, Гәрәй Рәхим кайтырга дип кыбырсый башлады. "Монда урын житәрлек, кайтып йөрмәгез, кызган баштан ... житмәсә—рульдә..."—дип Туфан Миңнуллин кыстап караса да, Гәрәй, иптәшкә мине дә ияртеп, житез генә кузгалды.

Төн уртасы. Киң урамнар. Ник бер хәрәкәт булсын. Машинада Гәрәй

белән жай гына сөйләшеп кайтабыз. Кинәт... туры гына барган унайдан машинабыз чалыклый башлады, әле унга, әле сулга ташлана торгач, шома бозга эләктеме—кырт борылып, урам кырыендагы мәһабәт йортка таба жуылдап очарга тотынды (Гәрәй тормоз урынына газга баскан булган икән). Шунысы сәер, жанда бернинди курку-шөбһә юк, без үлмәскә тиеш, дигән үҗәт бер уй гына чагылып алды. Машина алагаем тизлек белән гөрселдәп, алгы тәгәрмәче белән бордюр ташына килеп бәрелде (ярый әле бәйләнеп утырган идем), йорт диварына бер метрлар кала, кырт борылып, уң тәгәрмәчләрен дә әчтән бәрдереп, тротуар буйлап йөз метрлар барды да туктап калды. Секунд эчендә булган бу мәхшәрне без аңыбызга да сыйдыра алмый калдык. Ул арада әллә каян гына милиция машинасы килеп чыкты. Төштеләр. Шаккатып карыйлар. Алгы тәгәрмәчнең берсе киселеп, шакмак булган, арткы тәгәрмәчләр дә ямьшәеп беткәннәр.

—Бүген Шолохов үлгән көн. Барыбызга да уртак кайгы килде, шуны искә алып утырдык та..—дип, Гәрәй Рәхим СССР язучылар союзы билетын чыгарып күрсәтте. Тегеләр әлләни бәйләнеп тормадылар, тәгәрмәчне тиз генә алмаштырырга ярдәм иттеләр дә, Гәрәйнең егерме биш сумын кесәгә шудырып китеп бардылар.

Әкрен генә без дә кузгалдык. Машинаның көе киткән, унга каера. Төнге өчләр тирәсе иде. Еpактан ук ГАИ хезмәткәрен күреп алдык. Сәер генә ыңгырашып килгән машинаны туктатмый кала димени алар.

Гәрәйне автобуска утыртып каядыр алып киттеләр. Мин берьялгызым калдым. Жиде миллионлы Мәскәү халкы йоклый. Урам шомлы. Ярый әле салонда жылы, музыка уйнап тора.

Сәгать ярым вакыт үткәч, автобус янә күренде, яшь милиционер егет руль артына кереп утырды да машинаны ай-ваена карамыйча, зур тизлектә алып китте.

Ни өчен Гәрәйне озак тотканнар дисәм, хикмәт шунда икән: карап торуга ул Савва Морозовлар чорындагы рус купецы шикелле: шәп якалы күн пәлтәдән, мул сакал-мыеклы, зәңгәр күзле... документларда Григорий Васильевич... "Нишләп болай мәзәк сөйләшәсең, исерек диеп тә булмый, аек күренәсең шикелле", дип милиционерлар бәйләнә башлагач, Гәрәй үзенең татар икәнен әйтә. "Ах, син без русларны өч йөз ел иго астында изгән татармыни әле, хәзер без сиңа күрсәтәбез!"—дип адарынган "жантимер"ләргә Гәрәй чын тарих ул болайрак була, дип ата-бабаларыбызның үткәне хакында сәгать буе сөйләп, тегеләрне авызына караткан икән. Шулай итеп ул (аз гына түләү, хисабына) машина йөртү таныклыгын саклап калды (соңыннан, төзәтүче осталар машинаның төп рамы кәкрәйгәнен күргәч, "Моның эчендәге кешеләре исән калганмы?—дип сораганнар). Күпмедер вакыт үткәч, Гәрәй белән теге бәрелгән урынны барып карадык. Бордюр ташы тәбәнәк куелган булса, тугыз катлы йортны сөзеп, урталай бөкләнәсе булганбыз икән. Ходай саклаган...

Икенче көнне радиолар Шолоховның үлеме хакындагы хәбәрне дөньяга тарата башлады. Олуг шәхеснең үлеме, галәттә, уй-фикерләргә этәрә. Социализм шартларында яшәгән күп кенә бәхетсез талантлардан аермалы буларак, үз вакытында кадер-хөрмәт күргән бәхетле талант иде ул. Читтән караганда шулай... Аның да хәтәр елларда кыл өстендә калган мәлләре булган икән шул. "Тын Дон"ның кулъязмасын укып чыккач, Максим Горький: мондый романга тотынырдай үзешчән язучылар илнең төрле регионнарында күпләп туачак, дигән. Үзе саф роман яза алмаган пролетар әдипнең көнләшүе түгелме бу?!

Нәкъ шул чорда ике томы чыгып өлгергән "Тын Дон"ның дәвамын бастыруны туктаталар. Шолохов Максим Горькийга мөрәжәгать итә. Күпмедер вакыттан соң Горький аны үзенең дачасында Сталин белән күрештерә.

—Син ак генералларны бик акыллы, көчле итеп сурәтләгәнсең. Эмиграциягә киткәннәргә азык бирү түгелме бу?!—ди Сталин.

—Көчсез, акылсыз дошманны жиңү большевикларга дан китерәме соң? —ди яшь, кайнар канлы казак язучысы. Сталинга аның үз фикерен хаклый, раслый алуы ошый. Шушы сөйләшүдән соң романның дәвамын бастырырга рөхсәт бирә. Янәшәдә утырган Горький исә Шолоховны яклап та, яманлап та бер кәлимә сүз дә әйтми; тәмәке көллегенә берәм-берәм шырпы кабызып сала

тора, сәгатькә сузылган әңгәмә барышында ике-өч кап шырпы яндырып бетерә...

Әдәби мохиттәге хөсетлек, көнчелек, астыртын мәкер заманында күпләрнең язмышын бик аяныч хәлләргә куйган. Сиксәненче елларда сәләтле, кулыннан эш килгән әдипләр өстеннән "корымлы" анонимкалар язу яңа бер күтәрелеш алган иде. КПСС Үзәк Комитетына, РСФСР язучылар союзына килгәннәре, урау юллар үтеп, Гәрәй Рәхимнең өстәленә кайтып өеләләр иде.

—Татарның бер-берсен бетерергә маһир халык икәне үзебезгә билгеле инде,—ди Гәрәй Рәхим,—руслар каршында оят бит. Шулкадәр ваклык... Шулкадәр мескенлек... Руслар каршында читен... "Их, сез татарлар... Бөтен кенәз-морзаларыгызны безгә биреп бетердегезмени соң, үзегезгә калмаганмыни..." дип бездән көләләр бит.

Гәрәй Рәхимнең әчтән сыкрануы күзләренә моңсулык сирпеде. Аның житдиләнеп калуы тәэсиреннән Мәскәү күгенә дә томсә болытлар тартылды.

* * *

Мәскәүне күз яшьләренә ышандырырга тырышып түгел, ә үзенең Ходай биргән сәләте, көч-хезмәте белән ирләрчә яулады ул. Мәйданы, халык саны ягыннан үзе бер дәүләткә тиң шаукымлы башкалада ышанычлы түбәнне булдыру, ижади оешмада эшләп, хөрмәт казану ана жинел бирелмәгәндер. Казна эшеннән тәмам арган бер чорда ул Сергей Михалковка кереп, яңа әсәрләр язасым килә, эштән азат итсәгез иде, дигән теләген белдерә. Сергей Михалков, гадәтенчә, тартык авазларда тотлыгып, таптана-таптана, мыек астыннан шаяртып:

—Мин синең энергияңне тулысынча сыгып бетермәдем бит әле, сыгып бетергәч, кит, дип үзем әйтермен,—ди.

Эшләде, димәсләр, язмады ... диярләр. Әдипләр арасында таралган бу әйтем баш очында һәрдаим чаң сугып тора. Әмма үз әсәреңне генә байрак итеп йөртүдән битәр, әдәбиятка хезмәт итү дигән мәгънәле төшенчә дә бар бит әле. Монысына инде сирәкләр алына. Гәрәй Рәхим, бик сак эш иткән археолог шикелле, татар шигърияте курганын ачып, аның бәгырендә мең еллар буе тупланган җәүһәрләрне сабыр төгәллек белән бөртекләп җыеп, бакый хәзинәләрне бүгенгегә ялгап, поэзия антологиясе төзеп дөньяга чыгарды. Матди яктан



*СССР Язучыларының VIII корылтаенда. Сулдан—Р. Гаташ, Г. Рамазанов (Уфа), Т. Миңнуллин, М. Шаханов (Алма-Ата), Г. Рәхим, М. Львов (Мәскәү), Р. Вәлиев h.б. Мәскәү, 1986 ел.*

бәһаләнми торган мондый катлаулы хезмәткә тотыну өчен фидакарьлек, әдәби мирасны колачлый алырдай тәвәккәллек, күпме ихтыяр көче сораладыр.

Ул Мәскәүдә "әдәбият илчесе" чагында башкаланың мәртәбәле залларында Акмулла, Кол Гали, Тукай, Җәлил, Такташ кебек олуг затларның юбилей кичәләре уздырылды. Партиянең Үзәк һәм өлкә комитетлары дәрәҗәсендә бу эшне рәсми кузгатудан алып, афишалар ясату, йөзләрчә артист, музыкант, язучыларны яхшы кунакханәләргә урнаштыруга кадәр ул үзе башлап йөрде. Мондый кичәләрдә партия эшлеклеләре дә, төрки халыкларның зыялылары да, чит ил кунаклары да катнаша иде. Чын мәгънәсендә милли бәйрәмгә әверелеп киткән тантаналы залларга башкала татарлары сыеп бетә алмый, җыр-бию, күтәренке рухлы бәйрәм урамнарга ташып җәелә иде.

Кол Гали һәм Габдулла Тукай юбилейларын ЮНЕСКО дәрәҗәсендә, дөньякүләм билгеләп үтүне гамәлгә ашыруны да Гәрәй Рәхим башлап кузгатты.

Еллар үткәч, бу кылган гамәлләрне хәзер инде учка алып күрсәтеп булмый шул. Сүз кодрәте белән вакытны иярләгән китабың гына, үткәннәргә тере шаһит булып, учыңда ята ала... Әлбәттә, китапның да төрлесе була шул. Берәүне генә куандырганы, меңнәрнең уй-киртәләрен аударганы...

Вакытлы мал, арзанлы дан алу мәсләгенә бирелеп, бәхетсез иҗаты үзеннән алда үлгән күпме язучылар мисалыннан гыйбрәтле сабак алган Гәрәй Рәхимнең, олыгая башлагач, тарихка борылуы табигый ихтыяр иде. Көнлекче әдәбияттан аермалы буларак, тарихи фикер, милли тамырлардан сугарылган фәлсәфә, дини рух өртелгән иҗат кына гомерле була икәнен ул үз вакытында төшенеп өлгерде. Күп өйрәнеп, борынгылыкның тәмен тойган әдип тарихи әсәрләр: татар дөньясының шанлы дәверен чыгылдырган поэма, киносценарийлар язды.

Аның бүгенге хезмәт урыны—Татарстан Дәүләт Советында. Ул язучыларыбыз, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләре Разил Вәлиев, Туфан Миңнуллин һәм Фоат Галимуллин белән бер комиссиядә мәдәният һәм милли мәсьәләләргә багышланган эшләр алып бара.

Утырып уйласаң, исең китәрлек: ничә еллар буена казна эшендә, иҗатка китәсе никадәр акыл-зиһен, күз нуры түгелгән, вакыт тегермәненә уралып кереп китәсе күпме рәсми кәгазь тутырылган. Кәгазь кыштырдавын күрәлмас дәрәҗәгә китергән бу хезмәтләрне бергә җыйсаң, ничә том хасил булыр иде микән? Әнә шулай итеп, язар өчен яшисе вакыт яшәр өчен эшләүгә киткән...

Гәрәй Рәхимнең һәрчак үзен чарлап торган хыялы—көндәлек "богаулардан" котылып, иректе иҗат галәменә чуму—аргы яры күренгәнче, дулкыннарны ярып, кинәнеп бер йөзү...

Кайчакларда мин: Гәрәй Рәхим дә олыгаеп, мыжыклана күрмәсен, Ходаем, алай булса, дөнья бик күңелсезләнер иде, дип уйлап та куям. Шөкер, ул һаман элеккечә; шаян-шук, җор сүзен гүя түш кесәсеннән генә үрелеп ала. Үз борчуларын онытып, кеше гаменә күчә белгән җайлы, иҗтиһадлы, син катлаулы дип уйлаган мәсьәләдән гади генә чишелеш таба белгән хикмәтле шәхес ул. Кеше белән бүлешергә күңелендә һәрчак бер уч җылы булыр...

Аны очратып, хәл-әхвәл алышкач, бер йомышсыз китеп барсаң, үпкәләтерсең шикелле. Чөнки гозереңне аның кебек тә рәхәт итеп, авырыксынмыйча, теләп башкарып чыга алучы бүтән берәү бар микән безнең даирәдә.

Якташы—күзләренә Шөгер күгенең зәңгәрлеге сыйган, гөнаһсыз-юка гәүдәле Шамил Бикчуринга багышлап язган "Чишмә" дигән шигыре бар аның. Шул шигырьнең бер тәлгәшен өзеп алып, Гәрәй Рәхимнең үзенә, бумеранг итеп, юллыйсы килә.

Синдәйләр аз. Синдәй киң күңелле
Аләмнәргә кытлык, йә Ходам...
Кече күңеллелек өлкәсендә
Син бит безнең соңгы могикан.

# Gərəy Rəxim

## Dimək

Yaqın bulsa üz ilen—
İldə bulsın üz gəlen.
Əgər bulsa üz əyen—
Üzençə kür üz kənen.
Cırlar bulsan üz kəyen—
Kəygə kilsen üz telen.

Tabalmasan üz gəlen,
Qoralmasan üz əyen,
Küralmasan üz kənen,
Tabılmasa üz kəyen,
Anlamasan üz telen —
Aptırap yərmə, gələm.
Yuq, dimək, sinen ilen.

Künelen kər, kəyef əybət bula,
Kər bulğanda xalqın, ilkəyen.
İlnen cilkəse kin bulsa ğına
Kəçe bula sinen cilkənnen.

İlendə kəç, xalqında dərt-dərman,
Nəselendə dəwam bulmasa —
Əzməwerdəy taza ir bulsan da,
Bədənenne izep mon basa.

## Bəyek tatar xalqı

Çal tarixnın türennən min
Qarıym: yulın yaqtı.
Ber bahadir bulıp kürenəsen,
Bəyek tatar xalqı.

Pugaçlarğa əytkən bəyetləren,
Cır-monnarın tatlı.
Batır da sin, eşçən, kin künelle,
Bəyek tatar xalqı.

Maqtawlarğa moxtac tügelsen sin,
Tik maqtawğa xaqlı.
İlgə Cəlil kebek ullar birgən
Bəyek tatar xalqı.

Hər tuğanın kebek kəçle, zirək,
Unğan sin, talantlı.
Bu dənyanın şanlı ber balası,
Bəyek tatar xalqı.

Namusın aq tarix qarşısında,
Yəzen açıq, yaqtı.
Kiləçəkkə qıyu atlap ker sin,
Bəyek tatar xalqı!

## İsə Bolğar cillərе

Küz aldımda cəyrəp yata
İske Bolğar cirlərе.
Bıyıl igen muldan bulır—
İsə Bolğar cillərе.

Traktorlar sərep yəri
İske Bolğar qırların.
Baş oçında yəp-yəş turğay
Sayrıy Bolğar cırların.

Paroxodlar kilep tuqtıy
İske Bolğar yarına.
Yəş ber yeget Yosıf ğıyşqın
Səyli səygən yarına.

Yalğız ber at utlap yəri
İske Bolğar çirəmen.
İnde küptən salğan malqay
İŋnərennən iəren.

Yəşellənep cəyrəp yata
İske Bolgar cirlərе.
Bıyıl ildə ikmək uŋar—
İsə Bolgar cillərе.

## Yosıf-Zələyxa kəye

Tupırdatıp at çaptırğan,
Doşmannarğa uq attırğan
  Yosıf-Zələyxa kəye.
Tuğan ilne satmağan ul,
İl namusın saqlağan ul
  Yosıf-Zələyxa kəye.

Yərəklərgə utlar yaqqan,
Gəmerlərne ozınaytqan
  Yosıf-Zələyxa kəye.
Bolğar ilen maqtağan ul,
Məŋgelekkə atlağan ul
  Yosıf-Zələyxa kəye.

Borınğılar cırlap yərgən,
Ğaşiqlarnı səyendergən
  Yosıf-Zələyxa kəye.
Haman da il terəge ul,
Haman da il yərəge ul
  Yosıf-Zələyxa kəye.

Məxəbbəttə sinen belən
Saraylar qoralmadım;
Min Tahir bulğan çaqlarda,
Sin Zəhrə bulalmadın.

Ləkin sin də minem belən
Çatırlar quyalmadın.
Sin Zəhrə bulğan çaqlarda,
Min Tahir bulalmadım.

Nişlisen, beznen səyülər
Yəşilər ike yaqta.
İkese ber ük yalğışu,
İkese ike xata.

Bügennən son sina kilməm, axrı,
Bik ğazaplıy mine bu səyü,
Küzlərenə tulğan sağışlarnı
Məmkin tügel, axrı, beterü.
Qayğırma, dip niçə tapqır əyttem,
Kemnen də, dip, bula yalğışı.
Ləkin kitmi sinen küzlərennən
Ükenü həm qoyaş bayışı.
Qaraşınnan ütə almıym haman
Tomanlanğan kiçke ofıqlar.
Ni tən kilmi sina, ni kən kilmi,
Waqıt, axrı, sine onıtqan.
Bik ğazaplıy mine bu məxəbbət,
Yalıqtıra betməs sağışın.
Min aşqınam tanğa, ləkin sinen
Küzlərendə qoyaş bayışı.

Bügennən son sina kilməm, axrı...



**Әхәт Сафиуллин**

# ҖЕПНЕҢ ОЧЫ

МАҖАРАЛЫ ПОВЕСТЬ

–Калтыранма, чишен, әйдә! Менә күрерсең, барысы да әйбәт булыр!—дип Юрий өстеннән пальтосын сала башлады. Сергей һаман ишек төбендә кымшанмыйча басып тора иде.

—Бу эш өчен безгә рәхмәт әйтмәсләр, Коробок...—дип ниһаять, ул телгә килде.—Атарга да мөмкиннәр...

Коробок эләргә җыенган пальтосын ачу белән идәнгә ташлады да, бер сикерүдә аның янына килеп, якасыннан эләктерде һәм ямьсез караш ташлап ысылдады:

—Җиттеме сиңа, юкмы?! Телеңә тилчә чыккыры! Әйтәләр бит сиңа: барысы да әйбәт булыр. Тик телеңне тый! Эш эшләнгән, артка чигенү юк. Шыншып нервыны бозма! Ишеттеңме?!

—Ишеттем, ишеттем. Җибәр яканы! Шаштыңмы әллә?!

—Ишетсәң, бик яхшы! Бу турыда башка сүз катма! Чишен, барысын да онытырга тырыш! Хәзер тамак чылатып алырбыз...

—Онытырга тырыш, имеш... Әйтүе генә ансат. Кеше тикле кешене үтер дә...

—Хәзер дөньясы шул аның, Серый. Йә сине үтерәләр, йә син үтерәсең...

—Мин аларны белмим дә ич!

—Шуннан ни булган! Шеф кирәк дип тапкан икән, димәк, шулай кирәк булган,—диде Юрий һәм, пальтосын идәннән күтәреп, элеп куйды.— Аннан соң миенә шуны беркет, без бу эштә бары катнаштык кына. Аңладыңмы? Кайчан ни эшләргә кирәклеген Шеф үзе белә. Өченчедән... безне башта тотарга кирәк әле! Менә монысы милиция кулыннан да, прокуратура кулыннан да килердәй эш түгел. Хәзер көн саен үтереш, көн

Әхәт САФИУЛЛИН *(1936)—язучы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. «Язларында ялгыз йөрсәң...» (1982), «Онытылган вәгъдә» (1986), «Сер бирмәдек» (1997), «Тулгана дөнья» (2000) исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

саен жинаять—алар кая карарга да белми. Ә монда черки дә борын тыга алмас. Курыкма!

Юрий юан, кыска бармаклары белән күптән кайчы күрмәгән жирән чәчләрен сыпыргалый-сыпыргалый ишек катыннан бүлмәгә таба атлады. Аннары кухняга керде, савыт-саба шалтыраган тавышлар ишетелде.

—Давай!—дип килеп чыкты ул бераздан, нәрсәдер чәйни-чәйни.—Бераз йомшарырга кирәк безгә, Сергей... Без дә кеше бит, безнең дә нервылар бар.

Өс-башын салып өлгергән Сергей да елмайгандай итте.

Утырыштылар. Иптәшләре арасында Коробок кушаматы белән йөргән Коробов ипи кисте, бер кисәк казылыкны урталай сындырып, яртысын Сергей алдына куйды. Аннары, шешәсен ачып, ике стаканга яртышар итеп аракы салды.

—Әйдә, Серый, күңелсезлекләрне оныту өчен күтәрик әле!—диде дә ул, чәкештереп тә тормыйча, эчеп жибәрде. Беравык ипи иснәде, аннары аны авызына капты.—Тот, әйдә, тот! Нервыларны тынычландыра бу.—Ул иптәше эчеп бетергәнче аннан күзен алмады. Тегесе стаканын бушаткач, мона чын күңеленнән сөенгәндәй, Храммның аркасына сугып куйды.—Молодец! Менә хәзер бар мәхшәр дә онытылачак!

—Белмим, онытылыр микән...

—Карале, Серый, онытылу өчен эчтек түгелме?! Житәр бу турыда! Әйдә, капкала син, капкала! Ату йомшарасын. «Аекның—уенда, исерекнең—телендә», диләр... Артык бер сүз дә ычкындырырга ярамый—эчтән тынудан яхшысы юк. Аңладыңмы?

—Син нәрсә мина һаман акыл өйрәтәсең? Аны гына үзем дә аңлыйм мин,—диде Сергей, казылык кабып.—Тик... Әйтәм бит, нәрсәдер гел күңелне тырнап тора.

Эчтеләр. Шактый вакыт ипи, казылык һәм суган ашап утырдылар. Һәр икесенең дә эчендә гасабилану сизелеп тора, тик аны менә хәзер ашау белән мавыккан булып, икесе дә тоймаска, үз-үзләреннән яшерергә тырыша иде.

—Әйт әле, Коробок, ни өчен яратмый ул мине?—дип авыр тынлыкны Сергей бозды.—Нигә мина һаман кул күтәрә? Ә?

—Кем?—Юрий, ашавыннан туктап, кысык күзләрен аңа төбәде.

—«Кем, кем?» Кем булсын—Шеф! Мин малай-шалай түгел бит аңа. Миннән бер яшькә генә олы ул. Үзен әллә кемгә санагач та...

—Аның сина кул күтәргәнен бер дә хәтерләмим. Барыбызга да тигез карый бугай ул...

—Ничек хәтерләмисең?!—дип гажәпләнде Сергей, зәңгәр күзләрен зур ачып. Инде ул шактый ук исерә дә төшкән иде.—Ничек хәтерләмисең?! Ә Жиңү бәйрәме алдыннан? Сигезенче май көнне?.. Исеңә төштеме?

—Ә-ә, син аңа граната биргән көнне әйтәсеңмени?—дип көлде Юрий.—Соң, ул чакта аның котын алдың ич! Кем инде гранатаны запалын куйган килеш тоттыра кешегә, ә?!

—Кем белгән аны ничек кирәген... Шулай яхшырак булыр дигән идем.

—Син шулай дигәнсеңдер дә... Ә ул үзен шартлатырга жыеналар дип курыкты,—диде Юрий һәм жинелчә генә аның иңбашына суккалап алды.—Исең китмәсен, Серый, шуна күрә Шеф дип йөрибез дә инде аны. Сугарга да мөмкин, кыйнарга да. Быелтыр минем физиономиягә дә менеп төште бит. Син моны белмисең—анда юк идең...

—Ничек килеп чыкты?—дип кызыксынды Сергей, аңа таба иелә төшеп.

—Бик очынып кына гаражга килеп чыкты бу. Ашыгыч кына каядыр барырга жыена. Хәзер хәтерләмим инде: машинасы ватык булганмы, үзен йөртә торганы каядыр киткәнме—минем янга килде. «Әйдә, тиз генә барып киләсе жир бар»,—ди. Ә мин, үч иткән шикелле, кичтән бензин салып калдырмаган идем, бак—буш! Менә шунда жанны көйдереп ала торган яшел күзләрен кысып бер генә карады да... сул яңагыма чалтыратып та

җибәрде. Күземнән утлар очты. «Без һәрвакыт военное положениедә булырга тиеш!»—дип китеп барды аннары. Менә шулай, Серый... Нишләтәсең, бер караганда, шунсыз булмый да. Ә тәртип юк икән, бер оешма да, бер коллектив та яши алмый. Аңа ачу тотарга кирәкми. Дөрес, холкы җинелдән түгел анысы...

—Ул сиңа бер генә суккан...

—Шуннан соң ник бер мәртәбә машинаны заправкасыз калдырыйм! Файдасы тиде...—дип эре тешләрен күрсәтеп көлеп алды Юрий.

—Берничә көн узгач, башны тишә язды бит әле тагын...—дип Сергей өстәлгә сугып куйды.—Пистолет түтәсе белән... Битне канатып бетерде, хәшәрәт! Сәбәбе булса иде...

—Ни өчен?

—Кибеткә дип чыккан идем. Карасам, аның машинасы! Шеф, машина ишеген ачып, мине эчкә суырып та алды! Өнгә килергә дә өлгермәдем. «Нишләп рөхсәтсез постыңны ташладың?»—дип бәйләнде генә бит! Пистолетын чыгаргач, атып үтерә дип торам...

—Нинди пост соң ул?

—Беләсең ич инде: өен сакларга туры килә... Әйтерсең, өен урлап китәләр. Кибеткә барып килергә дә ярамый...

—Син хаклы түгел, Серый. Туры әйтүем өчен гафу ит, ләкин һич тә хаклы түгел! Кем белә, бәлки, нәкъ менә син кибеттә чакта йорт-җирен яндырып яисә шартлатып китәрләр?! Безнең төркем белән «Борисково» төркеме арасындагы хәлләрне үзең беләсең... Алардан теләсә кайсы вакытта теләсә нәрсә көтәргә була. Сакларга кушкан икән, син инде, кем әйтмешли, будь добр, сакла! Ышанычын акларга тырыш!

—Ә нигә ул кулын озайта? Аз сакладыммы мин аның өен? Әйткәч тә, мин дә кеше! Аның шикелле үк...

—Аңлап бетермәдең. Син бит аның шәхси нигезен генә түгел, ә «Таулар»ның штабын да саклыйсың! Мәсьәләне әнә шулайрак куярга кирәк, җүләр булмасаң. Бу исә дисциплина сорый торган нәрсә. Ә син тоткансың да—кибеткә! Җавапсызлык бит бу! Шеф хаклы.

—Һаман аны яклыйсың син,—дип Сергей ачу белән йодрыгын йомарлады, тешләрен шыгырдатып куйды.—Ул... ул хатынының янына йөри диләр... Ә син шуны яклап утырасың. Аңламыйм, нәрсәсе...

Сергей сүзен тәмамлый алмады, кинәт Юрий утырган урыныннан сикереп торды. Хәтта урындыгы атылып китте. Японнарныкы кебек кысык күзләре зур булып ачылды, чырае авызына агу капкан кешенекедәй сытылды. Ул көрәк сыман куллары белән шешәдәшенең якасыннан эләктереп, аны урыныннан йолкып алды.

—Син нәрсә, бүген мине чыгырымнан чыгармакчы булдыңмы?—диде ул, Сергейның кечкенә, ябык гәүдәсен кулларында тоткан килеш.—Минем хатынга тел-теш тидермәсәң, башка сөйләр сүзең юкмы?! Әллә яшәүдән туйдыңмы, ә, сволочь?!

Сергей мондый хәлне һич тә көтмәгән иде бугай, ул кинәт айнып киткәндәй булды. Яшен тизлеге белән: «Әй, көч бу явызда!—дип куркынып уйлап алды.—Иблис куәте бардыр монда! Бәндә түгел, ерткыч бу, валлаһи, күзләрендә иман әсәре юк! Моңа кеше үтерү берни тормый. Теге егетне дә... Кеше түгел, ә үгез. Чын-чыннан үгез...»

—Бетте, бетте, Коробок! Мин бит кеше әйткәнне генә...—диде ул, аякларын селки-селки.—Гафу ит, ялгыш ычкынды. Валлаһи, ялгышлык белән. Исердем бугай...

—Кара аны, әгәр дә мәгәр кайчан да булса авызыңнан тагын шундый бер сүз ычкына икән, үзеңне мәет дип сана!—дип сөзеп чыгарды Коробов эре, сары тешләре арасыннан.

—Аңладым, Коробок. Аңлашылды,—диде моңа каршы Сергей, күлмәк якасын рәтләп.—Кая, сал әле бераз!

—Күпкә китә! Болай да ни сөйләгәнеңне белмисең...

Юрий тыныч күренергә тырышты, ләкин бу тыштан гына шулай иде. Ә эчтән... Ә эчендә, күңеле түрендә, әллә ниткән утлар кайнады. Гәрчә

хатыны турында андый имеш-мимешләрне инде байтактан ишеткәләргә туры килсә дә, моны ул һәрвакыт яна хәбәр кебек кабул итә, хыянәтне кабат-кабат кичерә. Ә андый үзәк өзгеч хәбәрне әледән-әле ишетеп тору сукса тимер өзәрдәй ир-ат өчен күнелле хәлме әллә?! Монын коры имеш-мимеш кенә түгеллеген, Шефнын Лиза белән йөргүен ул үзе дә белә белүен...

... Шулай бер мәртәбә аны кооператив машинасы белән Яшел Үзәнгә түбә калаена жибәргәннәр иде. Аккош күле янына да житмәде, машинасы ватылды, шактый акча түләгәч, берсе, өстерәтеп, гаражларына кайтарып куйды. Шунда ук анын сүтәсе жирен сүтеп, төзәтергә үк кереште.

Үзе машинасын ремонтлый, ә үзенен күнеле һич тә урынында түгел. Нишләп ярсый бу күнел дигәнен? Юрий аптырап калды. Юк, күнеле эшкә ятмый гына бит!

Юрий бераз кайнашкач, төштән сон рәтләп бетерермен әле, дип «Жигули»ена утырды да өенә кайтып китте. Йортлары янына килеп туктавы булды, карый, подьезд төбендә кооператив башлыгы (аны үзара Шеф дип йөртәләр) машинасы тора! Шундук күнелен ниндидер билгесез тынычсызлык биләп алды. «Нишләп йөри икән бу монда?! Нинди йомышы калган безнен тирәдә? Әллә, чыннан да, теге күрше хаклымы?»—дип уйлап алды ул, ниндидер эчке бер борчылу белән.

Әйе, хатыны турындагы беренче шикне ана күршесе житкергән иде. Анда да бик сак кына, «Хәлләр шулайрак түгел микән, күрше, берничә мәртәбә бу кешенен фатирыгыздан чыкканын күрергә туры килде» дип кенә әйткән иде. Якын итеп, диярргә була. Монарчы күргән саен дусларча исәнләшеп-күрешеп йөргән күршесен өзгәләп атардай булган иде Юрий.

Ул көнне хатыны белән Юрий арасында шактый ук күнелсез сөйләшү булып алды. Лизасы башта анын шигенә көлеп кенә карады. Янәсе, яраткан иренә ничек хыянәт итсен?! Янәсе, юкка жанымны ашама.

Ләкин, без капчыкта ятмый, диләр бит. Мондый шик, имеш-мимешләр тагын да ишетелгәләп торгач, артыннан мыскыллы елмаюлар сизелә башлагач, тормышлары күзгә күренеп бозылып китте: гаиләдә тавыш-гауга ешайды, ир кеше исә хатыны турындагы чәнечкеле, кинаяле сүз-хәбәрләрне еш кына аракы белән «уздырып» жибәрә башлады. Менә шундый көннәрнен берендә араларында зур гауга купкач, Лизасы—яратып өйләнгән, ышанычлы дип йөргән Лизасы!—кинәт күз яшьләре аша ярсый-ярсый, аны тәмам өнсез калдырды:

—Синен төрмә юлыннан башын чыкмый—инде өч мәртәбә утырдын. Уйлап караганын булдымы: ике бала белән ничек яшәргә тиеш идем мин? Әйе, йөрдем! Чөнки ул мина син төрмәдә чакта ярдәм итеп килде,—дип ни булса шул булыр, дигәндәй, ярып салды.—Жүнле булсан, гаиләбезне саклап калырга булышканы өчен тавыш күтәрү түгел, рәхмәт әйтер иден син ана. Ә син, идиот, көн саен тавыш күтәрәсен... Моннан сон жанымны ашама: безнен белән яшәргә теләмисен икән, чык та кит! Яшәрбез, үлмәбез...

Яраткан хатынынын шушы сүзләреннән сон Юрийнын уй-фикере тәмам чуалды. Ул кинәт, паралич суккан кеше сыман, бер мәлгә, нишләргә дә белмичә, баскан жирендә таш сындай катты да калды. Әйтерсен, шушы мизгелдә дөньядагы бар сүз дә онытылды. Ниндидер күренмәс көч муенынннан буа, суларына һава житми иде.

Хатыны исә, ана айнырга да ирек бирмичә, бер башлагач барын да әйтеп калыйм, дигәндәй, елый-елый, ашыга-ашыга сүзен дәвам итте:

—Сине, төрмә юлыннан кайтып кермәгән сукбайны, эшкә кем урнаштырды да, кем алды дип беләсен? Мин булмасам, бу кооперативка кем ала иде сине?! Менә шулар турында уйлап караганын бармы, исмаса?

Хыянәт, ачы чынбарлык турында менә шулай хатынынын үз авызыннан ишеткән иде ул. Чыгып китмәде, әрләштеләр, тавышландылар-тавышландылар да тынычланып калгандай булдылар. Юрий бу вакытлар эчендә әллә нәрсәләр уйлап бетерде, әллә ниткән фикер каршылыклары кичерде. Берара күнелен: «Бәлки, атылып үләргәдер?» дигән шыксыз уй да биләп алган иде, ләкин бу ямьсез уен күнеле түреннән тиз кысрыклап чыгарды. Шунысы кызык, шушы ачы хакыйкатьне ишеткән көннән башлап—

кешегә әйтсәң, кеше ышанмаслык хәл!—эчүен ташлады. Юк, бөтенләй үк түгел, ләкин шунысы хак, хәзер көн саен эчми, чөнки Лизасы да кайчандыр «ялгышлык белән җибәрелгән бу хата»сын ташларга вәгъдә итте. Ә аны ярата иде шул ул. Уйлар дингезенә чумып йөри торгач, Юрий хәтта вакыты-вакыты белән аны аңлагандай да булды, хәленә керде дияргә була. Чыннан да, тормыш алып бару аңа да җиңел булмагандыр. Ә ул, тормыш арбасына төптән җигелеп тартасы кеше, тормыш тотнагы булырга тиешле ир, өч мәртәбә төрмәдә утырды. Ә мондый очракта ике бала белән калган хатын нишләсен? Аннан соң, бер караганда, үзенең хәзерге эше дә начар түгел бит: Шефның тырышлыгы аркасында үзенә яңа машина бирделәр, акчасы да яхшы төшә. Хәер, бу мәсьәләдә кыенлык сизми алар: «Таулар» төркеме үзләре яшәгән микрорайонның күп кенә кибет, предприятие, кооперативларыннан шактый саллы ясак алып бара. Акмаса да, шуннан да өлеш чыгып тора...

Соңгы вакытларда менә шулай яшәде ул. Куркып-куркып яшәде. Бер караганда, үзе теләсә кемне куркытырдай көч-куәткә ия ир-ат, икенче караганда, хатынына ялынучы көчсез ир, өченчедән, зурдан кубып бу турыда Шеф белән сөйләшә дә алмый торган, куркуыннан үз-үзенә хөрмәтен дә югалтырга әзер булган ихтыярсыз кеше. Мин-минлеген югалта баручы зәгыйфь адәми зат.

Менә хәзер Сергей күптәннән сызлап килгән ярасына кагылгач, Юрийның күз алдыннан бер-бер артлы әнә шул күңелсез хәлләр узып китте.

—Сал инде бераз, Колобок!—диде Сергей, ялынып.

—Ярар, салам мин сиңа, салам. Тик менә нәрсә: эчүгә бераз ял итеп аласың. Килештекме, Серый?—дип Юрий суыткычтан икенче шешәне алып килде.—Шунсыз тамчы да бирмим!

—Рәхмәт, Коробок, син мине һәрчак аңлыйсың. Теге егетне үтергәндә дә коткардың син мине...—Сергей сөйләнә-сөйләнә стаканына үрелде.—Син булмасаң, муеннан гөнаһка бата идем. Берүзем генә... Беткән иде баш!..

—Тагын юк-барны исенә төшерүеңме?!—диде Юрий, тона башлаган ачулы күзләре белән яшен атып.—Бу турыда бетердек бит инде. Тыныңны чыгарма!

—Мин болай гына бит, Коробок. Рәхмәт әйтүем генә...—дип мыгырданды Сергей.—Коткардың, диюем.

—Житте!—дип өстәлгә сукты Юрий, стаканындагы аракысын эчеп җибәргәннән соң.—Костыра башладың! Бетердек бу турыда.

—Бетердек икән, бетердек,—дип мыгырданды Сергей, стаканын кулына алып.—Мин болай гына...—Ул эчеп җибәрде дә ашыкмыйча гына авызына суган кисәге капты. Аннары, рәхәт мизгел кичергәндәй, уң кулы белән күкрәк турысын угалап алды, шуннан соң ике кулы белән берьюлы берничә мәртәбә кыска, кара чәчләрен артка таба сыпыргалады.—Кая, Коробок, теге егетнең муен чылбырын карыйк әле, ә!

Казылык чәйнәп утырган Юрий кинәт дерт итеп сискәнеп китте.

—Син нәрсә?!—диде ул, гаҗәпләнеп. Аның кысык күзләре зур булып ачылды, калын, кара кашлары маңгай уртасына сикерде.—Тагын нәрсә уйлап таптың?!

—Курыкма, карыйм гына. Чын алтыннан микән?—Сергей, ваемсыз бала сыман, инде аракыдан тоныкланган зәңгәр күзләрен Юрийга төбәде.—Алтын булса, машина бәясеннән дә артык торадыр ул...

—Белмим,—диде тегесе төксе генә.—Бар, бераз ятып тор! Юк-бар нәрсә белән аптыратма...

—Ничек юк-бар нәрсә булсын ул?!—дип тавышын күтәрә төште Сергей, аңа гаҗәпләнеп карап алганнан соң.—Мин аны сиңа үз кулым белән бирдем ич! Мәет муеныннан өзелеп төшкәч...

—Ярар, ярар, тынычлан!—диде бу юлы Юрий, сабырлана төшеп.—Бирмәдең, димим ич мин. Ял итеп ал, дим. Торгач карарсың. Ашыгыч түгел...

—Дөрес, Коробок. Чыннан да, кая ашыгырга?—дип мыгырданды Сергей борын астыннан һәм кәнәфигә барып ятты. Исерүе житкән иде бугай, бераздан гырылдый ук башлады.

«Бөтен нервыны какшатып бетерде бүген бу адәм актыгы,—дип уйлап алды Юрий, Сергей ягына усал караш ташлап.—Болай калай әтәч шикелле кукраеп йөргән булса да, «эш»тә куркак икән. Шыншый да шыншый. Мондыйлар сатарга да күп алмый: бераз кысуга ук кикрикләре шинә торган була мондый калай әтәчләрнен...—Үзенен уйларыннан үзенә дә куркыныч булып китте һәм ул, ашыгып, эченнән: «Милиция кулына эләгүдән Ходай сакласын инде»,—дип куйды. Әйтерсен, Ходай анын үтенечен, һичшиксез, ишетергә, һичшиксез, хәленә керергә һәм, һичшиксез, аны милициягә эләгүдән, кулга алынудан саклап калырга тиеш иде.

Ул, урыныннан торып өстәл өстен жыештырды да, бераз ял итәргә теләп, караватка барып ятты. Ләкин күзенә йокы кермәде, күз алдында һаман бүгенге вакыйгалар бөтерелде...

Әйе, аны бүгенге вакыйга—куркынычлыгы, зур жинаять икәнлеге әле менә хәзер генә миенә барып житә башлаган вакыйга—эзәрлекли иде. Аннан, күзенне йомып, яисә бер яктан икенчесенә әйләнеп ятып кына котылып булмый иде шул...

* * *

Хезмәттәшләре арасында Шеф кушаматы белән йөртелгән Владимир Илюхин урта мәктәпне көч-хәл белән генә ерып чыккан иде. Бишенчедәме, әллә алтынчыдамы, хәтта ике ел утырды. Нишләтәсен, укуга хиреслеге юк иде, гомумән, мәктәпкә, шулай кирәк булганга, ирексездән генә йөрде. Житмәсә, ул тугызынчы класста укып йөргәндә әтиләре, аларны ташлап, Казанга терәлеп торган шул ук Талмычы авылындагы бер хатынга йортка керде. Кем белә, бәлки аларны ташлап чыгып китүе яхшы да булгандыр әле анын: көн саен диярлек эчеп кайтып өйдә тавыш күтәрә, еш кына хатынын кыйный иде. Әнисен яклап араларына барып кергән Володяга да шактый кыен эләкте. Күз төпләре күгәреп, иптәшләреннән, классташларыннан оялып ничәмә-ничә тапкырлар мәктәпкә бармый калды ул. Аннары шундый тавыш-гауга арасында нинди дәрес әзерләү ди?! Дөресен генә әйткәндә, ул әтисен күралмыйча, ана нәфрәт йотып үсте, һәр көн диярлек гаиләләрендә купкан давыл өчен дә, болай да бөрешкән сыман кечкенә гәүдәле, аз сүзле, һәрвакыт башы эштән чыкмаган әнисенә кул күтәргән, аны сүз белән рәнжеткәннәре өчен дә ачулы иде ана. Көче житсә, үзен туйганчы тотып кыйнарга, монарчы эченә жыелып килгән бар ачуын чыгарырлык итеп тукмарга теләгән вакытлары да аз булмады. Ләкин кая ул! Әтисе көрәшче пәһлевандай таза, көчле ир-ат иде. Үзе әллә ни физик эш белән дә шөгыльләнми—шофер булып эшли. Күрәсен, нәселләре шундый булган. Хәер, үсә-үсә Володя үзе дә көч, гәүдә ягыннан әтисенә тартты.

Унны бетергәч, институт турында уйларга да кыймады: аттестатын тулы «өчле»ләр белән кая инде вуз турында хыяллану! «Армиягә барып кайткач күз күрер» фәлсәфәсе белән яши бирде ул. Ләкин армиягә түгел, көтмәгәндә генә суд эскәмиясенә, аннан исә төрмә сәндерәсенә эләкте. Казанга дискотекага барган жиреннән, салмыш баштан бер кыз өчен сугышып, үзе шикелле яшүсмернен башын ярган, кулын сындырган иде. Бу «батырлыгы»нын бәясе ике ел төрмә булды.

Аннан кайткач, дүрт-биш ай да үтмәгәндер, үзара сүзгә килеп, берәүгә пәке белән кадады. Ярый әле егет исән калды. Бу юлы дүрт ел бирделәр. Дөрес, ул утыруында аннан шактый ук акылга утырып, тәүбә итеп кайтты бугай, Казан автопредприятиеләренен берсенә слесарь булып урнашты, бераз сабырлана да төште сыман, кирәккә-кирәкмәскә көчен күрсәтмәскә тырышты, гаилә корып жибәрде, искерә барган йорт-жирләрен караштырды. Ниһаять, малаенын акылга утыруына инде чәчләре вакытсыз агара башлаган

әнисе шатланып туя алмады. Шулай матур гына яшәп ятканда, ireккә чыгуына дүрт ел тула дигәндә, янадан кулга алдылар: берәүнең машина тәгәрмәчен салдырган. Тагын төрмә...

Өченче срогын тутырып кайтканда, ил үзгәртеп кору мәшәкатьләре белән яши иде инде.

Володя, төрмәдән чыккач, бераз вакыт бу демократик тормышка гаҗәпләнеп йөрде. Элек машина турында хыяллана да алмаган дусларының күбесе инде машиналы, элек бернинди һөнәре булмаган, ни кушсалар шуны эшләп «разнорабочий» исемен йөрткән кайберләре ниндидер кооператив, шәхси предприятие хуҗаларына әйләнеп беткәннәр, кайберләре киосклар ачып җибәргән. Шунысы гаҗәп: аларда үзләре сату итми, моның өчен чибәр-чибәр кызларны яллаганнар, ә үзләре товар юнәтү, китерү эше белән шөгыльләнә, «точка»ларына контрольлек итә. Аларның эте-бетендә дә машина! Хәтта борын аслары кибеп җитмәгәннәре дә машинада җилдерә.

—Сиңа да машина кирәктер инде, туган?—диде көннәрдән бер көнне тамак чылатып утырганда дусларының берсе, кыйммәтле чит ил сигаретын суыра-суыра.—Нигә дәшмисең, кирәкме, юкмы?

—Көлүеңме, Сашок?!—дип гаҗәпләнде Володя.—Нинди машина ди ул?! Башта берәр рәтлерәк эшкә урнашасы иде. Хәзер анысы да авыр икән—күпләр эшсез калган. Хатын, бала бар, аларны туйдырырга кирәк. Күп җүләрләндем—акылга утырырга вакыт...

—Карале, Володя, бу юлы акылга җиңеләеп кайтмагансыңдыр ич? Мин сиңа конкрет сорау бирәм: машина кирәкме сиңа, юкмы?

—Мин түгел, син җиңеләйгән ул акылга. Нинди машина ди монда?! Сукыр бер тиен акчам да юк ич минем!

—Ай-ай күп сөйлисең син. Горби шикелле, тәмам ораторга әйләнеп кайткансың! Бер сүз белән генә җавап бир: кирәкме, юкмы?

—Кирәк түгел,—диде ул, сүзен кыскарта төшеп.—Хәзергә аңа ерак әле. Кайчан да булса күз күрер анда...

—Ә мин күзләреңнән укыйм: кирәк сиңа машина! Бүген үк кирәк!

—Җитәр, Сашок, көлмә миннән! Муеныңдагы алтын муенчагыңа, иномаркаңа, ахыр килеп дус булуыңа да карамам, физиономияңне танымаслык итәрмен. Беләсең, мин бервакытта да үземнән көлдермәдем. Пычак белән чәнчесәм чәнчедем, ләкин көлдермәдем! Менә шулай, Сашок.—Ул рәнҗегән кыяфәттә урыныннан ук тора башлады.—Ярый, сау бул! Сыең өчен рәхмәт.

—Тукта, җүләрләнмә! Кем көлгән синнән?! Утыр урыныңа! Көйсез кияү шикелле кыланасың. Ярар, бетердек, алайса, бу турыда. Башка вакытта сөйләшербез,—диде Александр.

Алар тагын бераз юк-бар темага сөйләшеп утырдылар да саубуллаштылар. Берничә көн күрешмәделәр. Хәер, Владимирның аның белән очрашасы да килми иде. Иномаркалы булган да, үзен әллә кемгә саный башлаган, янәсе.

Бер иртәдә йокысыннан торып ашап кына утыра иде, капка төпләрендә машина кычкырткан тавыш ишетелде. Володя тәрәзә янына килде. Караса, анда—ике машина, берсе янында Александр басып тора. Аны күрүгә, ул кулын күтәреп исәнләште дә тышка әйдәде. Ул, чәен дә эчеп тормыйча, ишеккә таба юнәлде.

—Син кая, Володя?—дип сорады хатыны.

—Мин хәзер, Нинуля...—Бу җавабы инде ишек артыннан ишетелде.

—Сәлам! Утыр, әйдә, машинага!—дип каршы алды аны Александр.—Бер җиргә барып киләсе бар...

Саша белән алар иномарканың арткы утыргычына кереп урнаштылар. Ике машинада да—бишәр кеше, таза егетләр...

—Кая барабыз?—дип кызыксынды Владимир, бераз баргач.

—Аулага, туган, аулага...—Александрның кызларныкыдай чибәр йөзен елмаю балкытып җибәрде.—Бераз күңел ачып керик әле. Өйдә яту туйдыра бит ул, Володя.

Алар автомобиль базары янына килеп туктадылар. Машиналарның

берсен бөтенләй читкә куйдылар да, чыгарга ашыкмыйча, урыннарында утыра бирделәр. Үзләре жыен юк-бар турында сөйләшә, кайсыдыр мәзәк сөйләп ала... Аннары Александр кулы белән шоферның иңбашына кагылып:

—Бар, тегеләргә әйтеп кил, «бишле»не яисә «алтылы»ны карасыннар!—диде ул.—Исләренә төшер, шоферы ялгыз булсын...

Теге тиз әйләнеп килде.

—Тәртип!—Ул алтын тешләрен ялтыратып елмайды да Александрга борылды.—Музыка куйыйммы?

—Кирәкми,—диде тегесе, катгый тавыш белән.

«Кара син моны!—дип гажәпләнде Владимир.—Кайчан гына кызлар сыман оялчан бер малай-шалай иде, хәзер нинди ир-егеткә әйләнгән! Урындагы «авторитет»мы әллә югыйсә?»

Төрле мәзәк хәлләр турында сөйләшә-сөйләшә ярты сәгатьләп вакыт узгандыр, мөгаен. Шунда ваемсыз гына кыяфәт белән, шул ук чакта ашыгуы да әллә кайдан сизелеп торган бер яшь кенә егет—Владимир аны теге машинада күргән иде—килеп арткы ишекне ачты да Александрга:

—Обьект ачыкланды, Ефимыч,—диде.—Нәкъ сез әйткәнчә...

—Яхшы. Хәзер нишли?—дип кызыксынды Александр.

—Кибеткә кереп китте. Нәрсәдер караштырып йөри.

—Күздән югалтмагыз, урыннарыгызда булыгыз! Күпергә житәрәк чамаларсыз...—диде Александр егеткә.

—Яхшы, Ефимыч,—дип тегесе үз машиналары янына ашыкты.

—Ә син, Рябчик, әнә тегендә басып күзәтеп тор: безнекеләр кузгалып китүгә сигнал бирерсең,—диде Ефимыч үзенең йомшак тавышы белән алда, шофер янында утырган таза егеткә.—Кара аны, йоклап калма, юкса, башыңны борып алып култык астына кыстырырмын!

—Барысын да о кей булыр, Ефимыч!—диде тегесе, аңа да эш табылуына шатлангандай елмаеп һәм, машина ишеген ачып, тышка атлады.—Сез дә уяу булыгыз, сигналны күрми калмагыз!..

—Бар, бар, эшеңдә бул!

Бу сөйләшү дә, монда нидер көтеп утырулары да Владимирны кызыксындыра башлады: «Ни сагалый болар? Нишләргә жыеналар? Бу әзмәвердәй егетләргә Сашка кем була? Ни өчен алар аның һәр сүзен, һәр боерыгын бернинди карусыз башкаралар?»

—Карале, Сашок, нишләп торабыз монда?—дип сорады ул, аңа борылып.—Кемне көтәбез?

—Без бик әһәмиятле операция үткәрәбез, туган,—диде Александр.

—Беләсеңме, мин шундый бер «операция»дән соң күпме төрмә шулпасын чөмердем? Житкән, башка утырасым килми!—Владимир, машинадан чыгарга омтылгандай, урынында хәрәкәтләнеп куйды.—Дус булып йөргән буласың тагын...

—Тик кенә утыр!—диде аңа дусты.—Беркем дә, бернинди начар эшкә дә тартмый сине. Ә тегендә утыруың—син моны яхшы беләсең!—башка нәрсә өчен бит. Нәрсә, без каракларга охшаганмыни?

—Мин алай димәдем,—дип мыгырданды Владимир.—Булыр-булмас эштә катнашып тагын эләгәсем килми, диюем.

—Курыкма! Безнең белән булганда, беркая да эләкмәссең, туган. Бу яктан тыныч бул! Без...

Шулчак аның сүзе өзелде—шофер:

—Ефимыч, сигнал!—дигән хәбәр салды.

—Киттек,—диде Александр.

Кузгалдылар. Юл уңаеннан Рябчик кушаматлы теге егетне дә утырттылар.

Алдагы машиналары «бишенче» «Жигули» артыннан бара иде, кинәт ул, тизлеген арттырып, аны узып китте һәм күпергә житәрәк, Владимирны гажәпләндереп, тизлеген кинәт кенә киметеп бара башлады һәм... кисәк кенә туктап калды. Шунда әле генә узып киткән «Жигули» машинасы арттан аларга килеп бәрелде. Бу шулкадәр тиз, кем әйтмешли, күз ачып йомганчы килеп чыкты.

—Нинди пешмәгән шофер утыра анда?!—диде ул Александрга, гаҗәпләнүдән күзләрен түгәрәкләндереп.—Узып та китте, шундук туктап та калды. Кем шулай эшли инде?!

Алар килеп җиткәндә егетләр, машинадан чыгып, «девятка»ларын карый иде. Аларның берсе, атлет гәүдәле шофер, бармагы белән әйдәп, «Жигули» шоферын чакырып чыгарды. Алар янында туктап, машинадан төштеләр.

—Ни булды, егетләр?—дип сорады Александр йомшак кына тавыш белән, аларның хәлен уртаклашкандай. Һәм үзләренең машинасы янына килде.—О-о! Ярыйсы ук сылаганнар сезгә!..

—Ничек кенә әле! Карагыз моны, хет кузовны алыштыр...—диде шофер, машинасына ишарәләп.—Доверенность буенча гына йөри идем, хәзер бу утильне ничек хуҗасына кайтарып бирим?! Миннән әбизәтельни яңа машина сораячак...—Аннары ул куркынган «Жигули» шоферына эндәште:—Йә, нишлибез?

—Соң, үзең... үзегез бит... Кем узып китүгә машинасын кырт туктата инде?!—дип җавап бирде тегесе.

—ГАИ чакырыгыз!—дип сүзгә Александр кушылды.—Үзем шаһит була алам. Күреп тордык. Син, абзый,—ул «Жигули» шоферына таба борылды,—бөтенләй йөри белмисең икән... Машина узганда кем шундый тизлек белән куа? Сине узып киткәндә тизлегеңне киметә төшәргә кирәк...

—Мин тизлекне арттырмадым!—диде шофер, еларлык булып.—Мин, гомумән, әкрен йөрим, әле моны алганыма ай чамасы гына...

—Әйтәм бит! Йөри белмисең, ә шундый юлга чыккансың. Ярар, анысы синең эш. Менә «девятка» тикле «девятка»ны яраксызга чыгаруың аяныч. Чыннан да, хәзер бу егет моны ни күзе белән хуҗасына кайтарып бирсен?! Кем алсын аны аннан?!

—Моны төзәтеп була ич...—диде кырык биш-илле яшьләрдәге «Жигули» шоферы, кулы белән ак чәчләрен сыпырып.—Чак кына яньчелгән ич... Бер сәгатьлек эш... Үзем төзәтеп бирә алам...

—Кирәкми миңа төзәтергә,—диде үзләренең шоферы. Владимир сизде, болар хәзер шулай кылана, янәсе, «девятка» егетләре иномаркадагыларны белмиләр. Янәсе, бу машина алар янында очраклы рәвештә генә туктаган. Төзәтелгән нәрсә барыбер төзәтелгән инде ул... Хуҗа миннән барыбер яңа машина таләп итәчәк. Син бөгештермә, турысын әйт, бу авария бәясен ничек, ни белән түлисең?

—Соң, егетләр, ни ич... үзегез гаепле ич... Причем монда мин?!—диде гәүдәсе генә түгел, куллары да калтырый башлаган мескен шофер.—Үзегез ич...

—Мин синнән, кем гаепле, дип сорыймммы? Әйт, сорадыммы?—диде аңа әзмәвердәй «девятка» шоферы, якасыннан эләктереп.—Йә машинаңны ярты бәясенә миңа сатасың, йә үзеңне дә, машинаңны да юк итәм! Сайла тизрәк, синең белән сүз көрәштерергә вакытыбыз юк.

—Алай кирәк түгел, егетлә-ә-әр,—дигән булды Александр, борынын җыерып.—Якалашудан кемгә файда? Машинага кереп утырыгыз да матур гына килешегез. Дөресен генә әйткәндә, аварияңең бәясе ярты «Жигули» тора да тора инде анысы,—«девятка» ич бу!—дип ул үзләренең шоферына бер кәгазь кисәге сузды.—Монда минем һәм иптәшләремнең адреслары. Әгәр эш ГАИга яисә судка барып җитсә, кирәгебез чыкса, диюем, табарсыз. Күргәнне шаһитларбыз...

—Бик зур рәхмәт инде сезгә,—дигән булды ана шофер егет.—Яхшы кеше икәнсез... Берәү булса, туктап та тормас иде. Чын күңелдән рәхмәт...

—Мин дөреслекне яратам,—диде Александр.—Әгәр йөри белмәгән һәр шофер «девятка»ны бәрдерә башласа... Ярый, сау булыгыз!

Ул, кырт борылып, бик эшлекле кыяфәт белән машинага таба атлап китте. Утырыштылар, кузгалдылар.

—Менә «операция» тәмам, туган,—диде Александр, бераз җир киткәч.—Ә син курыккан идең...

—Тегe шофер хаклы бит, сезнеке гаепле,—дип куйды Владимир.

—Хәзер, туган, кем көчсез, шул гаепле. Шуны хәтеренә сеңдереп куй!—дип елмайды дусты.—Замана бөтенләй башкача хәзер. Көчлеләр заманасы! Ярар, монысын гына үзең дә аңларсың. Йә, әйт, теге «бишле» «Жигули» ошадымы сиңа?

—Яхшы машина! Әле күптән түгел генә алдым, ди ич.

—Кулдан алган, яна түгел.

—Яна бугай?

—Юк. Алай да, ярыйсы гына әле.—Александр кулы белән Владимирның иңбашына каккалап алды.—Менә шул булыр синең беренче машинаң... Правана фотоларыңны әзерли тор! Ә эш турында ничек, кая кермәкче буласың?

—Белмим әле,—дип иңбашларын җыерып куйды дусты.—Ләкин болай эшсез йөрү килешмәс, каядыр урнашырга кирәк булыр...

—Үз эшеңне ачып җибәрергә кирәк сиңа, туган. Син бер елны кайдадыр шабашкада йөреп кайткан идең түгелме?

—Бер районда ферма төзегән идек...

—Алайса, нишләп сиңа төзүчеләр кооперативы оештырып җибәрмәскә?! Әйтик, башта зур булмаган бригада туплады ди...

—Син нәрсә Сашок?! Миннән нинди төзүче чыксын?—диде Владимир, аның сүзен бүлдереп.—Мин шабашкада разнорабочий булып йөрдем... Бу турыда уйлап та караганым юк...

—Ә син уйла! Хәзер слесарь-фәлән акчасына гына гаиләңне туйдыра алмассың. Заман башка, заман! Хәзер кемгәдер эшләү түгел, кемнәрнедер үзеңә эшләтү заманы. Баштарак оештыру эшләре, заказлар табу буенча үзем булышырмын. Ә аннары, әйтик, бер-ике айдан, үзең шундый кооператив башлыгы булып китәрсең, эшне кинәйтү юлларын эзли башларсың! Бер җаен алгач, үзеннән-үзе тәгәри ул. Хәзер бит гараж, коттеджлар күп салдыралар...

—Мин ташчы да, балта остасы да түгел ич, Сашок,—дип гаҗәпләнде Владимир.—Кая инде миңа андый нәрсәләр салу?!

—Ә кем сиңа, кулыңа кельма тотып кирпеч саласың, ди? Анысы ташчылар эше. Синең эш—оештыру! Җитәкчелек итү!

—Белмим, белмим... Гомердә дә уйлап караган эшем түгел...

—Ә мин нәрсә, элек сәүдәдә эшләгән идеммени?! Хәзер әнә, Аллага шөкер, дүрт киоск тотам! Бер кибет салып куярга да исәп бар тагын. Хәзер урын мәсьәләсен хәл итеп йөрим. Шунсыз булмый, туган. Кергән акча тагын акча эшләргә тиеш! Менә шулай.

Сөйләшүләре шуның белән өзелде—аны Талмычыга, өенә кайтарып куйдылар.

Александр аның янына нәкъ бер атнадан соң яңадан килеп чыкты. Тагын ике машина белән килгәннәр, тик бу юлы теге «девятка» түгел, ә «бишенче» «Жигули». Ул ниндидер серлелек белән елмая-елмая керде дә бик җылы, бик эшлекле кыяфәт белән күрешеп:

—Капканны ач, туган, машинаңны кертәбез, кабул итеп ал!—дип кесәсеннән кәгазьләр чыгарып аңа сузды.—Курыкма, законлы итеп синең исемгә теркәлгән, автомагазин аша сиңа сатылган. Менә документлары...

—Син нәрсә, Сашок, син нәрсә?!—дип Владимир, бу хәлнең чынлыгына ышанырга да, ышанмаска да белмичә, бөтенләй каушап калды.—Кирәк түгел миңа машина! Хәзергә рәт юк, дип әйттем ич...

—Менә нәрсә, туган, күп сөйләшкәнне җенем сөйми,—дип бүлдерде аны дусты.—Ташла шул сентиментальлегеңне! Синең шикелле әзмәвердәй, мәһабәт ир затына килешми ул. Шоферга әйтелгән, ул сине бер атна эчендә «Жигули»еңда ут уйнатып йөрергә өйрәтер. Шуннан соң праваңны үзем рәтләп бирермен...

—Права алыр өчен курсларда укырга, аннан соң машина йөртү һәм урам кагыйдәләре буенча имтихан тапшырырга кирәк бит әле, Сашок. Мин мотоцикл правасын алу өчен генә дә өч мәртәбә имтихан үттем. Анда кисәләр дә кисәләр. Ә монда—машина!..

—Әйе, элек шулай иде. Көчсезләр өчен хәзер дә шулай. Тик бу безгә

кагылмый, Володя. Теләсәм, бүген үк берничә права юнәтә алам. ГАИдан, законлы итеп! Чөнки дуслар бар, дуслар...—Александр, тын алгандай, беразга туктап калды, сүзен аннары гына дәвам итте.—Менә нәрсә, туган, машинага утыруга, эчүне ташларга кирәк булыр. Юк, юк, бөтенләй димим, әлбәттә. Вакытын һәм кешесен белеп кенә, чама белән генә кабарга... Әгәр кооператив та оештырып җибәрсәң, бигрәк тә... Карале, ул мәсьәләдә эшне озакка сузма! Яхшы гына ташчылар бригадасы тупла, берничә, әйтик, дүрт-биш балта остасын чакыр... Менә шуннан башланып китә инде ул эш дигәнең. Совхозыгыз житәкчеләре белән сөйләш, машиналар паркыннанмы, гаражларыннанмы бер почмак бирсеннәр. Сөйләшә белсәң, кирәк чагында машиналарыннан да файдаланып булыр. Бөтенесе дә үзеңнән тора. Бел, тәгәрмәчтәге тиен шикелле бөтерелергә туры киләчәк. Менә ни өчен кирәк сиңа машина! Шунсыз сине кешегә да санамыйлар хәзер!

—Бу тәгәрмәч өчен кайчан, ничек түләрмен икән соң мин, ә, Сашок?—дип сорады Владимир, инде бераз йомшара төшеп.—Хәтта моны хатынга ничек аңлатырга да белмим. Тагын ярамас юлга баскансың, дип елаячак.

—Дуслар вакытлыча биреп торды, үз эшемне башлап җибәрергә җыенам, диген. Аңламый калмас. Ә түләү мәсьәләсендә кайгырма, бераз аякка баскач анысы. Бер җае чыгар әле...

* * *

Владимир Илюхин үзенең эшен дусты Александр Журавлев идеясе, аның турыдан-туры булышлыгы белән, курка-курка гына, кыюсыз гына башлап җибәргән иде. Ләкин барысы да нәкъ ул әйткәнчә килеп чыкты. Таныш-белешләре аркылы тиз арада уникe кешелек ташчылар бригадасы туплады, алты балта остасын эшкә алды. Дустына рәхмәт, йөз шәхси машиналык коллектив гараж төзелеше заказын табып бирде, хәтта килешү төзергә дә булышты. Инде дәүләт кул астындагы төзелеш оешмалары да әкренләп эшсез кала барган, эшчеләрен көннән-көн кыскартырга мәҗбүр булган бер вакытта мондый заказ алу зур уңыш иде. Тиздән тагын бер ташчылар бригадасы җыярга туры килде. Дусты дөрес әйткән: эшен башлап җибәрүенә ай ярым чамасы да үтмәде, ул бу эшенең асылына, төбенә үк төшеп җитте. Әйтерсең, уннарча ел төзелеш белән генә шөгыльләнгән! Баксаң, аның куркырлык нәрсәсе дә юк икән ләбаса! Заказчыны табасың, килешү төзисең, аннан бераз аванс акчасы аласың, заказчикны материаллар турында кысасың, һәрдаим хәтерләтеп торасың. Әгәр дә мәгәр аның гаебе белән эштә өзеклек килеп чыга икән, моның өчен аннан өстәмә акча каерасың... Шуның өчен килешүне бик акыллы итеп, һәр нәрсәне ачыктыртып, искә алып төзү бик мөһим. Дөрес, чабарга туры килә, шунсыз эш бармый. Тора-бара алдан күрергә дә өйрәнде: әле бер объекты бетеп җитмәгән, ә инде аның кесәсендә икенче төзелеш турында килешү ята.

Тиздән тагын бер нәрсәне бөтен тирәнлеге белән аңлап алды: иң мөһиме—тәртип! Шул нәрсә юк икән, бу инде эшнең сыйфаты да юк дигән сүз. Шуңа күрә ул тиздән, эшчеләр әйтмешли, ерткычка әйләнде. Эш вакытында берәрсен исерек хәлдә күрсә, аны шундук эшеннән куды. Алай гына да түгел, андыйларга кул күтәргән чаклары да булды. Аның Гулливерныкыдай гәүдәсе үк кешеләрдә курку хисе уята, ямьсез, төсен дә аерып булмый торган күзләре белән бер караса, котың ботыңа төшәр.

Кызык хәл, кешеләр аннан курыккан саен, күңел төпкелендә ниндидер рәхәт хис уянды, үзен дөньяда бик көчлеләрнең берсе итеп сизә башлады, ә бу исә анда зур канәгатьләнү тудыра, кешеләрнең үзеннән куркып торуларын күрү аңа яна көч өсти иде.

Анынча, эшнең сыйфаты мәсьәләсендә дә чалбар төбе туздырып биш ел буе институтта укып йөрүнең дә кирәге юк икән. «Ошый», «ошамый», «яхшы», «начар»—болар аның сыйфат үлчәмнәре, эшкә бәясе. «Ошамый», «начар» дип ничә ташчының яңа салган стеналарын аягы белән тибеп җимергәне булды. Шуннан соң барысы да «ошый», «яхшы» үлчәменә туры килерлек итеп эшләргә тырыша. Әлбәттә, көн саен тибеп стена җимерә

дигән сүз түгел, ләкин эшчеләр тугарылып китмәсен, эшләренең җаваплылыгын һәрдаим сизеп торсыннар өчен ул моны әледән-әле кабатлап тора иде.

Кыскасы, кооператив көннән-көн ныгый барды, озын телләр әйтмешли, Талмычыда «Илюхин хуҗалыгы» пәйда булды.

Дөресен әйтергә кирәк, бу кешедә ниндидер җитәкчелек таланты дигән нәрсә дә юк түгел иде: эшнең асылын, нишләргә, нәрсәне ничек ерып чыгарга кирәклеген бик тиз төшенеп алды ул. Ни әйтсән дә, анда алдан күрә, нәтиҗәләр ясый белү, чагыштырып карау сәләте бар иде.

Илюхин хәзерге заманның тагын бер кырыс чынбарлыгын аңлады: барысы да ала! Акча—кирәкле йомышыңны тиз башкарып чыгу инструменты. Кыштырдап торган әнә шул акчаны кирәкле җирдә кирәкле кешесенә төртмәсән, юк кына эшенне ерып чыгу өчен дә чиновниклар катына аяк киемен тузганчы йөрергә мөмкин, ә шуны төрттеңме яисә аларның кирәгенә колак салдыңмы, йомышыңны көне белән түгел, сәгате белән башкарып чыгалар! Кырыс та, кызык та хәзерге замана...

Ел ярым дигәндә Илюхин үзенә ике катлы кирпеч йорт, гараж салдырып куйды, йорт-җирен биек кирпеч коймa белән әйләндереп алды, яңа машиналы булды. Чит илдән кайткан, абруй-дәрәҗәлек билгесе саналган иномарка иде монысы!

Кооператив та үсте. Төзелеш материаллары сатуны, фатир, офислар ремонтлауны оештырып җибәрде. Яңа йөк машинасы, автокран сатып алдылар.

Менә шулай җай белән генә, матур гына эшләп-яшәп ятканда, көтмәгәндә генә бер күңелсезлек булып алды. Борисково бистәсендә кирпеч йорт белән гараж салып яталар иде. Моны әллә ни зур күләмле эш дип булмый, моннан дүрт-биш мәртәбә күләмлерәкләре, бик ашыгыч кирәклеләре дә бар. Шуңа күрә ул, берничә ташчыны аннан алып, әнә шул кирәклеләренең берсенә өстәгән иде. Нәтиҗәдә бу объектны төзү сузыла төште, килешүдә күрсәтелгән вакыт өзелде. Заказчик, үзе шикелле үк әзмәвердәй, ләкин күпкә яшьрәк егет, тавыш куптарды. Бу, әлбәттә, үз-үзен хөрмәт иттерергә өйрәнеп җиткән прорабка ошамады. Сүз иярә сүз чыгып, алар бер-берсенең бакчасына шактый гына авыр ташлар аттылар.

—Телим икән, үзеңне ташчы итеп бастыра алам мин, кәҗә!—дип җикеренде егет шундый сөйләшүләрнең берсендә.—Алдымда шуышып йөрергә риза булырсын...

—Менә бу нәрсәмне тот!—диде моңа каршы үзе белән бу тонда сөйләшергә беркемнең дә кыймавына күнеккән прораб, ярсый төшеп, һәм оят җиренә төртеп күрсәтте.—Күргәнең бармы шуны? Булмаса, күрсәтермен мин сиңа, салага!..

Егет тә сүзгә дип кесәгә керә торганнардан түгел иде бугай.

—Нәрсә, сиңе бу дөньяда яшәү туйдырдымы әллә?—диде ул.—Монысыңнан туйсаң, тегесенә олактыра алам. Иртәгә үк эшне җанландырып җибәрмәсән, кара аны, кооператор, мин сүземне җилгә җибәрергә күнекмәгән... Аннан соң инде сиңа кооперативың да кирәк булмас...

—Куркытма! Синең ише фраерларны күп күргән мин! Ачуны китерсән, башта үзең китеп бармагаең анда... Мин дә шаярырга яратмыйм.

Дөрес, ташчыларны кире кайтарырга, хәтта берничә кеше өстәргә дә туры килде. Алай гына да түгел, икенче көнне үк, теге егет янына килеп, гафу үтенергә дә мәҗбүр итте үзен. Баксаң, ул «Борисково» төркеме лидерларының берсе икән ләбаса! Ярый әле бу турыда шул ук кичтә Александрга сөйләгән иде. Аңа рәхмәт, теге әзмәвернең кемлеген ул төшендерде, өен дә, гаражын да тизрәк бастырып куярга кушты.

—Куркыныч фигура!—дип куйды Александр сүз ахырында. Аннары аңа бик тә әһәмиятле кисәтү ясады:—Киләчәктә эшең гөрләсен дисәң, бервакытта да заказчы белән сүзгә кермә! Дипломат бул! Яхшы репутацияне яулавы гына авыр, ә бер төшә башласа, көч белән дә тотып кала алмассың, туган. Ышаныч дигән нәрсәне югалтудан курык! Һәрвакыт курык!

Нишлисең, олы башын кече итеп егеттән гафу үтенергә мәҗбүр

булды. Эшнең күплегенә, кешеләрнең җитмәвенә зарланып алды. Гафу иткәндерме аны бу «куркыныч фигура», юктырмы, ул бары тик:

—Болар синең проблема. Ярар, аңладым мин. Әгәр дә мәгәр тагын юлларыбыз менә шулай очраша икән, миннән яхшылык көтмә, сытам!—дип Илюхинны ниндидер билгесезлек дәрьясына ташлап сүзен тәмамлады.

Җитмәсә, бу турыда сөйләп биргәч, Александр да аны пошаманга салып:

—Күрдеңме, туган, нинди ялгышлык җибәрдең. Ул бит бөтен бистәне дер селкетеп тора!—диде.—Сак бул, алдыңны-артыңны карап йөр! Аның өчен Илюхин дигән кооператор чебенгә дә тормый. Әллә ниләр көтәргә мөмкин ул бәндәдән. Тән сакчысы кирәк сиңа...

—Анысы ниемә тагын?!—дип гаҗәпләнде Владимир һәм көлеп куйды.—Мина кем кагылсын? Андый адәм табылса, мин аны шушы уч төпләремдә порошокка әйләндерәм!

—Хәзер бөтен бәла да шунда, туган, кагылып-сугылып тормыйча, почмактан гына аталар. Ә кешегә, ул нинди генә көч-куәткә ия булмасын, тугыз граммлы бер кургашын кисәге җитә... Менә бит эш нәрсәдә. Син әйткәләшкән адәм үзенең ике көндәшен юк иткән дип сөйлиләр. Ике ел инде үзләрен дә, эзләрен дә таба алмыйлар! Ә син—порошок, имеш...—Александр сигарет кабызып, ашыкмыйча гына тирән итеп суырып алды.—Сак кирәк сиңа хәзер, кичекмәстән сак кирәк. Әлбәттә, безгә сыенырсың, без дә рәнҗетергә ирек бирмәбез...

—Кемгә инде бу «безгә?»—дип сорады Илюхин, үгезнекедәй юан, кыска муенында утырган башын кинәт аңа борып.

—Безнең егетләргә,—диде тегесе, нечкә, озын бармагы белән сигаретының көлен кагып.—Син аларның берничәсен теге «операция» вакытында күрдең. «Таулар» төркеме егетләре булыр алар...

—Әйт, Сашок, ә син... ә син шуларның лидеры, башлыгымы? Дөрес чамаладыммы?—диде Владимир, үзенең билгесез мәсьәләне чишүенә сөенгәндәй.—Шулаймы?

—Шулай, шулай. Синнән яшереп булмас. Тик авызыңа май кап!

—Әйтәм аны... Синнән күпкә таза, озын буйлы егетләр дә алдыңда калтырап торалар. Мин моңа бик гаҗәпләнгән идем ул чакта. Сере бар икән...

—О-о! Бездә дисциплина нык!—дип елмайды Александр.—Шунсыз ярамый, шунсыз беттең дигән сүз. Карале, туган, бер йомыш бар сиңа...—Ул, сүзләре ничек тәэсир итүен белергә теләгәндәй, кинәт кенә үзенең чем-кара күзләрен дустына төбәде, бераз пауза ясап алды. Сүзен шуннан соң ашыкмыйча гына дәвам итте.—Берәүне куркытасы иде...

—Ничек куркытасы?!—дип гаҗәпләнде Илюхин.—Нигә куркытырга аны?

—Бурычы бар... Ә түләргә теләми, сволочь! Аңлыйсыңмы?

—Ә монда минем ни эшем бар?!—дип кашларын җыерды Владимир.—Ул миңа бурычлы түгел ич, Сашок...

—Шәхсән үземә дә тиешле түгел. Тик ул безнең бер танышыбызны төп башына утырткан. Кешегә ничек ярдәм итмисең? Бу дөнья шуның белән бара. Кирәк чакта үзеңә дә ярдәм кулы суздык бит, туган. Син курыкма, минем егетләр белән барасың.—Ул Илюхинның башыннан аягына хәтле күз йөртеп чыкты.—Куркытырлык солидность бар синдә...

—Мине карачкы урынына кулланмакчы буласыңмы, Сашок?—дип көлде Владимир.

—Син нәрсә инде?—Александр, үпкәләгәндәй, юка иреннәрен турсайтты.—Ярар, булышырга теләмисең икән, сина сүз катмадым дип сана.

—Әллә үпкәләдең? Соң, мин каршы түгел, Сашок... Булдыра алсам... Тик аңлат, нәрсә, ничек, кайда?

—Менә бу икенче эш!—дип елмаеп куйды дусты.—Менә хикмәт нидә...

Ул аңа бәйнә-бәйнә эшнең асылын төшендерә башлады. Сөйләвенчә, танышлары берәүгә машина саткан. Теге кеше ярты бәясен алганда ук

түләгән, ә калганын ГАИда рәсмиләштереп бетергәч бирергә килешкәннәр. Ләкин инде эшне бар яктан да законлаштырып куйганнан соң, бу машина алай ук тормый, дип калганының бик азын гына бирмәкче булган. Әле анысын да инде биш ай буе бирми йөртә икән. Ә үзе шактый ук хәлле кеше ди, кайдадыр күп акча алып эшләүче чиновник ди. Шәһәр читендә коттедж салдырып ята, яхшы гына дачасы бар икән. Менә шул кешедән бурычын—инде күпкә арттырып!—түләттерергә кирәк икән... Үзе генә түгел, аның белән өч машинада тагын берничә егет барачак. Александрның сүзләренә караганда, ул кеше ял көнне дачасында була икән, шунда сөйләшү зарур.

Билгеләнгән көнне өч машина теге кешенең дачасы янына килеп туктады. Хужа трусиктан гына бакчасында йөри иде.

—Шушы ул,—дип пышылдады Илюхинга Александр егетләренең берсе.

Хужа кеше, килеп туктаган машиналарга башта әллә ни игътибар итмәсә дә (азмыни монда ял итәргә килүчеләр!), көтелмәгән кунакларның аларга таба килүләрен күргәч, ниндидер эчке сиземләве белән моның яхшыга түгеллеген аңлап бугай, тынычсызланып куйды, әкрен генә өенә таба борылды.

—Сәлам, Василий Иннокентьевич!—диде Илюхин, бакча капкасын тибеп ачып.—Көттегезме безне? Каршы алыгыз!

—Сәлам!—дип җавап кайтарды корсагы тезенә салынып төшкән, тәбәнәк гәүдәле, пеләш башлы хужа, кояштан саклангандай, уң кулын маңгаена куеп.—Ләкин мин бернинди кунаклар да көтмим...

—Без чакырмыйча килә торган кунаклар,—диде Владимир, капкадан керүгә туктап.—Чык әле! Сүз бар...

—Эш нәрсәдә? Нинди йомыш?—дип баскан жирендә катып калды дача хужасы. Аның тавышына курку төсмере сеңгән иде.

—Булышыгыз!—дип егетләргә ым какты Илюхин, аннары ир-атка мөрәҗәгать итте:—Начар ишетәсеңме әллә?

Егетләр аңа таба атлады. Ул исә моны күреп, исенә килеп бугай:

—Мин хәзер... Өскә генә киям дә...—дип мыгырданды.

—Киеп торма. Нигә мәшәкатьләнергә? Болай гына сөйләшәбез...

Чыгып, уртадагы машинага утырдылар: ике егет—алда, арткы утыргычта—ялангач Василий Иннокентьевич белән Илюхин.

—Хәтерлисездер, хөрмәтле Василий Иннокентьевич, өстегездә зур бурыч тора. Шуңа килдек,—диде Владимир бер дә ашыкмыйча, һәр сүзенә басым ясап, янә «Сез»гә күчеп.—Хәзерге заманда килешә торган нәрсә түгел бу. Бурыч түләнүе белән яхшы, ди бит халык мәкале.

—Мин сезгә берни дә тиеш түгел! Сезне беренче тапкыр күрүем,—диде «корсак».

—Альберт Хөсәеновтан машина сатып алдыгызмы?—дип сорады Илюхин.—Әллә инде бу турыда онытттыгызмы? Менә шул бурычны юллап йөреш безнең, хөрмәтле Василий Иннокентьевич. Ә сез, тиеш түгел, дисез. Тиеш икән бит, ә?

—Ул машина килешкән бәя тормый...—дип мыгырданды бурыч турында ишеткәннән соң ничектер кечерәеп, мескенләнеп калган ир.—Ялгышканбыз...

—Сезгә аны ирексезләп такмаганнардыр ич, алмаска иде,—диде Илюхин, «Мальборо» сигареты кабызып.—Без сүз көрәштерергә килмәдек, хөрмәтле Василий Иннокентьевич. Йә ике көн эчендә килешенгән сумманың калганын һәм плюс тагын шул хәтле акча түлисез,—чөнки вакытында түләмәгән өчен пенясы шулай артты!—йә ул машина малаегыз белән бергә авариягә эләгә... Бездән булсын изгелек, тагын бер вариант бар: дачагыз—ул болай ярыйсы гына икән—машина иясенә күчә. Законлаштырып, нотариус аркылы. Йә...—Ул ике кулын ике якка җәеп җибәрде. Шунда алда утырган егетләрнең берсе, кесәсеннән пистолет чыгарып, ашыкмыйча гына карагандай итенде дә аны кире салып куйды. Сизелеп тора, ул моны бу кешене куркыту өчен эшләде.—Аннары ни инде... Тиешле бурычыңны да түли алмагач, дөньяда нигә яшәргә?—Владимир шоферның иңбашына кагылып алды.—Кузгалдык!

Шофер сигнал бирде, кулы белән алга әйдәде һәм машиналар кузгалып китте.

—Туктагыз әле, егетләр, туктагыз!—дип ялварды ир кеше.—Сөйләшеп бетермәдек бит әле. Уйларга ирек бирегез!..

—Бер ел вакыт эчендә әллә нәрсәләр уйларга мөмкин иде. Мин әйтәсемне әйттем,—диде Илюхин.—Безнең—вакыт, сезнең намус юк. Күпме вакыт үтте, ә сез...

Машиналар, «корсак» дачасын артта калдырып, урман янына якынлашты. Илюхин шоферга алдагы машинаны узарга кушты һәм узып бераз баргач, төп юлдан борылып, урман юлына керде, бер ачыклыкка килеп туктады. Василий Иннокентьевичтан башкалары барысы да машиналардан чыгып, кул-аякларын язып, саф һава суларга керештеләр.

—Чыгыгыз, чык, Василий Иннокентьевич! Килеп життек... Монда һава саф, кошлар сайрый. Шуны әйтәм әле, яшәү дигән нәрсә ничек күңелле, шайтан алгыры!..

«Корсак» башта куркынып-шикләнеп торса да, теләмичә генә машинадан чыкты. Үзе калтырый, кыяфәте бөтенләй мескенләнгән, гәүдәсе бөрешеп калган иде.

—Мондый саф һавада уйлавы да жиңел,—дип елмайды Илюхин.—Йә, хөрмәтле Василий Иннокентьевич, вариантларның кайсысын сайладыгыз?

—Акча, егетләр, акча! Сез әйткәнчә... Тиененә тикле!—дип ашыга-ашыга әйтеп салды ир кеше.

—Кайчан?

—Өемдә юк. Сишәмбе көнне банктан алып бирәм! Үз кулларым белән... Әйдәгез, сәгать уннар тирәсендә банк янында очрашыйк...

—Ю-у-ук,—дип сузды Владимир, елмаеп.—Болай эшлибез: тиешле акчаны—әле генә сөйләшкәнчә, ике тапкыр арттырып!—Хөсәенов фатирына китерәсез. Нәкъ унбер сәгатьтә! Аңлашылдымы? Тик карагыз аны, әгәр дә мәгәр милиция-фәләнгә белгертәсез икән, шундук үзегезне мәет дип саный аласыз... Без шаяра торганнардан түгел...

—Сез нәрсә инде, егетләр?!—диде калтыранган ир-ат. Әйткән сүз—аткан ук. Бурычымны вакытында кайтармавым өчен гафу үтенәм... Чын күңелдән... Ялгышып киттем...

Владимир Илюхинның «Таулар» төркеменә юлы менә шушы көннән, менә шушы «куркыту операциясе»ннән башланды. Бу яңа эш аңа кызык булып тоелды. Ул үзе башкарган бу тәүге эшенең нәтижәсен түземсезлек белән көтте: «Сүзендә торырмы бу корсаклы ир заты, әллә тагын алдарга тырышырмы?» Шул ук вакытта бераз шөлләде дә. «Ә милициягә житкерсә?» Үзенең шиге турында Александрга да әйтте.

—Курыкма!—диде тегесе.—Аның һәр хәрәкәтен күзәтеп торучылар бар... Безгә һәр адымы билгеле...

Василий Иннокентьевич дигәннәре, чыннан да, сүзендә торды (кемнең инде тик торганда гына үләсе килсен!), билгеләнгән көнне, килешкән сәгатьтә Хөсәенов яшәгән йорт янында сораган акчаны тулысы белән алар кулына тапшырды. Бу эштә төп рольне үтәгән Илюхинга акчаның шактый өлеше эләкте.

Әйе, Александр аны машиналы итте, кооперативын оештырып жибәрергә, заказчылар табарга булышты. Шуңа күрә аның әллә нигә бер чыккан йомышын үтәүдән баш тарту килешми генә түгел, дуслыкларына тап төшерү кебек нәрсә итеп кабул ителер иде. Тора-бара мондый йомышлар, мондый «операция»ләр күп тапкырлар кабатланды. Хәтта бу роль, бу «эш» аңа кызыклы булып тоела башлады. Аннары, ни әйтсән дә, әжерләре дә зур акчалар белән исәпләнә иде. Шулай итеп, ул «Таулар» төркеме лидерларының берсенә әверелде. Александр аны «штаб»ына тәкъдим итеп, көннәрнен берендә кыска гына, ләкин һәр сүзенә басым ясап:

—Аның боерыгын минем боерык дип санагыз!—диде.

Бу зур ышаныч дигән сүз иде. Аны озын буйлы, тап-таза ике тән сакчысы озатып йөри башлады. Өендә дә сакчы тотты. Йә «Төзүче»

кооперативы эшчеләре, йә «Таулар» төркеме әгъзалары иде алар. Бу эш барысыннан да күбрәк кооперативта сакчы булып эшләүче Серый кушаматлы Сергей Храмм жилкәсенә төште. Моның өчен аңа көпшәсе киселгән ау мылтыгы—обрез бирелде.

Корал дигәннән, әле ел чамасы элек кенә моны кирәксез нәрсәгә санаган Илюхин соңгы вакытта бер-бер артлы «ТТ» һәм «Вальтер» пистолетлары, көпшәләре киселгән ау мылтыклары, берничә Ф-1 гранатасы сатып алды. Сәбәбен әйтүе кыен, ләкин шунысы хак, анда утлы коралга карата ниндидер азарт уянды. Аның өчен корал көч символына әверелде. Дөрес, ул тиздән берәр көпшәле ике обрезын «Таулар» төркеме әгъзасына сатып жибәрде. Үзе исә «ТТ» пистолетын корылган килеш гел кесәсендә йөртә торган булды. Ул аңа кагылып-кагылып алганда да бетмәс-төкәнмәс көч тоя иде шикелле.

Тормыш үз чираты белән тәгәри, көн артыннан көн уза торды. Кооператив зур табыш китерде, төп эшләре сәүдә «нокта»ларыннан, төрле кооператив, фирма, шәхси предприятиеләрдән (жае чыкканда хәтта хөкүмәтнекеләрдән дә!) ясак жыю, икенче төрле әйткәндә, рэкет белән шөгыльләнү булган «Таулар» төркемендә дә гажәеп зур акчалар кулга керә торды. Илюхин хәзер көчлеләр заманы икәненә бөтен барлыгы белән инанды. «Көч булса, патша шикелле яшәргә мөмкин икән ләбаса!—дип горурланды, тормышының, ниһаять, кирәкле, тиешле эздән китүенә куанып.—Сашокка рәхмәт, үз эшемне башларга беренче булып ул тәкъдим итте, зур булышлык та күрсәтте. Йөргән булыр идем тиеннәргә бил бөгеп...»

Ләкин, көннәр дә гел кояшлы булып тормаган кебек, тормыш та һаман без теләгәнчә генә бармый шул. Көннәрдән бер көнне «Таулар» белән «Борисково»лыларның юлы кисеште...

Зур гына кибет ачылды. «Ачылган—ачылган. Бик яхшы. Хәзер аны үз түбәбез астына алырга кирәк», дип уйлады «Таулар» төркеме лидерлары. Гади генә әйткәндә, төркем аны үз саклавына ала, ә кибет хужалары ай саен аларга билгеле бер сумманы түләп барырга тиешләр. Әгәр «түбә астына» керергә теләмәсәләр, ягъни акча түләп торудан баш тартсалар, ни буласы билгеле: йә анда янгын чыга, йә шартлый, йә хужасы физик көчләүгә тартыла.

Ә «Супермаркет» дигән бу яңа кибеттән шактый акча каерып барырга мөмкин—зур да ул, халык күп йөри торган урында да урнашкан, кереме яхшы булырга охшый. Инде кибет хужасы белән килешеп, бер айлык акчасын да алып аны «үзләренеке» дип саный башлагач кына аның «Борисково» төркемен дә кызыксындыруы билгеле булды. Дөресрәге, алар да, кибет хужасы янына килеп, «түбә» тәкъдим иткәннәр икән.

—Сез нәрсә, егетләр?!—дип күзләрен түгәрәкләндергән тегесе.—Без «түбә» астында инде!..

Кемнәр алар өлешенә кергән? Кемнәр аларның майлы калжасына кул сузган? Бу кибет алар биләмәсенә туры килә ич! «Борисково» төркеме лидерлары чыгырларыннан чыгарлык дәрәжәгә житә. Мондый «нокта»ны вакытында күрә, «эшкәртә» алмаган тиешле әгъзаларга да эләгә. Ачыклый торгач, моның «Таулар» төркеме эше икәнлеге беленә. Александр Журавлев янына, мәсьәләне уртага салып сөйләшү өчен, яраннарын ияртеп, «Борисково» төркеме лидерларының берсе килеп чыга.

Алар килеп кергәндә Владимир Илюхин да шунда иде. Салкын гына күрештеләр. Караса, лидер дигәне,—теге вакытта Александр дөрес әйткән икән,—«Төзүче» кооперативы өй белән гараж салып биргән, шул чакта сүзгә килгән егет!

—Ә бу «төзүче» монда нишләп йөри?—дип сорады ул, күрешергә дип кулын сузган Илюхинны танып, ләкин аңа кулын бирмичә. Күрәсең, теләге аны кимсетү иде.—Бу бәндә кешечә сөйләшә дә белми...

—Ул безнең егет, Григорий туган. Киләчәктә моны искә алуыңны сорыйм, ә хәзергә кул бирешегез!—диде Александр. Шунда Григорий дигәне жиңелчә генә елмаеп Илюхинга карап алды һәм күрешергә мәжбүр булды. Алай да, күзләреннән ниндидер салкынлык сизелә иде.—Сөйләшү

мәсьәләсендә дә ялгышасың, туган, теләсә кайсы ил дипломаты белән сүз йөртә алырлык ул!

Беренче булып сүзне «Борисково» төркеме лидеры башлады. Ашыкмыйча гына, һәр сүзен үлчәп кенә сөйләүчән икән. Читтән күзәткән кеше аны дипломат дип уйларга мөмкин, валлаһи. Мөлаем йөзенә, кыяфәтенә килешеп торган ап-ак күлмәк, бик пөхтә, зәвык белән бәйләнгән зәңгәрсу галстук, чем-кара, бераз бөдрәләнеп-дулкынланып торган чәч, кызларныкыдай дугаланып йөзенә ямь, ниндидер матурлык өстәүче кара каш. Кемгәдер, бу бер төркемнең башлыгы, дисәң, гомергә дә ышанасы түгел. Аны табиб яисә укытучы дип уйларга мөмкин.

—Нигә безгә үзара конфликтка керергә?—диде ул, затлы тәмәкесен суыра-суыра.—Безнең—үз территориябез, сезнең—үзегезнеке. Маркет безнең биләмәдә урнашкан. Сезгә нигә анда барып керергә иде? Белеп торасыз, органнар безне болай да сөйми, хәтта күралмый. Үзара тавышланып алар игътибарын тарту кирәкле эш түгел, минемчә. Джентельменнарча гына килешергә кирәк, ул безнең түбә астында булырга тиеш. Дөреслек буенча... Корал белән чишелергә тиешле нәрсә түгел бу. Әгәр телисез икән, ул чагында...

Озын, нечкә бармаклары белән пианистка, бөтен кыяфәте, үз-үзен тотышы белән интеллигентка охшаган Александр да дипломаттан ким түгел иде.

—Беренчедән, ул маркет, Григорий туган, безнең биләмәгә якынрак урнашкан. Икенчедән, аның белән беренче булып без контактка кердек. Ә бит кибет ачылуга ук йөгереп бармадык без аңа: көттек, тукта, бәлки аны сез үз яклавыгызга алырсыз дип уйладык.—Ул «сез» сүзенә мәгънәле басым ясап алды. Әлбәттә, көттек, дию чеп-чи ялган иде.—Ә хәзер, инде тиешле контакт урнаштыргач, юкны таләп итәбез. Егетләрчә түгел бу, Григорий туган. Күрәм, тыныч кына, бер-беребезнең хокукларын хөрмәт итеп яшәү ошамый сезгә. Корал белән куркыту егетлек түгел. Корал бездә дә җитәрлек... Аннан беребез дә отмый...

Сөйләшү шактый озак барса да, тәгаен бер карарга килә алмадылар—һәр ике як та үзенә каерды. Һәр ике якның да үз туксаны—туксан: «Үземнекен беркемгә дә бирмим!» Шуңа күрә салкын гына аерылыштылар. Бәхәсле мәсьәлә хәл ителмәде, ике төркем арасындагы киеренкелек исә әүвәлгедән көчлерәк иде инде. Моны барысы да яхшы аңлады. Александр, эш «разборка»га җитә-нитә калса, дип төркем әгъзалары арасында уяулыкны көчәйтергә боерык бирде. Кораллар барланды, кизү торучы сугышчан төркем төзелде, кирәк булган очракка дип машиналар билгеләнеп куелды.

Вакыт үтә торды, «Борисково» төркеме ягыннан нинди дә булса зыянлы адым сизелмәде. Инде бу мәсьәлә онытыла да башлаган шикелле иде. Ләкин беркөнне,—ял көнне иде бугай,—Илюхин йортында сакта торучы Сергей Храмм өйгә, аның янына, йөгереп керде дә ашыгып:

—Анда сиңа Борисководан кунаклар килгән. Сине сорыйлар, Шеф,—дип, көтелмәгән хәбәр җиткерде.—Ни диярга? Кертергәме?

Бу сүзләрне ишетүгә Владимир коелып төшкәндәй булды, бер мәлгә хәтта кинәт баһадирдай гәүдәсе куырылып-кечерәеп калгандай тоелды. Ә башыннан яшен тизлеге белән: «Әллә разборкамы? Үч алу өчен килгәннәрме? Ни өчен миңа, Ә Сашокка түгел?!»—дигән уй йөгереп үтте.

—Ничә кеше? Ничә машина?—дип сорады ул тиз генә.

—Бер генә машина, Шеф! Ике маңка малай-шалай шунда...—дип җавап бирде аңа Сергей ваемсыз гына.—Ләкин үзләре «девятка»да!

—Тик берәм-берәм тикшереп керт—кораллары булмасын! Кара аны!..

—Аңлашылды, Шеф!—дип Сергей шундук ишегалдына атылды.

Владимир, капка ягындагы тәрәзә янына килеп, пәрдә аша урамга күз салды. Сергей капкадан чыгып машина янына килде, нәрсәдер әйтте. Егетләрнең берсе аның белән бергә ишегалдына керде. Капка бикләнде. Сергей тегене баштанаяк тентергә керешге. Егеткә бу гамәл ошамады бугай, сүгенгән тавышы ишетелде.

—Бездә тәртип шулай,—диде аңа Храмм һәм «маңка малайлар»ның

икенчесен дәшеп кертте. Монысында да бернинди утлы корал да, пычак-мазар да юк иде. Өчәүләшеп өйгә керделәр. Сергей шундук кире чыгып китте.

—Әйдәгез, түргә узыгыз!—дип каршы алды аларны Илюхин һәм, кул биреп күрешеп, танышып чыкты.—Чишенегез! Без кунакларга һәрвакыт шат.

Егетләрнең уртача буйлы, кара тутлы, яшел күзлесе «Борисково» төркеме лидерларының берсе Анатолий иде. Илюхин аны таныды: теге юлы Григорий белән сөйләшүгә килгән иде ул. Егетләрнең икенчесе, арык гәүдәле, тәбәнәгрәк буйлысы, аның иптәше, шик юк, төркем әгъзасы.

—«Кунаклар, кунаклар...»—дип үчекләгәндәй итте Анатолий.—Кем кунакларны кесә капшап каршылый?! Мыскыл итү бу!

—Гафу... Мыскыл итү түгел, саклану чарасы гына,—диде Владимир, өстәл әзерләп.—Йә, утырышыгыз!

—Утырырга дип килмәдек без.Ниләр уйладыгыз, нишләргә җыенасыз?—Моны өстеннән озын, кара пальтосын сала-сала Анатолий әйтте.—Уйланырлык вакыт үтте.

—Туктагыз әле, егетлә-ә-әр!—дип сузды Владимир, тәлинкәгә банкадан кара уылдык салып.—Кем чишенмәс борын эш турында сүз башлый инде, ә?!—Ул бөтен йөзен тутырып диярлек елмаеп куйды.—Утырышыйк, очрашу хакына берәр рюмка җибәрик. Аннары сөйләшергә дә булыр. Кая ашыгырга? Көн безнеке бит...

Кунаклар да капылт кына сүз башлауның урынсыз икәнен аңладылар булса кирәк, утырыштылар. Өстәлгә эчемлекләрдән әрмән коньягы белән өч төрле аракы куелды. Кайсын телисез, шунысын эчегез, янәсе.

Төрле юк-барны сөйләшә-сөйләшә берәрне йотып куйдылар. Аннары тагын берне, тагын, тагын... Инде бераздан кунакларның башына да йөгерде, Владимирның да миенә үрмәләде. Дөрес, аны исертер өчен үзенә бер литр аракы кирәк! Ул тиз исерми, чөнки эчкәндә ашарга ярата.

Ишегалдында сакта торган Сергей әледән-әле өй тәрәзәләренә карап алгалый. Аннан торган саен тавышлар көчлерәк ишетелә, вакыты-вакыты белән алар кычкырышуга да охшаган, бәхәсләшәләр бугай.

Сәгатьтән артык утыра торгач, өчесе дә ишегалдына тартырга, саф һава суларга чыктылар. Алар, өйдәге бәхәсләрен дәвам иткәндәй, сүгенү катыш сөйләнә-сөйләнә чыктылар.

—Ни генә әйтсәгез дә, маркеттан китәргә тиеш сез! Немедленно!—диде Анатолий баскычтан төшешли.—Ниткән эш ул башкалар өлешенә кул сузу?! Нәрсә, сезгә дөнья тармы әллә?

—Ташлале, Толя, һаман бер балык башын чәйнисең! Җитте! Бу турыда сүз дә булырга мөмкин түгел!

—Алланың кашка тәкәсе булып кыланма! Синең кикригеңне шиңдерер көч тә табылыр,—дип кинәт көтмәгәндә генә үзара көрәшә башладылар, икесе дә, аяклары таеп, берничә мәртәбә егылып та алдылар. Ул Владимирга сагыз кебек ябышкан, һич тә кулын ычкындырырга теләми.—Таза дигәч тә...

Күренеп тора, Илюхин аның белән дустанә шаярып кына көрәшә, әгәр теләсә, инде ул аны күптән болгап аткан булыр иде.

Шулвакыт Сергей, капканы ачып, ишегалдына Владимирның дусты Петр Сасулин дигән егетне кертте. Илюхиннан машинасына тәгәрмәч сорарга килгән. Аның артыннан ук диярлек Коробок кушаматы йөрткән кооператив шоферы Юрий Коробов килеп керде.

Анатолий Афанасьевның Сасулинны күрүе булды, Илюхиннан кулларын алды да, мыскыллы елмаеп, аңа табан килә башлады.

—Сәлам, дөньяның бөек әләкчесе!—диде ул аңа, уң кулын күтәреп.—Әйт әле, әләкләрең өчен милиция күпме түли сиңа? Ә? Безне юкка чыгарасың киләме? Юк, брат, юкка тырышасың, синең кулыңнан килә торган эш түгел ул!—Былтыр ниндидер эш буенча кулга алынгач, Сасулин анда «Борисково» төркеменә кагылышлы мәгълүматлар биргән, дигән сүз йөргән иде. Чын булгандырмы ул, юктырмы, тик шунысы хак: Сасулин судан

коры чыккан иде. Анатолийның шул турыда хәтерләтүе. Ул, якын ук килеп, аның киеменнән эләктерергә маташты.—Сатлык җан исән, хәшәрәт!

Петр аны сүзсез генә этеп җибәрде, Анатолий аягы таеп егылды. Шунда, йодрыкларын йомып, әле моңарчы берсүзсез тәмәке тартып торган Илгиз Хәйбуллин иптәшен якларга ташланды. Ул берничә мәртәбә Петрга сукмакчы булды, ләкин Сасулин аны да этеп җибәрде, тегесе исә берничә мәртәбә артына барып утырды.

—Сез оятсыз булып чыктыгыз әле егетләр!—диде ачуыннан күзләрен кан баскан Владимир.—Өемә килеп, минә, дусларыма кул күтәрәсезме? Кунакчыллыгыма рәхмәтегез шушымы, анагызны салып селкисе адәм калдыклары?—Ул кызганнан-кыза барды, шулай сөйләнә-сөйләнә яшен тизлеге белән борылды да Анатолийга сукты. Тукмактай йодрык төшүдән егет чайкалып китте һәм җиргә егылды.

—Нигә терәлеп каттың? Из шуны, Коробок!—диде Илюхин ачу белән янында басып торган Коробовка. Аның башында: «Боларны моннан исән чыгарырга ярамый!»—дигән куркыныч уй туып өлгергән иде.

Юрий ике-өч мәртәбә Афанасьевка тибеп алды.

—Саллы гына бер арматура кисәге табып кил! Ә син, Серый, машиналарын ишегалдына керт!

Юрий гараж яныннан озын гына юан арматура алып килде. Сергей, машиналарын ишегалдына кертеп, капканы яңадан бикләп куйды.

—Лом тап!—дип боерды аңа Владимир.

Бу йортның һәр почмагын белгән Храмм, сарайдан лом алып чыгып, җиргә кадап куйды. Әле беркем дә Шефның нишләргә җыенуын белми иде.

—Серый?! Ал ломыңны, тукма, әйдә!

—Булмый миннән, Шеф... булдыра алмыйм... Минем көч белән...—дип мыгырданды Храмм, арткарак чигенеп.

—Белоручки, мать вашу...—дип сүгенеп алды Илюхин, һәм Анатолийның башына сукмакчы булып, арматурасы белән кизәнде. Ләкин кулын Сасулин тотып калды.

—Җитәр, Володя, тынычлан!—диде ул сабыр гына һәм колагына:—Эшне зурга җибәрсәң түгелме? Ахырын уйла!—дип пышылдады.—Кара аны, моның өчен «Борисково»ныкылар рәхмәт әйтмәс...

Тик Владимир тәмам шашынган иде инде.

—Гаражга алып керегез!—дип боерды ул, «әсир»ләргә күрсәтеп.

Аяклары сынган Анатолий белән Илгизне өчәүләп гаражга алып керделәр. Монда берниндди тавыш да ишетелерлек түгел, тыныч иде. Шунда Владимир, Анатолийга күрсәтеп, Храммга:

—Тиш шуны лом белән!—дип боерды.

—Булмый миннән, Шеф,—диде аңа Сергей, еларга җитешкән баладай.—Булдыра алмыйм...

Ярсыган Илюхин кан баскан күзләре белән як-ягына каранды да, тәгәрмәч дискасын күреп, аны кулына алды һәм шуның белән Хәйбуллинның башына сукты. Тегесе утырган җиреннән бетон идәнгә сыгылып төште. Аннары, шул дисканы ашыга-ашыга идәндә яткан Афанасьевның баш астына куеп, кулына балта алды. Муенын чабарга ниятләве иде бугай. Тик эшнең бөтенләй куркыныч төсмер алуын чамалаган Сасулин аның кулындагы балтасына килеп ябышты.

—Нишләвең, Володя?! Шашындыңмы әллә? Акылыңа кил!—диде ул.—Әйт, егетләрне минем машинага чыгарып салсыннар, Борисковога үзем илтеп кайтам. Шашындың бугай син...

—Бетте, Петро, бетте,—дип тынычландырырга тырышты аны Илюхин, акылына килгәндәй.—Башка кагылмыйм! Бераз айнысыннар да, мин аларны үзем илттерәм...

—Кара аны, бармак белән дә чиертмә! Зур тавыш куптарасың...

—Әйттем бит, җибәрәм, дип. Бераз хәл алсыннар да...—диде Владимир.—Тавыш-гауга миңа да кирәк түгел...

Ләкин Илюхин бу сүзләрне аны тынычландыру өчен генә әйтте,

куркыныч уеннан баш тартуы түгел иде. Берничә минуттан Сасулин кирәкле тәгәрмәчен машинасына чыгарып салды да Казанга, Горки бистәсенә, кайтып китте.

Ул кузгалып китүгә диярлек «Таулар» төркеме әгъзалары Станислав Льков белән Иван Старостин килеп керделәр. Илюхин шундук аларны тагын берничә кеше артыннан җибәрде. Төркемдә тәртип каты куелган иде. Тиздән тагын җиде «сугышчы» килеп җитте. Илюхин аларга «Борисково» төркеменнән булган шушы ике «хәшәрәт»нең үз өендә аны үтерергә маташулары, Сасулинны мыскыл итүләре, зур тавыш-гауга күтәрүләре, бу төркемнең үзләрен күрә алмаулары турында ышандырырлык итеп сөйләп бирде.

—Төнгегә машина кирәк! Чит машина...—диде Илюхин аннары.

Төркем әгъзаларына машинаны кулга төшергәч кая барырга, нишләргә кирәклеге хакында әйтелде һәм коралланган биш «сугышчы» «машина операциясе»нә кереште. Талмычыга кайтышлый Бертуган Касыймовлар урамындагы АЗС янына җитәрәк Скорбицын белән Мичугов утырган ВАЗ-2109 машинасын туктаттылар һәм күз ачып йомганчы руль артындагы Семенны үз машиналарына күчерделәр, аның урынына үз кешеләре утырды. Шундук «әсирләр»нең күзләрен бәйләп кузгалып та киттеләр. Куркыту өчен юлда берсе ике мәртәбә пистолеттан атты. Аларны «Казанский» совхозының гаражы янындагы бушлыкка алып килеп, төрле сораулар белән тинтерәтә, кыйный башладылар. Бер сәгать чамасы азаплагач, аларны РКБ янына алып чыгып, шунда ташлап калдырдылар...

Алар кичке сәгать алтылар тирәсендә Илюхин өенә кайтып керделәр. Алар артыннан ук диярлек үз араларында Доктор кушаматы белән йөртелгән Фомин да килеп керде. «Машина операциясе»нең уңышлы тәмамлануына бер сөенгән булса, аны күргән Илюхинның авызы тагын колагына җитте: нәкъ вакытында, янәсе. Ул хастаханәдә медбрат булып эшләгән Фоминның үзе белән үтергеч көчкә ия препарат йөртүен яхшы белә. Афанасьевка үтергеч доза бирергә! Чыннан да, Доктор «даруын» ирексезләп Анатолийга эчертте. Озакламый Афанасьев мәңгелек йокыга талды...

Монысы белән эшне бетергәч, котельнаяга керделәр.

—Сөлге белән буып үтер шуны!—дип боерды Илюхин Храммга.—Ышанмыйм мин аңа: моннан чыгуга йә төркеменә, йә милициягә чабачак...

Храмм үзалдына нидер мыгырданып, почмактагы кульюгыч янында эленеп торган сөлгене барып алды да, идәндә яткан Илгизнең муенына ташлады. Хәлнең уен түгеллегенә тәмам ышанган егет җан ачысы белән:

—Нишләвегез, братва?! Зинһар, җибәрә күрегез!—дип ялварды.—Балам хакына сорыйм... Гомеремдә дә сүз чыгарасым юк!—Аның күзләреннән яшь бөртекләре тәгәрәде.—Теләсә нинди йомышыгызны үтим...

—Тизрәк маташ!—диде Илюхин Сергейга ачу белән. Аннары Коробовка дәште:—Булыш әле, Коробок, бу җебегәнгә!

Тегеләр, сөлгене «әсир»нең муенына чолгап, икесе ике башыннан тартты. Фомин исә чәбәләнгән Хәйбуллинның кулларыннан тотып торды. Гырылдау тавышы ишетелде һәм бераздан ул да тынды.

Ике мәетне машинаның арткы утыргычына урнаштырдылар.

Күп тә үтмәде, бу ике машина, фараларын яндырып, берсе артыннан берсе Казан—Чаллы юлы буйлап бара иде...

* * *

Казан—Чаллы трассасының егерме икенче чакрымындагы җинаять эшенең авырлыгын, вәхшилеген истә тотып, аны ачу эшенә Эчке эшләр министрлыгы үзе алынды. Шул ук көнне җинаять эше кузгатылып, подполковник Равил Фәйзрахман улы Алтынбаев җитәкчелегендә махсус оператив төркем төзелде, ул исә үз чиратында Питрәч һәм Казан шәһәре милиция бүлекләренә аерым йомышлар җиткерде: алар хәтта вак-төяк дип саналган очраклар турында да хәбәр итеп торырга, уяулыкны

арттырырга тиешләр иде. Кем белә, бәлки, җинаятьчеләр ни белән булса да үзләрен күрсәтеп алырлар, бәлки, кемдер бу турыда сүз чыгарып куяр?.. Шуңа күрә ресторан, сыраханәләр күз уңына алынды... Кыскасы, барысына да эш җитәрлек иде.

Җинаять урынында җыелган мәгълүматлар, Алтынбаевта тупланды.

«Хәзер иң мөһиме—янган машинаның кемнеке икәнен ачыклау»,—дип фикер йөртте подполковник.

Телефон чылтырады.

—Тыңлыйм, тыңлыйм. Әйе, мин,—дип җанланып китте ул.—Энәдә утыргандай, сезнең хәбәрне көтәм. Шулаймы? Язам: Дягилев Иван Михайлович... Аңлашылды. Адресы? Яздым... Рәхмәт сезгә! Тик аннары мина рәсми документ бирерсез.

Ул, урыныннан торып, канәгатьләнүдән кулларын угалап, бүлмәсе буенча йөренергә тотынды. Кем икән соң бу Дягилов дигәннәре? Нишләп аның машинасы моннан егерме ике чакрым җиргә барып эләккән? Әллә мәетләрнең берсе шул машина хуҗасымы? Алай булуы да бик мөмкин бит. Тизрәк ачыкларга кирәк, әгәр дә ул исән икән, аны тизрәк күрергә, күрергә... Этәргеч нокта менә шушы...

Алтынбаев үзенең дүрт бармаклы уң кулы белән (бармагын ике ел элек бер җинаятьчене кулга алганда пуля өзгән иде) кайчандыр кара булып хәзер көмеш йөгергән кабарынкы чәчен сыпыргалап алды һәм өстәлендәге селектор төймәсенә басты.

—Керегез әле, капитан!—диде ул.

Шул ук секундта диярлек, әйтерсең ишек төбендә генә көтеп торган, бүлмәсенә яшь кенә капитан килеп керде.

—Безнең «эш»тә беренче, ләкин бик тә кирәкле ГАИ мәгълүматы алынды: мотор һәм шасси номерлары буенча картотекаларыннан янган машинаның кемнеке икәнен ачыклаганнар,—дип тезеп китте ул, аңа урын да тәкъдим итмичә.—Менә фамилиясе, менә адресы. Хәзер үк белергә кирәк: нинди кеше? исәнме ул? Исән булса, машинасы нинди юл белән—әйтик, урлаганнармы анда, әллә башкамы—җинаять урынына килеп чыккан? Бу кеше яшәгән район милициясе, кирәк икән, участок милиционеры белән дә бәйләнешкә керегез.

—Аңладым, иптәш подполковник. Китәргә рөхсәт итегез!

—Барыгыз, бар, капитан!

Дягилев Иван Михайлович дигәннәре исән-сау булып чыкты. Кырык биш яшьлек бу ир заводта инженер булып эшли, үрнәк гаилә башлыгы, намуслы кеше. Утырмаган, тартылмаган. Машинасын, үзе әйтмешли, «гомер буе акча җыеп» моннан җиде ай элек кенә алган булган. Ләкин дүрт ай да йөрмәгән, авариягә эләккән. Дөресрәге, аның машинасын арттан килеп иске генә «Жигули» бәрдергән. Аннан чыккан әзмәвердәй дүрт егет авариядә аны гаепләгәннәр.

—Ә нишләп ГАИ чакыртмадыгыз?—дип сорады аннан капитан.—Кем гаепле икәнен алар, шәт, дөрес ачыклаган булыр иде...

—Алар миңа сүз әйтергә дә ирек бирмәделәр,—диде Дягилев.—Кем гаепле икәне көн кебек ачык: мин туктап тора идем, миңа килеп тә бәрелделәр. Юри бәрдергән шикелле булды ул. Аннары пистолет белән янап, ремонт хакы дигән булып дүрт ай машинамда йөреп торырга ышаныч кәгазе яздырдылар... Үләсе килми, язып бирергә туры килде...

Ышаныч кәгазен Илгиз Хәйбуллин исеменә язган икән. Димәк, машинасы өч ай чамасы бандит кулында булган. Адресын хәтерләми (әллә куркып әйтми!), аны бүтән очратмаган. Килешкән вакыттан соң машинаны аның капка төбенә китереп куярга вәгъдә иткәннәр, янәсе...

Кат-кат тикшерә торгач—күрше-күлән, завод җитәкчеләре, участок милиционеры да калмады—Дягилевның, чыннан да, үз көче белән яшәүче намуслы кеше икәнлеге ачыкланды. Ул теге чакта үзе белән «көрешкән» егетләр турында белгәннәренең бөтенесен дә сөйләп бирде. Бигрәк тә исендә калганы шул: берсенең астагы ике алгы теше алтыннан...

Илгиз Хәйбуллин дигән кешене эзләү башланды. Казан районнарында

яшәүче меннәрчә кешеләр исемлеге энә күзеннән үтте. Һәм менә, ниһаять, эзләгән фамилия, эзләгән исем! Борисково бистәсендә яши икән, адресы күрсәтелгән. Монысы инде Дягилевка рәхмәт, беренче булып бу фамилияне ул атады!

Подполковник бу эш белән шөгыльләнүче коллегаларын ашыгыч кинәшмәгә җыйды. Соңгы көннәрдә алынган мәгълүматларны анализларга, шулардан чыгып аларның һәрберсе алдына яна бурыч, яңа сораулар куярга кирәк иде. Башта ул шәһәрдәге бүгенге хәл белән таныштырып чыкты. Игътибарны җәлеп итәрлек, бу эш белән бәйле күренгән нәрсә юк иде шикелле. Алай да шулар арасыннан берсе үзенә игътибарны юнәлтергә, ниндидер бер эчке сиземләү, интуиция белән сагаерга мәҗбүр итте. Борисково бистәсенең бер тыкрыгында ташлап калдырган ВАЗ-2109 машинасы табылган. Әлегә кемнеке икәнлеге ачыкланмаган, хәзер ГАИ сотрудникы шуның белән шөгыльләнә икән. «Безнең эшкә катнашы булуы ихтимал. Моны бик җентекләп тикшерергә кирәк. Хуҗасы кем? Ничек анда килеп чыккан?»

Җинаятьне ачу эше көне-төне барды. Нәтиҗәләр, мәгълүматлар подполковник бүлмәсенә агылды. Ул аларны бер-берсе белән чагыштырып карады, төрле фаразлар төзеде, кайберләре расланмыйча төшеп кала бирде, кайберләре өмет уятты. Яналары туа торды. Аны бигрәк тә Илгиз Хәйбуллин һәм аның даирәсе, дуслары кызыксындырды. Ләкин әле боларны ачыкларга кирәк иде. Шуна күрә түземсезлек белән яна хәбәрләр көтте.

Башта өстәленә Борисково бистәсендә табылган машинаның инде ачыкланган хуҗасыннан һәм аның белән бергә булган дустыннан сорау алу беркетмәләре ятты. Нәкъ шушы машинаның җинаять эшенә катнашы булуы бик мөмкин! Беренчедән, ул хуҗасыннан егерменче декабрьдә, җинаять эшләнгән көндә талап алынган. Ләкин ана бер нәрсә аңлашылмады: кайдадыр Горки бистәсендәге Бертуган Касыймовлар урамындагы АЗС янында кулга төшерелгән машинаны ни өчен әле Борисково бистәсендә ташлап калдырганнар? Хәйбуллин да шунда яши. Бу җинаять «Борисково» төркеменең эше түгелме? Подполковник Алтынбаев торган саен шушы фараз ягына авыша бара иде. Анда табылган машина Семен Скорбицынныкы. Төнлә милициягә алып килеп сорау ала башлагач, башта ул «машинаны егерменче декабрьгә каршы төндә гараждан урладылар», дип барды.

—Нишләп бу турыда милициягә хәбәр итмәдегез? Ник бу вакыйганы йолып калмакчы булдыгыз?—дигән сораулар бирелде ана.

—Әйтеп ни файда? Барыбер тапмыйлар...—дип җавап бирде Семен.

Иртәгесен ул яшәгән Северный бистәсендәге күршеләреннән сораштырдылар, ләкин алар мондый хәбәрне ишетмәгәннәр дә икән. Гараж йозагы ватылып машинасы урланса, бу турыда алар сәгате белән белерләр, ишетерләр иде. Ишетмәгәннәр... Алай гына да түгел, бер күршесе егерменче декабрь көнне инде төштән соң ана Соцгородка тикле утырып баруын әйтте.

—Янына килеп йөри торган дусты Олег белән иде алар,—диде ул.

Бу каршылык шик уятты. Скорбицынга берсеннән-берсе күнелсезрәк сораулар тагын-тагын бирелде. Ахырда ул машинасын кайчан, ничек алулары, кыйнаулары, куркытулары турында дөресен сөйләп бирергә мәҗбүр булды. Олегның фамилиясен дә атады. Бүлеккә китерелгән дусты Олег Мичугов та аның сүзләрен җөпләде. Тик алар үзләренә һөҗүм итүчеләрнең берсен дә сурәтли алмадылар.

—Бу шундый тиз, күз ачып-йомганчы килеп чыкты,—диде алар, үзара сүз беркеткәндәй.—Йөз-битләрен күрми дә калдык. Аннары күзне бәйләп куйдылар. Берни күрә алмадык...

Ул арада Илгиз Хәйбуллинга кагылышлы мәгълүматлар да алынды. Ләкин алар әллә ни сөенерлек түгел иде. Инженер Дягилев әйткән егет, чынлыкта ике бала атасы, егерме дүрт яшьлек ир, менә инде берничә көн өендә күренмәгән.

—Өйгә кайтмый калганы юк иде. Егерменче декабрь көнне бер иптәше белән чыгып киткән иде, шуннан күренгәне булмады,—диде хатыны Галия.—Белмим, нәрсә булгандыр...

—Ирегез кем булып, кайда эшли иде?

—Бер заводта тәэминат бүлеге агенты булып, дия ие мина...—диде Галия жавабында.

Ләкин белешә-ачыклый торгач, Илгизнең инде ике ел бернинди заводта да, гомумән, беркайда да эшләмәве беленде. Әле РТИ заводында эшләп йөргән вакытында ук «Борисково» төркеменең актив әгъзасы булып алган. Бу исә әлеге төркемнең җинаятькә катнашы барлыгына тагын бер дәлил сыман кабул ителде. Шуңа күрә ул көнне аның белән бергә чыгып киткән иптәшен эзләп табу, белү бик мөһим иде. Хәйбуллинның хатыны тасвирлавы буенча аның фотороботын ясадылар. Кат-кат аңа күрсәтә-күрсәтә, менә хәзер нәкъ үзе, диярлек хәлгә китерделәр. Дөрес, башта бәлки кемнеңдер юкка чыгуы хакында милициягә туганнары хәбәр итәрләр дип уйлаганнар иде дә, юк, андый хәбәр кермәгән. Бер яктан, бу аңлашыла да: әле фаҗигагә берничә генә көн үтте бит. Гадәттә милициягә юкка чыккан кешене эзләүләрен сорап айлар үткәч кенә мөрәҗәгать итәләр, чөнки туган-тумачалары һаман: «Менә кайтыр, менә кайтыр», дигән өмет белән яши бирә.

Тулы бер көн Илгиз Хәйбуллинның теге дустын ачыклауга китте. «Борисково» төркеме лидерларының берсе—Афанасьев Анатолий булып чыкты ул. Аның да нәкъ Илгиз белән чыгып киткәннән бирле күренгәне юк икән...

Суд-медицина экспертизасы материалларын Илгиз Хәйбуллин белән Анатолий Афанасьевлар беркетелгән, авырган чакларында мөрәҗәгать иткән үз поликлиникаларындагы медицина карточкаларындагы анализ нәтиҗәләре белән чагыштырып-тикшереп карагач, әлегә шартлы рәвештә «№1»,«№2» дип йөртелгән мәетләрнең алар икәнлеге һичнинди шик калдыргысыз итеп расланды. Шулай итеп, җинаять чылбырының тагын бер буыны сүтелде. Ләкин бу да ачыклык кертәсе урынга, күп санлы сораулар гына тудырды...

«Ярар, җинаятьне «Борисково» төркеме эшләгән дип фараз кылыйк...— Подполковник Алтынбаев башын ике кулы белән кысып уйга калды.— Ләкин алар менә шулай үз әгъзаларын—җитмәсә, берсе төркем лидеры бит әле!—Тик торганда гына юк итәрләр идеме?! Юк, бу нәрсә логикага туры килми. Алар мондый җәзага үзләрен органнарга саткан кешеләргә карата гына кулланалар. Ә соңгы вакытларда андый очрак булмады...»

«Борисково» төркеме әгъзаларын, аларга якын дип саналган яшь-җилкенчәкне энә күзеннән үткәрү башланды. Ләкин дистәләгән кешеләрнең бик күп вакытын алган бу эш җинаятьне ачуга берни дә өсти алмады. Ә бит, чыннан да, нинди четерекле эш башкарылды! Кемнең нинди сигарет, папирос тартуына хәтле кызыксындылар. Бигрәк тә «Мальборо» сигаретын тартучылар аерым игътибар үзәгендә булды. Күпме «Мальборо» төпчеге генә җыйналып, җинаять урынында табылганы белән—ә ул төпчек цитологик экспертизага тартылган иде—чагыштырылды. Ул төпчекләрнең яшерен генә җыйналып—юнәлтелүен искә алсак, моның нинди четрекле эш икәнен күз алдына китерүе кыен түгел. Чөнки шундый сигарет тартып торган һәр кеше янына килеп: «Тартып бетергәч төпчегенне миңа бирерсең, без аңа цитологик экспертиза үткәрәчәкбез», димәссең ич! Ә кешеләрнең намуслымы, әллә шиклеме икәнен ачыклау гына да нинди көч, күпме вакыт сорый торган нәрсә! Ярый ла ул дистәләгән кешегә генә кагылса?! Ә монда берничә йөз ир-атны энә күзеннән үткәрергә кирәк иде... Ачыклау вакытында тагын бер нәрсәгә игътибар бирелде. Машинасы тартып алынган Скорбицын белән Мичугов үзләрен «әсир» иткән егетләрнең берсе, салкын тигән шикелле, карлыккан тавыш белән сөйләшә, дигәннәр иде. Тикшерү вакытында андый ир-атның булу-булмавы да искә алынды. Ләкин андый кеше очрамады...

Аның каруы Скорбицын машинасының «һәр квадрат сантиметрын» тикшерә торгач, аннан бер пуля табылды! Ул, арткы утыргычның арка терәгечен тишеп чыгып, кузов калаенда тоткарланып калган иде. Аның нинди тип коралдан атылуын ачыклау өчен экспертизага бирделәр. Икенче көнне үк пуляның «Вальтер» пистолетыннан атылуы турында рәсми документ Алтынбаев өстәленә ятты.

«Жинаять эшлә дә, эз калмасын, имеш! Ничек кенә сак кыланырга тырышмасыннар, эз барыбер кала ул!—дип уйлап алды подполковник, нигәдер сөенгәндәй, нииндидер күнел күтәренкелеге белән. Әйтерсен, хәзер алдында ятучы шушы пуля—бу жинаятьне ачу юлындагы соңгы буын!—Тик эзләрнең кайсы өстә, күз алдында ук ята, кайберләре эчкә яшеренгән була... Туктале тукта, моның Гвардейская урамындагы вакыйгага катнашы юкмы?»—Ул ашыгып селектор төймәсенә басты.

* * *

Егерменче декабрьдән соң Илюхин инде айнып, үзләренең нинди авыр жинаять эшләүләрен төшенүдән куркып йөрсә дә, берничә көннән тынычланып калгандай булды. Эшендә ул нәкъ элеккеге Владимир Михайлович, «Шеф», гаиләсендә хатынын яратучы, ике баласын сөюче әти булып калырга, шулай булып күренергә тырышты.

«Ярый әле теге машинаны Борисково бистәсенә илтеп калдырырга баш житте!—дип ирен кырые белән елмаеп алды ул өенә төшке ашка кайтышлый.—Менә хәзер милиция баш ватсын инде! Шик шундук «Борисково» төркеменә төшәчәк. Талкысыннар әле үзләрен! Бераз кикрикләре шинәр... Ә аннары, тырышып та эшләре пешмәсә, «Эш»не ябарга мәжбүр булырлар...»

* * *

Милиция бүлегендә утыз яшьлек егеттән сорау алу башланды. Подполковник Алтынбаев группасы бу кешенең карлыккан тавышына игътибар итте.

—Сезгә салкын тидеме әллә?—дип сорады капитан.

—Юк, минем тавыш гел шулай,—дип жавап бирде аңа егет.

Шунда капитанның башыннан: «Скорбицын машинасын тартып алучыларның берсе карлыккан тавыш белән сөйләшкән бит!—дигән уй йөгереп узды.—Бәлки, аны егетләргә күрсәтеп, тыңлатып карарга̃дыр? Кем белә... Кайчак ничәмә-ничә айлар берсеннән-берсе катлаулы, чиләнгән нәрсәләрне ачыклауга китә, ә баксаң, эзләгән жавабың, мәсьәләнең чишелеше өстә генә, хәтта бөтенләй көтмәгән, игътибар да итмәгән жирдә генә ята...»

Икенче көнне егет милициягә тагын китерелде һәм шунда Семен Скорбицын белән Олег Мичугов та чакырылды. Алар шикленең тавышына игътибар итәргә тиешләр иде. Үзләренә һөжүм иткән, машиналарын тартып алганнарның берсе шушы түгелме? Ләкин алар төгәл генә жавап бирә алмады. Бер караганда, тавышы да, йөзе дә таныш кебек, икенче яктан, берничә секунд эчендә генә күреп калган кеше турында ничек кырт кистереп: «Нәкъ үзе!» дип әйтмәк кирәк?! Әгәр ул бөтенләй гаепсез кеше булып чыкса?!

Ничек кенә булмасын, бу кеше хәзергә шикләләр исемлегендә кала бирде, күз уңына алынды...

Вакыт уза торды. Яңа ел да житте. Подполковниктан да, район милициясеннән дә жинаятьне тизрәк ачу чараларын күрүне, эшләрне тизләтүне көннән-көн катгыйрак таләп итә башладылар. Таләп итү—бер нәрсә, ә жинаятьне ачу—икенче нәрсә, әлбәттә. Болай да көне-төне эшлиләр бит инде югыйсә... Шуна күрә тикшерүчеләрнең кәефләре күтәренке дип әйтеп булмый иде. Тырышалар-тырышалар, ә эшләренең төп, начальство таләп иткән нәтижәсе күренми. Гәрчә инде шактый нәрсә ачыкланса да, жинаятьчеләрнең кемлеге әлегә билгесез, алар һаман иректә кала бирә. Кыскасы, эшне тәмамлар өчен чылбырда нииндидер буыннар житешеп бетми...

Равил Алтынбаев шулай төшенке күнел белән уйланып утырганда, аның алдына жинаятьләр турындагы көнлек мәгълүматларны—кайда нинди хәлләр булуы турындагы хәбәрләр жыйналмасын китереп салдылар. Ул аңа

әллә ни игътибар итмичә генә күз йөртеп алды. Кызыксындырырлык берни дә юк шикелле... Кемнедер талаганнар, кемнендер фатирын басканнар, Фучик урамындагы 83 нче йорт янында бер этне атып үтергәннәр... Туктале, бу эт атып үтерелгән бит! Димәк, кемдер корал кулланган! Бәлки, аның «безнең» эшкә катнашы бардыр?..»

Ул тиз генә район милиция бүлегенә шылтыратып, эт мәсьәләсе белән тулырак таныштыруларын сорады...

... Егерме алтынчы гыйнварда Эмма Ледовских атлы хатын иртәнге җиделәр тирәсендә фатирыннан ике этен алып чыккан. Аларны йортыннан ерак түгел бер мәйданда йөрткәндә ике ир очраган. Ни турындадыр сөйләшә-сөйләшә баралар икән, шунда этләрнең берсе, өреп, аларга таба чапкан.

—Ал этенне, тешли бит!—дип кычкырган берсе хатынга.

—Курыкмагыз, ул борынчаклы,—дигән Эмма ханым һәм этен үзенә чакыра башлаган.

Эт шуннан соң ир-атлардан сигез-ун метрда туктап калган. Тегеләрнең берсе пальто эченнән ике көпшәле обрез чыгарган да ике мәртәбә эткә аткан, яралаган.

—Их, Олег, Олег, махмырдан кулың калтырый, ахры, синең!—дигән шунда икенчесе.—Менә кара, ничек атарга кирәк!—Ул ашыкмыйча гына куен кесәсеннән пистолет чыгарган да эткә атып җибәргән. Эт шундук тынган...

—Ул пуляны җир астыннан булса да таба күрегез!—дип боерды подполковник бу хәлне сөйләп биргән милиция бүлеге хезмәткәренә.—Бу бик мөһим! Бу шул кадәр мөһим! Ә теге хатын аларның йөз-кыяфәтләрен сурәтләп бирә алдымы соң?

—Бик төгәл сурәтләде! Хәтере искиткеч икән! Хәзер аларны ачыклау өстендә эшлибез, иптәш подполковник.

Икенче көнне, ягъни егерме җиденче гыйнварда, кичке сигезләр тирәсендә шул ук микрорайондагы Р. Зорге һәм Ю. Фучик урамнары чатында ике ир-ат, Мөхетдинов фамилияле берәүне пистолет белән куркытып, аның «Москвич—2140» машинасын тартып алганнар.

«Тәмам йөгәнсезләнде, оятсызланды бу шакшы җаннар!—дип куйды подполковник, җинаятьләр турындагы җыйналманы караштырып.—Көн саен корал куллана башладылар. Үз башларына кылана болар... Валлаһи, юкка түгел...

«Москвич» хуҗасы да үзенә һөҗүм итүчеләрне шактый тулы, бөтен нечкәлекләре белән сурәтләп бирде. Аның тасвирламасын эте атып үтерелгән Эмма ханым сөйләгәннәр белән чагыштырып карагач, бу ике җинаятьне дә бер үк кешеләр кылган дигән нәтиҗә ясалды. Инде «Таулар» төркеме әгъзалары турында шактый бай мәгълүмат туплаган милиция бүлеге тикшерүчеләренә аларны исәпләп чыгаруы бик авыр булмады: шул ук төндә, ягъни соңгы җинаятьләренә дүрт сәгать тә үтмәде, аларның берсе—Владислав Никитин кулга алынды. Һәрвакыт үзе белән йөртә торган «Вальтер» пистолеты да кесәсендә иде. Кулга алуларына ул шул хәтле гаҗәпләнде ки, хәтта бер генә сүз дә әйтә алмады—әйтерсең, аны паралич сукты. Ул мондый хәлне күз алдына да китермәгән, күрәсең... Икенчесен, Олег Новиковны, таң алдыннан, йоклап яткан җиреннән «җылы килеш» алдылар. Тентү вакытында пальтосының эчке ягында махсус элмәкләр ярдәмендә йөртелә торган ике көпшәсе дә киселгән ау мылтыгы—обрез табылды.

Аларны эт хуҗасы белән шофер да таныды. Ул арада эткә тигән пуляның да нәкъ Никитинның «Вальтер» пистолетыннан икәнлеген раслаган экспертиза нәтиҗәсе килде. Бу дәлилләрдән беркая да китеп булмый иде. Хәер, башта икесе дә кылган җинаятьләрен үз өсләренә алмыйча, һәр нәрсәне кире кагып маташканнар иде маташуын, ләкин коры сүз белән ышанычлы дәлилләргә каршы күпме торырга була? Аннан соң барысын да үзләре үк сөйләп бирергә ашыктылар. Янәсе, дөресен сөйләгәч, суд карары йомшаграк булыр...

Тик иң кызыклысы, Казан—Чаллы юлындагы җинаятьне ачу чылбырының иң мөһим буыны алда иде әле...

Подполковник Алтынбаев этнен гомерен өзгән коралның «Вальтер» пистолеты икәнен белеп, бу турыда трассолог ясаган нәтиҗә белән танышкач, үзендә дәлил буларак саклanучы пуляны да аларга тикшерергә бирде. Аны тик бер генә сорау борчыды: эттән һәм Скорбицын машинасыннан алынган пулялар шушы «Вальтер» пистолетыннан атылмаганмы? Ул бу сорауга җавап бирерлек нәтиҗәне нииндидер бер өмет һәм эчке дулкынлану белән көтте. Әгәр Скорбицын машинасын кулга төшерүдә катнашучы табылса, Казан—Чаллы трассасының егерме икенче чакрымындагы җинаять эшен ачылды дип санарга була. Җинаять урынындагы тәгәрмәч эзе нәкъ шуныкы бит. Димәк, инде хәзер көн кебек ачык: бу машина анда булган! Мөгаен, җинаятьчеләр, эзләрен югалту, тикшерүне башка юлдан җибәрү өчен бу машинаны махсус кулга төшергәннәрдер. Алдан уйланып эшләнгән эш бу!

Ниһаять, берничә көннән соң аның өстеннән тау төшкәндәй булды: трассолог ике пуляның да нәкъ шушы «Вальтер»дан атылуын шик калдырмый торган төгәллек белән раслады. Дәлилле итеп, яңа техник җиһазлар кулланып! Бу инде алар шөгыльләнгән җинаять эше буыннарының калганнарын чишәр өчен иң әһәмиятле ачкычы. Йокысыз үткән күпме төннәрнең матур нәтиҗәсе иде.

Үзенә бу гаеп тә ташлангач, Никитин тәмам коелып төште.

Бөтен җинаять эшләре берләштерелде, шушы соңгы ачыш нәтиҗәсендә эш күптән көтелгән агым һәм зур тизлек белән бара башлады. Тикшерүчеләрнең «урак өсте» иде бу: сорау алулар, күзгә-күз очраштырулар, урыннарга чыгу...

Борисково бистәсендә табылган Скорбицын машинасының эзе «Төзүче» кооперативы прорабы, шул ук вакытта «Таулар» җинаятьчел төркеме лидерларының берсенә әйләнгән Владимир Илюхин яшәгән Талмычыга алып килде. Бер төн эчендә ул һәм шушы ук кооператив шоферы Юрий Коробов, сакчы Сергей Храмм, «Доктор» Дмитрий Фомин һәм тагын берничә кеше кулга алынды, аларда тентү үткәрелде. Коробов фатирыннан «ПМ», Илюхинныкыннан «ТТ» пистолетлары, башкаларныкыннан да төрле утлы кораллар табылды...

Баштарак үзләренә ташланган һәр гаепне кире кагып барган элеккеге дуслар тикшерү вакытында кылган җинаятьләре өчен тиешле җәзаның котылгысыз икәнен аңлап һәм монда ничек тә үз «өлешен» кечерәйтергә теләп, тырыша-тырмаша бер-берсен батыра башладылар. Һәрберсенең аз җәза аласы килә иде...

... Подполковник Алтынбаев тәрәзә янына килеп урамга карады. Анда, кышкы урамда, машиналар чабыша, тиз-тиз атлап, берәм-сәрән кешеләр үтеп китә. Юл буендагы агачлар исә шәп-шәрә булып, каралып калган. Алар шулай моңаеп, сагышланып язны көтәләр сыман. Менә шунда инде—язга чыккач—алар яшеллеккә күмелер, кешеләр күзен иркәләр, аларда саф, изге, жылы хисләр уятыр...

Ул яңадан өстәле янына килеп утырды һәм алдындагы кәгазьләр өстенә иелде. Аны инде хәзер бүтән төрле четерекле эшләр көтә иде...



## Абдулхак Игебаев

### ВАКЫТ ТУЛПАРЫН ИЯРЛӘП...

### Нәрсә соң ул гомер?

Нәрсә соң ул гомер? Агымсудай,
Сиздермичә аккан еллармы?
Әллә, шул елларның төсе булып,
Җанга уелып калган моңнармы?

Нәрсә соң ул гомер? Хыял җитмәс
Серле офыкларда җилүме?
Әллә инде фани дөньяларда
Үз-үзеңне онытып сөюме?

Нәрсә соң ул гомер? Ак өметме,
Балкуыны изге теләкнең?
Әллә көне-төне, илкәем, дип,
Дөп-дөп тибешеме йөрәкнең?

Нәрсә соң ул гомер? Кичерүме
Җан рәхәтен, күңел ярасын?..
Әллә күкри-күкри үтүме ул
Яшәү белән үлем арасын?!

### Пәйгамбәре кайда дөньяның?

Тәкъдир каләмнәре сызган эзләр
Маңгайларга ята сырланып,
Әле зиһенебез томалана,
Әле чишеп булмас җепләр белән
Күңелебез бетә чорналып.

---

Абдулхак ИГЕБАЕВ *(1930) — танылган башкорт шагыйре; башкорт, татар, рус телләрендә дөнья күргән күпсанлы китаплар һәм популяр җырлар авторы. Башкортстанның Салават Юлаев исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.*

Нинди хурлык, һәр тарафта бурлык,
Хәвеф изә халкым вөҗданын,
Заман залимнәре котырганда,
Илне иман белән тотып торган
Пәйгамбәре кайда дөньяның?!

## Батырларның батыры

*Патриот шагыйрь Муса Җәлилгә*

Башкаена кайгы төшкән адәм
Бөгелә, диләр, нечкә тал төсле,
Ләкин, шагыйрь, кайгы кичерсәң дә,
Арысландай булдың син көчле!

Якты көн күрсәтми, әсир итеп,
Рисвай кылганда да дошманың,
Тез чүкмәдең аңа, бөгелмәдең,
Тазартмадың дошман олтанын.

Урал кыясыдай горур булдың,
Чыдамлыкта—каты корычтай,
Ә шигырең палач йөрәгенә
Кадалды нәкъ үткер кылычтай!

Батырларның батыры син, Җәлил,
Исемеңне данлый Туган ил!

## Аксакал сөйли

Йоклап яткан еланның
Койрык очына басма,
Кара елан шикелле
Хәтәр агуын чәчкән
Дошманыңа сер ачма!

Барлык иблис, шайтаннан
Бәндә шайтаны яман,
Ә син шайтанга түгел,
Һәрчак терәк булырлык
Тугры дусларга таян!

Мәгәр дан таҗы киеп,
Утырсаң да син түрдә,
Изгеләрдән-изге йорт—
Ата йорты икәнен
Оныта күрмә бер дә!

## Белгертмимен

Шыгыр-шыгыр килеп, тавыш биреп,
Табаннарга сарыла салкын кар,
Язлар килгәч, карлар эреп агар,
Ләкин һичкайчан да эремәс шул
Күкрәк төпкелемдә яткан зар.
Аһ-зарларым язмышыма сеңде,
Уелып-уелып керде бәгырьгә,
Беркемгә дә белгертмимен аны,
Вакыт җиткәч, бөтен кайгыларым
Үзем белән китәр кабергә!

## Сабый күңелкәе кителсә...

Сабый күңелкәе кителсә,
Көнгә баккан чәчкә боегыр,
Ярын көтеп гашыйк тилмерсә,
Аккош каурыйлары коелыр.

Авыр сүз ишетсә тол хатын,
Башын ияр каен уфылдап.
Үксез ятим үксеп еласа,
Янартаулар куяр сулкылдап.

Чәчән бинахакка интексә,
Сайрар кошлар зарга сабышыр.
Буйдак уфтанганда, моңсу ай
Болытларга кереп адашыр.

Яшь киленнең җаны ачынса,
Өянкеләр елар бөгелеп,
Солдат ыңгырашканда, чал бөркет
Дертләп китәр хәвеф сизенеп.

Ана бәгырькәе әрнесә,
Давылланып дәрья чайкалыр.
Рәнҗетелсә ата йөрәге,
Урал ташларыннан кан тамар.

Кыз керфеге яшькә чыланса,
Зәңгәр болан үксер тынлыкта.
Яугир йөрәген учлап егылса,
Капыл йолдыз сүнәр офыкта!

## Яшьлек илендә калам

Вакыт толпарын иярләп,
Йөрәксеп-ярсып чабам,
Әмма, күңелем белән мин
Былбылларны сайраттырган,
Гомерлеккә яраттырган
Яшьлек илендә калам!

Ак бәхетләр юрый-юрый,
Җәйгорлы сукмак салам,
Әмма, күңелем белән мин
Сарыларга сабыштырган,
Язмышларны адаштырган
Яшьлек илендә калам!

Гомернең ак кышына да
Якынаеп киләм һаман,
Әмма, күңелем белән мин
Җан дусларны очраштырган,
Гашыйкларны кавыштырган
Яшьлек илендә калам!



## Нурия Измайлова

# «ОКЕАННЫҢ АРЪЯГЫНДА...»

## Ирекле Америка

*«Азат ил!*
*Азат илгә күмер кирәк,*
*Тимер кирәк, иген кирәк!*
*Азат ил!..»*

БЕЗ ШУЛАЙ дип җырлый торган идек бала чакта—мәктәптә. Ул «азатлык, бәйсезлек, ирек» дигән төшенчәләр, чәйнәлә торгач, чүбеккә әйләнеп бетеп, бер тиенсезгә калган иде. Аларның «китап сүзе» генә икәнлеген һәркем белгәнгә күрә, адәмчә сөйләшкәндә, телгә дә алып тормый идек. Шул мәктәптәге җыр-шигырьләрдә, трибуналарда яки мәзәкләрдә генә искә төшерелә торган сүзләр... Акыллы, җип-җитди кешеләрнең әңгәмәдә чып-чынлап: «Бу—ирекле ил!»—дип әйтеп куюларына һаман өйрәнеп җитә алмыйм әле мин «бу ирекле ил»дә. Кызыл сүз түгел ул биредә, пафосы-фәләне дә юк. Мәгънәсе бар—ягъни нәрсәдер аңлату, ачыклау өчен кулланыла. Чын күңелдән ышанып әйтелә ул. «Американнарның патриот икәнен синнән башка да беләбез!»—дияргә торучыларга да җавап бар: беренчедән, һич тә патриотик хисләр белдерер өчен әйтелми бу гыйбарә, икенчедән, американнарның патриотлык дәрәҗәсе башкаларныкыннан бер дә артык түгел. Бу урында тик бер генә нәрсәне искәртеп куясы килә: дөнья халкының бик күп миллионнары Америкада яшәргә атлыгып торгач, американнарга үз илләре турында «һич югы башкалардан яхшырак» дип уйларга кала. Алар бик азга да шөкер итә белә торган, һәр казаның бер файдалы ягын табарга

---

Нурия ИЗМАЙЛОВА—*шагыйрә, «Яратам» (1981), «Язылган хатлар» (2001) һ.б. китаплар авторы. Америкада яши.*

тырыша торган халык. Хуҗа Насретдин турында бер мәзәк бар бит әле: туны суга батамы, утка янамы шунда, ул: «Бердәнбер киемемнән дә мәхрүм калдым!»—дип яшь түгәсе урында: «Ярый әле, тун эчендә үзем юк чакта туры килде!»—дип шатлана. Менә американнар да шулайрак... «Әт лист» («һич югы, аз дигәндә») гыйбарәсен еш кулланалар. Бер кулын югалткан кешеләргә ике кулсызларга карап юанырга киңәш бирәләр...

Сиздегезме-юкмы, ирекле илчә фикер йөртергә өйрәнмәгәнмен әле, ирекле илдә бер үк нәрсә турында һәркем төрлечә уйларга мөмкин һәм барысы да хаклы булыр. Әле менә күптән түгел бер бәлагә тарыдым. Мәскәүгә кечкенә генә бандероль салып җибәргән идем, 75 доллар түләттеләр, шаккаттым. «Ярар, инде беренчесе-соңгысы шул булсын , башка әйбер-фәлән җибәрдем юк»,—дип, уйладым да түләдем теге акчаны. «Һич югы сабак алдым»,—дип, үземне американнарча юатып та куйдым. Бә-әй, ничәдер атна үткән иде, Мәскәүдән сеңлем шылтырата: бирмиләр, ди, бандерольне, тагын 45 доллар сорыйлар, ди. Бу юлы безнекеләр сорый икән инде. Кыр талашыр өчен генә Мәскәүгә чыгып чабып булмый Атлантик океан аша чатыр-чотыр, нишлим, киттем теге бандерольне җибәргән «Мәел бокс» дип аталган почта шикелле урынга. Миннән 75 доллар түләткән кыз анда эшләми икән хәзер, эшләсә дә, «Сорри»дан башка ни дисен ул? «Без Россия өчен җавап бирмибез»,—дип торалар эшләүче кызлар. Хуҗаларын чакырткан булдым. Шулай да шулай, имеш, менә бу адресны күрәсезме—мин сезгә түләгән акча шушы адреска илтеп тапшыру өчен иде, дим. Ә ул әйтә, шулай да шулай, без чит илгә әйбер җибәргәндә, шул илгә илтеп җиткерү өчен генә җаваплы. Ә мин әйтәм, шулай да шулай, нишләп сез аны миңа башта ук әйтмәдегез?! «Сорри, без сезнең белмәгәнегезне каян белик»,—ди хуҗа. Ачуыңнан үләрсең! Әле файдалы киңәш тә бирә: «Бәлки, сез Россия хөкүмәте вәкилләре белән бәйләнешкә керергә тиештер». Бездә булса, ичмаса рәхәтләнеп талашыр идең, болар талашып көч чыгара торган адәммени! Аңлатты, гафу үтенде, киңәш бирде—тагын ни кирәк? Бер абзый безне тыңлап торган икән. Урамда артымнан килде дә «Сорри,—ди. Син, әлбәттә хаклы,—ди.—Ләкин ул да хаклы—алар Россия законнарын белмиләр бит. Бәлки, башта син Нью-Йорктагы Россия консуллыгына шылтыратып белешергә тиеш булгансыңдыр». Күңел ярсыган чакта йомшак тавыш та ярдәмгә тиң, чын күңелдән рәхмәт әйттем. Үзенең мәрхәмәт кылганына куанып елмайды да тагын бер киңәш бирде абзый: «Икенче тапкыр бу «Мәел бокс»ка килмә син. Башкасына бар. Бу—ирекле ил, синең сайларга хакың бар».

Менә бу булды ирекле илдә яшәүнең бер мисалы. Андый мисалларны күп китерергә мөмкин: кая гына барсаң да, ата улны, ана кызны белми, дигәндәй, бер нәрсәнең төбенә төшә алмыйсың, бигрәк тә телефон аша—ә күп нәрсәләрне телефоннан хәл итәргә туры килә. Бәреләсең, сугыласың да: «Башка болар белән бәйләнмим, икенчесенә күчәм!»—дип ант итәсең: башка банкка, башка страховкага, башка табибка... Бөтен кеше шулай күчеп тик йөри! Аннан судлашырга тотыналар, рәт чыкмаса, адвокат алыштырырга тотыналар. Ирекле ил!

Шунысы кызык, мондый хәлләрне чынлап та «ирекле» булу дип аңлый алар! Безнең кебек юньләп сөйләшә белмәгән, ирексез илдән килгәне күренеп торган кешегә үзләренең бу «казанышларын» искәртеп куюны бик тә кирәк санайлар: мактанып яки патриот булып түгел, мәгълүмат өчен генә—төрмәдәй илдән генә килгән мескен бит бу, каян белсен ирекнең ни икәнен, янәсе.

Шулай бер кибеттә, юри генә киеп карыйм дип, иң кыска шортыны сайлап алдым. Озын киемгә күчкәнемә ун елдан артыктыр инде, ә монда бик эссе дә, бөтен кеше кыска кигәндә озын киеп йөрү аякларың кешенекеннән ямьсезрәк дигән кебек тә. Туктале, мин әйтәм, кайсыларының ике аягы минем бер аягыма тормый, нигә мин шулардан да ямьсез булып, бөтен җиремне каплап йөрергә тиеш?! Бот төбеннән

генә шортыны киеп алдым да—көзгегә карасам, ару гына... Күрше чаршау артындагы хатынга күрсәтәм: «Ничек, мин әйтәм, артык кыскамы минем яшьтәге кешегә?» Әй, мактап алып китте теге хатын: «Әмәйзиң!— ди. «Искиткеч» дигән сүзе инде.—Син илле яшьлекме? Булса ни! Син теләсә кайсы яшьтә теләсә нинди кием кия аласың—бу ирекле ил!» «А-аh!—дидем эчемнән генә.—Бу мине теләсә нинди кием киеп булмый торган илдән килгән дип уйлады бит». Хәер... Нишләп соң әле бу илдә генә шушындый ыштан киеп көзге алдында басып торам, моңарчы нишләп йөргәнмен? Алдым мин бу нәрсәне. Киям. Беләсезме, нәрсәсе кызык? Үземне ирекле итеп сизәм! һәм ирекле илдә итеп. Тансыга да бардым әле шуны киеп. Үземне-үзем җиңеп... Шундый вак-төякләрне тирә-ягыңда күрә-күрә, үзеңдә сынап карый-карый, күңелдә нindiдер яңару туа: үз-үзеңә ышану, үзеңне дә, башкаларны да юк-бар өчен гаепләү урынына хуплау теләге, сәбәпсезгә көенгәнче сәбәпсезгә сөенергә омтылу. һәм—ирек тойгысы!

«Ирекле ил» төшенчәсе алай ук көлке һәм алай ук гади түгелдер. Күңелендә ирек тойгысы булган кешеләр иле дигән сүздер ул, бәлки. Ә ирек үзе, нindiдер гамәл булудан да бигрәк,—ирeklелек тойгысыдыр. Ул тойгыны булдыру һәм югалтмау өчен кыска ыштан киеп биеп йөрү генә җитми инде, шул тойгы белән тумасаң да, шуның белән үсәргә кирәктер. Мин үзем әлегә аның ни икәнен дә бик аңлап бетермим. һәрхәлдә элек мин уйлаган нәрсә түгел ул, мин уйлаганнан азрак ул һәм... күбрәк тә: балачакта җилгә каршы йөгергәндәге рәхәтлек хисе...



Әнә Нью-hоптагы бер кибеттә сатып алучылар өчен «Рәхим итегез!» дигән язу урынына «Мин сезне күрәлмим!» дип язып куйганнар. Американнарның гадәти җүләр сатуы. Нигә кирәк икән? Белмим, тик гаеп итәргә дә ашыкмыйм. Гаепләргә өлгерербез, башта карап карыйк әле. Әнә бер кыз китеп бара, кофтасының аркасына «Лив анд лөрн!» дип язылган—«Яшә һәм өйрән!». Җил-җил атлап китеп бара. Бәй, кыз дигәнем 60 яшьләрдәге хатын булып чыкты... Әллә минем гаҗәпләнгән карашыма җавап итеп, әллә үз күңелен күреп, елмаеп, кул изәде. Мин дә елмайдым. һич югында елмаерга өйрәндем бит әле!

Өйрәнәсең ул. Чирканчык та алдырып тормый, тирән суга

ыргытсалар, йөзеп китми хәлең юк—батасың да калкасың... Шулайрак «йөзә» алсаң, бик шөкер дип санала бу илдә. «Ап әнд дәуын» диләр алар адәм баласының яшәү рәвеше турында: «Өскә һәм аска». Тормышка фәлсәфи караш бу—алай да була, болай да була, һәм тормышны үзгәртергә дә була.

Хәтта дин шикелле катгый нәрсә дә, шул ук тормышның бер ягы буларак, күп вакыт шулай фәлсәфи кабул ителә. Мин үзем динилекне иң җитди нәрсә дип аңыма сеңдергәнмен. Дини булгач, ул диннең һәр канунын бөртекләп үтәргә, аңа тулысы белән инанырга һәм һәр кушканын, сыңар сорау да бирмичә, эшләп барырга кирәк бит.

Бер кеше белән сөйләшергә туры килде. Дини түгел, дини булырга теләге бар икән. Эшне кайсы динне сайлаудан башларга уйлый, американча: башта барлык диннәрне дә өйрәнеп, үзенә кулаен кабул итмәкче. Мин, «Дини булу бик зур җаваплылык, кайсы гына диннең дә кагыйдәләрен фанатикларча үтәсәң генә, чынлап та дини була аласың, ә бу бик җиңел түгел»,—дибрәк үз калыбымны алга этәрә башлаган идем, ул, американча, «юкны сөйлисең» дип бетереп ташламаса да, үз фикерен бик әйбәтләп аңлатып бирде: «Ә нигә фанатик булырга? Син ирекле булырга тиеш—бу ирекле ил!»

Бу «өйрәнү»—җил кайсы якка иссә, шул якка юнәлеш алу кебегрәк тә килеп чыга бугай... Аумакайлык дигән ямьсез нәрсәгә гомер буе җирәнеп карыйм, югыйсә, һәм үземдә андый сыйфатның тумыштан ук булмавына иманым камил. Ә менә монда ни күрсәм дә, җенем кузгалмый: чит ил булгангадыр. «Минем илем түгел әле, нигә мин кайнап түгелергә тиеш аның өчен?»—дип, түшәмгә төкереп тик ята җенем! Кайчакларда гаҗәпләнеп кенә куясың да фәлсәфи җавап бирәсең: «Димәк, болай да була—законга каршы килмидер, күрәсең».

Әлеге ирек һәм дин мәсьәләсенә кайтыйк әле. Монда күп яһүдиләрнең балалары католик мәктәбендә укый: мәктәп, түләүле булса да, бик арзан һәм башлангыч мәктәп өчен иң яхшылары дип санала—укырга, язарга өйрәтү каты куелган. Дини мәктәп, әлбәттә. Шунда укыган балалар шимбә көнне ата-анасы белән синагогага да барырга мөмкин, күпләре атнага бер тапкыр җүиш (яһүд) мәктәбенә дә йөри. Җүиш дигән сүз, кайбер таныш яһүдиләрнең аңлатуынча, милләтне генә түгел, динне дә белдерә: «Үз динен тотмаган яһүди җүиш дип аталмый», имеш. Монысы инде бәхәсле мәсьәлә, мин үзем беләм: милләтен җүиш дип әйтсә дә, дини булмаган һәм синагогага да йөрмәгән яһүдиләрне. Бу ирекле илдә гаҗәпләнү үтә сирәк хис—бернәрсә белән дә исләрен китәрә алмыйсың! Мин аз дигәндә гаҗәпләнә беләм әле... Тик гаҗәпләнү—яхшымы, начармы? Ирекле илдә бик еш туа мондый сорау.

## Дәртләләр, гайрәтләләр иле

МОНЫ МИН татарча булсын дип шулай атадым. Американнарның бик яраткан «чәлленж» дигән сүзләрен озак вакытлар аңламый йөрдем мин. Сүзлек адәмчә итеп аңлатма бирә алмаган, «дуэльгә чакыру» дигәне истә. Монысы «гарьләнү»гә тартым. Ишетә-күзәтә торгач, «дәртләнү, гайрәтләнү» дип күңелгә салып куйдым. Бу «чәлленж» турыдан-туры иреклелек, бәйсезлеккә килеп тоташа. Бәйсезлек бит ул иң элек—кыюлык һәм җаваплылык. Үзеңә, тик үзеңә генә ышанып карар кабул итү һәм эшне ахырына җиткерү, барысы өчен дә тик үзең генә җавап бирү. Оренбур татарларында әлеге сыйфатларның барысын да берләштергән «чәм» сүзе бар. Димәк, «дәртләләр, гайрәтләләр иле»н «чәмләләр иле» дип атарга да булыр иде.

Бандероль кыйссасын мисалга китергән идем бит әле. Мин аны гомере буе Америкада яшәгән бер яһүд хатынына сөйләгән идем. Ул бер дә гаҗәпләнмәде. «Бу илдә сиңа беркем дә, берни дә аңлатырга тиеш дип саналмый. Бу—ирекле кешеләр иле, һәркем үзенә кирәген

үзе сайлый. Син шушы «Мөел бокс»ны сайлап, аңа ышанып, тәвәккәлләгәнеңне белеп торгансың, курыкмагансың, чәлленж тоткансың һәм моңа тик син генә җаваплы.» «Шуның өчен «ирекле ил» дип атыйсызмы сез бу илне?»—дидем, тик эчемнән генә. Җавабын белә идем: кешеләре шундый булса гына, ил ирекле була ала. Ирек—һич кенә дә бал-май түгел. Ул—усал, кызганусыз, куркыныч. «Атсам—атып калам, ятсам—ятып калам!»—дия алсаң гына, ирекле була аласың. Ирек ул уңайсыз, тынгысыз, көрәш тә көрәш! Чәм дә чәм: үлсәм дә, бирешмим дигән сүз. Бирешсәң, ирекне югалттың дигән сүз. «Югалту»—«луз», ә бирешкән кеше «лузер» була. Монысы—иң хурлыклысы.

Исемдә, без кечкенә чакта бирешү дигән нәрсә бик мыскыллы сүз иде. Бармак белән төртеп: «Ә-ә! Бирештең, бирештең!»—дип ирештерсәләр, еламый калу бик кыен иде... Үзең елыйсың, үзең чәмләнеп «дошман»га ташланасың—ни теләгәнеңне дә белмисең, туктый да алмыйсың. Күрәсең, табигать салып куйган чәм булгандыр инде ул «бирешмәскә» дигән чәм.

Табигать аяусыз—ирек шикелле. Су икән су—йөзмәсәң, батасың. Тау икән тау—тайсаң, тәгәрәп төшәсең. Зарлану да, үртәлү дә файдасыз. Американнарның кыска гына, гади генә, тик бик мәгънәле әйтемнәре бар: «Ноу» минс ноу»—«Юк» юкны белдерә». Алар: «юк, булмый»,—дисә: «Тырышып карале, абзыкай!»—дип йөз суы түгү файдасыз, мәгънәсез, Тау белән суны үзгәртергә тырышу яки «берәр заман үзгәрер әле» дип өметләнеп утыру шикелле. «Җан биргәнгә җүн бирер әле»,—дип, тау астында яки яр читендә кырын ятсаң була инде, тик син «аста һәм читтә» булачаксың, «өстә һәм алда»—башкалар... Бердәнбер чара—үз кулың белән юкны бар итү. Бу бик җиңел—«итс изи» диләр бу илдә һәм өстәп куялар: «Җаст ду ит»—«Тот та эшлә син моны».

Менә бөтен хикмәт тә шунда—эшлә! Эшләү хәрәкәт итүне белдерә—акт. «Актив» сүзе шуннан чыккан, актив булу да бик җиңел—«изи»: юктан бар ясап кую. Йөзә белмисең икән, өйрән, нәрсәсе бар аның! Диңгезне ут төртеп яндыру мөмкин түгел—«бу кыен» диләр, ә йөзәргә мөмкин—димәк, «бу җиңел». Бер очучыдан: «Гомер буе күктә очу бик куркыныч, бик катлаулыдыр инде?»—дип сораган идем. Көлә: «Ю кидиң!»—ди: «Син шаяртасың! Күктә самолет белән идарә итү җирдә машина йөртүдән җиңелрәк тә, куркынычсызрак та. Нәрсәсе бар аның!» Американнар шулай тәрбияләнгән, шундый казанда кайныйлар. Алар гомер буе өйрәнә, гомер буе укый, һөнәрләрен югары дәрәҗәдә тотар өчен генә түгел, гомумән, тормыштан артта калмас өчен дә. Бер танышым—биналар инспекторы. Атна буе эшли, ә шимбә көнне укырга йөри: биналар төзү, ут-су куркынычларын булдырмау... Гомумән, бу эш белән бәйле законнар гел үзгәреп тора, ә ул аларны белмәсә, эшли алмый. «Бушка укыйсыңмы?»—мин әйтәм. «Ю-ук,—ди.—Бу илдә бушны оныт, акча түлим. Имтихан өчен кыйбат алалар, тик шунысы бар—минем бер имтиханны ике кат биргәнем юк. Бу яхшы». «Нәрсә, имтиханыңны бирә алмасаң, акчаңны кире кайтармыйлармыни?» Аптырый: «Ничек инде? Алар бит үз эшләрен эшләгән, вакытларын сарыф иткән, минем имтихан бирә алмавым—аларның проблемасы түгел». Менә шулай, сиңа кирәк икән—синең проблемаң. Җирдән яңа күтәрелгән балаларга да, шыңшып зарлана башласалар, әти-әнисе: «Бу минем проблемам түгел»,—дип кенә әйтергә мөмкин. Сиңа кирәк, син тырпылда!

Хәер, кирәк дигән нәрсәне дә алар үзләренчә аңлый. Әнә Тони—60 тан узган буйдак. Ялгызлар клубына язылган, әле тансы дәресләре алып йөри, акча түләп, әлбәттә. «Икешәр эштә эшләп, биергә ничек хәлең кала?—мин әйтәм.—60 ел буена ничек булса да биегәнсең бит инде, шул җитмимени?» «Кирәк,—ди.—Тансылар үзгәреп тора. Нинди леди карасын миңа, бии белмәгәч?» Менә шуннан була ул—«җиңел»...

Әлбәттә, моны гына без дә беләбез. Тик менә эш «эшләү»гә килеп терәлгәч, койрыкка ут капмыйча, тотынып булмый... Уйлыйсың, телисең, хыялланасың—бик яхшы, монысы да «юк»тан алдарак («Нәкст ту

носиң» диләр) тик бу—эш түгел. Бу илдә кеше белән танышканда бирелә торган сорауларның берсе һәрвакыт: «Син нәрсәләр эшләргә яратасың?»—булыр. «Нәрсәләрне яратасың?»—түгел. Эш дигәне көрәк алып җир казу гына түгел, әлбәттә. Тик барыбер театр ярату гына түгел—театрга йөрергә ярату. Дөресен әйтим, шушы гади генә сорау мине һәрчак авыр хәлгә куя. «Укырга, язарга яратам»,—дип әйтәм, анысын бик хуплыйлар, тик бар белгәнем шуның белән тәмам була... Кайчагында ачуым да килә: әйтерсең, без алар кебек, клубтан клубка, мәктәптән мәктәпкә чапкан—«йөзү дәресләре, музыка дәресләре, пешерену дәресләре, спорт дәресләре, бакчачылык дәресләре... Очы-кырые юк. Хәер, «тормыш шулай булды» дип кенә аклану хак булмас иде. Эчтәге пассивлык корты бөтен энергияны йотып бара! Кемдер әйткән (мин үзем түгел микән): «коллык кортын җиңү—иң зур җиңү» дигән кебегрәк. Безне дәртсез, гайрәтсез—пассив булырга совет системасы күнектергән.

«Хәрәкәттә—бәрәкәт» дип, безнең ата-бабалар әллә кайчан әйткән әйтүен, андый гына сабакны алыр өчен Американы өйрәнеп торасы юк. Шунысына гына эч поша—безнең бабайлар әйткән, болар ишетеп тә алган, хәрәкәт тә итә башлаган, ә без... без хәрәкәтне дә яратабыз, бәрәкәтне дә яратабыз, хәрәкәт итәргә көч җитми. Хәрәкәте дә һаман бер урында таптану килеп чыккач, бөтенләй җен котыра!

Әллә берәр хәйлә уйлап табасы инде? Беркөнне кемдер: «Син гольф уйныйсыңмы?» дип сорый. Гел турысын гына әйтә идем, бу юлы әллә ничек кенә: «Уйныйм»,—дидем дә куйдым. Менә хәзер нишләргә инде? Гольф клубына язылырга микән? Каян тәвәккәллек алырга? Каян акча табарга? Ул клубның үзен каян табаргадыр әле? Монда сиңа, акча түләгәнеңә карап, өеңә китереп бирергә тормыйлар, сиңа кирәк—син эзлә, тап! Ә хәйлә дигәннән, ару гына бит бу: шулай алдашкаласаң, үзең дә ышана башларсың, һич югы алдакчы булып калмас өчен хәрәкәткә керешерсең. Ә? Их, кайда соң шул бала чактагы: «Бирештең, бирештең!»—дип кычкыручылар?! Хәер, монда олысы-кечесе гел бер-берсенә: «Доунт гив ап!»—дип кенә торалар: «Бирешмә!» «Әллә бирешергә булдыңмы?»—дип котыртып, оялталар. Улым хоккейга йөри. Яңа ботинкалары аягын кырган, кып-кызыл кан диярлек. «Иртәгә бу аягың белән хоккейга бара алмассың инде»,—дигән идем, гайрәтләнеп: «Ноу гивиң ап!»—дигән булды: «Бирешү юк!»

## Бәйсезлек корбаннары


«МАШИНА—бәйсезлек»,—диләр американнар. Аның чынлап та шулай икәнен исбатлап торасы юк, һәркемгә аңлашыла. Миңа анысы кызык та түгел, мин машинасыз да гомер буе үземне бәйсез итеп сиздем, һаман да машинам юк... Һәм әзрәк бәйсезлек җитмәве сизелә башлады... Бәйсез илгә килеп капкач кына! Гел шулай була бит ул. «Без өйләнгәч, төн кыскарды»,—дигәндәй.

Әйе, американнарның «машина—бәйсезлек» дип, минем өчен нindидер яңа мәгълүмат бирергә азапланулары көлке дә, кызганыч та: әллә безнең илдәге халыкның бердәнбер транспорты—агачтан агачка сикерү дип уйлыйлар инде! Әйе, машина—бу илдә бәйсезлекнең котылгысыз юлдашы. Әнә бара бәйсезлек, менә бара машина. Тик бу әле машина бәйсезлекнең иярчене икән дигән сүз түгел. Бу илдә бәйсезлекне машинасыз берничек тә күз алдына китереп булмый, ә машинага нәрсә—китте барды пытыр-пытыр, бар ни аңа, юк ни Американың бәйсезлеге! «Машина—бәйсезлек» дигәнне шик астына алмый гына, «бәйсез американнар—машина коллары» дип тә өстисем килә.

Ни өчен? Бәйсез булырга теләгән өчен. Иң беренче чиратта—бер-берсеннән. Машинасыз яшәргә мөмкин урыннарның мисалларын күп табып булмас, ярый, әлегә Нью-Йоркны алыйк. Анда, чынлап та, күп кеше

машинасыз, һәрхәлдә күп вакыт машинасыз көн итә ала. Бу ни дигән сүз? Автобус, метро, поезд шикелле транспортта йөрү дигән сүз. Димәк, аларга бәйле булу дигән сүз. Хәтта таксига утырсаң да, барыбер бәйлелек—һич югы таксистның сине нинди тизлектә алып барганына чыдарга тиешсең, һич югы ул таксистның чыраен яки аркасын күрергә тиешсең... Үз машинаңнан тыш нинди генә транспортта да синнән башка тагын кемдер булырга мөмкин, сиңа кайберсенең борыны, кайберсенең авызы, кайберсенең төсе яки исе ошамаска мөмкин, һәм син шуңа түзәргә тиеш, син—бәйле! Моның белән генә эш бетми әле. Зур шәһәрдә, машинасыз йөри алырлык урында яшәргә теләсәң, ул һәрвакыт үз өең булмаска мөмкин—сиңа күп фатирлы кондоминиумда яшәргә туры килүе бар! Бу инде—бәйсезлекнең тамырына балта чабу белән бер. Әнә Сулейма дигән хатын берүзе бер өйдә яши. Бай түгел. Бөтен эшләгән акчасы шул йортка кереп бара—ул бит бурычка алынган, җитмәсә, күпме салым! «Нигә матур гына кондоминиум алып яшәмисең?—димен.—Хөкүмәт фатиры бигрәк тә уңайлы булыр иде, шушы кадәр эшләмәс идең, ичмасам». «Ю-ук,—ди.—Мин тирә-ягымда кешеләр йөргәнне ишетеп торырга, аларның авызга алмаслык азык исләрен иснәп торырга теләмим. Бу йорт минем өчен артык кыйммәт инде анысы, тик бәйсезлегем кыйммәтрәк». Зур шәһәрләрнең урамына да чыкмаслар иде әле американнар—анда бит башкалар белән бергә буталырга туры килә, тик кайчак ансыз мөмкин түгел: эш урыны, кибетләр, театр-мазарлар, табиблар һ. б.

Ә мөмкин булган очракта алар иң әүвәл бәйсезлекне сайлый. Кыйммәт булса да, уңайсыз булса да, хәтта куркыныч булса да. Кая гына илтеп салмаганнар йортларын! Мөмкин булганда йорт тирәсендәге җирләрне дә үзләштергәннәр—алай-болай берәрсенең исе килеп җитәрлек булмасын. Кайда басу, кайда урман, кайда урам—беркем дә чамаларлык түгел. Һәм адәмчә, ягъни ике аяклап, беркая да бара алмыйсың. Эшкә машина белән, кибетләргә машина белән; балаларны тәпи йөрергә ничек өйрәтәләрдер, алар машинада туа, машинада үсә... Алар башкача яшәүне бәхетсезлек дип саный: ялкаулар, авырулар, хәерчеләр тормышы... Кайсыбер кышларны берничә көн яки атна буе өйләреннән чыга алмыйлар—кар күбрәк яудымы, бетте: зур юллар гына чистартыла, зур юлга чыгар өчен машина кирәк, ә машина тирән кардан йөри алмый.



һәрбер өйгә керә торган юлларны күрәп бетерү мөмкин түгел, алар озын һәм исәпсез-хисапсыз. Нихәл итәсең, һаман Аллаһы Тәгаләнең коллары булып каласың шул! Һәм—машина коллары. Монысы да минем фикер генә. 80 нән узган кешеләр кукыраеп рульдә утыралар, булыр сиңа кол!

Европа кешеләренең чын американнар—индеецлар җиренә ялгыш кына килеп кереп, чын-чынлап басып алып, аяк терәп яши башлавына байтак вакыт үткән. Тарих кануннары адәм баласының гына акылына сыярлык түгел. Тарихта хәтта «җиңүчеләрне хөкем итмиләр» дигән оятсыз канун да бар. Шулай да, индеецлар турында җитди сүз чыкканда, бүгенге американнар «Итс шейм» дип әйтеп куярга мөмкин—«Бу оят, кызганыч». Ярый инде, ни булса да, гаделсезлекне гаделсезлек дип таныйлар, индеецларның калган өлешенә ярдәм итәргә тырышалар.

Минем игътибарымны җәлеп иткәне шул: индеецларның исән калганнарына түгел, кырылып беткәннәренә ярдәм итәргә тырышу кебек. Әйе, әйе, мин сизәм! Алар, шушы туфракта туып, шушы туфракка кереп юкка чыккан, күпсанлы серле халык, һаман да шушында, бүтән милләтләр, бүтән буыннар арасында йөреп ятадыр кебек һәм әлеге «башкалар» алар тирәсеннән башларын иеп, «Сорри»—«Гафу итегез» дип шыпырт кына үтеп китәдер кебек. Индеец аларга карата яман сүз әйтүне күз алдына да китереп булмый. Тарихларын өйрәнәләр, музейлар ачалар, төрле-төрле жанрдагы китаплар язалар, киноларда алар ходай белән кешеләр арасындагы җан ияләре—пәйгамбәрләр яки тылсым ияләре шикелле тасвирлана. Берәр әкияттән, риваятьтән берәр агачның индеецларга бәйле икәне ачыкланса, ул агач шундук изгегә әйләнә, аның турында шигырьләр языла, аның янына халык агыла. Ничек итсә итәләр, бу агач мәңге корымаска тиеш була... Хәер, индеецларның рухлары һәр агач тирәли очып йөри сыман. Рухлары гына түгел, бик күп атамалар калган индеецлардан—авыл-шәһәр исемнәре,географик атамалар... Алар шулай ук Кызыл кенәгәдәгедәй саклана һәм яклана. Җырдагыча: «Сүзләре ләй калган—үзе юк», диярсең...

Безнең аңда Америка—гомергә сугыш, кан коеш күрмәгән, гел өзергә вөзир булып, чәчәк атып кына яткан ил булып сеңеп калган. Ләкин чынлыкта алай түгел. «Бу—ирекле ил» дип кабатлау да бер дә юктан гына гадәткә әйләнмәгән—яулап алынган ирек ул. Тик «бәйсезлек» дигәндә, Америка Англиядән азат булуын гына күздә тота. Ә мин («бәйсезлек корбаннары» дигәндә) башка нәрсәне күздә тотам. Ялгышлык белән «индеец» дип аталган әлеге «күпсанлы серле халык»ны. Бәйсезлек эзләп дөньяның төрле почмакларыннан җыелган килмешәкләр иң беренче эш итеп Американы шул индеецлардан чистартырга тиеш булган бит. Бәйсез кабиләләрне корбан итеп үзләренә бәйсез тормыш яулаганнар. Урман төпләп, йортлар салган шикелле.

Тагын бер әйберне күздә тотам әле мин. Болары—эреле-ваклы җәнлекләр, бәлки индеецлардан ук калган кыргый хайваннар. Табигый хәлдә гомер иткән халыкның җир-суын үзләштереп, кыргый хәлдәге җирнең теләсә кайсы почмагында дөбердәтеп йортлар салып, үзләре теләгән тормыш корып яши башлаган һәм искиткеч тизлектә искиткеч цивилизациягә ия булган бәйсез рухлы американнар, үзләре дә уйламастан, табигатьнең кыргый хайваннар өлешенә дә дөбердәтеп бәреп кергәннәр. Бу, әлбәттә, дөньякүләм проблема. Монда мин аны әлеге индеецларны исемә төшергәнгә генә телгә алам. Бер-берсеннән ераграк, бәйсезрәк яшәргә омтылып, кешеләр кая китсен инде? Кыргый хайваннар арасына.

Әнә, Принстон уртасында Һәррисон стрит (урамы) читендә машинага бәрелеп үлгән болан гәүдәсе аунап ята. Мин исемнәрен белмәгән әллә нинди йөнтәс җәнлекләр, еланнар, ташбакалар, кыргый күркәләр, кыр казлары—бөтенесе күз алдында, аяк астында. Ул тиеннәр белән кроликларны әйткән дә юк инде, бер табактан ашыйбыз, дигәндәй.

Бер кичне саф һава керсен дип, арткы ишекне ачып куйган идем. Карасам, почмакта әллә нинди ямьсез нәрсә! Котым ачты. Күсе

дисәң, күсе түгел, керпе дисәң, керпе түгел, борыны озын, алсу, койрыгы лапылдап тора, үзе кухня почмагында мыш-мыш килә. Үләм дип торам! Тиз генә песине табып алып килдем. Әйләнеп тә карамады песием, артына борылды да ипләп кенә чыкты да китте. Ул да шүрләде, сизеп торам, бөтенләй ду кубып чабарга гына оялды үзе. Песи тотмый торган нәрсә икәнен аңладым тегенең, тик бит мин тота торган нәрсә дә түгел, тычканнан да куркам. Ичмасам, малай да өйдә юк, ул булса, аюны да күтәреп ала... Бәй, бу мәхлукне нишләтергә инде? Яңадан песине алып килдем. Кулым белән тотып тегенең каршына бастырдым, песидән куркып чыгып китсен дим, юк, кузгалмый, әллә күрми, әллә ишетми, әллә башкача. Песине дә оялтып карадым: «Печелгән булсаң да, ир-ат бит син, нәрсә карап торасың! Мыраулап җибәр, белсен кем икәнеңне!»—дим. Юк. Песием ычкынды да качып китте. Артык кыргый җанвар булгандыр теге нәмәрсә. Кыюлыгымны җыеп, үзем куа башлаган идем, бүлмәгә кереп китте лапыр-лопыр. Икенче карауга шкаф астына ук кереп качты. Тизрәк үз бүлмәмә кердем дә бикләндем. Ачык кухня ишеге белән тән чыктым. Ни хикмәттер тагын, үзе юлны табып, кухня ишегеннән тышка чыгып киткән, иртән күренмәде. Моны инде кызык итеп кенә сөйләдем.

Еш кына кызганыч хәлләр дә булып тора. Машинага бәрелгән яралы боланнар начар авырулар тараталар, бу хәлдән боланнар гына түгел, машинадагылар да бик күп каза күрә, болан бәласенә юлыкмаган бәрәр машина хуҗасы бар микән? «Алар артык күп»,—дип зарланучылар да бар. Беркадәресен аталар бугай, тик артык кырырга базмыйлар—кыргый хайваннарны саклаучылар җәмгыяте бик көчле. «Күпсанлы серле кыргый хайваннар» дип әйтәсем килеп китте әле! Чөнки аларны яклау һәм саклау индеецларны да хәтергә төшерә. Американнар, мескен җәнлекләргә тәгаенләнгән урыннарны басып алганнар да, хәзер яклапмы-яклыйлар, яратыпмы-яраталар! Бәйсезлек американнарга гына кирәкмени? Җәнлекләргә дә кирәк ич ул, аларның да үз җирләре булырга тиеш. Бәреләләр дә сугылалар бичаралар, кая гына барып чыксалар да—адәм токымы, выж да выж машина: адәмнәрнең котылгысыз юлдашы, җәнлекләрнең һәлакәте. Беләләр микән ул мәхлуклар машина эчендәгеләрнең аларны яклаганын һәм саклаганын?.. Җәнлекләр кирәк, тик бәйсезлек кирәгрәк, машина—бәйсезлек. Кая карама—машина юллары, кая карама—тапталган җәнлекләр, аларны кат-кат таптап, җир белән тигезләп үк куялар... Рульдә утыручылар үзләре чырайларын сытып, күзләрен йома, кызганалар янәсе. Мин дә кызганам, берни дә эшли алмыйм, беркем берни эшли алмый, таптыйлар да узып китәләр бәйсезлек корбаннарын. Бәйсезлеккә нигә корбаннар кирәктер? Анысын әйтә алмыйм.

## Дискриминейшен

«ДИСКРИМИНАЦИЯ» буладыр инде бу, тик аны бик гади генә итеп «кеше аеру» дип атарга мөмкин—шулай тәгәлрәк тә кебек. Бу илдә катгыйдан да катгый тыелган нәрсәләрнең берсе ул: үзен түгел, сүзен дә кулланмаска тырышалар. Закон каты. Шундый начар күренешнең шулай каты тыелган булуы, әлбәттә—зур казаныш.

Кызганыч ки, язылган законнар язылмаганнарын юкка чыгара алмый. Минемчә, язылмаган законнар—көчлерәк, язылган законнар—аларга каршы көрәш чарасы гына. Яманлык яхшылыктан көчлерәк килеп чыга, чөнки яманлык кылу җиңелрәк. Алай гына да түгелдер әле, кешенең үзендә үк ике фәрештә кунаклап утыра бит—яхшылык һәм яманлык. Яманның яман икәнен бик белеп торып та, кеше аны чын-чынлап җиңәргә тырышмый, бәлки, җиңә алмыйдыр да. Адәм баласының тагын бер исеме бар бит әле—кол. «Кол» дигәндә бәндәнең яманлык колы булуын күздә тотам. Яхшылыкка кол булу кирәкми: яхшылык яхшы ич ул, кол—начар!

Дискриминация—кеше аеру яманлыкның да иң яманыдыр. Дөнья күптән белә инде моны. Моңарчы мин бу турыда әллә ни уйлаганым да, зур игътибарга лаек дип санаганым да юк иде. Чөнки безнең сулаган һава кебек иде ул: сине ничек телиләр, шулай мыскыл итәләр дә, син «сәдакасына күрә савабын кайтарасың», кулыңнан килсә... Әхлаксыз түгел идек без. Язылган законнарны бик белгән булмасак та, язылмаганы буенча нәрсә ярый, нәрсә ярамаганын бик белә идек. Хәер, белмәгән чаклар да булгандыр.

Яшь вакытымда чәчем бик озын иде. Трамвайда барам. Бер хатын үтә усал итеп: «Чәчен-башын туздырган, әйтерсең, ул гына трамвайда!»—диде дә әллә юри, әллә ялгыш кына, авырттырып чәчемнән тартты. Ачуланып борылып карадым—олы гына яшьтәге бер юан хатын. Секунды белән чәчрәп чыктым: «Сиңа минем озын чәчем мишәйт итсә, миңа синең юан корсагың мишәйт итә—тегендәрәк китеп бас!»—дидем. Янәшәмдә торган егет: «Молодец!»—дип үсендереп җибәрде, үземнең шәплегемә үзем дә сокланып куйдым. Чынлап та, көчле килеп чыккандыр, мескен апа каршы эндәшмәде... Исемә төшкән саен оялам. Низагны башлаучы шул хатын булса да, гаепле—мин кебек шул. Озын чәчле булу зур корсаклы булудан яхшырак, димәк, ул мине түгел, мин аны рәнҗеткәнмен. Дискриминейшенның гап-гади мисалы бу: кешенең кайсыдыр яклары бер сәбәпсез, бер нигезсездән җәмгыятьтә «начар» дип санала, һәм шушы «начар»лыгы өчен кешене кимсетергә, бетереп ташларга була. Без, татар балалары, моның ни икәнен белмиме соң! Хәер, татар гына түгел, бик күп башка милләтләр... Күпләр үзләренең урыс булмаганга күрә «начар» икәннәренә ышанып ук беткән иде. Шулай, шулай, чын исемнәреннән, телләреннән, ата-аналарыннан оялып, шуны яшергән кешеләрне мин һич кенә дә, дискриминация корбаны булып, тормышта лаеклы дәрәҗәгә ирешә алмаудан курыкканнардыр, дип аклый алмыйм. Төп сәбәп ул түгел, Ходай тарафыннан «начар» булып яратылганнарына ышанган бәндәләр алар һәм шуны «төзәтергә» тырышкан мескеннәр. Моны аклап булмаса да, аңлап була, билгеле.

Уфада Динә исемле дус кызым белән троллейбуста сөйләшеп утыра идек, чучка кебек пычракка баткан бер исерек урыс: «Чево на весь троллейбус разошлись, татарки наглые!»—дип кычкыра башламасынмы! Татарча—пышылдап кына сөйләшергә кирәк икән! Дискриминация, чынлап та, бер секундта бетереп ташлый ала кешене. Көчсезрәкләр, күрәсең, җиңелрәк юлны сайлаган—кем икәннәрен яшергән дә, оныткан да. Бер чуаш кызының: «Шул нацияны күрә алмыйм, бер авыз чуашча белмәсәк тә, нишләп чуаш диләр икән безне?»—дип зарланганын мәңге онытмам. Күпме чуаш үзен урыс дип йөртә! Кимсетүнең ни икәнен белмәгән татар да юк. Исемдә гомерлеккә калачак тагын бер ямьсез күренеш бар: 22 яшьтә идем, ял көнне, троллейбуста, Уфада. Бер башкорт радиосын ачкан, көндезге башкорт концерты бара. Артымда басып торган хатын очып кунмасынмы бу кешегә: «Это тебе что, татарский клуб?! Может, никто не хочет слышать твою дурацкую гармошку! Заткни свое радио сейчас же!»—ди. Андый гына тупаслыкларны колакка да элмәскә өйрәнгән, ахрысы, теге абзый, бер сүз эндәшмәде, радиосын да сүндермәде. Мин әлеге хатынның «татарский» дигән сүзенә чыдый алмадым: «Не башкиры пришли на русскую землю, русские пришли на башкирскую, пусть слушают!»—дип, яңгыратып җавап бирдем. Теге хатын аптырап калды. Интеллигент кыяфәтле хатын иде ул һәм... татар иде! Валлаһи, татар иде! Телен оныткан манкорт. Менә шулай! Милли дискриминация көчле милләтнең көчсез милләтне рәнҗетүе генә түгел ул, ул күпкә шакшырак. Һәркем белә иде: «Милләт аерырга ярамый!» Әмма икенче бер язылмаган закон монысына каршы иде шул—бер милләт яхшырак, икенчесе начаррак. Мәсәлән, татар егете мари кызына өйләнсә, җөй көне кар бураны чыгар иде, әллә кайдагы әллә кайсы авыл кызын «ир тапмаган, марига барган» дип сөйлиләр иде әле... Бер-беребезне мыскыл итеп яшәгәнбез һәм

үзебезне-үзебез дә аяп тормаганбыз: «Ярамаган безгә—татарга...»

Кистереп әйтәм: монда алай түгел. Монда башкача. Язылган законнар тормышта кулланыла торган ил бу. Әмма ләкин язылмаган законнар да кабергә керергә тормый. Язылган законнарның кискенлеге язылмаганнарының да көчлелеге турында сөйли. Юк дошман белән кем көрәшсен инде?!

Һәркем белә: монда милләтләр юк. Тик уңайлылык өчен, паспортта булмаса да, тормышта халыкны берничә төркемгә бүлеп йөртәләр: каралар, спәниш (испанча сөйләшүчеләр—латиноамериканнар), калганнар—аклар, кайчак алардан «әйжен»не (азиатларны) аерып карыйлар. Кара ни өчен кара? Тәсе кара булганга, янәсе. Ә алар кара түгел, алар төрлесе төрле төстә, кайсысында ничә процент «кара» барлыгын беркем дә әйтә алмый, кайсылары «ак»лардан да аграк әле: әйтик, һиндлар, башка кайбер көнчыгыш халыклары бер дә «кара»лардан аграк түгел. Тик Африка каны аз гына катнашкан булса, андыйлар «кара»га керәләр. Үзебезне уйлыйм да тагын бер уйлап куям: нинди генә халыкларда безнең татар каны юк, берсе дә үзләрен татар дияргә ашыкмый! Ә болар чатнап тора: «Мин—кара». «Мин—кара». Кибеттә эшләгән чагымда, улым белән бер сыйныфта укыган малай бар иде, дәрестән соң килеп эшләп йөри иде. Бик матур, бик акыллы малай, бик ярдәмчел үзе. Тәсенә карап, килеп чыгышын аеру кыен. «Син итальянмы, испанмы, кем син?»—дип сорыйм. «Мин африкан американ—кара»,—дип җавап бирә. «Кит, син кара түгел бит!»—дим, чынлап та, кара тәнле түгел. «Юк, минем әти кара,—ди.—Монда килә ул, күрсәтермен әле». Соңыннан әтисен дә, әнисен дә күрдем: әтисе кара, әнисе ак. Шулай итеп, халыкның 25 проценты «каралар» санала. Шулай чатнап торсаң, безнең татарлар саны күпмегә җитәр иде икән. Югыйсә негрлар кара булганнары өчен күпме җәфа чиккән халык! Кем икәннәрен яшермиләр дә, кимсенмиләр дә, үзләре «начар» булып яратылган дип уйларга башларына да килми. Дөрес, аларны яклый торган законнар яхшы эшли. Тик бит әле... тегеләре бар—язылмаганнары! Җәмгыятьнең аңын, халыкның психикасын үзгәртү, ай-һай, кыен! Юк кына кеше дә, ак булса, үзен барыбер каралардан өстен саный. Шундый ипле-тәртипле бер танышым бар иде: әнисенең бабасы индеец булган, әтисе ягыннан—ирландлы. «Моңарчы индеецлар катнашкан караларны гына күргәнем бар иде»,—дип әйтеп салдым, аны-моны уйламыйча. Танышым иплән кенә әйтеп куйды: «Син мине ул класска кертмә инде, плиз...» Тагын бер генә мисал. Бер «ак» белән урамнан китеп барабыз. Каршыга кара егет белән ак кыз килә. Тегеләр аз гына үтеп киткәч, әйтә бу: «Ак кыз кара белән... Ак егетләрне бервакытта да кара кызлар белән күрмәссең.» Нәрсә әйтергә телисең?»—дип сорыйм. «Бернәрсә дә,—ди.—Син чит ил кешесе, белеп торсаң, зыян итмәс». «Бер яңалык та юк. Мин күп милләтле илдә яшәдем»,—дидем. Әллә нишләп әзрәк ачу килде. «Сорри,—ди.—Син шулай уйлыйсың. Бу илдә алай уйламыйлар. Каралар белән кеше арасына чыксаң, үзең күрерсең». Ул хаклыдыр, ул монда туып-үскән.

Нинди генә закон да кешенең башындагы, аңындагы уй-хисләре өчен хөкем итә алмый. Шулай ук беркемне дә көчләп яраттыра, хәтта ихтирам да иттерә алмый, хәтта күрше булып та яшәтә алмый. Һәм «дискриминейшен» сүзен дә кулланып булмый—кайда ул, юк монда дискриминейшен! Ә расизмга каршы законнар гадәттә караларны яклый икән, үзе үк кеше аеру турында сөйли ич! Кимсетү булмаса, нигә кирәк яклау? Хәер, яклаудан кызгану исе килә бит, анысыннан—кимсетү исе... Уку йортларына алганда, яки укыганда караларга өстенлек бирелә, диләр. Бигрәк тә Африка илләреннән килгәннәргә. Без моны бик яхшы беләбез: милли кадрлар әзерләү битлеге астында бездә дә бар иде андый яклау. Мин, яшь булуыма карамастан, студент вакытта ук моның кимсетүгә якын торганын сизә идем. Начар гамәл дип булмый моны, кире кагып та булмый, тик кабул итүе дә бәхет өстәми. Акылга—ярый, күңелгә—авыр. «Эт күңеле—бер сөяк» дигән әйтем хәтергә килә.

Америкада юаннарга кырын карау да бар. Ышанмас идем, бик житди, зур кеше сөйләде: иптәш егете юанлыгы аркасында эш таба алмый икән. Юан—могаен, авырудыр, ә икенчедән, кешеләр андый ямьсез симез адәмне яратмаска мөмкин һәм бизнесын югалтырга мөмкин. Американнар өчен карар күзгә матур булсын, елмаеп кына торсын, аның белән аралашу күңелгә рәхәт булсын, акылы, белеме белән әллә ни файдасы тиярдәй булмаса да, шундый кешене эштә тотарга мөмкин—клиентлар ярата! Америка—байлар иле, ә байларның үз кирәкләре, аларга ни житмәгәнен белмәссең...

Нью-Йорк консерваториясен бетергән кыз бай кешеләрнең этләрен урамда йөртеп акча эшли. Көлә: «Алар этләрен консерватория бетергән кыз йөрткәнгә бик горурлана, миңа бүтән эт караучылардан күбрәк түлиләр»,—ди.

Берәүнең дә капчыгы буш түгел. Алыйк безнең беренче буын эмигрантларын. Кем булуларына, нинди булуларына карамастан, болар—иң соңгы сорт кешеләр. Аның белән генә дә эш бетми әле. Тел белүең яхшы түгел икән, беренчедән, синең белемең юк, син надан дигән сүз, икенчедән, син ышанычлы түгел. Банкта ничә тапкыр тап булдым инде—документ күрсәтәм, кул куям, шул житәргә тиеш. Тик, гафу үтенгән булып, әллә кая эчкә кереп китеп, башлыкларыннан нәрсәдер сорыйлар, тикшерәләр, торасың аптырап, чынлап та, гаепле кеше шикелле, халык та сиңа шикләнеп караган төсле... Чит ил кешесе икәнсең, башкаларга булган мөнәсәбәтне таләп итә алмыйсың. «Мин карак түгел!»—дип кычкырасыңмыни?! Беркемне дә синнән шикләнмәскә, сине хөрмәт итәргә яки сиңа ышанырга мәжбүр итә алмыйсың. Сүз арасында әйтеп китим, «чит ил кешесе» инглизчә «әлиен» була, шул ук сүз «чит планета вәкиле»—»инопланетянин» дигәнне дә аңлата. Кызларның иң матурлары, иң үткерләре килә бу илгә бездән. Кемнәргә генә кияүгә чыгып, нинди генә түбәнлекләр аша үтмиләр! Үз тиңнәренә барганнары йөзгә бер. Хәер, алар ничек тиң булсын—бу илдә аның теле тел түгел, белеме белем түгел, дәрәжәсе дәрәжә түгел; аны тик сатып алырга гына ярый—алырдай жире булса. Хәер, «дискриминация» дип тел әрәм итәсе дә юк, капиталистик базар бу, туры мәгънәсендә, ыжгырып торган базар! Американнар фәлсәфи: «Датс уат ит из»,—диләр.—Ягъни «Бар булганы шул». «Дискриминейшен»га карата да шуны әйтергә кирәктер: законы бар, закон кысаларына кермәгән өлеше—»датс уат ит из».

## Көчле илнең көчсез яклары да бар

КӨЧЛЕЛӘРНЕ генә санга саный торган ил бу. Һәм, чынлап та, көчле кешеләр иле. Көчле кешеләр карар күзгә үк күркәм. Алар үзләренең кем икәнен онытырга юл куймас. Үз-үзеңне мактау бер дә гаеп эш саналмый: «Мин сәламәт, энергияле, актив, шат күңелле»,—диләр алар. «Шат күңелле» дип «хәппи»не тәрҗемә иттем—ул «бәхетле» белән «шат»ның икесен дә белдерә. Американнар танышканда: «Син хәппи кешеме?»—дип сорарга ярата, бу бик мөһим—«хәппи» булсаң, исәнлегең дә, холкың да яхшы дигән сүз: сәламәт тәнле һәм сәламәт рухлы.

Монда сәламәтлек белән ябыклык аглый белән таглый кебек. Үзен мактаучы сәламәт, энергияле, актив, шат күңелле кеше авырлыгын да күрсәтми калмас. Һәм, әлбәттә, авырлыгы азрак булган саен ул сәламәтрәк, жегәрлерәк, активрак, шат күңеллерәк... Юаннардан да ишеткәнем бар: «Мин бик көчле һәм сәламәт»,—дигәнне, могаен, дөрестер. Тик, нишләптер, аларның ул сүзләре аклану шикелле яңгырый.

Бик күпләр йөгерү, жәяү йөрү белән шөгыльләнергә тырыша. Ябык кеше йөгереп узып китсә, «хәппи» тоела, симез кеше—киресенчә: аның чыраенда гаеплелек тә төсмерләнә... «Ил авызын иләк белән каплый алмыйсың», дигән шикелле, жәмгыятьтә урнашкан карашны берничек тә жиңә алмыйсың. Хәер, ул караш хаксыз да түгелдер,

табиблар, галимнәр бөтен дөньядан бу илгә агыла, алар берни дә белми булмас. Шулай итеп, «сәламәтлек—ябыклык» өчен көрәшү чиргә әйләнгән монда. Болай ук кылану бер мания шикеллерәк ул. Мания—начар авыру.



Булдымы көчле илнең бер көчсезлеге! Безнең мескен фәкыйрь илдә халык «ашарга акча җитми» дип зарлана, ә монда, мөгаен: «Ичмаса ашарга булмасын иде бер-ике атна!»—дип уйлаучылар да бардыр! Күпчелек халык иртәнге сәгать дүрт-биштән торып эшкә чаба, кичке җиделәргә кадәр җүнләп ашамыйлар: берәр сэндвич, бер-ике банан белән көн үткәрәләр. Тик шунысы бар, организмны күпме алдаласаң да, бер килеп үзенекен итә бит ул: «көчле» булып йөриләр-йөриләр дә бер мәлне тотыналар ашарга! Ресторандагы порцияләрен күрсәгез, шаккатарсыз—андый зур тәлинкәләрне беренче тапкыр монда күрдем мин. Алдыңа китереп куйгач, ашыйсың шул—төмле бит, җитмәсә, акчасын барыбер түлисе. Әлбәттә, кайда да кешене төмле ашатырга тырышалар, әлбәттә, бу симертә. Һәм, әлбәттә, моны һәркем белә. Белә-белә бөлəсең—баш тартырга көч җитми. Индеецларның күпчелеген эчертеп юкка чыгарганнар, дип ишеткәнем бар, әллә шуңа үч итеп, тарих бу ил халкын ашау белән юкка чыгарырга дигән максат куйганмы?! Җитмәсә, физик эш, табигый хәрәкәтләнү—теләсәң-теләмәсәң дә анда чабу, монда чабу—юк дәрәҗәсендә. Машинада гына йөриләр бит. Тагын бер мәсьәлә. Безнең ил белән Америка арасындагы дошманлык мөнәсәбәте үзгәргәнне монда да бөтен халык белә. Сәясәт белән кызыксынучы катлам бик калын түгел түгелен. Барысы да бик шат. Без дә дошманлык ягында түгел анысы. Тик әллә ничек килеп чыкты бит әле: дошманлык дуслыкка алышынган иде, болар көчәйде, без көчсезләндек... Тьфу-тьфу, әйттем исә кайттым, болар әйткәндәй, «политикали коррект» («сәяси яктан дөрес») булмады бу. Дуслыкка ни җитә! Бай ил белән тауар алмашсаң да, күпме файда!

Бу илдә чит ил тауарларын табу бик кыен. Сәбәбе билгеле—үз әйберләрен сатарга тырышалар. Бездән килгән бер әйбер күрмәдем әле. «Бездә ни бар соң?!»—дигән булырсыз инде. Шулай үзебезне-үзебез юкка чыгарырга и яратабыз! Уйлап карарга кирәк—әллә бардыр берәр нәрсә. Мәсәлән... кар күп була бездә. Монда, Алясканы санамаганда, бик аз. «Аларга кар кирәкме икән соң?»—дисәгез, «Юк, кирәкми»,—сезгә шулай гына җавап бирерләр. Кар җибәрергә кирәк боларга, кирәк ул монда, алар аны белми генә.

Кардан котлары оча. Кыш туса, көн саен: «Иртәгә мәктәп эшлиме икән—юк микән?»—дип баш ватасың, һава торышын сугыш хәбәрләрен тыңлагандай, тын алмый тыңлап торасың. Аны телевизордан да әйтәләр, шылтыратып сорарга аерым номеры да бар. Күп вакытта кичке хәбәр иртәнгә ярамый, иртәнге сәгать алтыдан мәктәпләр ата-аналарга шылтырата башлый: «Бүген мәктәп эшләми, иртәгә иртән шылтыратмасам, эшли дигән сүз». Ул көнне кар йә ява, йә юк, тик аның яву ихтималы ук «өйдән чыкмаска» дигән сигнал. Чыксаң, кайтып керә алмавың бар. Чынлабрак явып җибәрсә, машиналар гына түгел, поездлар да туктый.

## Монысы да көчле илнең көчсез яклары...

КҮПЛӘРНЕҢ «кар страховкасы» бар: өйләреннән олы юлга чыга торган «драев уэй» дигән кечкенә-тар юлларны чистартып-көрәп торучылар белән килешеп, страховка түлиләр. Ул бизнес әллә нәрсә түгел үзе: кар чистартучы машина да, шуны йөртүче һәм берәр ярдәмче. Алар, әлбәттә: «Кар яумасын иде!»—дип телиләр, чөнки кар яумаса, эш булмый, ә акча барыбер бара—страховка бит ул. Бер танышым төп эшеннән тыш 18 мең доллар эшләгән былтыр кыш, аның шундый бизнесы бар. Кар яуса, эшеннән берничә көнгә сорап китә. Авырсаң, эшкә килмәс өчен, «сик дәй» дип атала торган буш көннәр дә була. Бездәгечә, «больничный» түләмиләр, әлбәттә. Кар күп елны бар туплаган акчаң да чыгып китәргә мөмкин: страховка булгач, страховка—ул карны чистартырга тиешсең. Өстәмә машина, өстәмә кеше ялларга кирәк була. Әмма андый еллар еш булмый. Мин дүрт кыш чыктым инде, кар диярлек кар күрмәдем әле. Мин киләсе елны булган карны һаман да һушлары китеп сөйлиләр: бөтен тормыш туктаган—өеннән чыга алмагач, беркем эшкә бара алмый. Шулкадәр бай ил ничек бер чарасын тапмый икән шуның? Шулкадәр көчле кешеләр кардан куркып, мич башында утырсын инде! Филнең дә көчсез ягы бар шул—тычканнан курка...

Нишләп дуслашкан илгә шундый дәһшәтне җибәрергә теләп утырам соң әле? Аларга файда булсын өчен, валлаһи! Башта бушка бирергә кирәк ул карны, файдасын сизгәч, үзләре үк акчаларын сузып килерләр. Нинди файдамы? Ә менә мондый. Беренчедән, карга өйрәнәләр, чистарту чараларын табалар. Башка төшеп, Ходай Тәгалә шундый урында яшәткәч, без табабыз бит. Икенчедән, көч-куәтләре тагын да арта. Үзләре үк әйтәләр ич: «Сине үтермәгән әйбер сине көчлерәк кенә ясый»,—диләр. Ә берәүнең дә үләсе килми, ничек тә тырпылдарга тырыша. Димәк, кулыңа көрәк тотасың да хәлдән тайганчы кар көрисең. Яки көрт ерып, чакрым артыннан чакрым, миль артыннан миль, олы юлга тәпи-тәпи атлыйсың. Бу, әлбәттә, «сәламәтлек—ябыклык» дигән сүз! Тагын бер бик файдалы ягы бар: кар күп булып, халык эшкә бара алмаса, кибетләр дә эшләми. Димәк, ашарга кытлык булу мөмкинлеге туа. Ниһаять, шундый мөмкинлек! Кыш озын түгел монда. Берничә тапкыр берәр атна ач торуның файдадан башка бер зыяны да юк. Һә-әй! Язга чыккач, бөтен халык зифа-сылу гәүдәләрен күрсәтергә пляжга чабар иде бугай! Бер генә җавапсыз соравым бар: ничегрәк итеп җибәрергә ул карны? Тырышып карасам, анысының да чарасын табар идем дә, күпкә китәр. Бер тиенсезгә баш ватып утырам бит, ике илнең берсе дә акча түләми миңа. Ә монда бушлай кыл да кыймылдатмыйлар.

## Кристмастан соң

АМЕРИКА ХАЛКЫ өчен һава белән су шикелле гадәти һәм, үзләре әйткәндәй, «крейзи (котырган)» бер бәйрәм бар—«Кристмас» дип атала. Ул декабрьның егерме бишендә була. Бәйрәмгә әзерлек әллә күпмегә алданрак башлана. Зур бизнес чоры: аңа багышланган рекламалар, телетапшырулар... Кибет, ресторан, төнге клуб шикелле урыннарны «крейзи»лаштырып җиһазлау, өйләрне эчтән һәм тыштан шул бәйрәмгә яраштырып бизәү... Мөмкин булган бөтен нәрсә төсле лампочкалар белән уралган булыр—бар җир ялт-йолт итеп тора. Юкса күп урыннарда төнлә яктылыкны шул чорда гына күреп каласың, бер дә юкка электр кабызып куймыйлар монда. Безнең кебек хәерче генә ул... көндез чыра яндыра.

«Кристмас шопиң» шулай ук алдан башлана. Монысы инде иң

мөһиме—шул бәйрәм өчен бүләк алырга кибетләргә бару. Ул вакытларда кичен зур юлларда тантаналы ыгы-зыгы, машиналар тезелеп торыр—бар халык «кристмас шопиң»га, ягъни кибетләргә агыла. Бу бәйрәмне «котырган» дип атау шушы бүләкләр алу мәшәкатен аңлата: бөтен таныш-белешкә бүләк бирелергә, ул бүләкләр киеп йөрерлек яки ашап кына куя торган гадәти нәрсә булмаска тиеш: үзе бер эшкә ярамасын, үзе кызыклы булсын! Монысы туклыктан сикеренүдән бар булгандыр инде. Һәр бүләкне тартмаларга салып, кристмас өчен тәгаенләнгән махсус матур кәгазьләргә төреп, як-ягыннан ябыштырып, аллы-гөлле тасмалар белән урап, кристмаска багышланган открыткалар куеп, нәкъ 25 декабрьдә бүләк бирелергә тиешле кешеләрне эзләп табып, бүләкләрне исән-сау килеш тапшыру җилкәдән зур йөк төшерүгә тиң. Һәм, әйтергә кирәк, кристмасның төп эчтәлеге дә шуңа кайтып кала, ул христианнарның рождество (раштуа) бәйрәменә туры килсә дә, кристмасның дини мәгънәсе юк.

Шулай да, аны бәйрәм итәргә минем бер дә күңелем дә тартмый, мәшәкатеннән дә башым әйләнә. Тик берни эшләп булмый, кеше миңа бүләк биргәч, каршы бүләк бирергә тиешмен, «Мери кристмас» («Бәхетле кристмас») теләгәч, мин дә шул ук сүзләрне кабатлап, авызымны ерырга тиешмен.

Яһүдиләр Америкада иң зур бөтенхалык бәйрәме булган кристмасны бар дип тә белми. Аларның 22 декабрьдә «Ханәкәһ» дип аталган үз бәйрәмнәре була. Тик ул «холи» («изге») дип бөтен Америка тарафыннан танылмаган һәм ял көне дә түгел, яһүдиләрнең моңа бераз эче поша. Ләкин яһүдиләргә кристмас бүләге бирергә ярамаганын һәркем белә.

Бер бәла генә миңа бу кристмас бәйрәме: башта кешегә бүләк бирер җаның чыга, аннан кеше биргән бүләкне нишләтергә белми тинтерисең. Менә бу кристмаста авыр гына, зур гына бер төргәк бирделәр, өстенә «Сак бул! Ватыла торган әйбер!» дип язылган. Шатыр-шотыр куптара торгач, көчкә барып җиттем моңа, аллы-гөлле бизәкләр төшерелгән пыяла шар булып чыкты бу. Бер ягында кечкенә генә келтемпие бар. Тишекле, димәк, шул тишегеннән бау кертеп берәр җиргә элеп куярга исәпләнгән. Тишегенә матур гына тар тасма тыгып куйдым да киттем бүлмәләр буйлап—элеп куярга кулай җир эзләп. Һич урын табып булмый, пыяла бит ул, төшеп ватылса, киләсе кристмаска кадәр пыяла чүпләрсең. Берәрсенең өстенә төшә калса? Моның бер хикмәте бардыр, мин әйтәм, Америка тормышын белмәвем галәмәте генәдер, кая, хуҗасыннан сорыйм әле. Бәлки, бик тирән мәгънәле әйбер булып, бик изге урында гына сакланырга тиештер бу, йә бик кыйммәтле-зиннәтледер дә кергән бер кешенең күзенә ташланырдай җиргә куярга кирәктер. Нишлим, сорадым: «Бүләгең шулкадәр матур, шундый ошый, нишләтергә дә белмим»,—дидем. Аптырап калды теге, соң инде бүләкләрдән котылдым дип кенә торганда, «нишләтергә?» дип килсеннәр әле! Җитмәсә, ул да белми икән... «Элеп куй берәр җиреңә»,—диде, бик елмаймый гына. Диварга эләргә җөрьәт итмәдем, диварлар катырга кебек кенә, авырлыкка чыдый торган түгел, тәрәзә пәрдәләрен дә Аллага тапшырып, өф итеп кенә тотам. Түшәмгә эләсең, тагын... Карале! Америка бит бу! Әгәр түшәмгә эләсең, бу башыңа килеп төшсә лып итеп һәм ару гына гарипләндерсә... судка биреп булмас микән теге «дус» кешене?! Монда бөтен кеше шулай итә! Әнә Макдоналдс кафесында бер хатын үз өстенә кайнар кофе түккән дә судка биргән тегеләрне (әллә ничә миллионга, оныттым инде) һәм бер миллион откан! Ни өчен дигәндә, диварга да «Әй, аңгыра баш! Өстеңә кайнар кофе түкмә!» дип язылмаган булган, ул каян белсен түгәргә ярамаганын! Юк, юрист белән сөйләшергә кирәк, башыңны ярырсың, законын табалмассың, башта законын табып, аннан баш ярырга кирәктер. Алай дисәң... «Андый закон юк» дигән җавабы өчен дә 150-200 долларны түләргә кирәк бит әле ул юристка. Ярый, законы булсын да, ди, ничегрәк итеп эләсең, дөресрәк итеп төшәр икән соң бу? Баш

яру дигәч тә, аның бит әле чамасы бар. Бөтенләй үтереп ташласа, йә ни үлмәслек, ни тормаслык итсә?.. Аны минә шундый итеп көйләргә кирәк иде, судлар узып, теге «дус»тан 50-60 меңне каерып алганчы гарип булып торсаң иде дә, 25-30 мең долларны шыпылдатып банкка салып куйгач кына ялт итеп рәтләнеп китсәң иде! Ни өчен 25-30 гына, диярсез, 50-60 дип авыз ачкан идем бит; юк шул—ачкан авызың ачык килеш калырлык: отышның яртысын адвокат каертып ала! Акыртып талыйлар! Юк инде ул гаделлек...

Бәй, бу хикмәтле шар белән хыялый була башладым бит әле. Әйтик, юристка 200 долларны җәлләми, кирәкле закон барын белдем, ди. Шуннан дәлил шикелле нәрсә дә кирәк бит әле. Тегенең «Элеп куй» дигәнен ничек исбатларсың? Их, телефоннан гына сорап, телефакска язып аласы калган! Җүнсез, мин дә Америкада торам, имеш! Ничә тапкыр кар күрәдем инде, бер кешене судка биргәнем юк. Ни өчен кар күрим? Ул бит үзе дә шундук эреп бетә мондагы җылыда. Тик законы бар шул—берәрсе синең йортың яныннан узганда таеп егылса, сине тота да судка бирә: карыңны күрәмичә, юри кешене еккансың!

Фу! Бу кристмасны юкка гына «котырган» димиләр икән, чистый шаштырды бу. Ярый әле, бәйрәме белән шашынулары да үтеп китте, подвалга төшереп, бер тартмага тыктым да оныттым, котылдым теге бүләктән.

Бу кристмастан соң икенчесе килде. Исемә төште дә шытырдавык кәгазьләргә төреп бирәүгә бирдем бүләк шарны. Икенче көнне шылтырата: «Шулкадәр зур бүләк биргәнсең, нишләтергә дә белмим!»—ди. «Элеп куй бирәр җиреңә»,—дидем... Бәй, минә хәзер башымны ярырдай булып әллә нинди шикләр газаплый! Былтыргы тартма исемә төште: аның өстенә «Сак бул! Ватыла торган әйбер!» дип язылган иде бит. Минә американнарның акылы юк, диген син! Алай-болай булса, җавап бирмәс өчен язылган ич ул! Мөгаен, ул язуның копиясен дә алып калгандыр әле «дус» кеше. Американнар һәр кәгазьнең копиясен саклый алар, ничек җенләнеп чыкмыйлардыр. Мин, тиле, «ватыла торган әйбер» дип телдән әйтергә дә онытмым. Минә хәзер бу «дус» түшәмгә элеп куеп, башын ярса?.. Судка бирә бит бу мине!

Баш тулы уй да уй, тормышка ашырырга җүн җитми. Буш хыял да кысыр хәсрәт! Бу башны бәреп ярсаң да, бер гөнаһысы юк, валлаһи! Әнә яһүдиләр: «Безнең Ханәкәһ бар»,—дигәннәр дә бетте-китте, кристмас дип мыек та чуалтмыйлар, ә мин ми чуалтам. Минем «Ханәкәһ» юк шул, татарлык кына бар—океан артыннан ук ияреп килгән кара сакал...

## Химия

АМЕРИКА—дуслык иле шул. Баштагы мәлләрне үк мин американнар телендәге «май френд»нең артык еш кабатлануына игътибар иткән идем: «минем дус» дигән сүз икәнен күпләр белә булыр: Америка фильмнарын карап та, «маный, доллар» һәм «май френд»не безнекеләр аңлый. Монда акча һәм дус-иш иң мөһим нәрсәләр икән. Хәер, аны гына белмәскә без дә күктән төшмәгән. «Йөз сум акчаң булганчы, йөз дустың булсын», дибез. Тик безнең халык, тыйнаграк булганлыктанмы: «Дуслар күбрәк булса, акча бик күп булмаса да ярар әйдә»,—дибрәк фикер йөрткән, ахры... Боларда тыйнаклык чире юк: икесе дә кирәк, акчасы да, дус-ише дә мөмкин кадәр күбрәк булсын! Һәм җәмгыятьнең аңы да шул юнәлештә: бик бай булып та, дус-ише юк икән, ул кешенең дәрәҗәсе үзеннән-үзе чүгә төшә. Шулай итеп, бераз вакытлардан соң гына аңладым аларның исемен дә юньле-башлы белмәгән таныш-белешен дә «май френд» дип мактануларының сәбәбен—үз дәрәҗәңне үзең күтәрмәсәң, чүккән килеш тик торырсың! Һәм «френдли»—дустанә мөгамәлә шулай ук бик зур нәрсәләрдән санала. Җитди генә эшләрдә дә коллективта ямьсез атмосфера тудыра торган, «френдли» булмаган

кешеләрдән котылырга тырышалар. Гәрчә ул кеше үз эшен җиренә җиткереп үти торган булса да. Бик әһәмиятле нәрсә—«толеранс» өзелеп сөйгәнне белдермәсә дә, безнең «кеше сөймәү» дигән сүзнең киресе.

Табигать белән химия да бик «толерант» кына итеп, сыешып яшиләр биредә. Бөтен җир ямь-яшел чирәмлек. Моңа бик зур игътибар бирелә. Улымның мәктәбеннән алып кайткан бер өй эшендә «Чирәм бетсә, ни булыр иде?» дигән сорау да бар иде әле. Тагын ниләр булыр иде, бер дә белмим, безнең авыллардагы кебек, тездән пычрак булачагы көн кебек ачык. Монда да адым атлаган саен асфальт түгел, күп урыннарда тротуар да юк әле, машина юллары гына. Европа илләрендә Американың чирәмен санга сукмыйлар дип ишеткәнем бар, үзләренеке шәбрәк, имеш. Ә мин инде бездәге мескен кадерсез чирәм белән генә чагыштыра алам. Бәби караган шикелле карыйлар чирәмнәрен. Акчага исәпләгәндә кайсысы кыйммәткәрәк төшәдер әле—чирәмме, асфальтмы? Һәрхәлдә асфальт белән шулай азапланганнарын күргәнем юк, бер җәелгән—тора шунда. Бездә кайчан карама асфальт җәяләр иде—бәлки, чирәм җитешмәү асфальтка да зыян китерәдер. Тирә-ягында чирәм үсмәгән йорт күрмәдем әле. Һәм бу үзе бер зур бизнес: үлән орлыкларыннан башлап, үлән чаба торган машиналарга кадәр—андый машина һәркемдә бар. Ике-өч атна саен үләнне чабып торалар, фәлән сантиметр биегрәк үлән өчен штраф түләтәләр, чөнки биек үлән талпан шикелле зарарлы бөҗәкләр таралуга сәбәп була икән. Чирәм бизнесының зур бер өлеше, әлбәттә—химия: үлән матур, куе булып үссен өчен, чәчкән орлыклар чыксын өчен, чүп үләннәренә, зарарлы бөҗәкләргә каршы көрәш өчен... Сибепме сибәләр химикатларны! Салынасы химикаты салынган туфраклар да сатыла: чүлмәктәге чәчәкләр өчен, фәлән үсемлек өчен, төгән үсемлек өчен, куак төпләренә матурлап сибеп куяр өчен.

Безнең халык агу шикеллерәк кабул итә торган химик даруларга да шундый ук караш: ярдәм итә, димәк, яхшы. Йокы даруы йоклый алмаудан яхшы—йоклата; ябыктыра торган дару симезлектән яхшырак; антидепрессантлар депрессиядән коткара, димәк, аларны эчү эчмәүдән яхшырак. Инде зыяннары бар икән, анысын галимнәр тикшерергә тиеш, теләсә кем барыбер белә алмый аны. Авыруың сорый икән—гомер буе эчәргә тиешсең даруларыңны, бу начар түгел, бу яхшы—хәлне җиңеләйтә. Шунысы гына бар: кеше белән сөйләшкәндә, үз хәлеңне бик тәфсилләп торма: «Эчем поша, башымда уем күп, тынгысызмын»,—дип зарланып алырга теләсәң, сине ялгыш аңлаячаклар: «Ниндидер кемикалларың дөрес түгел»,—диярләр. Димәк, чирлисең. Чирлеләрне кем ярата?! Лутчы көл дә көл—кемикаллары гөрләп тора икән, дисеннәр.

Күп кенә ата-аналар мәктәпкә балалар өчен даруларын китереп куя, укытучылары кирәкле вакытта балага бирә. «Ясалма, химия» дип, без витамин эчәргә шикләнеп тора торган идек, монда витаминсыз көн үткәргән кеше бар микән? Гәрчә табигый витаминлы азыкны—яшелчә-җимешне бездән күп ашыйлар үзләре. Даруханәләрдә «нутришиност» дип аталган белгечләр белән сөйләшергә була: алар дару бирми, витаминнар, «саплемент» («өстәмә») дип аталган матдәләр буенча киңәш бирә, ул «саплемент»лары да химиягә кайтып кала, тик ни өчендер даруга керми.

Мин үзем, «бер файдасы, биш зыяны» дип, кешегә бу рәвешчә ярдәм итүне кире кагарга ашыкмас идем. Ходай ярдәм итми икән, үзеңә-үзең ярдәм итә аласың икән—нигә шулай эшләмәскә! Гомер барыбер кыска, чирләп интегеп яшәгәнче, яшәүнең рәхәтен күрсәң, хәерлерәк түгелмени? «Үзеңне начар сизәр өчен—тормыш артык яхшы»,—диләр болар, кайчакта кеше сүзен тыңласаң да ярый.

Күпме тырышсам да, аңламаган һәм аңлауга якын булганда да кабул итеп бетерә алмаган тагын бер нәрсә бар әле химия өлкәсендә. «Кемистери» диләр американнар. Сораштырып та караганым бар, җүнле җавап ала алганым юк. Атлаган саен «кемистери» дигән булалар

үзләре. Бу сүзнең мәгънәсе бер генә түгел, мин үзем белмәгән һәм беләсем килгәнен генә алам: «Ир заты белән хатын затының бер-берсенә туры килүе кемистериңнең туры килүенә бәйле»,—дигән бәхәссез фикер яши монда. Һәм бөтен нәрсәне шушы хәл итә. Холыклар туры килү, аң-белем дәрәҗәсе туры килү һәм, ниһаять, мәхәббәт—алар барысы да юк нәрсә икән, тик кемистериләр генә ярашлы булсын. Әллә башка «туры килү»ләр барысы да шул кемистери эченә керә микән? «Мәхәббәт» дигән сүздән бер дә баш тартасы килми бит әле, нәрсә икәнен белүче булмаса да... Кемистери барыбер кемистери генә инде ул!

## Үзеңә үзең ярдәм ит

МОНДАГЫ тормышның булмышыннан гына түгел, сулышыннан ук бөркеп торган иң көчле идея: «Һелп юрселф»—«үзеңә үзең ярдәм ит». Рәхәт тә бу, кыен да—ирек, мөстәкыйльлек һәм—ялгызлык... Дөресен әйтим, америкаaннарның хәтере калмасын дип һәм гадел булырга тырышып кына «рәхәт» дигән булам, минем үземә бер бөртек тә ошамый ул фикер. Бәйсезлекнең иң яраткан сөяркәсе шул! Һәрбер сөяркәнеке шикелле, сөйкемле сөяге бардыр инде—сөяләр бит шуны, шуның белән яшиләр. Миңа калса, Чокыр башындагы кебек чөкердәшеп яшәүгә ни җитә!

Бер мәлне бик еракка туйга барып, әллә ничә көн ач торып кайткан иде безнең әнкәй. «Адәм көлкесе!—ди.—Туйдан ач кайт инде, өстәл тулы сый булсын үзе...» «Бәй, өстәлдә ни бар, шуны ал да аша идең, нигә ач тордың?»—дибез. «Өстәлдә ни бар, шуны алып ашарга ач тамагымнан барганмыни мин анда?!»—ди әнкәй. Хәтәр алар безнең Чокыр башлары, ашарлар сиңа өстәлдә ни бар, шуны! Эчсеннәр өчен җырлап, ашасыннар өчен сайрап торырга кирәк. Кыстамаганнар безнең әнкәйне, бер кулларына чәркә, икенче кулларына каз боты тотып тыпырдап тормаганнар: «Шулай да булмагач, кодагый булып туйга да бармыйм мин, кыз да үстереп тормыйм, дөнҗада яшәп тә тормыйм!»—ди. Көчле бит, ә? Безнекеләр тагын бик үткәреп кенә әйтеп тә куйган: «Яратмасаң—ярыгың!» Ә монда, алай-болай сырланып-зарланып азаплана башласаң: «Уалкем ту Эмерика!» «Америкага рәхим ит!»—диләр.

Әйе, ул сиңа килмәгән бит, син аңа килгәнсең, караштырып, чамалаштырып тор да кеше кыланганны кылан. Әлеге Чокыр башы бер апа Мәскәүгә килгән иде. «Курыкма, курыкма, адашмыйм, миңа зуррак магазиннар кирәк. Метрога төшәм дә халык күбрәк кая акса, шунда агам»,—диде. Америкага килеп, кай яккарак агарга икәнен чамалый алмасагыз, иң башта: «Үзеңә үзең ярдәм ит»,—дигән киңәшне искә төшерегез.

Әйтик, ашыйсыгыз килде, ди. Минем әнкәйнең туйга барганын онытмагыз: көтеп утырсагыз, ач каласыгыз көн кебек ачык. Як-якка караныгыз да эзләнегез. Әһә, суыткыч бар, гөрләп эшләп тора, автобус кадәр! Ачыгыз да ни телисез шуны алып ашагыз, пешереп ашасагыз да ярый. Хуҗаларның пешереп биргәнен көтеп утырсагыз, бер-ике көннән алар сездән гарык була. «Балык белән кунактан өч көннән соң ис килә башлый» дигән испан мәкале бар, бездә дә «Кунак өч көнлек» диләр. Монда кадерегезне озаграк сакларга теләсәгез, үзегезнең дөньяда барлыгыгызны мөмкин кадәр азрак күрсәтергә тырышыгыз, димәк, ни кирәген үзегез эшләгез. Ашарга пешереп ашатканнарын, урын җәеп яткырганнарын, душны-фәләнне әзерләп биргәннәрен көтеп, үзегез тотынырга кыенсынып утырсагыз, алар сезне һич кенә дә «тыйнак кунак» дип бәяләмәс, «ялкау, кешене файдаланырга тели» дияр. Һәм сорауны да күп бирергә ярамый, бу «бадериң» дип атала—«тынычсызлау, бимазалау»—начар нәрсә инде ул. Шкафларын ачып кара, тегесен кабызып, монысын сүндереп кара, үзең эзләп тап. Монысы да бик җиңелдән түгел. Бер танышларым шулай мөстәкыйль булырга, хуҗаларны

бимазаламаска теләп, плитә кабызырга көн буе шырпы эзләгәннәр. Ә плитә шырпысыз кабына монда, борып кына куясы, күп өйләрдә шырпы юк та, бездәге шикелле бер уч шырпы салынган шырпы капларын күргәнем дә юк әле.

Шулай, шырпылардан ук башлап—«һелп юрселф». Америка халкы шуның белән туган. Кая барсалар да, үз җайларын үзләре карый, «берәрсе беләдер әле» дип, кешегә салынырга тормый. Стенадагы язуларны укый, карталарны өйрәнә, төрле белешмәләр бирелгән брошюраларны җыя. Мәгълүмат, бигрәк тә дөрес мәгълүмат, бигрәк тә файдалы мәгълүмат алу шулай ук бик җиңел түгел. «Информейшен» дип язылган урыннарда утыручылар да кайвакыт хаталы юлга гына кертеп җибәрә: күп белер өчен бик белемле булырга кирәк, бик белемле кешеләр анда утырмый, американнар моны аңлаганга күрә, үзләренә үзләре ярдәм итүне артыграк саный. Аннан соң, бу—дәрәҗә билгесе дә: кешедән сорап торасың икән, бәйсез түгелсең дигән сүз, «бәйсез түгеллек»—хурлык. Шунлыктан, кешегә ярдәм итәсең килгәндә дә, башта уйлап кара: мохтаҗмы ул синең ярдәмеңә? Егылып яткан кешегә дә кул бирергә ашыкма: егылу ул болай да уңайсызлыкка куя торган нәрсә, ә кызганып кул бирүчеләр үзләренең сиңнән өстенлеген күрсәткән кебек була—алар егылмаган ич, син егылган! Бөтенләй торалмаслык хәлдә булмаса, андый кешене күрмәмешкә салышып үтеп китүдән яхшысы юк. Шул вакытта ул кеше үзен «комфортабл»рак сизәчәк: үзем егылдым, үзем тордым, беркем күрмәде, берни булмады.

Акыл белән аңлап булса да, күңел төрлесен уйлый, дигәндәй... Америкадан икенче кайтуым иде бугай, Шереметьево аэропортында чемоданнар әйләнеп йөри торган нәрсәдән олы һәм авыр чемоданымны сөйри башладым, һич көчем җитми, теге нәрсә һаман әйләнә бит, сине көтеп тормый! Шулай азапланганда, бер адәмгә бәрелдем, ул үзенең чемоданын алырга сузылган—ни үземнекен ала алмыйм, ни тегеңәргә комачаулыйм. «Извините»,—дигән булам инде. Америкадан арып-талып кайтучы урыслар бик ачулы—аты-юлы белән сүгенде бу: «На х.... нагрузилась, если поднять не можешь!» Мине читкә төртеп җибәрде дә башта минем чемоданны алып куйды, аннан—үзенекен. «Дальше сама можешь или помочь?»—дип акырды. «Юк, юк, тәгәрмәчле чемодан ул»,—дип тиз генә шылдым. Арттан берәү дустанә тавыш белән эндәште: «Ту бик, ха?»—«Артык зур, ә?» Теге урысның җикергәненнән тырт-тырт иткән йөрәгем рәхәтләнеп эреп китте... «Җылы сүз—җан азыгы»—туры мәгънәсендә шул. Тик ягымлы американга әйләнеп караган идем, сискәнеп куйдым: мин чемодан белән азапланганда, ул минем икенче ягымда басып елмаеп карап тора иде. Шулай итеп, ямьсез сүгенүче урыс миңа ярдәм иткән, ә сөйкемле американ матур итеп елмаеп карап торган! Ходайның каһәре төшеп, мәңге төзәлмәслек булып ватылгыры авыр чемоданымны кечкенә арбага күчереп куясы бар иде әле. Көчәнәм-көчәнәм, булдыра алмыйм, кинәт җип-җиңел булып китте, шып итеп арбага сикереп менде чемоданым. Карасам, бер яшүсмер малай елмаеп тора, ул булышкан икән. Юньләп рәхмәт әйтеп тә өлгермәдем, китеп тә барды аксый-аксый, бер аягы гарип яшүсмер малай... Күземнән яшь чыкканын сизми дә калдым—биш минутта таныттты үзен туган ил: «х...»лары-ниләре белән!

Чокыр башыннан чыккан акылга сыеп бетә торган түгел шул бәйсезлекнең хикмәтләре! Миңа калса, Чокыр башындагыча яхшырак: ни барын уртаклаш та үзең дә куан, кешене дә куандыр. Болар инде бигрәк—шулкадәр кыланам дигәч тә!—безнең авыллар әйтмешли...

Уртаклашуга килгәндә, күп очракта алуга караганда бирүне артыграк күрә американнар. Тик ул «бирү»нең чикләре шактый тар. «Ач кешегә балык бирмә, син аны балык тотарга өйрәт» дигән әйтем бар. Ә боларның «уртаклашуы» гадәттә әлеге «балык бирү»гә кайтып кала... Өйрәтteләр, ди, сине балык тотарга, акылың алтын икән! Балыкчылар күбәйгәнче, хәерчеләр күбәйсен. «Абзыкаем!»—дип кулларын сузып килсеннәр.

Бер сөер генә нәрсә ишеткән идем: политикали коррект» («политик яктан дөрес» ) булмаса да, сезнең белән уртаклашыйм әле шул серне. Болай бу: беркайда да эшләмәгән ярлы кешеләр хөкүмәттән «уэлфеер» дигән ярдәм алып торалар. Аларның күбесе «каралар» диләр. «Каралар» арасында байлар күбәйгәннән-күбәя, җәмгыятьнең калган өлеше моны хуп күрми икән... Шуңа күрә ялкауларга ялкау булуларын дәвам итәргә мөмкинлек тудыралар икән. «Ашагыз да йоклагыз, ашагыз да йоклагыз, тик уянмагыз гына, баемагыз гына, балык тота башлый күрмәгез!» «Бирү» менә шулай да була имди... Кашыгы белән каптырып, сабы белән төртүгә кайтып кала шул—ике рәхәт бергә булмый. Күңелсезрәк булып китте, үз генә сүз уйнатып алыйк әле. «Буш, бушлай» дигән сүз—«фри» һәм, гаҗәп ки, «азат, ирекле» дигән сүз дә—«фри». Әйтәсем килгәне: Америка сезгә бирер нәрсәне «фри» бирсә, сезнең «фри»егезне томалар өчен генә бирер. Халык телендә «фри»не су урынына эчәләр: «Бу—фри (ирекле) ил» диләр һәм «Бу илдә берни дә фри (бушлай) түгел» диләр. Теләсәгез ничек аңлагыз.

Ә мин үз тәҗрибәмнән бер мисал гына китерим. Кибеттә эшләгәндә, безнең бүлектә әзерләнә торган әйберләрнең рецепты бирелгән дәфтәр бар иде. Буш вакытта, кызыксынып шуны актардым да кайбер рецептларын язып алырга булдым. Бәлки, берәр заман әзерләп карармын, дип. Шунда бер-ике кеше шаяртып куйган иде: «Әһә, урлашасыңмы!» Шаяртулары чын булып чыкты: икенче карасам—юкка чыккан теге дәфтәр! Мин боларның рецептларын файдаланып, атаклы пешекче булып китәрмен дә табышларын авызларыннан тартып алырмын дип курыкканнар! Шаккаттым. Ә нәрсәсе бар моның шаккатарлык? Шушы дәфтәрдәге рецептларны кулланып гаиләләрен туйдырган кешеләр күпме акча түләп, күпме көч түгеп башта белем алганнар бит әле. Бу дәфтәргә барып җиткәнче күпме тәҗрибә туплаганнар, ә син агачын утыртмый гына җимешен җыярга килдеңме? Рәхим ит! «Уалкем ту Эмерика!»

❁

# Игътибар!

2001 елның икенче яртыеллыгы өчен вакытлы матбугатка язылу дәвам итә. Елның икенче яртысында да журнал укучыларыбыз сурәтләнгән вакыйгалары һәм язылышы белән гаҗәеп кызыклы әсәрләр укый алачаклар. Ел ахырына кадәр **Факил Сафинның** «Саташып аткан таң», **Суфиян Поварисовның** «Оҗмахка бер адым» романнары; **Зәки Зәйнуллинның** «Гарасатлы юллар», **Әдип Маликовның** «Тылсымлы хатлар», **Нәбирә Гыйматдинованың** «Аргы очта, бирге очта» повестьлары, **Илфак Шиһаповның** «Акка кара белән» исемле юмористик повесте; **Нурулла Гарифның** «Байлар ничек яши?», **Айдар Хәлимнең** «Бөркетле баганалар» хикәяләре; тарих фәннәре докторы **Индус Таһировның** «Җинү жинел бирелми» исемле публицистик язмалары «Казан утлары»нда дөнья күрәчәк. Шигырь сөючеләр журнал битләрендә **Гамил Афзал, Илдар Юзеев, Шәүкәт Галиев, Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләм, Равил Фәйзуллин, Лена Шагыйрьҗан, Роберт Әхмәтҗан, Газинур Морат, Рөстәм Кутуй һ. б.** яңа шигъри әсәрләрен укып куаначаклар.

***«Казан утлары»ның индексы—73210, ярты елга язылу бәясе—43 сум 20 тиен.***

# Әдəbi tənqit
# Әдәби тәнкыйть

Азат Әхмәдуллин

## ӘЛЕ НОКТА КУЙМЫЙБЫЗ...

«Мәгариф» нәшрияты узган ел (2000) профессор Фәрит Хатиповның «Әдәбият теориясе» исемле дәреслеген бастырып чыгарды. Ул югары уку йортлары, педагогия училищелары һәм колледжлар студентларына кулланма әсбап төсендә язылган. Озак еллар дәвамында Казан педагогика университетында әдәбият теориясен укытып килгән тәҗрибәле галим-педагогның бу эшкә алынуы һәрьяклап хуплауга лаек. Чөнки бездә фәннең бу җитди өлкәсе буенча китаплар нәшер ителгән булса да *(Г. Баттал—«Нәзарияте әдәбия», 1913; Г. Ибраһимов—«Әдәбият кануннары», 1916; Г. Сәгъди—«Әдәбият теориясе», 1941; «Әдәбият теориясенә кереш», 1987 һ. б.)*, алар бездә йә әдәбият белеме башлангыч адымнарын ясаганда гына, яки совет чоры кысаларында язылганлыклары белән үк кичәге көн казанышы булып торалар. Кыскасы, бу китап бездәге әдәбият теориясенең (нәзариятенең) үсү юлында бер баскыч дип карала ала.

Казан дәүләт университетында ике дистә ел буе әдәбият теориясен укыткан кеше буларак, мин бу хезмәтне гадел бәяләргә кирәк саныйм. Чөнки фән тәрәккыятендә бу китап соңгы нокта була алмый...

Матур әдәбият теориясе буенча русларда да яңача язылган дәреслекләр күренде. Иң беренче итеп В. Е. Хализевнең «Теория литературы» *(Мәскәү, «Высшая школа» нәшрияты, 1999)* китабын күрсәтергә кирәк. Теоретик яктан гаять катлаулы дәреслек ул. Әмма, безгә калса, фәлсәфи категорияләрне аңлату һәм бирү җәһәтеннән тирән эчтәлекле булган бу дәреслек, шулай да, матур әдәбиятның үз үзенчәлекләрен һәрьяклап, бербөтен төстә ачып бетерми. Кешелекнең «әдәбият гыйлеме» дигән гаҗәеп бу акыл эшчәнлеге, аның үзенчәлек-сыйфатлары, вазифасы һәм бурычларына ирешү юллары турында тулы һәм бербөтен мәгълүмат биреп җиткерми.

Бу яктан алганда мин профессор Ф. Хатипов дәреслегенең традицион рухта язылуын хуплыйм. Асылда марксистик тәгълиматка нигезләнгән теория китаплары (мәсәлән, Л. И. Тимофеев, Г. Н. Поспелов, Г. Л. Абрамович, Н. А. Гуляев, С. В. Тураев һ. б. хезмәтләре) аңар җирлек һәм үрнәк булып хезмәт иткән. Шуның белән бергә, аерым кагыйдә һәм күренешләрне аңлатуда автор соңгы өйрәтүләргә дә бөтенләй үк битараф түгел. Гомумән, дәреслек авторы бүгенге карашларга сизгер, күп кенә кагыйдә-билгеләмәләрне фәннең соңгы казанышлары югарылыгыннан торып формалаштыра. Әлбәттә, алар турында ул тәгаен бер урында, керештәме, йомгактамы (ә болары, кызганыч ки, китапта бөтенләй юк) ачык итеп әйтеп бирсә, тагын да яхшырак булган булыр иде...

Яңа дәреслекнең уңай һәм кайбер бәхәсле урыннарын махсус бүлекләрдә карыйк.

## Дәреслекнең күркәм яклары

Мондый нәзарият дәреслеге автордан аеруча игътибарлы булуны, бик конкрет фикер йөртүне, формулировкаларда, тәгъбир-кагыйдәләрдә, җөмлә төзелешләрендә төгәллекне сорый. Аз гына ачыклык җитмәсә дә теоретик белешмәдә буталчыклык, хәтта хаталар китә, ялгыш аңлау-аңлату барлыкка килә, мәгънә бозыла. Кыскасы, китап үз авторыннан аерата җаваплылык сорый, һәр тәгъбир-җөмләне һәм хәтта һәр сүзне уйлап-үлчәп куллануны таләп итә. Шулай ук мондый китаплар нигездә русча хезмәтләргә таянып язылганлыктан, андагы һәр мәгънә-төсмер, дөрес тәрҗемә итмәгәндә, татарча тәңгәл килерлек гыйбарәләр кулланмаганда, укучыны буташтырырга мөмкин.

Бу җәһәттән Ф. Хатипов дәреслеге асылда уңай тәэсир калдыра. Күпчелек җөмләләрнең ачык-аныклыгы, җыйнак булуы, катлаулы кагыйдә-билгеләмәләрнең дә саф татарча яңгыравы дәреслекнең уңай якларыннан берсен тәшкил итә. Автор иске сүзләрне, яки сирәк кулланылышта булган әйтемнәрне бик урынлы куллана белә. «Бию такмагын, фаразан, берничек тә уникешәр иҗекле шигырь рәвешендә күз алдына китереп булмый»,—дип яза ул *(51 бит)*. Яки: «Халык шивәсенә, көнкүреш сөйләменә якынлык, җанлылык бирү җәһәтеннән автор хикәяләвенең персонаж теленнән беркадәр кайтыш булуы, калышуы ихтимал» *(85 бит)* һ. б.

Хезмәтнең уңай якларыннан тагын да берсе—автор бик күп әсәрләргә мөрәҗәгать итә. Теоретик нигезләмәләрне раслау өчен ул урта гасырлар, классицизм, сентиментализм әсәрләрен дә ала. Тагын да мөһиме шунда, ул милли әдәбиятыбыздан мисалларны мул китерә. Бу җәһәттән бигрәк тә «Иҗат процессы» дип исемләнгән бүлекчәне аерып күрсәтергә кирәк. Татар язучылары әсәрләреннән алынган мисаллар гына түгел, язучыларыбыз үзләре әйткән-язган нәзари фикерләр дә иркен кулланылган. Монда Платон, Г. Филдинг, Н. Чернышевский һ. б. кебек дөньякүләм танылган галимнәр фикерләре белән янәшә Ш. Галиев, И. Гази, С. Хәким, Ә. Еники, Ф. Хөсни, Н. Юзиев, Р. Харис, Н. Фәттах, Г. Бәширов, М. Мәһдиев, З. Мәҗитов һ. б. кебек үз әдипләребез әйткән теоретик характердагы фикерләр-күзәтүләр белән дә очрашасың. Нәтиҗәдә дәреслекнең бу өлеше оригиналь дә, ышандыргыч та, җанлы да булып чыккан—ул авторның үз карашын ачык итеп раслап, аның мөстәкыйль фикерләү дәрәҗәсен күрсәтеп тора.

Нәзари кагыйдәләрне мисаллар ярдәмендә ныгыту вакытында Ф. Хатипов аерым әсәрләргә бәя-анализ да биреп уза. Аерым алганда, М. Гафуриның соңгы вакытларда кайберәүләр тарафыннан бәхәскә тартып кертелгән «Кара йөзләр» повестена бирелгән анализ-бәя үзенең объективлыгы һәм ышандыргыч булуы белән аерылып тора.

Хезмәтнең әйбәт язылган урыннарына мисалларны тагын да китерергә мөмкин. Мәсәлән, әдәби әсәр теленә хас фикерләрне һәм поэтик синтаксисны иркен бирү,—гәрчә беркадәр читкәрәк алып китсә дә,—кирәк, чөнки бу төшенчәләр сәнгати әсәр төзүдә (бигрәк тә шигырьдә) зур роль уйный. Гомумән, «Әдәби әсәр теле» бүлекчәсе тулаем уңай тәэсир калдыра, әсәр композициясенә караган бүлекчә турында да шуны ук әйтергә мөмкин. Анда матур әдәбият тармагы сәнгатьнең башка төрләре белән уңышлы рәвештә чагыштырып карала. Зур булмаган «Шигырь төзелеше» исемле бүлекчәдә исә без әдәби әсәрләрнең төзелеше ягыннан иң үзенчәлеклеләреннән берсе булган шигырьгә карата җыйнак, чагыштырмача кыска һәм конкрет бәяләмәләр белән очрашабыз, татар шигыренең үзенә генә хас яклары турында белеп калабыз.

Дәреслекнең үзенең композицион төзелешендә дә яңалык бар. Биредә автор әдәбият кануннарын өйрәнүне әдәби әсәрне өйрәнүдән башлый. Аннан соң гына әдәби хәрәкәт, матур әдәбиятның үзенчәлекләре кебек гомуми мәсьәләләргә күчә. Моңарчы язылган теория китапларында исә фикер гомумидән киленә, ягъни башта әдәбият нәзариятенең гомуми мәсьәләләре (образлылык, сәнгатьлелек, метод, кайбер очракларда әдәбиятның вазифасы үзенчәлекләре, андагы халыкчанлык һ. б. сыйфатлар) яктыртыла, аннары гына әдәби әсәр үзенчәлекләре һәм сыйфатлары карала иде. Ф. Хатипов бирედә образ, типиклык һ. б. кебек иҗатның гомуми мәсьәләләрен дә әсәр кысаларына кертеп, бу бүлекчәне алга чыгара.

Мәгънә ягыннан кечерәк белешмә-кагыйдәләрне бирүдә дәреслектә төзек, җыйнак урыннар аз түгел. Мәсәлән, авторның типиклык күренешен тарайтып аңлатуларны тәнкыйтьләве бик урынлы һәм ул безне ышандыра.

Бездә әдәби-нәзари терминология яхшы ук эшләнгән. Бу яктан сүз бара торган хезмәтне дә уңай яктан билгеләргә кирәк. Күп кенә терминнарның саф татарча яки электәге хезмәтләрдә кабул ителгән, кулланылган гарәп-фарсы сүзләре һәм гыйбарәләре белән бирелүне дә хупларга кирәк.

## Ачыклык кертү сорала...

Дәреслектә бүгенге фән югарылыгыннан торып караганда ачыкланып бетмәгән, хәтта бәхәсле урыннарның да булуын әйтергә кирәк. Аерым кагыйдәнигезләмәләр йә тулы ачылмый, яки берьяклы гына аңлатыла. Кызганыч ки, мисаллар аз түгел. Мәсәлән, китапның кереше төсендә тәкъдим ителгән «Әдәбият белеме» бүлеге тулы түгел. Иң әүвәл, аңа билгеләмә бирергә кирәк иде. Чөнки «сүз сәнгатен өйрәнүче фән әдәбият белеме дип атала» дип кенә әйтү, гәрчә асылда дөрес булса да, җитәрлек билгеләмә түгел, ул бик гомуми. Монда безгә «Краткая литературная энциклопедия» *(Мәскәү, 1967 ел, 4—том, 331 бит)* ярдәм итә ала. Анда бу фәннең төп үзенчәлекләре һәм вазифалары шактый тулы әйтелгән: «Әдәбият белеме—матур әдәбиятны, аның эчке мәгънәсен, килеп чыгышын һәм иҗтимагый бәйләнешләрен һәръяклап өйрәнүче фән; сүз ярдәмендә сәнгатьле фикер йөртүнең үзенчәлеге хакындагы, әдәби иҗатның генезисы, төзелеше һәм вазифалары, тарихи-әдәби процессның локаль (мәгълүм урынга һәм чорга туры килә торган) һәм гомуми закончалыклары хакындагы белемнәр җыелмасы».

Аннары китапта бу фәннең объекты һәм субъекты хакында да конкрет әйтү кирәк иде. Һәрбер фән тармагыныкы кебек үк, әдәбият белеменең дә үз субъекты (әдәбият галиме) һәм объекты бар. Соңгысына үрнәк әсәрләрдән (классикадан) тыш язучыларның матур әдәбият хакындагы фикерләре, тарихи-әдәби процесс (әдәбиятның мәгълүм тарихи шартларда барлыкка килүе, идеологик һәм әдәби агымнарның үзара көрәше һәм урыны һ. б.) һәм аның барлык вәкилләренең эшчәнлеге һәм иҗади хезмәтләре керә.

Әсәрләрдәге конфликт турында сүз барганда конкретлык җитми. Әйтик, аның асылда өч төрле булуы хакында ачык итеп әйтү сорала: 1) персонажлар арасындагы каршылык; 2) кеше һәм иҗтимагый тәртипләр, мохит, табигать көчләре арасындагы конфликт; 3) персонажның үз рухи дөньясындагы каршылык.

Ахыргача ачыкланып җитмәгән урыннар рәтенә тулаем алганда бик җентекле язылган композиция турындагы бүлекчә дә керә. Композициянең барлык компонентлары да (авторның аларны «берәмлекләр» дип атавы уңышлы) искә алып бетерелмәгән. Мәсәлән, әсәрне бүлекләргә (драмада—пәрдәләргә) бүлү, әсәрдә хикәяләү ысулы турында сүз юк. Аерым компонентларның урынын һәм күләмен арттырып җибәрмәү, ягъни һәр вакыйгага һәм персонажга әсәрдә нәкъ тиешле генә урынны бирү, хикәяләүдә күпсүзлелеккә юл куймау, сюжетның тиешле тизлектә үсешенә ирешү һәм артык эпизод-күренешләрнең булмавына омтылыш шулай ук әдипнең композиция төзү осталыгын күрсәтә. Композицияне җыйнак итү өчен язучы кабатлауларга юл куймый, тормышта урын алган кайбер күренешләрне җентекләп тасвирлаудан кача һ. б.

Китапта ялгыш аңлашылырга мөмкин булган урыннар да юк түгел. Мәсәлән, новелланы мәзәккә (юморга) якынайтып аңлату белән килешүе кыен *(183-184 бб.)*. Татар әдәбиятында хикәя жанрының XX гасырда гына формалашуы турындагы фикер дә сораулар тудыра (185 бит). Ә менә комедия турында сөйләгәндә автор юморны алга чыгара, ә комедиянең сатира үзенчәлекләренә җитәрлек игътибар итми. «Кызыклы хәлләрне, шаян характерларны сурәтләгән көлкеле сәхнә әсәрен комедия дип йөртәләр» *(231 бит)* дигән билгеләмәгә нәкъ менә характерларның тагын да сатирик, ачы көлүгә дучар ителгән булырга да мөмкин икәнлеген кистереп әйтү җитми.

## Бәхәсле урыннар һәм фикерләр

Алдагы бүлекләрдә күрсәтелгән искәрмә һәм сораулар китапның киләсе басмалары булган очракта шактый ансат төзәтерлек, кайбер каршылыклар алып ташланырлык. Ләкин дәреслектә принципиаль хәл итүне, анык бер фикергә килеп, барыбыз бер булып яклауны сорый торган нигезләмәләр дә юк түгел. Болары белән эш катлаулырак. Алар арасында дәреслек авторының ачыкланып җитмәгән үз карашларыннан килеп чыкканнары да, фәннең бүгенге казанышларына бәйләләре дә, үзгәртеп кору чоры буталчыклыкларына караганнары да бар. Әйе, уртак фикергә килү зарур...

Озак еллар буе әдәбият белемен дүрт тармакка бүлеп карау яшәде: әдәбият тарихы, әдәби тәнкыйть, әдәбиятның методологиясе һәм әдәбият теориясе. Соңгы вакытта аерым хезмәтләрдә әдәбият белемен өч тармакка гына бүлеп карау гадәткә керә бара: әдәбият тарихы, әдәби тәнкыйть һәм әдәбият теориясе.

Ф. Хатипов та бу хезмәтендә өч тармак һәм берничә ярдәмче дисциплина бар дип күрсәтә. Моны мин асылда хуплыйм. Шулай да фикерләшеп, ачыклап бетерәсе бер мәсьәлә бар. Ул методологиягә карый. Мөстәкыйль фән буларак әдәбият гыйлеменең методологиясе булмау мөмкин түгел. Аны кая куябыз? Әдәбият теориясенә генә кертер идең, аларның өйрәнү объектында нык аерма бар. Әдәбият методологиясенең төп бурычы—матур әдәбиятны, аның үзенчәлекләрен, аның үсеш закончалыкларын өйрәнүнең гомуми принципларын һәм ысулларын эшләп чыгару. Әдәбият теориясе исә конкретрак: матур әдәбиятның иҗтимагый тормышта уйнаган роле, үзенә генә хас үзенчәлекләре, художестволы иҗатның төрләре, әдәби әсәрнең төзелеше һәм иҗат процессының кануннары хакындагы тәгълимат. Нишләргә? Әдәбият методологиясен бөтенләй санга сукмаска, аның турында эндәшми генә узаргамы? Ләкин бит ул бар, ул мөһим, ул «әдәбият теориясе» дигән состав өлешнең дә гомуми принципларын эшләп чыгара һәм билгели.

Матур әдәбиятның төп вазифасы һәм үзенчәлеге—аның кешене өйрәнүче «фән» булуында. М. Горький аны турыдан-туры шулай атый да: кеше турындагы фән (человековедение). Ф. Хатипов та асылда аның шулай булуын таный, күп вакытта әдәбиятның һәм әдәби әсәрнең үзәгендә кеше торуын әйтә бара. Мәсәлән, композиция турында сүз йөрткәндә дә (39 бит), әдәби төрләр хакында аңлатканда да *(167-181 битләр)* шуны күрәбез. Ләкин бу ышанычына автор ахыргача тугрылык саклап бетерми. Күп очракта беренчелекне чынбарлыкка бирә, тормышны чагылдыру, тормышка охшатуны алга чыгарып, матур әдәбиятның төп вазифасын шунда күрә. Ә бит әдәбиятның предметы—тормыш, чынбарлык дигәндә дә аларның башлыча кеше язмышы һәм кеше психологиясе аркылы тасвирлануын истә тотарга кирәк. Дингә кире кайтуыбыз, ягъни материализмнан идеализмга борылу чорында һәрнәрсәне тормыш чынлыгы ноктасыннан гына карап бәяләү шулай ук дөрес булырмы, берьяклы булмасмы? Бу яктан караганда дәреслекнең «иҗат тибы», «иҗат методлары» бүлекчәләре шактый ук эзлексез язылган, күп кенә сораулар уята.

Иң әүвәл, иҗат тибы һәм иҗат методлары арасындагы аерма һәм үзенчәлекләр ачык итеп аңлатылмый. Моны бигрәк тә романтизм турында язылган юлларда күрергә мөмкин. Романтизм иҗат тибы буларак һәм романтизм иҗат методы төсендә ачык итеп аерып куелмаган. Бөтендөнья әдәбиятлары үсеше тарихында урын алган иҗат методлары арасында романтизм иҗат методы күренми, төшеп калган. Ә бу, үз чиратында, иҗат тибының чын асылын әйтеп бетермәүдән килә.

Ф. Хатипов «иҗат тибы»н асылда кешелекнең сәнгатьле фикер йөртүе, сәнгатьле (художестволы) аң дип карый булса кирәк. Ләкин монда ачык итеп куярга кирәк булган: образлылык принцибында, художестволылыкка ирешүдә төрле тарихи чорлар арасында гына түгел, бәлки бер-берләренә якын чорларның язучылары, хәтта бер үк вакытта яшәп иҗат иткән сүз осталары әсәрләре арасында да аермалык күренә. Мәсьәләгә тирән кереп тормастан, шуны гына әйтик: борынгы заманнардан башлап кешелекнең сәнгатьле фикерләвендә ике төрле юл бар. Аерым әдипләр иҗатында тормышны авторның үз теләк-омтылышына якынайтып (Белинский сүзләре белән әйткәндә—«идеаллаштырып») тасвирлау өстенлек алса, кайберләре тормышны «асылда нинди булса, шулай»

тасвирлауга йөз тоталар. Хәзерге әдәбият белемендә беренче төр сәнгатьле фикерләү—«романтик фикерләү тибы», икенче төр художестволы фикерләү «реалистик фикерләү тибы» дип атала. Сәнгатьле фикерләүнең һәр ике тибы, ике төре мәгълүм тарихи дәвердә дөньяга алдынгы яки реакцион караш белән сугарылып, әдәбиятта зур урын ала һәм хәтта әйдәүче булып китә. Мондый вакытта инде фикерләү тибының менә шул тарихи конкрет формасына туры килә торган исем табу хаҗәте туа.

Дәреслектә менә шул мәгълүм дәвердәге, ягъни XVIII гасыр ахырындагы—XIX гасыр башындагы әйдәүче күренеш буларак романтизм иҗат методы турында сүз юк. Автор аны художестволы иҗат тибы эчендә «эретеп» калдыра. Реалистик иҗат тибының билгеле бер чорда әйдәүче иҗат методы булып формалашкан классицизм, сентиментализм, мәгърифәтчелек реализмы турында ачык әйтелгән, аларны мөстәкыйль метод итеп таныткан яклары күрсәтелгән. Романтизм Аурупа һәм Америка әдәбиятларында классицизм әдәбиятына һәм эстетикасына каршы иҗат методы буларак, романтизм фикерләү тибына нигезләнеп формалаша һәм үсә. Аны иҗат методы итеп карарга мөмкинлек бирә торган принциплар ачыклана. Шундыйлардан иҗатта хөрлек таләп итүне, сәнгатьле иҗатны бернинди киртәләр-кысалар белән чикләп-бикләп куймауны алга сөрүне, тарихилык принцибының бөреләнә башлавын күрсәтергә мөмкин. *(Аңарчы бу иҗат тибында тарихилык принцибы булуы хакында сүз алып барырга иртә.)* Иҗат методы буларак романтизм киң мәгънәдәге романтизмның барлык сыйфатларын кабул итеп, яңа баскычка күтәрелә. Анда яшәп килүче чынбарлыкны каралтып күрсәтү һәм ачыктан-ачык кире кагу эзлекле төс ала.

Кабатлап әйтергә туры килә, хезмәттә иҗат тибы белән иҗат методын буташтырып җибәрү, кызганыч ки, урын алган. Моны авторның «романтизм XVIII-XIX йөз араларындагы Европа, Америка әдәбиятына гына хас күренеш түгел, ул күп халыклар әдәбиятының буеннан-буена сузылып бара» *(246 бит)* дигән сүзләреннән дә күрергә мөмкин.

Дәреслектә урын алган кайбер фикер тарлыгын һәм хатараслауларны түбәндәге юллар да күрсәтә: «Романтизмда күңел дөньясы бик тирән, җентекле бәян ителә, ул хис-кичерешләрнең, уй-фикерләрнең нечкә төсмерләрен, сизелер-сизелмәс тибрәнешләрен игътибар белән рәсемләп бирә» (243 бит). Бу фикер белән асылда килешергә дә мөмкин булыр иде, әгәр дә автор шуны романтизмның үзенчәлекле, башка иҗат тибыннан аерып тора торган ягы дип кистермәсә. Ә менә реализмга хас түгелмени бу сыйфатлар? Алайга китсә, «җан диалектикасын» үзләштерү җәһәтеннән реализм өстенрәк тә әле...

Авторның «романтик типиклаштыру гиперболизация белән тыгыз бәйләнгән» (162 бит) дигән раславы да берьяклы. Арттыру реализмга да хас. Гомумән, сәнгатьле арттыру-типиклаштыруның, ягъни гомумиләштерүнең мөһим чараларыннан берсе. «Безнең зур әсәрләр, югары сәнгать үрнәге булган барлык әсәрләр нәкъ менә арттыруга, күренешләрне киң типиклаштыруга нигезләнгән» (М. Горький).

Татар әдәбияты XVIII йөзләргә чаклы асылда романтизм фикерләү тибына нигезләнеп үсеп килә. Ә менә иҗат методы буларак романтизм XX гасыр башында гына формалаша,—бездә аның үзенчәлеге шунда.

Инде формалашкан, әдәбиятлар үсеше тарихында мөһим роль уйнаган иҗат методларына тукталып, дәреслек авторы аларның төп сыйфат-үзенчәлекләрен күрсәткән. Әмма монда да ахыргача әйтеп бетермәү, яртылаш фикер йөртү үзен сиздерә. Иң әүвәл, метод төшенчәсен буталчык аңлатуны күрсәтергә кирәк. «Иҗат методы» термины совет әдәбият фәнендә гасырыбызның утызынчы елларында гына кулланышка кертелгән. *(Аңарчы аның урынына «стиль» термины кулланылган.)* Аңа билгеләмәләр дә бирелгән. Шуларның берсен Ф. Хатипов та китерә: «Метод—ул чынбарлык күренешләрен сайлап алу, тасвирлау һәм бәяләүнең төп принциплары». Һәм автор бу билгеләмәне кабул итми. Сүз монда бу билгеләмәнең ни дәрәҗәдә тулы булуы хакында бармый. Ә хезмәт авторының бу билгеләмәне ни өчен кабул итмәве, аның дәлилләре хакында. Ул «сайлап алу» һәм бәяләү» тәгъбирләренә каршы килә. Менә аның дәлилләре: «Сайлап алу аерым методка гына түгел, ә гомумән бөтен сәнгатькә хас күренеш» (250 бит); «Сәнгатьчә сурәтләү бәя бирүдән башка була алмый» (251 бит). Гомумән, дөрес, ләкин бит сүз ул турыда бармый.

Сүз шул сайлап алуда һәм бәяләүдә методта нинди принципләр өстенлек итүе турында бара. Язучы «әсәр өчен отышлы, тәэсирле, мәгънәле күренешне сайлап алуда» нинди принципларга таяна, кайсыларын өстен күрә, шуларны җитәкче итеп ала—мәсьәлә шул хакта. Сентиментализмда ул принципләр бер төрле, классицизм иҗат методында—икенче төрле, романтизмда—өченче һ. б. Әнә шул принципләр җыелмасы методның үзенчәлеген, башкаларыннан аермасын билгели дә инде.

Кайбер иҗат методларындагы мондый үзенчәлекләрне конкрет алганда дәреслек авторы үзе дә нигездә дөрес эш йөртә. Аерым алганда, классицизмның үзенчәлекле яклары һәм сыйфатлары шактый тулы күрсәтелгән. Ләкин шулай да барысы турында да моны әйтеп булмый. Сентиментализм әдәбияты турында, мәсәлән. Бу үзенчәлекле әдәбиятны тудыручыларның кеше рухи дөньясын тирән чагылдырулары мохит белән, иҗтимагый шартлар, социаль тирәлек белән бәйләнештә алып барылмавы әйтелмәгән. Ә бу бик мөһим. Мәсәлән, мисал итеп китерелгән «Бичара Лиза» *(авторы Н. М. Карамзин)* әсәрендә крестьян кызы шундый итеп, бай рухлы, гаять белемле, югары тәрбияле итеп бирелгән ки, әйтерсең ул бер дворян кызы. Аның крестьян кызы булуы берничек тә күренми. Мәгълүм булганча, реализм гомумән кешенең эчке дөньясын, хис-кичерешләрен тасвирлауга төп игътибарын юнәлтә. Әмма җитлеккән реализм әдәбияты тарихи конкрет кешене ала, аңардагы уй-хисләрне конкрет тарихи тирәлек белән бәйләнештә карый, мохит тәэсиренең ролен истә тотып эш йөртә. Әйе, сентиментализм—реалистик иҗат тибының бер үзенчәлекле чагылышы. Әмма психоанализ җәһәтеннән ул шактый ук беръяклы, хәтта кимчелекле.

Сентиментализм әдәбиятын дворяннар катламы белән бәйләүнең рус әдәбияты өчен генә характерлы булуын да әйтү кирәк иде. Ул руста XVIII йөзнең 70-80 елларында крепостнойлык тәртипләреннән ризасызлыкны үз эченә алган дворян-нар агымы рәвешендә яши. Ә әдәби агым буларак сентиментализм XVIII йөз ур-таларында Англиядә туа, асылда буржуазиянең көч җыйнавы белән бәйле була.

Шулай ук сентиментализмның алым-формаларын санаганда көндәлек төрен дә күрсәтү кирәк (Л. Стерн—«Франция һәм Италия буйлап сентименталь сәяхәт», Н. М. Карамзин—«Рус сәяхәтчесенең язмалары» һ. б.).

Китапның мәгърифәтчелек реализмына караган бүлекчәсе асылда әйбәт язылган. Аның бигрәк тә татар мәгърифәтчелек әдәбияты турындагы, аерым алганда, мәгърифәтчелек әдәбиятының дин проблемаларына мөнәсәбәтендәге үзенчәлекләр хакындагы фикерләр оригиналь, алар беренче мәртәбә шулай ачык итеп куелган.

Тәнкыйди реализм һәм социалистик реализм әдәбиятлары турындагы аңлатма-төшенчәләр дәреслектә бер исем—«классик реализм» астында бирелгән. Хәлбуки аларны үзбашка аерып, аерым карау дөресрәк булыр иде. Авторның «тәнкыйди реализм»ны термин буларак уңышсыз санап, рус галимнәренә ияреп, реализмның бу үсеш баскычын «классик реализм» дип атавы белән килешергә дә мөмкин. Әмма терминның асылын аңлатуда шактый ук ачыкланып бетмәгән урыннар барлыгын да әйтергә тиешбез. Элекке терминны уңышсыз санап кире какканда китап авторы шулай да шактый ук беръяклы фикер йөртә.

Бу бүлекчәнең зур гына өлешен «тәнкыйди реализм» терминының ни дәрәҗәдә уңышсыз булуын фаш итү алып тора. Бәлкем, монда төп игътибарны бу иҗат методының үзенчәлекләрен барлап күрсәтүгә юнәлтергә кирәк булгандыр?! Дәреслек бит! Дөрес, алар нигездә әйтелә дә кебек, ләкин бик көпшәк рәвештә, кайчак хәтта буталчык итеп.

Иң беренче, бу иҗат методында үзәк урыннарның берсен алып торган тәнкыйть рухы турында. Дәреслек авторы аны бу методка гына хас түгел, гомумән художестволы иҗат типларының буеннан-буена хас дип раслый. Ләкин үз эчтәлек-юнәлеше белән тәнкыйтьнең төрле характерда булырга мөмкин икәнен исәпкә алып бетерми. Әнә ничек диелә: «Чынында бит җиһандагы, кеше холкындагы алама якларны, яман сыйфатларны бәян итү һич тә XIX-XX йөз әдәбиятына гына хас күренеш түгел» *(278-279 битләр)*. Дөрес. Ә менә «классик метод» *(ягъни тәнкыйди реализм)* чоры әдәбиятында тәнкыйтьнең болар өстенә яңа сыйфат белән баюы, аның тагын да тирәнәюе, киңрәк колач алуы турында әйтелми. Ә болары җәмгыятьнең тәрәккыяте һәм иҗтимагый шартларга бәйле төстә кешелекнең сәнгатьле фикер үсеше белән, әдәбиятның

да үсеше белән мөнәсәбәттә барлыкка килә. Дәреслектә исемнәре аталган рус галимнәре ачык язалар, югыйсә: «Иҗат методы буларак реализм—тарихи күренеш; бу күренеш кеше акылы үсешенең билгеле бер баскычында барлыкка килде; ул кешеләр алдында иҗтимагый хәрәкәтнең мәгънәсен һәм юнәлешен аңларга котылгысыз ихтыяҗ килеп чыккан вакытта, кешеләр башта стихияле рәвештә, аннары исә аңлы рәвештә дә,—кешеләрнең характерлары һәм хисләре теләкләрнең яки ирадә ихтыярның нәтиҗәсе түгел икәненә, бәлки алар реаль сәбәпләр, тәгәлрәге материаль сәбәпләр белән билгеләнәләр икәнлегенә төшенә башлаган вакытта барлыкка килде. Сәнгатьтә реализм методы иҗтимагый мөнәсәбәтләрне тудыручы, ләкин үзләре ачыктан-ачык күренүдән яшеренеп калучы көчләрне аңлау вазифасы... кабыргасы белән торган вакытта барлыкка килде» *(Б. Л. Сучков. Исторические судьбы реализма.—М.: Союз писателей, 1967.—11 бит).* Димәк, бу реализм конкрет тарихи шартлар продукты икән. Алай гына да түгел, «реалистик методның эчтәлеген, аның җанын, аның йөрәген социаль анализ, кешенең социаль тәҗрибәсен тикшерү һәм тасвирлау, шәхес һәм җәмгыять арасындагы иҗтимагый мөнәсәбәтләрне дә, җәмгыятьнең үзенең структурасын да өйрәнү һәм тасвирлау тәшкил итә» *(шунда ук, 19 бит).*

Аңлап-төшенепме, әллә инде художникълык интуициясе ярдәмендәме социаль анализ үткәргән язучы җәмгыятьнең төзелеше камил түгеллеген күрә, андагы кимчелекләрнең асылына тирән төшенә бара. Бу инде «кеше хакындагы алама якларны, яман сыйфатларны» күрүдән өскәрәк күтәрелү, ә җәмгыять төзелешендәге, иҗтимагый мөнәсәбәтләрдәге яман якларны күрә башлау. Күрә икән, димәк аларны тәнкыйть тә итә, димәк, тәнкыйть яңа югарылыкта булып чыга. Шулай итеп, матур әдәбият үсешенең әүвәлге барлык баскычларында язучылар иҗатында мөһим урын тоткан тәнкыйть элементы инде яңа сыйфат-көч алган, дигән сүз. Менә ни өчен дип уйларга кирәк, бу методны «тәнкыйди реализм» дип атаганнар да. Чөнки атаучылар әдәбиятны, иң беренче, җәмгыятьне үзгәртеп коруда көчле корал итеп карыйлар.

XIX гасыр әдәбияты һәм сәнгате, ягъни «тәнкыйди реализм» чоры турында В. Г. Белинский ачык әйтә: «Безнең заманда ни ул сәнгать? Хөкем, җәмгыятьне анализлау, **тәнкыйть ул**» *(ассызык безнеке—А. Ә.).* Күренә ки, танылган теоретик һәм тәнкыйтьче бу дәвер әдәбиятында тәнкыйть элементын, әмма инде җәмгыять тәртипләрен тәнкыйтьләүне алга чыгара. Кыскасы, бу иҗат методын «тәнкыйди реализм» дип атауда хаталык эзләү артык бер эш, күрәсең.

Ә менә Ф. Хатипов тәкъдим иткән «классик реализм» исеме астына кергән әдәбиятның төп принциплары исә тулырак аңлатуны сорый. Әдәбиятның асыл байрагы булган гуманизм бу дәвер әдәбиятында нинди билгеләргә ия? Ул чагында халыкчанлыкның тирәнәюе бармы, булса, нинди юнәлешләрдә бара? Романтизм иҗат методында бөреләнгән тарихилык принцибының реализмдагы урыны нидә? Дәреслектә социаль детерминизм турында сүз бар. Ә менә психологик детерминизм турында бер сүз дә юк. Ә бит матур әдәбият өчен монысы мөһимрәк һ. б., һ. б. Жанрларның нык үсеш алуы һәм тасвирлау чараларының, алымнарының байлыгы классик реализм әдәбиятының тагын да бер сыйфаты икәнлеген дә ассызыкларга кирәк иде.

«Социалистик реализм» иҗат методын «классик реализм»га кертеп карау берничек тә аңлашылмый. Ә бит бу—асыл билгеләре бик ачык күренеп торган, шактый ук нык формалашкан һәм билгеле бер уңышларга да ирешкән әдәбиятның иҗат методы. Аны аерып куеп өйрәнү, казанышларын да, кимчелекләрен дә аерып күрсәтү дөресрәк булыр иде.

Инде алда әйтелгәнчә, совет чорында бездә дә теория буенча хезмәтләр язылды. Алар асылда рус китапларына һәм хезмәтләренә ияреп язылдылар. Фәрит Хатипов дәреслеге мондый рухтагы хезмәтләрдән кайбер яклары белән югары тора. Алар турында алда сүз булды. Ләкин югары уку йортлары өчен эшләнгән дәреслек һәръяклап камил булырга, тулы булырга тиеш. Андагы һәр билгеләмә, һәр нигезләмә-төшенчә, хәтта һәр җөмлә ачык, ныклы, уйланылган булырга тиеш. Теориянең һәр мәгънәсе, һәр ягы ахыргача ачылып бетәргә тиеш. Шуңа күрә дә, күзәтү астына алынган бу китап нәзариятне үзләштерү юлында, матур әдәбиятның нәзари якларын өйрәнү һәм өйрәтү юлында бер адым дип каралырга тиеш. Алга таба бу эшне тагын да тирәнәйтү сорала.

# «ЗУР ӘДИП ӘЗЕР ХАКЫЙКАТЬ БЕЛӘН ЯШИ АЛМЫЙ...»

«Хакимлек итүче идеологиягә буйсынган безнең әдәбият ялган-ясалма чор таләпләренә башлыча көйләнгән иде. Ләкин чын хәлне күрә белгән, уйлый белгән, үзенең иҗатында тормышны ничек тә дөрес чагылдырырга омтылган язучылар бар иде»,—дип язган иде күренекле әдип Әмирхан Еники бер мәкаләсендә *(«Казан утлары», 1990, № 3)*.

Х. Сарьянның да шундый әдипләрдән берсе булуын, алтмышынчы-җитмешенче елларда җәмгыятебездәге күрсәтергә ярамаган «авыруларны» кыю тәнкыйтьләгән сатирасы раслый.

Польша шагыйре һәм сатирик язучы Станислав Ежи Лец болай дигән: «Сатира беркайчан да имтихан бирә алмаячак, чөнки жюрида аның объектлары утыра». Әйе, дөреслекне фаш иткән сатирик әсәрнең дөнья күрә алмыйча интегү очраклары—шул әсәрдә фаш ителгән тискәре типларның тормышта да әлегә бик көчле икәнен күрсәтүче билге ул. Х. Сарьян иҗат иткән «Нокталы өтер» әсәренең 1967 елда язылып та, 1990 елда гына дөнья күрүе дә әнә шул хакта сөйли. «Менә шушы «Нокталы өтер» минем өстән КГБга ике-өч әләк язды. Имеш мин—милләтче»,—ди автор *(«Казан утлары, 1998, № 9)* коллегасы өстеннән донослар язучы адәмне искә төшереп.

«Башта «Нокталы өтер» әсәрен нәшрият та, әдәби журнал редакциясе дә хуплап кабул итә. Әсәрне бастырмау өчен бер аксакалыбызның сүзе җитә: «Сарьян безнең галимнәребезне мыскыллап язган китап чыгарырга йөри. Телче галимнәребез бармак белән генә санарлык. Ул китапны чыгармаска кирәк»,—дип искә ала Л. Хәмидуллин *(«Казан утлары», 2000, № 3)*.

Инглиз фәлсәфәчесе А. Шефтсбери фикеренчә: «Басым никадәр ныграк булса, сатира да шуның кадәр кискен. Коллык көчлерәк булган саен сатира шуның кадәр нечкәрәк» *(Энциклопедия афоризмов. М., Изд. АСТ, 1999)*. Алтмышынчы еллар ахырында илебездә нинди иҗат атмосферасы булуы мәгълүм. «Нокталы өтер» кебек сатирик әсәр нәкъ менә Хрущев «җепшеклеге»ннән соң килгән «суыту» вакытындагы идеологик басым астында гына языла алгандыр да.

Г. Тукай, К. Тинчурин, Г. Камаллардан килә торган көчле сарказм белән сугарылган «Нокталы өтер» әсәрендә Х. Сарьян җәмгыятьнең гарип күренешләрен тәнкыйтьли. Повестьта кешене сәләте буенча түгел, бәлки өстән кушу буенча эшкә алу, укыган кешенең кадере булмау, кода-кодагыйлык кебек шул заман җәмгыяте тудырган тискәре күренешләр үзәккә куела.

Гаделсезлекләрне күп күргән Хәсән Ямалов татар теле кафедрасына мөдир сайлаганда, конкурс турында түбәндәге фикерләрне әйтә: «... Мин инде илле өстенә басып килгән кеше—конкурс тәртибен бераз беләм. Аңа дүрт кеше түгел, кирәгем исә дүрт йөз кеше катнашсын—барыбер бирәү генә үтә. Ә ул бирәү, әлбәттә инде, конкурс игълан ителгәнче үк мәгълүм була. Әнә шул кешене үткәрү өчен генә кирәк ул конкурс. Ә калган кандидатуралар театр сәхнәсендәге статистлар кебек кенә. Бер артист төп рольне башкара, калганнары аңа фон ясыйлар...»

Әсәрдә кеше хезмәтен урлап диссертация язган, аны Казанда яклый алмагач «күп акча түгеп» Алма-Атага барып яклаган, «тел белгече» Гали Галиевичның протекция белән мөдирлеккә үрмәләве, креслога утыргач, «важный мәсьәләләр» күтәреп чыгуы хикәяләнә.

«Сезнең игътибарны кайбер кимчелекләргә очлайтасым килә»—бу Чәмәт (Гали Галиевичның кушаматы) сүзләре. Үзенең «кошмар», «спрашивается», «разве», «сразы» кебек рус сүзләрен кыстырып һәм бик дорфа сөйләшүенә карамастан, ул башкалардан культуралы сөйләшү таләп итә. Язучы сөйләм аша Чәмәт характерын тулы ачуга ирешкән. Герой еш кына «нитәрбез», «ниме»,

«нитмәсен» сүзләрен куллана. Әгәр дә Чәмәт безне хатыны белән таныштырса, рус телен гел үрнәк итеп куйганлыктан: «бу—минем икенче яртым»,—дияр иде. «Рус телендә «Где ваша половина?» дисәң, хатынны сорый бу диләр, ә «Кая синең яртың?» дисәң, татар кибеткә чабачак». «Әгәр мөселман 5-6 хатынга өйләнсә, хатыннары чиректән дә кимрәк була түгелме соң?»—дип мәсхәрәләп көлә автор. Ә бервакыт Чәмәт Айдарга: «Иптәшенә хатын дип әйтү—культурасызлык билгесе»,—ди. «Алайса сез русларны да культурасыз дисезмени, алар да бит «жена» диләр, товарищ димиләр»,—дип, Айдар Чәмәтне чарасыз калдыра.

Күренешнең яисә кешенең эчке асылы белән тышкы гәүдәләнеше арасындагы шундый каршылыклар комик эффектны тагын да арттыра.

Х. Сарьян тел остасы буларак кечкенә генә деталь, параллельләр ярдәмендә геройның портретын, холкын бирүдә нечкә эш итә. «Борынын феноменаль пошкырта» торган, ябык чырайлы, кыйгач кашлы, нәзек муенлы, очлы баш Чәмәтнең портретын биргәндә, автор контраст өчен рәттән «ирләрчә нык йөзле, таза тамырлы» Ямаловны да сурәтли. Татар халкында «йомры баш» дип акыллы кешегә әйтәләр, ә Чәмәтнең кушаматы «очлы баш»...

Чәмәтнең галим Халидинеке кебек башын бер яккарак борып йөрүе, галимнең портретын Алпаровныкыннан да зуррак итеп ясаттырып түргә элүе—үзенә кирәкле кешегә ярарга тырышуын күрсәтә торган детальләр. Ә инде геройның комсыз, вакчыл бәндә булуын Камилдән венский урындыкларны алу күренеше тагын да ныграк ача.

Геройның характеры тышкы портрет аша гына түгел, эчке портрет детальләре аша да ачыла.

Чәмәтнең кеше психологиясен «белеп» эш итүе монологларда чагыла. Буранбаевичның мактанырга яратуын, эре икәнен сизеп алгач, Чәмәт салпы якка салам кыстырырга кирәклеген уйлап куя һәм үзен түбән куеп сөйләшә башлый. Язучы аларны баскычта очраштыра һәм «бөеклек өянәге»нең нәрсә икәнен белгән Чәмәтне басып торган жиреннән бер баскыч түбән төшерә. Кешеләргә эшләгән гадәти эшләрне кафедра житәкчесе үз яхшылыгы итеп, психологик басым ясап, үзенә дә нәрсәдер өмет итеп эшли. (Мәрзиягә ял бирү, Камилгә «старший» исеме бирергә вәгъдә итү, энекәшенең иншасын бәяләү күренешләре).

Ямаловның гадәт буенча кунакка чакыруын да эчкерле Чәмәт «Эчертеп сер алмакчы»,—дип бәяли. Аның әйләнә-тирәдәге кешеләргә карата мөнәсәбәтендә, космополитик карашларында усал цинизм белән сугарылган ирония күренә. Ул бөтен кешедән көлә. Үзен исә барысыннан да акыллырак дип саный.

Язучы Чәмәт кебек типларның килеп чыгу сәбәпләренә дә ачыклык кертә. Сугышка кырык бернең җәендә китеп, көзендә кулын өздереп кайткан Чәмәтнең әтисе сугыш елларында балда-майда йөздерә торган эшләрдә эшли. Ә инде сугыштан соң тире җыю эшенә эләгеп кала, «Бер баскычка төшкән саен, ун баскыч югары жиргә шикаять кыла». Чәмәтне кечкенә чагында ук донос язарга, кешеләр турында информация җыярга, бюрократ-командачыл система колы булган әтисе өйрәтә. Герой характерындагы теге яки бу сыйфатның килеп чыгуын балачактагы хәлләр белән әнә шулай мотивлаштырып бирү образны тормышчан итә. Геройның бер гаепсез иптәшләре, хәтта укытучылары өстеннән кызып-кызып яла язган моментлары Т. Миңнуллинның «Хәсәен Вәгыйзович»ындагы, Ә. Баяновның «Аязучан болытлы һава» повестендагы адәмнәрне хәтерләтә.

«Ялган сүз, гайбәт, пычрак язма Рәсәйдә генә дә күпме олы шәхесләрнең башына житте»,—ди аноним хатлар ярдәмендә «көрәшү» турында Т. Галиуллин.—Шул ук шикаять хатларның ерак чал тарихы бар. Ул—кешенең явызлана, усаллана баруының бер билгесе генә түгел, вакыты белән үзен башкача яклый алмаган шәхеснең иҗтимагый тигезсезлекләргә каршы көрәш алымы да» *(Галиуллин Т. Замана балалары. Казан: Таткитнәшр., 1993.).* Ә менә Чәмәттән аермалы буларак, Айдар Бәхтизин андый алымнан файдаланмый, чөнки дәреслекне алай табып булмасын аңлый. Хәсән Ямалов әйтмешли: «Ул (Айдар) безнең өчен бер генә кеше уйлый дигән чорда түгел, үзегез дә уйлагыз дигән чорда үскән». Фразеологизмнар, мәкальләрне яхшы белгән Айдар әсәрдә профессор Халиди әйткән мәкальне дә белми түгеллер: «Ике козгын сугышканда карга тук була»...

Айдар һәм Хәсән кебек сәләтле, акыллы кешеләргә киртә булган Гали Галиевичның наданлыгы, уку-укыту, сәнгать өлкәсендә делитантлыгы мәктәптә

практика вакытында, кафедра җыелышларында, Алпаров рәсемен ясатканда сарказм белән күрсәтелә.

Геройның «шагыйрьлеген» күрсәтү өчен, автор пародия алымына мөрәҗәгать итә. Консультант, Чәмәтнең йөзләп шигырен укып чыккач, аңа шигырь язмаска киңәш бирә. Бушкуык Чәмәт урындыкка менеп:

Сал колак син сүземә и адәм: килер көн, Гали шигырьләрен эзләп йөрерләр көн вә төн,—дип Тукай шигырьләреннән урлашкан юлларны укый. Аннан: «Маяковскийны да шулай агулап килгәннәр!»—ди дә ишекне бәреп чыгып китә һәм кайтып өлкә комитетына җалоба яза.

Көлүнең иң югары ноктасы Чәмәтнең «Тыныш билгеләре» дип исемләнгән монографиясендә. Язучы арттыру алымы белән хезмәтнең яраклы өлешен 5-6 бит кенә калдыра. («Автор монографияне повестена тулысынча кертергә уйлаган иде—редактор якын да килмәде. Аңа каршы килеп буламыни!»—дигән автор репликасын кертеп, Х. Сарьян ул елларда иҗат ирегең кысып, әсәрләрне ничек «кисүләренә» дә ишарә ясый). Соңрак Ф. Шәфигуллинның «Суда балык йөзәдер» әсәре кайбер тәнкыйть мәкаләләренә пародия буларак язылса, Х. Сарьян китергән монография юллары исә начар фәнни хезмәткә пародия:

«Телебездә миңа кадәр беркем дә тыныш билгеләре турында минем кадәр нык итеп баш ватып карамаган. Алыйк К. Насыйриларны (...), алыйк шулар ише күренекле һәм күренексез галимнәрне». «Дефис—бик күп нокта молекулаларыннан торган геометрик фигура». «Йөз кеше белән эксперимент үткәрелде—берсе дә сорау, өндәүне киреле-башлы куймады...» Биредә автор Чәмәтнең коллегалары белән филология мәсьәләләре буенча бәхәсләрендәгечә үзара ярашмаган төшенчәләрне юри берләштерә. Шундый «җитди» фәнни терминнар белән язылган хезмәтен «Гыйльми язмалар»га биреп герой кеше көлкесенә кала, авыруга сабыша.

Геройның тискәре тормыш теләге җәмгыятькә никадәр зарарлы тоелса, сатирик әсәр аны шул кадәре нык чалшайтылган сәнгатьчә формага төрә, тышкы кыяфәте нык күпертелгән художестволы алым аша әлеге тискәрелекнең җәмгыятькә зарарын, халыкка куркыныч булуын фаш итә. Сарьян да геройны деформацияләнгән рәвештә сәнгатьчә тирән гомумиләштереп сурәтли. Чәмәтнең сәер чирен рентген таплаѳының формасына карап «Noktalae utrum» («Нокталы өтер») дип атыйлар. Рентген сурәтләрендәге баш миенең формасы, йөрәктәге «караңгылык», кыяфәтнең нокталы өтергә охшавы Гогольнең «Борын», Салтыков-Щедринның «Бер шәһәрнең тарихы», В. Маяковскийның «Мистерия-буфф», «Утырыштагылар», «Кандала», «Мунча» әсәрләрендәгечә гаҗәеп формаларны хәтерләтә. Ягъни, автор биредә сатирик образ тудыруның гротеск алымына мөрәҗәгать иткән. Монда Ф. Шәфигуллинның «Куадрат Нургиз» исемле юморескасындагы бөтен дөньяны квадратларга бүлеп күз алдына китерә торган Нургиз белән дә охшашлык бар.

Әсәр ахырында автор алогизм куллана. Чәмәтнең кафедра мөдирлегеннән алынып мич чыгарып йөрүен әйтә. Шунда ук: «Тукта, Сарьян! Шыттыра башладың түгелме? Фәннәр кандидатының кайчан мич чыгарып йөрүен күргәнең бар?»—дип автор репликасы да килеп керә. Димәк, тормышта алай була алмый. Димәк, Чәмәт кебекләр үз җирлекләрендә яши, үрчи бирәләр.

Шулай итеп, «Нокталы өтер» әсәрендә фән дөньясына очраклы килеп кергән кешенең фаҗигасе бирелә. Гомумән, Х. Сарьян сатирасы совет чынбарлыгы тудырган рухи мещаннарны, карьеристларны, шәхеснең деградацияләнүенә китергән сәбәпләрне тәнкыйтьли.

Шәхеснең таркалу мотивлары әдәбиятта күп очрый. Мәсәлән, Х. Сарьянның замандашларыннан американы Д. Апдайк иҗат иткән «Кентавр» (1963), японлы К. Абэның «Человек-ящик» (1973) романнары шундый. Х. Сарьян сатирасында аларга авазлаш мотивларның булуы, безнең язучының идеологик басым елларында да дөнья әдәбиятындагы гомумкешелек идеалларына тугры калуы хакында сөйли.

«Тагын поэма язармын
Өстән күрсәтмә булса»,—

дигән иде ул еллар турында шагыйрь Р. Вәлиев. Х. Сарьянның «Финал» (1969)

исемле икенче бер сатирик әсәре әнә шундый—әдәбият өстеннән административ басым көчәйгән елларда язылган. Әсәрдә бер оешмадан икенчесенә «типкәләнеп» йөреп алданган, түбәнсетелгән яшь язучы мисалында иҗади рухның басылып яшәве күрсәтелә. «Финал» әсәрендә тасвирланган бюрократлар һәм «Ноклалы өтер» повестындагы Чәмәтнең кафедра мөдире булып алгач кыланышлары В. Шукшинның бер хикәясендәге вахтершаны да хәтерләтә. «Кечкенә генә властена да мөкиббән киткән хатын үзеннән мең мәртәбә югары торган кешеләрне түбәнәйтүдән, кимсетүдән, җир белән тигезләүдән иксез-чиксез ләззәт таба» *(Нуруллин Ибраһим. Тормыш һәм сәнгать чынлыгы. Казан: Таткитнәшр., 1983.)* Әлеге образлар зуррак власть эләктергән намуссыз, вөҗдансыз һәм таш бәгырьле кешеләрнең әхлакый-сәяси зарарын күз алдына китерергә булыша.

Х. Сарьянның «Финал» хикәясе Ф. Шәфигуллинның «Әфләтүнов—бүлек мөдире» дигән әсәре белән бик аваздаш. Әдәбиятның һәрвакыт күзәтү астында яшәгәнен Ф. Шәфигуллин тасвирлаган Әфләтүнов образы аша да күрергә мөмкин. Сәнгатьне аңлау дәрәҗәсе түбән кеше биредә шагыйрьне шигырь язарга өйрәтә. Ул шигырьгә сәнгать әсәре буларак түгел, ә агитация таләпләре белән генә карый. «Менә сез монда таңга чаклы авыл тын кала дигәнсез. Кайда бара бу вакыйга? Колхоздамы? Нәрсә булган ул колхозга? Барысы да йоклый дигәнсез? Ә житәкчеләр? Актив? (...) Комсомол оешмасы да йоклыймы? Ә уңышны кем саклый?»...

Гомумән, Ф. Шәфигуллин сатирасы белән Х. Сарьян сатирасы арасында охшашлыклар күп. Бу охшашлыклар бигрәк тә сүз һәм тормыш арасындагы көлке дәрәҗәсенә барып житкән каршылыкларны ятыртуда ачык күренә. Мәсәлән, Х. Сарьянның «Дөнья бу» хикәясендә төрле әдәбиятларда, шулай ук, татар әдәбиятында күп тасвирланган «коллык психологиясе» чагыла. «Ул (бүлек мөдире—В. М.) мине кочаклап алды да, карт иреннәре белән уңнан да, сулдан да үбә башлады, битләремне чылатып бетерде. Мин шатланып түзеп торам. Түзмәс идең—дөнья бу!—иртәгә үк үземнең әйберне (мәкаләне—В. М.) бирергә уйлыйм».

«Ноктаы өтер»дәге Камил Хәсәнов ничек тә Чәмәткә ярарга тырыша. Өмете: «Бәлки яна житәкче квартира юнәтергә, «старший» исемен алырга булышыр». Ф. Шәфигуллинның «Бүрек», «Яхшылык хакына» хикәяләрендә дә Габит Таһиров кебек образларда «кечкенә кеше» трагедиясе бирелә. Ике язучы иҗатында да коллык психологиясенең сәбәпләре кешенең икътисади яктан ирексез булуларына бәйләп аңлатыла. Айдар Бәхтизин, Хәсән Ямалов кебек гадел кешеләргә яшәү авыр булган заманда «кеше никадәр чиста булса, тормышның аңа шулкадәр рәхимсез булуын» А. Гыйләжевның «Урамнар артында яшел болын» исемле реалистик әсәрендәге Мөзәкир образында да күрәбез. Яшүсмер Мөзәкир рухы сынган әтисенең колхоз житәкчеләре алдында бишкә төрләнгән Хәлил агайның коллык фәлсәфәсен кабул итәсе килмичә, асылынып үлә.

Түрәләргә ярарга тырышу, икейөзлелек, шәхеснең түбәнсенүе әлеге әсәрләрдә алтмышынчы-житмешенче елларга хас күренеш буларак тасвирлана. А. П. Чеховның «Чиновникның үлеме» («Смерть чиновника») әсәрендәге Червяков, Н. В. Гогольнең «Шинель» әсәрендәге Башмачкин образларында бирелгән «кечкенә кеше» проблемасы, гомумән, татар әдәбиятындагы актуаль бөтен мәсьәләләр яктылыгында тагын да үзенчәлеклерәк яңгыраш алды.

«Түрә—акыл иясе, ә мин—ахмак» дигән тәкъбир Коръән аяте кебек ятланып йөртелгән әнә шундый елларда, җаны әрнүгә түзә алмыйчадыр инде, безнең бер аксакалыбыз: «Зур әдип әзер хакыйкать белән яши алмый, ул аны үз зиһене белән ирешә», дип белдергән иде»,—дип язды Фәиз Зөлкарнәй үзенең «Сабыр төбе алтынмы?» исемле бер мәкаләсендә *(«Чакма чакмый ут чыкмый». Казан, Таткитнәшр., 1991).* Әйе, тәнкыйтьче хаклы: «Әдәбиятыбызның бүгенге көндә азмы-күпме абруе сакланып калган икән, ул менә шушындый нык иманлы, нык буынлы, нинди генә авырлыкларга да карамастан, үз сүзен бирмәгән әдипләргә бурычлы».

**Венера МАКАРОВА,**
*Чаллы дәүләт педагогия институты укытучысы*

Tarix
Тарих

# ТАТАР МӨҺАҖИРЛӘРЕ МАТБУГАТЫ

Татар вакытлы матбугатының бай һәм сикәлтәле тарихы бар. Ул инде бер гасырга якын яшәп килә. 1905 елның 2 (16) сентябрендә Русия башкаласы Санкт-Петербургта чыга башлаган беренче рәсми «Нур» газеты анын башлангычы булып тора. Шуннан соң үткән чорда ана телебездә төрле фикри-сәяси юнәлештәге 900 дән артык газет-журналлар дөнья күргән. Алар арасында консерватив, либераль-демократик, революцион-демократик һәм социаль-демократик, шул хисаптан, большевистик мәсләкне, яисә шуларга өлешчә якынлыкта торган басмалар бар.

Татар көндәлек матбугатының шактый бер өлешен чит илләрдә мөһаҗирләр (эмигрантлар) чыгарып килгән газет-журналлар тәшкил итә. Фикри-сәяси юнәлеше буенча алар, нигездә, милли рухтагы либераль-демократик басмалардан гыйбарәт.

—1905-1945 елларда һәм Икенче бөтендөнья сугышыннан соң Төркия, Венгрия, Алмания (Германия), Ләһстан (Польша), Кытай, Япония, Финляндия, Швеция, Румыния һәм АКШта татар мөһаҗир матбугаты үсеш алган. Әлегәчә табылган чыганаклардан күренгәнчә, бу илләрдә әйтелгән чорның төрле елларында 40 тан артык типографик ысулдагы, берничә җилем басма һәм кулъязма газет-журналлар барлыкка килгән. Аларның кайберләре хәзергә кадәр чыгуларын дәвам итә.

Бу газет-журналларны 1917 елга кадәр Русиядән чит мәмләкәтләргә күчеп киткән һәм аннан соң, большевистик режимны кабул итә алмыйча, туган җирләрен калдырып китәргә мәҗбүр булган татар зыялылары, җәмәгать һәм дин эшлеклеләре, аларның варислары, Беренче һәм Икенче бөтендөнья сугышлары вакытында әсирлеккә төшкән хәрбиләр оештырганнар.

Татар мөһаҗирләре матбугатының тарихы турындагы мәгълүматлар чит мәмләкәтләрдә һәм туган илебездә дөнья күргән әдәбиятта шактый кин яктыртылыш тапты инде. Шуның белән беррәттән, әлеге зур фәнни проблема киләчәктә төрле гыйльми юнәлеш белгечләренең аны тагын да тирәнтенрәк һәм бөтен яктан өйрәнүен көтеп кала.

* * *

Татар мөһаҗирләренең беренче газет-журналлары иң башта Төркиядә дөнья күрә. Төркия халкы белән татарлар арасында элек-электән тугандашлык мөнәсәбәтләре яшәп килә. Канкардәшлек, тел якынлыгы, уртак Ислам дине, гарәп-фарсы мәдәниятенә табыну аларны бер-берсенә рухи җәлеп итеп тора. Төрле сәбәпләр аркасында XIX гасырның икенче яртысында һәм XX гасыр башында, 1917 елгы Октябрь түнтәрелешеннән соң кузгалган күчеп китү вакытында меннәрчә татар Русиядән Төркиягә күчә. Тоталитар большевистик хакимият белән ризалашмыйча, туган якларын ташлап китәргә мәҗбүр булган Гаяз Исхакый-Иделле (1878—1954), Садри Максуди-Арсал (1878—1957), Габделбари Баттал-Таймас (1883—1969), Әхмәт Зәки Вәлиди-Тоган (1890—1970), Рәшит Рәхмәт-Арат (1900—1964), Хәмит Зөбәер-Кушай (1897—1978) һәм башка күренекле татар вә башкорт шәхесләре, аларның балалары өчен Төркия икенче изге Ватанга әверелә.

Төркиядәге татарлар төрле милли оешмалар төзи, газет-журналлар һәм

китаплар чыгара. 1905 елда, мәсәлән, Истанбул шәһәрендә, Казан татарлары белән бердәмлек җәмгыятенең уртак җәмәгать фикере буларак, «Казан» исемле журнал барлыкка килә. 1908 елда шул ук шәһәрдә милләттәшебез Морад бәй мөхәррирлегендә «Мизан» (Үлчәү) газеты дөнья күрә.

1910 елда биредә үк Р. Ибраһимов һәм Ә. Таҗетдин «Тәгарифе мөслимин» (Мөселманнар белән танышу) дигән атналык журнал чыгаруга керешәләр.

1911 елдан бирле гомумтөрек телендә чыгып килгән һәм төрле мөселман халыклары арасында киң танылган фәнни-популяр «Төрек йорты» журналының беренче нашире һәм мөхәррире мәшһүр татар эшлеклесе Йосыф Акчура (1876—1935) була. 1914—1915 елларда бу басманың мөхәррире булып билгеле журналист, җәмәгать һәм дин эшлеклесе Галимҗан Идриси (1887—1959) эшли.

1913 елда Әхмәтбай Агаев җитәкчелегендә «Халыкка тугры» журналы чыга башлый.

1914 елдан башлап Истанбулда айга ике тапкыр әдәби-дини «Ислам» мәҗмугасы бастырыла. Аның нашире һәм мөхәррире—якташыбыз Хәлим Сабит.

1910 елларда шул ук калада татар шәкертләре басмасы—«Ислам дөньясы» нәшер ителә. Ватандашларыбыз «Тәгавын ислам» *(«Исламга хезмәттәшлек»)* һәм «Галлям ислам» *(«Ислам галиме»)* исемле журналлар да чыгарганнар.

Әлеге матбугат битләрендә һәм төрек телендә чыгарылган башка газет-журналларда И. Гаспралы (1851—1914), Р. Ибраһимов (Рәшит казый. 1857—1944), Г. Идриси (1887—1959), Р. Фәхретдинов (1859—1936), Ф. Кәрими (1870—1937), Г. Баруди (1857—1921) һәм тарихта билгеле башка затлар актив катнашкан. Үз чиратында төрек зыялылары 1917 елгы октябрь түнтәрелешенә чаклы һәм аннан соңгы беренче айларда Русиянең төрле төбәкләрендә татар телендә чыгып килгән либераль-демократик газет-журналларда язышканнар.

Икенче бөтендөнья сугышыннан соң Төркиягә Кытай, Япония, Корея һәм Алманиядән татарларнын яңа төркемнәре күчеп килә. Җитмешенче елларда бу илдә инде 25 меңләп татар яши (бу санга Кырым татарлары керми). Төркиядә татар милли тормышы янә җанланып китә. Төрле милли оешмалар барлыкка килә, татар дөньясына кагылышлы күп китаплар чыгарыла, яңа газет-журналлар пәйда була.

1965—1968 елларда Истанбул шәһәрендә Г. Тукай исемендәге клуб «Тукай бюллетене» чыгарып килә.

1970 елда «Казан төрекләренең мәдәни һәм ярдәмләшү җәмгыяте»нең шәрәфле рәисе, күренекле татар эшмәкәре Әхмәт Вәли Мәңгәр (1891—1971) наширлегендә һәм аның матди ярдәме белән әлеге милли оешма «Казан» исемле әдәби-нәфис, сәяси һәм фәнни журнал чыгаруга керешә. Ошбу олуг шәхес элегрәк Кытайның Мукден шәһәрендә ун ел дәвамында мөһаҗирләрнең «Милли байрак» газетына да зур матди булышлык күрсәткән була. Ә. В. Мәңгәр бу басмаларда автор буларак та катнаша, эчтәлекле мәкаләләр язып тора.




«Казан» журналы исә өч айга бер мәртәбә латин хәрефләре белән төрек телендә нәшер ителә. Аның сәхифәләрендә беркадәр мәкаләләр әдәби һәм халык авыз иҗаты әсәрләре әүвәл татарча, аннары төрекчә китерелә.

Мәҗмуганың Надир Дәүләт рәислегендәге идарәсе хезмәткәрләре күбрәк вакыт Истанбулда эш итә, ә «Казан» үзе исә Әнкараның «Ай-йолдыз» басмаханәсендә чыгарыла.

Журналны башта Рифат Мөхтәсип, ә бераздан доктор Мәхмүт Аликәй җитәкли. Язу эшләре мөдире Надир Дәүләт, сонга

таба Рәшит Агый һәм сәркатибе Сәйдә Арсланбәк була. Редакция коллегиясе ун ел буе диярлек үзгәрешсез кала: Әхмәт Тимер, Рифат Мөхтәсип, Мәхмүт Таһир, Надир Дәүләт. Соңгарак аларга Әмрулла Агый белән Наилә Бинарк кушыла. Бу хакта тулырак мәгълүматны Х. Миңнеголның «Йөрәк һаман сиңа ашкына...» исемле мәкаләсеннән табарга була *(«Казан» журналы, № 1, 1993 ел.)*.

Бу журнал үзенең беренче санында төп максаты итеп, Төркиядә һәм башка мәмләкәтләрдә нигезләнгән татарларның күпкырлы тормышын яктыртуны һәм үзара хәбәрдарлыкны киңәйтүне куя. Һәм чыннан да, журнал редакциясе белән Җир шарының төрле төбәкләрендә яшәүче зыялы татар шәхесләре арасында тыгыз элемтә урнаша. Шуңа күрә басма битләрендә, бигрәк тә аның «Төрле хәбәрләр» дип исемләнгән бүлегендә, Төркия, Финляндия, Алмания, Кытай, Япония, Австралия, АКШ һәм башка илләрдә барлыкка килгән татар җәмгыятьләренең, шөһрәт казанган милли шәхесләрнең күпкырлы эшчәнлеге, төрле тормыш яңалыклары даими яктыртылып килә.

Җурнал эшендә зур галимнәр һәм сәләтле гыйлем ияләре катнаша. Аларның язмаларында татар халкының үткәне, аның төрле чордагы дәүләтчелекләре тарихы, урыс патшалары һәм совет хакимияте елларындагы хәле киң чагылыш таба. Бу өлкәдә мәҗмуганың беренче санынан ук башлап, энциклопедик белемле Мәхмүт Таһир (1921—1991) аеруча активлык күрсәтә.

Журнал битләрендә татар халкының мәшһүр уллары Г. Курсави (1776—1812), Ш. Мәрҗани (1818—1889), К. Насыйри (1825—1902), Х. Фәйзи (1928—1866), Г. Ильяси (1856—1895), Г. Баруди (1857—1921), Р. Фәхретдинов (1859—1936), Ф. Кәрими (1870—1937), З. Бигиев (1870—1902), М. Бигиев (1875—1949), Ю. Акчура (1876—1935), С. Максуди (1878—1852), Г. Исхакый (1878—1954), Г. Баттал (1883—1969), Г. Тукай (1886—1913), Ф. Әмирхан (1886—1926) һәм башка күпләрнең тормыш юлы, эшчәнлеге һәм иҗаты турында кыйммәтле мәгълуматлар тупланган, фоторәсемнәре урын тапкан. Әлеге мәгълүматлар һәм башка махсус мәкаләләр халкыбызның иҗтимагый-сәяси, фәлсәфи, икътисади, дини-рухани һәм педагогик фикере, мәдәнияте, әдәбияты, теле һәм сәнгате тарихы белән тирәнрәк танышу мөмкинлеге бирә.

«Казан» журналында әдәби әсәрләргә дә зур урын бирелә. Бу мөнәсәбәттән, беренче чиратта, чит илләрдә яшәп иҗат иткән, хәзергәчә күпләребезгә бик аз таныш булган шагыйрьләр Минһаҗ Исмәгыйли, Заһидә Таһир, Шаһвәли Кләүле Илдар, Әхнәф Тангатар, Казанлы (мәшһүр галим Рәшит Рәхмәти-Арат), Шиһаб Нигъмәти һәм башкаларның шигырьләрен күрсәтү фарыз. Әлеге әдәби язмалар татар милләтен сөю, саклау һәм берләштерү, ата-бабалар гомер иткән туган илне сагыну кебек изге хисләр белән сугарылган. Гражданнар сугышы чорында Кытайга киткән һәм шунда вафат булган язучы, журналист Хөсәен Габдушның хикәяләре дә журнал битләрендә еш күчеп бастырыла һәм укучыларның яратуын казана.

Журнал редакциясе совет илендә чыга һәм Төркиягә тоткарлыксыз килә торган әдәбият белән даими танышып бара, күп кенә татар әдипләренең әсәрләрен күчереп бастыра. Алар арасында С. Хәким, Г. Афзал, З. Нури, Ш. Галиев, З. Туфайлова, М. Газизов шигырьләре һәм В. Монасыйповның хикәясе бар. Әлеге әсәрләр еш кына татар һәм төрек телләрендә бирелгән.

«Казан» сәхифәләрендә татар вакытлы матбугаты тарихына, кагылышлы кыйммәтле язмалар дөнья күргән. Шундыйлардан профессор Рәшит Рәхмәти Аратның «Казан төрекләрендә периодик матбугат» исемендәге зур күләмле, бай эчтәлекле мәкаләсе, Кытайда нәшер ителгән «Ерак Шәрык» журналы һәм «Милли байрак» газеты турындагы иллюстрацияле тасвирнамәләр аеруча игътибарга лаеклы.

Журналда шулай ук татар театры һәм музыкасы үсеше тарихына багышлы мәгълүматлар да күп. Анда Г. Камал (1879—1933), М. Гафури (1880—1934), Ф. Борнаш (1898—1942), К. Тинчуринның (1887—1938) драматургия, атаклы артистлар Г. Кариев (1886—1920), Г. Мангушев (1887—1919) һәм З. Султановның (1892—1952) сәхнәдәге, С. Сәйдәшев (1900—1954) һәм Ф. Яруллинның (1917—1943) музыка өлкәсендәге эшчәнлеге яктыртылыш тапкан. Биредә аларның барсының да фоторәсемнәре дә урнаштырылган.

Мәҗмугада еш кына төрле урыннарда дөнья күргән яңа татар китапларына

һәм башка басмаларга күзәтү ясап барыла. Анда шулай ук уку-ятлау өчен татар авыз иҗаты әсәрләре, милли җыр-бию үрнәкләре, милли аш-су хәзерләү һәм тормыш-көнкүреш өчен кирәкле башка киңәшләр тәкъдим ителеп тора.

1980 елда, 23 санынннан соң, матди-финанс авырлыклар аркасында, «Казан» журналы чыгуыннан туктарга мәҗбүр була. Артык озак яшәмәсә дә, әлеге мәҗмуга, чит илләрдә тормыш итүче милләттәшләребезне берләштерүче, аларның рухи көчләрен, милли гореф-гадәтләрне, телне, мәдәниятне саклау өчен көрәшүче буларак, татар мөһаҗирләре матбугаты тарихында лаеклы урын биләп тора.

Кайбер чыганаклардан күренгәнчә, Икенче бөтендөнья сугышыннан соң Төркиядә хәрби академия профессоры генерал Мәҗис Акмар нәширлегендә татар телендә «Идел-Урал» дип аталган журнал да чыгып килә. Бу мәҗмугада генерал Хәсән Салихов хезмәттәшлек итә.

Татар һәм төрек матбугаты арасындагы бәйләнеш безнең көннәргә кадәр дәвам итә. 1993 елның апреленнән башлап, Казан шәһәрендә татар һәм төрек телләрендә халыкара иҗтимагый-сәяси, мәдәни «Zaman-Татарстан» газеты нәшер ителә. Аның Татарстандагы хәзерге баш мөдире—Туфан Доган, баш мөхәррире—Алик Гарәфетдин.

1915—1916 елларда Венгриянең Эстергам шәһәре янында мөселман хәрби әсирләре өчен төзелгән лагерьда (анда 5000 нән артык кеше булган) татар телендә «Кечкенә җуаткыч» дип аталган кульъязма газет чыгарыла. Газет аена бер мәртәбә яшерен рәвештә чыгарылган. Аның сәхифәләрендә халык җырлары, әсирләрнең үз шигырьләре, хатирәләре һәм Беренче бөтендөнья сугышы турында фикерләре урнаштырылып килгән.

1915 ел башында Алмания башкаласы Берлиннан 40 километрдагы Вюнсдорф тимер юл станциясендә урнашкан Цоссен шәһәрчегендә Русия, Бөекбритания һәм Франция армияләреннән әсирлеккә төшкән мөселман хәрбиләре өчен лагерь төзелгән. Ул рәсми рәвештә 1922 елның маена кадәр яшәп килгән. Лагерьда татар, башкорт, Кавказ халыклары вәкилләре, гарәп һәм һиндләр тоткынлыкта булганнар.

Төрле чыганаклардан күренгәнчә, алар арасында 15 меңнән берничә дистә меңгә кадәр солдат һәм ике йөздән артык офицер булган.

Немец армиясе генераль штабы, әлеге мөселман әсирләренең Алманиягә карата илтифатын яулап алу максаты белән, үзенең махсус Көнчыгыш бүлеге аркылы, киң күләмле оештыру һәм агитация эшләре алып барган. Генераль штаб акчалары хисабына, әсирләрнең дә актив катнашуында, мәһабәт, зур гөмбәзле, биек манаралы ике катлы мәчет, укый белүчеләр өчен китапханә, белемсезләрне уку-язуга өйрәтү максаты белән мәктәп, физик культура белән шөгыльләнү өчен спорт корылмалары төзелгән, матбугат басмалары чыгару оештырылган. Мәсәлән, немец һәм кайбер Кавказ халыклары телләрендә «Кавказ» исемендәге гомумлагерь газеты чыгарылган.

1916—1920 елларда Вюнсдорфтагы әсирләр лагеренда татар телендә 5 газет нәшер ителүе турында мәгълүматлар бар. Шуларның икесе 1916—1917 елларда чыгарылган. Беренчесе—ике атнага бер тапкыр дөнья күреп килгән «Әл-җиһад әл-ислам» *(«Исламның изге сугышы»)* газеты типографик, ә икенчесе—«Әл-җиһад» *(«Изге сугыш»)* газеты гектографик (җилем басма) ысулы белән чыгарылган. Беренчесенең нәширләре һәм мөхәррирләре Габделрәшит Ибраһимов (Рәшит казый) һәм Галимҗан Идриси булган.

Күренекле публицист, җәмәгать, дин һәм әдәбият эшлеклесе Габдерәшит Ибраһимов татар вакытлы матбугаты гамәли оештыручыларының иң беренчеләреннән булган. Ул 1900—1909 елларда татар телендә журнал тибындагы «Миръат» *(«Көзге»)* исемендәге җыентыклар сериясен, 1905—1908 елларда—«Өлфәт» *(«Бердәмлек»)*, «Нәҗат» *(«Котылу»)* һәм «Ватан хадиме» *(«Ватан хезмәтчесе»)*, гарәпчә—«Әт-тилмиз» *(«Укучы»)* һәм казах телендә «Сиркә» *(«Җитәкче»)* газетларын чыгарып килгән. 1915 елда ул әсирлеккә төшкән татар хәрбиләренең бер өлешен азат итү һәм аларны Төркиягә озату максаты белән Алманиягә килгән була.

Журналист, җәмәгать һәм дин эшлеклесе Галимҗан Идриси Истанбул университетын тәмамлаган, Лозанна (Швейцария) һәм Льежда (Бельгия)

философия һәм телләр өйрәнгән, тугыз телдә сөйләшкән, Оренбургта нәшер ителгән «Вакыт» газетының чит илләрдәге хәбәрчесе булган. 1914—1915 елларда ул—Истанбулда чыккан «Төрек йорты» журналының икенче мөхәррире һәм 1915 ел ахырыннан Алманиядә яши. 1916—1922 елларда Г. Идриси мөселман хәрби әсирләренең Вюнсдорфтагы лагеренда имам һәм аның житәкчесе булып хезмәт итә.

1918 елда Вюнсдорф станциясендә урнашкан Цоссен шәһәрчегендә татар милли хәрәкәтендә актив катнашкан офицерлар Усман Токумбетов һәм Йосыф Мозаффаров әсирләр арасында тарату өчен татар телендә газет чыгаруга керешкәннәр. Кызганыч, архив документында бу газетның исеме күрсәтелмәгән.

Моннан соң Вюнсдорф лагеренда әсирләр өчен татар телендә тагын ике газет чыгарылган. Аларны оештыруга лагерь житәкчесе һәм имамы хезмәтен үтәүче Галимҗан Идриси зур көч куйган. Газетларның берсе «Яңа тормыш», ә икенчесе «Татар иле» дип аталган була.

1919—1920 елларда нәшер ителеп килгән «Татар иле» газеты үзенең тышкы күренеше белән журналга охшаш булган: айга ике мәртәбә сигезәр биттә бастырылган. М. Мәһдиев раславынча, бер чыкканда газетның гомум тиражы 2000 данә, сатып алучылары саны 200-300 кешегә житкән. Газет мөселман хәрби әсирләренең Алманиядәге барлык 32 лагеренда һәм төрле уку йортларында белем алучы студентлар арасында таратылган. Ул чакта Берлин шәһәрендә «Русияле Ислам шәкертләренә ярдәм итү жәмгыяте» яшәп килгән була.

Әлеге газетның нашире һәм баш мөхәррире вазифаларын Бәдретдин Сәйфелмөлеков башкарган. Бу шәхес Ырынбурда бай сәүдәгәр гаиләсендә туган, Истанбулда солтан көллиятендә укыган, Льежда (Бельгия) югары белем алган теш табибы була, Беренче бөтендөнья сугышы башлангач, Берлинда хәрби разведка органнарында хезмәт иткән.

«Татар иле» газетына югарыда әйтелгән Галимҗан Идриси аеруча актив язышкан. Анда еш кына шагыйрь Габдулла Мостакаев (Биги) үзенең шигырьләрен бастырып килгән. Хәбиб Фәйзи исә даими рәвештә лагерь тормышын яктыртып торган. Аның язмаларыннан әсирләр янына күренекле татар жәмәгать эшлеклесе Йосыф Акчураның кунакта булып киткәнлеге, лагерьда дини бәйрәмнәр, сабантуйлар, үзешчән сәнгать, халык инструментлары оркестры концертлары һәм спорт ярышлары уздырылып торганлыгы күренә.

Газет битләрендә жирле немец авторлары да катнашкан. Мәсәлән, әсирләр белән күп аралашкан немец Пипр, әлеге басманың 1920 ел 1 февраль санында дөнья күргән мәкаләсендә татарларны: «Тырыш, иткән яхшылыкны танучан вә кайтаручан, намуслы, саф көенчә калган вә бер дә бозылмаган бер халыктыр»,—дип бәяләгән.

«Татар иле» газетының 8 саны дөнья күргәнлеге билгеле. Бу саннарның тегелмәсе, азат ителгән татар әсирләренә, туган жирләренә китәр алдыннан, истәлек рәвешендә бүләк ителгән. Тегелмә тышлыгының беренче битендә Вюнсдорфтагы мөселман мәчетенең мәһабәт фоторәсеме, ә арттагы битендә—1920 елда булачак мөселман дини бәйрәмнәренең календаре урнаштырылган була.

1923 елда Берлин шәһәрендә мөһажирләрнең төрки-татар телендә «Азат Шәрек» исемендәге журналы нәшер ителгән. Анда Гаяз Исхакый, Фуад Туктаров, Мехмет Әмин Рәсүл-заде һәм башкалар хезмәттәшлек иткәннәр. Журналның 21 нче саны чыкканы мәгълүм.

1923 елның көзендә Берлинда, Гаяз Исхакый инициативасы белән, билгеле татар, башкорт һәм казакъ мөһажирләре Садрый Максуди, Габделбари Баттал, Гомәр Терегулов (Тәңреколый), Фуат Туктаров, Ибраһим Акчурин, Абдрахман Шәфиев (Шәфи Алмас), Зәки Вәлиди, Мостафа Букейханов һәм башкалар катнашында үткәрелгән кинәшмәдә татар телендә «Милли юл» исемендәге журнал чыгару турында карар кабул ителгән.

Матди финанс һәм башка авырлыклар булу сәбәпле, әлеге карар бары тик биш ел үткәннән соң тормышка ашырыла алган.

1928 елның 23 декабрендә Берлинда сәяси, әдәби, гыйльми, икътисади «Милли юл» журналының беренче саны дөнья күрә. Ике елдан соң ул «Яңа

милли юл» исемен ала. Журналның нигезен салучы, мәсъүл мөхәррире һәм төп авторы Гаяз Исхакый була. Биредә аның йөзләгән мәкаләләре басылган. Басманың 1-19 саннарында баш мөхәррир дип К. Русак күрсәтелгән. Бу журналның барлыкка килүе тарихын һәм әдәбиятен тасвирлап, соңрак Г. Исхакый болай дип яза: «Ниһаять, 1928 елда Балтыйк дәүләтләрендәге агай-эне торган бөтен җирләрне шәһәр-шәһәр йөреп акча җыйдым вә шуның белән берлә «Милли юл» мәҗмугасын кордым. Укырга сусаган халкыбыз «Милли юл»ны зур сөенеч белән каршылады. Мөһаҗирәттәге зыялыларыбыз аның тирәсенә җыелды. Бөтен төрек-татар аңа сырылды. Ул Аурупа, Азия һәм Американың төрле шәһәрләренә таралган милләттәшләребезнең бердәнбер җитәкчесе урынын алды».

Журнал чыгаруны оештыруга Г. Исхакыйның Казан укытучылар мәктәбендәге сабакташы һәм дусты Гомәр Терегулов та (Тәңреколый) үзеннән зур өлеш кертә. 1934 елга кадәр баш мөхәррирнең урынбасары булып күренекле язучы, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе Фатих Кәриминең туган энесе Гариф Кәримов хезмәт иткән. Берлин университетын тәмамлаган һәм соңгарак мәшһүр тарих һәм тел галименә әверелгән Рәшит Рәхмәти-Арат журналны бастыру һәм тарату эшләре белән шөгыльләнгән. Ул актив автор да булган. Журналда аның Али Биктимер, Шакир Йосыф, Рәхмәти Арат псевдонимнары белән татар тарихы һәм мәдәниятенә багышланган байтак хезмәтләре пәйда булган. Журналны нәшер итү һәм таратуда Абдрахман Шәфиев (Шәфи Алмас) та катнаша. Аның Берлиндагы йортында басмаханә һәм склад урнашкан була.

1939 елның октябренә кадәр, унбер елга якын дәвердә, журналның 136 саны дөнья күргән. Аларның барысы да, 1929—1930 елларда Варшавада чыккан берничә санынннан тыш, Берлинда бастырылган. Язмалар гарәп графикасына нигезләнгән. Журналның йомшак тышлыкларында нашир һәм баш мөхәррир Г. Исхакый исеме, һәр саны һәм аның чыгуы вакыты, редакция адресы немец телендә язылган. Журналның теле—татарча. Кырым татарлары, төрек һәм башка кайбер төрки телләрдәге текстлар да очрый. Басманың күләме төрлечә: 16 биттән 42 биткә җиткән саннары бар.

Журналның матди-финанс хәле җинел булмаган. Ул, нигездә, чит илләрдә яшәүче милләттәшләрдән ярдәм рәвешендә килгән акчалар хисабына эшен дәвам иткән. Шуның белән беррәттән, журналны бастыру өчен акчаның күбесе Польша армиясе генераль штабының сәяси разведка белән шөгыльләнгән II бүлеге махсус фондыннан килеп торганлыгы да билгеле. Шуңа күрә редакция хезмәткәрләренә поляк хәрбиләре өчен төрле-төрле информацион мәгълүматлар җыю белән шөгыльләнергә туры килгән.

Г. Исхакый, үз тәҗрибәсенә нигезләнеп: «... чит мәмләкәттә мәҗмуга чыгару Казанда да Мәскәүдә чыгару кебек җинел түгелдер. Аның чыгышы вә мәшәкате дүрт-биш мәртәбә авырректыр. Бигрәк тә таратылуы уйлап бетерә алмаслык дәрәҗәдә унайсыздыр»,—дип ассызыклаган.

«Милли юл» журналын акчалата язып алдыручылар күп булмаган. Шунлыктан аның күпчелек саннары агентлары тарафыннан якын урыннарда кулдан, ә Төркия, Финляндия, Балтыйк буе, Ерак Шәрек һәм башка илләрдә почта аша бушлай таратылган.

Мәҗмуганың Советлар Союзында таратырга билгеләнгән, папирос кәгазендә бастырылган һәм конвертларга төрелгән, һәр чыгарылышы 200 гә якын данәдә, дипломатик почта белән Польшаның Мәскәүдәге илчелегенә җибәрелгән. Һәрбер конверт тышында Г. Исхакый һәм аның хезмәттәшләре язган, конкрет адресат күрсәтелгән була. Польша илчелеге йомышчылары, әлеге журнал төрелгән конвертларны күрсәтелгән адресатларның почта ящикларына илтеп сала торган булганнар.

Журналның авторлар коллективын, башлыча, Кытай, Япония, Төркия, Финляндия, Алмания, Польша, Румыния һәм башка илләрдә яшәгән татар мөһаҗирләре тәшкил иткән. Алар арасында күренекле каләм осталары Сания Гыйффәт, Закир Кадыйри, Хөсәен Габдуш, Хәсән Хәмидулла, Ләбиб Каран, Финляндиянең мәшһүр имамы Вәли Әхмәд Хәким, Кытайда нәшер ителгән «Милли байрак» газеты мөхәррире Рокыя Мөхәммәдиш, фин шәһәре Тампередагы

татарларның мәдәни тормышын оештыручы Мәхрүсә Вафа һәм башкалар бар. «Милли юл»—«Яңа милли юл» журналының төп максаты, аның исеменнән күренгәнчә, татар халкының тарихи үсеш юлын һәм аның милли азатлык өчен көрәш бурычларын яктыртудан гыйбарәт булган.

Шул максаттан чыгып, мәҗмуга татарлар арасындагы милли-азатлык хәрәкәте, аның 1917—1918 елларда аеруча көчәеп китүе турында тарихи материаллар бастырган. Әлеге басма сәхифәләрендә, мәсәлән, демократик татар дәүләте—»Идел-Урал штаты»н төзү хакында тарихта билгеле карарны кабул иткән «Милли мәҗлес»нең 20 еллыгы киң яктыртылыш тапкан. Журнал бу юбилейга багышлап, 1938 елда Варшавада үткәрелгән Бөтендөнья төрки-татар корылтае турында тәфсилләп язган, махсус фоторепортаж урнаштырган. Ул шулай ук Варшава радиосы буенча Гаяз Исхакый ясаган чыгышның тулы текстын халыкка житкергән. «Яңа милли юл» бертуктаусыз диярлек Идел-Урал штаты»н барлыкка китерү өчен көрәшергә чакырган, аның булачак территориясе контурларын, идарә һәм хакимият органнарын тасвирлаган.

Журнал битләрендә татар һәм кайбер башка төрек халыкларның Шиһабетдин Мәржани, Каюм Насыйри, Исмәгыйль Гаспралы, муса Акъегетзадә, Габдулла Тукай, Ризаэтдин Фәхретдинов, Габдерәшит Ибраһимов, Йосыф Акчура, Фуад Туктаров, Гомәр Терегулов, Кырым халык шагыйре Мөхәммәд Ниязи бек кебек атаклы җәмәгать, сәяси һәм дин эшлеклеләре, әдәбият классиклары һәм милли матбугатка нигез салучыларның тормыш юлы, эшчәнлеге һәм тарихта калдырган мираслары турында кыйммәтле язмалар урын тапкан. Аларның күбесен Гаяз Исхакый язган. Басма тышлыкларында күбесенең фоторәсемнәре һәм портретлары урнаштырылган. Тышлыкларда шулай ук аеруча күренекле шәхесләр иҗат иткән әдәби әсәрләрдән, эпиграфлар рәвешендә тәэсирле әйтемнәр һәм өзекләр бастырылып килгән. Бередә XIV гасыр татар сугышчысын, Польшадагы татар атлы гаскәрен (1660 ел) һәм Наполеонның татар гвардиясен сурәтләүче өч картинаның репродукцияләре бар. Алар Польша мөселманнарының милли музееннан алынган.

Журнал, үткәндәге тарихи вакыйгалар белән беррәттән, агымдагы, хәзерге вәзгыять, дөньяда бара торган иҗтимагый-сәяси үзгәрешләр, төрле ил халыкларының күпкырлы тормышын даими яктыртып килгән. Аерым алганда, ул Советлар Союзында большевиклар үткәрә торган урыслаштыру сәясәтен, дин һәм аның әһелләрен рәхимсез эзәрлекләү, крестьян хуҗалыкларын көчләп күмәкләштерү, сәяси репрессияләр һәм башка тискәре күренешләрне кискен тәнкыйтьләгән. Шундый язмалар арасында Гаяз Исхакый каләме астыннан чыккан «Милләтләр хокукы һәм урыс шовинизмы», «Большевиклык-урысчылык», «Большевикларның динемезгә каршы золымнары», «Икътисади торгынлык», «Татарстан тоташтан колхозлаштырыла», «Советлар төрек халыклары өчен урыс әлифбасы», «Большевикларның соңгы уены», «Русиянең киләчәге» дигән һәм башка мәкаләләр дә бар.

«Милли юл» сәхифәләрендә чит илләр буенча сибелгән татарларның яшәеше турындагы хәбәрләр дә аз түгел. Бигрәк тә Финляндия һәм Ерак Көнчыгышта нигезләнгән татар кешеләренең иҗтимагый һәм сәяси тормышы киң яктыртылган. Журналда Сания Гыйффәт, Хөсәен Габдуш, Мансур Арысланбек һәм башкаларның әдәби әсәрләре урын алган. Анда шулай ук татар һәм кайбер башка төрки халыкларның әдәбияты тарихына багышланган язмалар да бар.

Г. Исхакый журналы, билгеле бер дәрәҗәдә, татар мөһаҗирләренең барлык матбугаты өчен рухи юнәлеш бирүче үзәк булып хезмәт иткән. Ул туган телдә дөньяга килгән яңа газет-журналлар турында хәбәр итеп, аларга тәбрик сүзләре, үзенең киңәш-тәкъдимнәрен һәм нәсыйхәтләрен юллаган. Мәҗмуга еш кына көндәлек матбугат басмаларының агымдагы эшчәнлегенә күзәтүләр биреп килгән, кайберләренең әһәмиятле язмаларын үз сәхифәләрендә күчереп бастырган. Мәсәлән, ул Кытай шәһәре Мукденда Г. Исхакый нигезләгән атналык «Милли байрак» исемле газетаның 1935 елның 1 ноябрендә чыккан беренче санына җентекле күзәтү бастырган. «Яңа милли юл» шул ук шәһәрдә 1934 елдан бирле нәшер ителгән «Шәкердләр таңы» исемле яшьләр журналының ике еллык юбилеен котлау сүзләре белән билгеләп үткән.

Журналның игътибарыннан шулай ук башка төрки телләрдә чыга торган мөһаҗирләр матбугаты да читтә калмаган. Аның битләрендә, мәсәлән, кырым-татар телендәге «Әмәл» журналы, әзәрбәйҗанча «Истикъляль» газеты, «Яшь Төркестан» журналы һәм башка басмаларның тарихы һәм эчтәлеге хакында шактый киң мәгълүматлар бәян ителгән.

Мәҗмуга даими рәвештә үзенең укучыларына чит мәмләкәтләрдә татар һәм төрек телләрендә бастырылган яңа китаплар турында да хәбәрләр биреп килгән.

СССР—Алмания пактына кул куелгач һәм Икенче бөтендөнья сугышы башланганнан соң, озакламыйча, алман хакимиятләре боерыгы буенча, 1939 елның октябрендә «Яңа милли юл» журналы чыгарудан туктатыла. Аның хезмәткәрләре төрле якларга таралыша. Нашир һәм баш мөхәррир Гаяз Исхакый бераз вакыт Лондонда һәм Парижда яшәгәннән соң, Төркиягә барып урнаша һәм, 1954 елда вафат булганчыга кадәр, шунда яши.

Үзенең чыгуы озаклыгы, авторлар составы, бастырылган язмалар тематикасы төрлелеге буенча, «Милли юл»—«Яңа милли юл» татар мөһаҗирләре чыгарган барлык газет-журналлар арасында аеруча күренекле урын тота. Аны, нигезле рәвештә, Гаяз Исхакыйның иҗтимагый-сәяси һәм иҗади эшчәнлегенең елъязмасы, милли азатлык өчен көрәш мөнбәре дип бәяләргә мөмкин.

Г. Исхакыйның: «... киләчәк буыныбыз гына «Милли юл»ның хезмәтләренә дә, эшләренә дә бәһане бирә белмәктер»,—дип алдан күреп әйткән зирәк сүзләре тулысынча раслана бара. Совет чорында бары тик кара буяуларда гына тасвирланган әлеге журналның эшчәнлеге бүгенге галимнәрнең (Х. Миннегулов, Р. Гайнетдинов һ. б.) дөнья күргән фәнни хезмәтләрендә унай һәм югары бәяләнә.

Икенче бөтендөнья сугышы вакытында Алманиядә татар мөһаҗирләренең тагын берничә вакытлы матбугат басмалары чыгып килгән. Яшь галим Искәндәр Гыйләҗев хезмәтләреннән күренгәнчә, ул чак алман шәһәрләрендә казан татарлары телендә, латиница нигезендә, «Идел-Урал» һәм «Төрек берлеге» газетлары белән «Татар әдәбияты» һәм ике телдәге «Германча-татарча белешмә. Deutsch-Tatarisches Nachrichtenblatt» журналлары нәшер ителгән.

Мондый басмаларның барлыкка килүенә һәм эшчәнлегенә Германиянең Көнчыгыш министрлыгы һәм вермахтның югары командованиесе булышлык иткән. Әлеге эштә аеруча зур роль арадашлык итүче милли вәкиллекләргә туры килгән. Газет-журнал редакцияләре дә шул вәкилләкләр белән бер бинада урнашкан булган. Төрле телләрдәге матбугат басмалары совет хәрби әсирләре, шул хисаптан, милли гаскәри легионерлар, Советлар Союзының басып алынган районнарыннан куып китерелгән эшчеләр һәм Алманиядә электән үк яшәүче төрле милләт халкы арасында таратылган.

Югарыда әйтелгән көндәлек матбугат басмалары арасында чыгу озаклыгы һәм дөнья күргән саннары күплеге буенча беренче урында Идел татарлары легионы нәшере «Идел-Урал» газеты булган. Ул даими рәвештә 1942 елның 15 ноябреннән атнага бер тапкыр, гадәттә дүртәр, ә кайбер очракларда исә—алтышар һәм урталай бөкләнгән сигезәр биттә чыгып килгән.

Газетның редакциясе Берлинда, 1945 елның гыйнварыннан—Потсдамда урнашкан була. Ул «Deutscher Verlag» нәшриятының басмаханәсендә чыгарылган. Атналык «Идел-Урал»ның барлыгы 100 дән артыграк саны чыккан булырга кирәк. И. Гыйләҗев әйтүенчә, бу басманың 1944 ел 23 июнендә дөнья күргән 25 (82) саны хәзергәчә Берлин китапханәсендә сакланып калган.

«Идел-Урал» газетына нигез салучыларның берсе, тарихчы, юрист, җәмәгать эшлеклесе Тимурбек Дәүләтшин булган. Ул 1938—1941 елларда Бөтенсоюз юридик институтының профессоры, Татарстан Югары Советы Президиумы каршындагы юридик бүлек җитәкчесе булып эшләгән, 1942 елда немец әсирлегенә эләккән. Үзенең автобиографиясендә ул болай дип язган: «Бер татар кешесе белән (сүз Шәфи Алмас хакында бара булырга кирәк. Т. Н.) хәрби әсирләр, басып алынган өлкәләрдән китерелә башлаган көнчыгыш эшчеләре һәм Алманиядә яшәгән башка татарларга хәбәрләр биреп тору өчен татар телендә газет чыгаруга керештек. Ләкин беренчеме, йә икенчеме саныннан соң, әлеге газет ул чак оештырылып килүче татар легионы

органына әверелде. Редакция легионерлар белән тулыландырылды. Мөхәррир итеп әлегегә кадәр таныш булмаган бер яшь легионер билгеләнде. Минем легионга мөнәсәбәтем булмады, ләкин газетта хезмәттәшлекне дәвам иттем».

Газетның баш мөхәррире Кыям Галиев булган. «Идел-Урал» редакциясендә бераз вакыт әсирлеккә төшкән язучы Абдулла Алиш тәрҗемәче, журналист Рәхим Саттар фотокорреспондент һәм инженер Фуат Булатов хәреф җыючы булып эшләгәннәр.

Газет сәхифәләрендә аны нигезләүче һәм рухи юнәлеш бирүчеләрнең берсе Шәфи Алмас (Абдрахман Шәфиев) аеруча актив катнашкан. Ул—Сембер фабрикантлары Акчуриннарның кияве, Мәскәүдә Төркия илчелегендә, ә алман-совет сугышы вакытында Германиянең Көнчыгыш министрлыгының әйдәүче хезмәткәре һәм хәрби әсирләрдән төрки-татар милли легионнарын оештыручылардан булган.

«Идел-Урал» газетының бер еллыгына багышлап һәм 1943 елның 14 ноябрендә дөнья күргән 46 (52) санында Шәфи Алмас бу басманы: Берлинда җыелган берничә сәясәтченең газеты гына түгел, ә асылда—1917—1918 еллардагы «Милли мәҗлес»нең дәвамчысы һәм аның карарларын тормышка ашыру өчен көрәшүче дип атаган. Әлеге газетада ул «бөек Алмания» ярдәм итә торган татар легионерлары кылган эшләрне хокукый дип бәяләгән, чөнки алар, янәсе, «Милли мәҗлес» игълан иткән «Идел-Урал штаты»н булдыру өчен көрәшкәннәр.

«Идел-Урал»ның төп материаллары татар телендә бастырылган, ә 1944 ел 5 марттагы 5 (66) санынннан алып, аның Урта Идел халыклары телләрендәге кушымталары чыгарыла башлаган. Бу көнне чуаш телендәге беренче кушымта дөнья күргән. Ул аннары атна саен чыгуын дәвам иткән. Күрәсең, бер газет күләме генә мондый башлангыч өчен җитәрлек булмаган. Шуңа күрә 1944 елның июленнән башлап, Идел татарлары легионындагы чуаш, мари, мордва һәм удмуртлар өчен билгеләнгән «За национальную свободу» исемле газетны нәшер итүгә керешкәннәр. Аның алдагы ике бите урыс һәм калган ике бите әлеге милли телләрдә чыгарылган. Газетның баш мөхәррире чуаш Ф. Пулод булган.

1944 ел сентябрь ае башында, совет әсирләреннән эсэсчыларның Көнчыгыш-төрки хәрби легионын төзү башлану белән бер үк вакытта, аның басма органы—«Төрек берлеге» («Идел-Урал») газетын чыгару турында да сүз кузгала. Әлеге гомумтөрки газет редакциясенә җитәкче итеп немец Винанде, төркестанчылар, әзәрбәйҗаннар, Кырым һәм Идел буе татарларыннан берәр шеф-мөхәррирләр кертелә. 1945 ел башында «Төрек берлеге»нең Идел буе татарлары редакциясендә шеф-мөхәррир Шиһап Нигъмәти, Миннегол Гарипов, Константин Харченко (Хәмит Науруз), Барый Фәтхуллин, Фатих Азизбаев һәм Әсфәндияр Чанбаевлар эшләгән. Шул ук вакытта, Идел буе татарлары басмасында, татар телендәге язмаларыннан тыш, урыс, башкорт, чуаш, удмурт, мордва һәм мари телендәгеләре дә дөнья күреп килгән.

1944 елның 8 ноябрендә Берлинда «Deutscher Verlag» басмаханәсендә «Төрек берлеге»нең Идел буе татарлары телендәге, сынау өчен хәзерләнгән саны нәшер ителгән. Аның чираттагы саннары, өч-дүрт атна саен бастырылып килгән һәм 1945 ел марты ахырына кадәр 5 саны чыккан. Һәрбер санының тиражы 1400 данә тәшкил иткән.

1943 елның апрелендә Берлинда Татар милли вәкиллеге, сәяси-агарту максаты белән, ике телдәге «Германча-татарча белешмә. Deutsch-Tatarisches Nachrichtenblatt» журналын чыгаруга керешкән (кайчакта, тышкы күренеше буенча, аны газет дип тә атаганнар). Журналның баш мөхәррире Гариф Солтан булган. Журналның немец телендәге өлешендә, алманиялеләрнең җитәрлек дәрәҗәдә хәбәрдар булмауларын искә алып, татар һәм башка төрки халыкларның тарихы, мәдәнияте, милли традицияләре һәм гореф-гадәтләрен яктыртуга төп игътибар бирелгән. Баш мөхәррир сүзләренчә, журналның татар телендәге өлеше үзирекле берләшмәләрдә пропагандистик материал итеп файдалану өчен хезмәт иткән.

Журналның күпме вакыт дәвамында һәм ничә санда чыгуы әлегәчә мәгълүм түгел. Аның хәзергәчә табылган 14 санында: 1944 елның 20 июлендә

Свиномюнде (хәзерге Польшаның Свиноустье) шәһәрендә «Германча-татарча белешмә. Deutsch-Tatarisches Nachrichtenblatt» журналының берьеллык юбилеена багышланган тантаналар турында язылган.

1944 ел урталарында Алмания башкаласында «Идел-Урал төрек татарларының көрәш берлеге» басмасы буларак, «Татар әдәбияты» исемле тагын бер яна журнал барлыкка килгән. Аның баш мөхәррире—Шәфи Алмас, ә мөхәррирләре—Әнвәргали Айдагулов һәм Г. Хәмиди булган. Журналның эчтәлеге житәрлек тәгаллек белән аның исеменә туры килгән. Аның сәхифәләрендә татар әдәбияты тарихы турындагы материаллар, хикәяләр, шигырьләр, пьесалар, очерклар һәм башка әдәби әсәрләр пәйда булганнар.

Икенче бөтендөнья сугышыннан соңгы чорда Алманиядә татар телендә тагын берничә газет-журнал дөнья күрә. 1947—1948 елларда Ной Ульм шәһәрендә Габделхалик Алимзадә мөхәррирлегендә «Очар яфраклар» газеты чыгарыла. 1952—1953 елларда югарыда искә алынган Тимурбек Дәүләтшин тарафыннан төзелгән татар-башкорт милли комитеты басмасы буларак, Мюнхен шәһәрендә латин хәрефләре белән «Азат Ватан» исемле әдәби, сәяси журнал чыгып килә. Журналның барлыкка килүе турында, әлеге шәхес болай дип язган: «1951 елда Мюнхенгә килгәч, ул чак әле шактый күпсанлы (башка илләргә мөһажирлеккә киткәнче) татар һәм башкортларга мәдәни, икътисади һәм хокукый ярдәм күрсәтүне ин якындагы максаты итеп куйган татар-башкорт комитетын оештырдым. Әлеге комитет бераз вакыт татар телендә «Азат Ватан» дигән журнал чыгарды». Журналның мөхәррире Әкрам Фәйзуллин булган.

Сугыштан соңгы 40-60 елларда Алманиядә татарча газет-журналлар чыгаруда Минһаж Исмәгыйли дә катнаша. Аның катнашында, барлыгы 10 санда «Безнең фикер» һәм 2 санда «Таң йолдызы» исемле милли, әдәби, сәяси мәжмугаларның, шулай ук «Урал авазы» һәм «Азат Ватан» дигән газетларның нәшер ителүе турында аерым мәгълүматлар бар.

Гомумән алганда, алман илендә XX гасырның төрле елларында татар телендә 17 газет-журнал дөнья күргән.

XIX гасыр ахырыннан алып, төрле сәбәпләр аркасында—1897—1903 елларда Кытайның Көнчыгыш тимер юлы (КВЖД) төзелгәндә, 1904—1905 еллардагы урыс-япон сугышы вакытында һәм бигрәк тә, 1917—1920 елларда Русиядә булган Октябрь революциясеннән һәм Гражданнар сугышыннан соң, күпсанлы татарлар Ерак Көнчыгыш илләре—Кытай, Япония һәм Кореягә күченеп урнаша, яисә әсирлектә тоткарланып кала. Тора-бара аларның төрле милли, сәяси, әдәби, мәдәни, хатын-кызлар, яшьләр һәм башка оешмалары төзелә, мәчетләре, уку йортлары эшли башлый.

1920 еллардан башлап, Кытайда һәм Японияда татар мөһажирләренең вакытлы матбугаты барлыкка килә, китаплары чыгарыла. 1917 ел октябренә кадәр алар ана телендәге газет-журналларны һәм китапларны туган якларыннан, Русиянең милли төбәкләреннән алдырганнар. Совет хакимияте большевистик булмаган басмаларны чыгарудан туктатканнан соң, мондый мөмкинлек калмый. Рухи ихтыяжны канәгатьләндерү, милли бердәмлекне, мәдәниятне саклау омтылышы татар мөһажирләрен үз матбугатын нигезләүгә этәрә.

Татар мөһажирләренең көндәлек матбугаты Ерак Көнчыгышта иң әүвәл һәм иң күп булып Кытайның Харбин шәһәрендә пәйда була. Һәм бу табигый ки, чөнки 1920 еллар башында әлеге шәһәрдә Ерак Көнчыгыш илләрендәге татар мөһажирләренең, шул хисаптан, Гражданнар сугышы чорында Колчак-Каппель гаскәрләрендә хезмәт иткән татар хәрбиләренең дә иң күп өлеше шушы калада тупланган була.

Бу хакыйкатьне, Ерак Көнчыгыш илләренә 1933 елда ясаган сәфәреннән соң, Гаяз Исхакый да билгеләп үтә: «Харбин Ерак Көнчыгышта төрки-татар колониясенең иң күптәнге үзәге. Инде 30 еллап монда мөселман мәхәлләсе, мәктәп, мәчет бар. Ә ана хәтле монда бай татар сәүдәгәрләре үзәге булган... Инкыйлабтан соң, Харбин Ерак Көнчыгыш төрки-татарларның иң зур эмиграция үзәгенә әверелгән. Монда мәдәният эшләре киң колач белән алып барылган. Фәнни-мәгърифәт һәм әдәби эшчәнлек көчәеп киткән, татар телендә газета чыккан. Боларның бөтенесе дә Татар йорты тирәсендә

тупланган. Бу йорт китапханәне, тамаша залын һәм барлык татар оешмаларын (яшьләр, хатын-кызлар, спортчылар мәктәпләрен һ. б.) үзенә сыендырган».

Мөһаҗирләр матбугаты башта гарәп хәрефләре белән кулъязма журналлар һәм газетлар рәвешендә дөнья күрә. Аннары шуларны гектография һәм литография ысулында күбәйтәләр. Заманча типография корырга теләкләре булса да, мөһаҗирләрнең моның өчен шактый вакыт матди мөмкинлекләре булмый.



*«Ерак Шәрык» журналының тышлыгы*

Харбинда шундый басмаларның беренчесе буларак, «Ерак Шәрык» журналын 1920–1922 елларда Гиниятулла Әхмәди, Хөсәен Габдуш һәм Рәшит Рәхмәти мөхәррирлегендә татар җәмгыяте нәшер итә. 1922 елда, 31 санынннан соң, журнал чыгуыннан туктап тора. 1924 елда, аның дәвамы буларак, шул ук «Ерак Шәрык» исеме белән газет дөньяга килә һәм 10 (50) санына кадәр чыга. 1925 елда, 51-57 саннары пәйда булгач, әлеге газет яшәвен тәмамлый. 1923—1924 елларда татар яшьләре өчен «Ялкын» журналы нәшер ителә. Хөсәен Үтәш «Пилмән» дигән сатирик басма чыгарып килә.

Харбинда бер көнлек газетлар чыгару да оештырыла. Мәсәлән, 1922 елның 28 маенда, Идел буе болгарларының Ислам динен кабул итүенә мең ел тулу уңае белән, «Мең ел» исемле зур күләмле, дүрт сәхифәле бер көнлек газет чыгарыла. Матур каллиграфик кулъязма белән башкарылган бу газет яхшы сыйфатлы кәгазьдә, яшел буяу белән, таш басмаханәдә күбәйтелеп бастырыла. Анда Гиниятулла Әхмәди, Газиз Сакмари, Хөсәен Габдуш, Ярулла Вәли, Мөхәммәтсалих Хәбиров кебек күренекле татар эшлеклеләренең мәкаләләре урнаштырыла.

1927 елда Төркия латин әлифбасына күчә. Шунлыктан анда гарәп хәрефләренә ихтыяҗ калмый һәм аларның бәясе күпкә арзаная. Мөһаҗирләр арасында иганә җыю оештырыла һәм Төркиядән гарәп шрифтлары Кытайга һәм Япониягә кайтарыла. Татар телендәге барлык газет-журналлар типографик ысулда чыгарыла башлый.

1932 елда Харбин шәһәрендә Хөсәен Габдуш «Чаткы» газетын чыгаруны җайга куйган. Аның соңгы саны 1933 елның 15 апрелендә дөнья күрә. 1934 елда «Тәммүз» (Июль) исемле газет пәйда була. 1933 елның 13 апрелендә, Габдулла Тукайның үлүенә егерме ел тулу мөнәсәбәте белән, «Шагыйрь» дигән беркөнлек газет чыга. 1934 елның 23 июнендә Харбинда нәшер ителгән беркөнлек газет «Бәйрәм нуры» дип аталган.

Кытай шәһәре Тяньцзиндә 1928 елда «Йолдыз» газеты, ә 1939—1940 елларда «Шәрык авазы» журналы чыгып килә.

Татар телендә берничә көндәлек матбугат басмасы Кытайның Мукден каласында нәшер ителә. 1923 елда биредә «Азат Шәрык» журналы пәйда була. 1934—1935 һәм 1939—1940 елларда «Төрек-татар шәкердләренә ана телен онытдырмау һәм аны тәрәккый индерүче айлык мәҗмуга—«Шәкердләр таңы» журналы чыгарыла. Ул «Ерак Шәректагы Идел-Урал төрек-татар мөселманнарының милли-дини комитеты» басмасы була. Алмания башкаласы Берлинда Гаяз Исхакый чыгарып килгән мәшһүр «Яңа милли юл» журналы, әлеге яшьләр басмасының ике еллык юбилее уңае белән, аны шәкертләрне һәм балаларны милли рухта тәрбияләүгә өлеш кертүче дип билгеләп уза. Мәхмүт Таһирның шәхси архивында «Шәкердләр таңы» журналының 1935 елда чыккан 10-11 саннары сакланганы мәгълүм.

1935 елда шушы ук шәһәрдә «Ерак Шәрык төрек-татар мөселманнарының корылтае» дигән баш астында биш саннан торган көндәлек матбугат басмасы-

бюллетень нәшер ителә. Анда 1935 елның февралендә Мукдендә узган әлеге форумның материаллары якгыртыла.

Милли азатлык өчен көрәш тарихында билгеле бер урын алган бу корылтайны оештыруда һәм үткәрүдә Гаяз Исхакый хәлиткеч роль уйный. Аның тәкъдиме буенча делегатлар сайлана, ул корылтайны кереш сүз белән ача һәм аның барышында рәислек итә. Корылтайда, милли көчләрне берләштерү максаты белән, махсус үзәк газет чыгару турында карар кабул ителә һәм аны оештыру Г. Исхакыйга йөкләнә.

Һәм чыннан да, 1935 елның 1 ноябрендә Мукден шәһәрендә «Милли байрак» исемле зур форматлы атналык газет дөнья күрә һәм 1945 елның җәенә кадәр яшәп килә. Бу басма үзенең озак вакыт һәм күп санда чыгуы, укучыларга җиткергән мәгълүматларының байлыгы һәм татарлар яшәгән чит илләрдә киң таралуы белән аерылып тора.

«Милли байрак» газетын нигезләүче, аның рухи җитәкчесе һәм иң актив, төп авторларының берсе Гаяз Исхакый була. Газетның исеме дә ул 1928 елда нигезләгән «Милли юл» журналына аһәңдәш һәм охшаш. Аны Г. Исхакый биргәнлеге бик ачык күренеп тора.

Газетта Гаяз Исхакыйның дистәләрчә мәкаләләре басылып чыккан. Алар милләтне һәм мәдәниятне саклау, татар халкының яшәеше, киләчәге, бәйсезлеге өчен көрәш рухы белән сугарылган. Бу турыда аның «Милли байрак»ның беренче санында дөнья күргән «Максадымыз» исемле баш мәкаләсе һәм газетның алдагы саннарында басылган зур күләмле «Ерак Шәрыкгагыча милли агымның төп максаты вә аның юллары», «Ерак Шәрыкта милли матбугат», «Милли-мәдәни мохтәриятнең мәгънәсе нәрсә?», «Милли мәҗлес»нең 20 еллыгы», «Финляндия татарлары», «Советларның урыслаштыру сәясәте», «Большевикларның динемезгә каршы золымнары», «Киләчәгебезнең нигезе» дигән һәм башка күпсанлы язмалары бик ачык сөйли.

«Милли байрак»ның нашире С. Аити, мөхәррирләре Ибраһим Дәүләт-Килди һәм аның тормыш иптәше Рокыя Мөхәммәдиш булган. Газета редакциясендә даими рәвештә Әхмәтша Гыйззәтулла, Мансур Арслан, бераз вакыт шагыйрь Шаһвәли Илдар эшли. Актив язышучыларыннан Хөсәен Габдуш, Хәбибрахман Болгари, Фәхретдин Гыйльман, Хәбибулла Сулаев, Кәшшаф Сәлиәхмәт, Әмирулла Агыйны һәм башкаларны күрсәтергә була.

Тарихта якты истәлек калдырган күренекле татар эшмәкәре Әхмәт Вәли Мәнгәр газетны чыгаруга зур матди ярдәм иткән.




*«Милли байрак» газеты*

«Милли байрак»ның гомум юнәлеше һәм эчтәлеген кыскача тасвирлау өчен 1936 елның 15 гыйнварында чыккан унберенче санына күз салыйк. Аның беренче битендә «Ерак Көнчыгыштагы Идел-Урал төрек-татарларының атналык газетасы вә беренче Корылтайның тәрҗемәи әфкаре» диелгән. Бу санда Разыя Дәүләткилдинең «Шиһап хәзрәтнең тәрҗемәи хәле», Рокыя Мөхәммәтдишнең «Милли матбугат», «Хәсән Агинең «Хайлар (шәһәрендә)да Рамазан бәйрәме», Г. Тукайның «Шиһап хәзрәт» исемле шигыре, татар халкы тарихы сериясеннән «Без кем?» исемле тарихи очерк (авторы күрсәтелмәгән), Г. Ильясинын «Шанхайда (татар) балалар кичәсе» дигән һәм башка мәкаләләр бар. Шушы ук санда Гаяз Исхакыйның исеме күрсәтелгән ике мәкаләсе бар. Берсе «Урынсыз таләп» исемле, Маньчжурия татарлары тормышыннан, ә икенчесе Шиһап Мәрҗанинең тууына 120 ел тулу уңае белән язылган күләмле мәкаләсе, үзенең әйтүе буенча, Шиһап хәзрәттән ишетеп белгәннәре турында истәлек сымак язылган.

«Милли байрак» газетасын чит илләрдәге татарларның язмышы, аларның

тарихы, мәдәнияте, әдәбияты, икътисади хәле, милли рухы турындагы энциклопедия диярге була.

Бөтендөнья татар Лигасы президенты, милли хәрәкәтнең күренекле эшлеклесе Гали Акыш (Г. Исхакый аны үзенең «иң ышанычлы ярдәмчесе» дип атаган) бәяләвенчә: «Милли байрак» газетасының чит илләрдә яшәгән төрек-татарларны, аеруча яшьләрне, милли рухта тәрбия итү эшендә роле гаять зур булды».

Газетның барлыгы 440 саны дөнья күрә. 1945 елның август аенда «Милли байрак» редакциясе хезмәткәрләре Маньчжурия чикләренә кергән совет армиясенең тикшерү органнары тарафыннан кулга алына һәм озак вакытка төрмәгә ябыла.

Кайбер мәгълүматлар буенча, 1920—1940 елларда татарча газетлар Кытайның хәзерге Синьцзян уйгур автоном районындагы Урумчи, Голжа һәм Тарбагатай шәһәрләрендә дә чыгып килгән («Безнең ватан», «Аксу», «Хинган гәзите»).

1931 елда Токиода «Япон мөхбире» исемле журнал дөнья күрә. Ул моннан дүрт ел элек әлеге шәһәрнең имамы Мөхәммәт Габдулла Корбангали (1892—1972) тырышлыгы белән оештырылган «Матбагаи исламия» дигән татар басмаханәсендә нәшер ителә. Бер елдан соң журнал «Яңа Япон мөхбире» дип атала башлый һәм 1945 елга кадәр чыгуын дәвам итә. Чит илләрдә дөнья күргән барлык татарча газет-журналлар арасында бу басма иң озак чыкканы була, ул ундүрт ел буе яшәп килә. Журналның 50 дән артыграк саны бастырылганлыгы билгеле.

1934 елда Кобе шәһәрендә «Япон императорлыгында яшәүче төрек-татар мөселманнарының 1934 ел 9 майда булачак корылтаена хәзерләнү хакында» дип исемләнгән махсус бюллетеньнең 5 саны чыгарыла.

1937 елда Токиодагы исламия мәктәбенең ун еллык хатирәсе буларак «Рәсемнәр мәҗмугасы» исемле, 28 битлек әдәби басма-альбом нәшер ителә. Шул ук Япония башкаласында 1936 елда, барлыгы биш санда, «Игълани хакыйкать» газеты, ә 1940 елда «Берлек мәҗмугасы» дип аталган басма чыгарыла. Соңгысының нашире Камал Йосыф була. Токиода татарча календарьлар да бастырыла.

1920—1940 елларда Ерак Көнчыгышта, аеруча Япониядә, татар телендә газет-журналлар, китаплар һәм башка басма әйберләрне чыгаруга Гыйниятулла Сәлиәхмәд, Мөхәммәд Алтынбай, Хөсәен Габдуш (1901—1944), Шаһвәли Илдар (1900—1970), Рабига Әгерже (1904—1973), Ибраһим Бадай (1907—1976) һәм башка кайбер милләтпәрвәрләр зур көч куйганнар.

XIX гасыр башында Финляндия Швеция составыннан Русиягә тапшырылганнан соң, бирегә беренче татар мөһаҗирләре күчеп урнаша башлый. Алар арасында урыс армиясе гарнизоннарында хезмәт итеп ялга чыккан татар гаскәриләре һәм Петербург, Мәскәүдә вак сәүдә итүчеләр булган. Тора-бара мөһаҗирләр саны шактый үскән. XX гасырның 20 елларында Финляндия татарларының ана телендә вакытлы матбугат басмалары барлыкка килә.

1925 елның 16 гыйнварында Кеми дигән фин шәһәрендә, ул ил татарлары арасында киң танылган язучы, егерме тугыз әдәби, тарихи китаплар һәм алты томлы әсәрләр җыентыгы авторы, китап бастыручы, мөхәррир һәм журналист Хәсән Хәмидулла (1895—1988) «Мәгърифәт» исемле газет чыгаруга керешә. Ана «фәкать җомга көннәрендә чыга торган сәяси, милли вә әдәби гәзитәдер» дигән искәрмә бирә. Әлеге газетны ул үзе өендәге басмаханәдә күбәйтеп, Финляндиядәге татарлар арасында гына таратып калмый, Төркиягә, Кырымга һәм Ленинградка җибәреп тора.

1943—1977 елларда бу газетның дәвамы рәвешендә, Х. Хәмидулла «Шимал очкыннары» исемле журнал нәшер итә. Журнал башта ике ел Кеми, ә аннары Хельсинки шәһәрендә бастырыла. Анда төп урынны, наширнең үзе тарафыннан язылган әдәби әсәрләреннән һәм публицистикасыннан тыш, дини сабаклар, сүрәләр һәм догалар алып тора. Хельсинки университеты профессоры Гомәр Таһир Казан галиме Илбарис Надировка язган хатында: «Шимал очкыннары» безнең мондагы халык өчен мәгърифәт таратучы бердәнбер популяр журнал булды. Аны карты да, яше дә яратып укый иде»,—диелгән.

1936 елда Тампере шәһәрендә фин татарларының «Туран» дип исемләнгән газеты нигезләнә.

1948 елда финнәр башкаласында Габдулла Мортазин, Зиннәт Ашкар һәм Госман Али мөхәррирлегендә «Беллереш» журналы дөньяга килә.

1949—1963 елларда башта Тампере, ә аннары Хельсинки шәһәрләрендә, Финляндия исламия җәмгыятенең рәсми басмасы буларак, «Мәхәллә хәбәрләре» дип аталган вакытлы матбугат чыгып килә. Аның барлыгы 60 саны дөнья күрә. Аның төп максаты: «Җәмгыятьнең эшләрен һәм фикерләрен белдерү»дән гыйбарәт була. Татар телендә нәшер ителгән әлеге басманың баштагы саннары гарәп хәрефләре, аннары—гарәп һәм латин хәрефләре белән аралаш басылган. Ахыргы берничә саны исә тулысынча латин хәрефләреннән тора.

«Мәхәллә хәбәрләре»ндә Финляндия татарларының дини, иҗтимагый, мәдәни тормышларына багышлы әһәмиятле мәгълүматлар урын тапкан. Мәҗмуга сәхифәләрендә Исламия җәмгыятьнең төрле яклы эшчәнлеге, матди-финанс хәле, уку-укыту мәсьәләләре, күренекле шәхесләрнең юбилейлары турындагы мәкаләләр һәм башка демографик белешмәләр бирелеп килгән. Анда шулай ук халыкара хәл хакындагы хәбәрләр дә даими басылып торган.

Мәҗмуганы Хәбибрахман Шакир һәм Фатыйх Арат чыгарганнар.

Эшчән китап бастыручы Садри Хәмит 1967 елда Оулу шәһәрендә «Тавыш» исемле газетның 6 санын нәшер итә. 1967—1974 елларда ул башта Оулу, аннары Хельсинки калаларында «Ак юл» дигән мәҗмуга чыгара. Басманың барлыгы 64 саны дөнья күрә.

1967 елда Стокгольм шәһәрендә Швециянен мөселман җәмгыяте үзенен «Безнең фикер»исемле 26 битле басмасын булдыра.

1973 ел башында Рожар Гали Сан-Франциско шәһәрендә Америка төрки-татар бүлегенең «Хәбәрләр мәктүбе» дип аталган бюллетенен чыгара башлый. Хәзерге вакытта ул «Яңалыклар» исемендә басылып килә.

Бүгенге көннәрдә Румыниядә 70 меңгә якын төрек-татарлар яши. 1990 елның апреленнән башлап, алар өчен айлык «Кара диңгез» газеты һәм еллык «Рәнәкләр» («Төсләр») альманахы чыгып килә.

Бер гасырга якын вакыт эчендә чит илләрдә мөһаҗирчел милләттәшләребез чыгарган дистәләрчә газет-журнал сәхифәләрендә татар халкы тарихын, мәдәниятен һәм иҗтимагый-сәяси фикерен тирәнтен, риясыз өйрәнү өчен кирәкле кыйммәтле мәгълүматлар тупланган. Шуңа күрә Русиядәге һәм башка мәмләкәтләрдәге төрле китапханәләрдә, архивларда һәм фәнни учреждениеләрдә, аерым кешеләрдә хәзергәчә сакланган татар телендәге газет-журналлар, китаплар һәм башка әдәби мирас чыганакларын эзләп табу, аларның фото күчермәләрен Казанга алып кайтып туплау буенча күп көч һәм тырышлык таләп итә торган эшне тагын да җанландыру бурычы тора. Шулай ук матбугат басмаларын чыгару белән шөгыльләнгән наширләр, мөхәррирләр һәм журналистларның тормыш юлы һәм эшчәнлеге белән бәйле материалларны эзләп табу һәм җыйнау да—зарур эш.

**Тәлгат НАСЫЙРОВ,**
*тарих фәннәре кандидаты*

Tarix
Тарих

# ТАТАР КАЛЕНДАРЬЛАРЫ ТАРИХЫННАН

## ТАТАР КАЛЕНДАРЕ ЧЫГА БАШЛАУГА 160 ЕЛ

**Хәзерге вакытта китап кибете киштәләренә күз салсаң, татар календарьларының күптөрлелеге игътибарны җәлеп итә: милли, мөселман, гаилә, сәламәтлек, балалар календарьлары һ. б. Ә элегрәк, ягъни 1917 елга кадәр татарда календарьчылык ни дәрәҗәдә булган? Бу һәм башка сорауларга әлегә кадәр тәфсилле җавап бирелмәгән.**

**XX йөз башында ук күренекле тюрколог Н. Ф. Катанов татар басма календарьлары хакында язып чыга. Ул «Деятель» журналында махсус «Восточная библиография» рубрикасында татар басмаларына күзәтү ясый *(Катанов Н. Ф. Обзор казанско-татарских отрывных календарей за последние 3 года (1902-1904) // Деятель: 1904.—N 6.—С. 228—237).* Бу бүлекчәдә, нигездә, Казан университетының табыгъханәсендә нәшер ителгән китапларга аннотация белән беррәттән, өстәмә мәгълүматлар да биреп барыла. Алар арасында календарьлар да очрый, мәсәлән, мәгърифәтче К. Насыйри, язучы Ф. Халиди һ. б. төзеп бастырганнары да бар. Галим-энциклопедист татарлар арасында да календарь бастырып тарату эше җәелде, дип яза һәм аларга югары бәя бирә. Узган гасырның 20 елларында әдәбиятчы, галим Җамал Вәлиди (1887—1932) «переводно-календарьная литература» дигән терминны кулланып, календарьларның әһәмиятлеген һәм популярлыгын күрсәтә (*Валиди Дж. Очерк истории образованности и литературы татар.—М.; Пг., 1923.—С. 41-44).***

**XIX йөз азагында—XX йөз башында календарьлар хакында вакытлы матбугат битләрендә кайбер язмалар дөнья күрә башлый. Эчтәлеге ягыннан аларны ике төргә бүлеп карарга мөмкин: беренчеләре—реклама характерында, мәсәлән Ш. Шәһидуллинның «Заман» календаре (1900—1917) хакында Исмәгыйль бәй Гаспралы үзенең «Тәрҗеман» гәзитәсендә зур булмаган игълан урнаштырып килә һ. б. *(Дивари календарь // Тәрҗеман.—1906.—1 декабрь; Календарь // Вакыт.—1907.—26 июль; Тәкъвим даими / / Дин вә мәгыйшәт.—1907.—N 36.—517 б.; Сәүдәгәр календаре // Йолдыз.—1911.—20 гыйнвар).***

**Кайвакыт мөселман руханилары белән календарь бастыручы татар зыялылары арасында бәхәс тә чыга. Әлбәттә, руханилар өчен бу мөһим мәсьәләләрнең берсе була, чөнки Русия мөселманнарының дини бәйрәмнәрне татар календарьлары буенча үткәргәннәр. Мәсәлән, «Йолдыз», «Өлфәт», «Әхбар», «Дин вә мәгыйшәт» кебек гәзитә-журналларда мондый язмаларны очратырга мөмкин. Вакытлы матбугатта татар календарьларын төзеп бастыручыларны «календарьчылар» дип тә атау милли матбагачылыгыбыз өлкәсендәге бу тармакның асылда формалашып җитүен күрсәтүче кызыклы бер факт *(Календарьчылар отчеты // Әхбар.—1908.—9 апрель.; Календарьчылар // Йолдыз.—1914.—5 февраль).***

**Календарьларны фәнни нигездә тикшерү XX йөзнең 50 елларында язучы һәм галим-археограф Мостафа Ногманның, мәгърифәтче К. Насыйри**

кулъязмаларын тасвирлавыннан башлана *(Каюм Насыйри кулъязмалары тасвирламасы. 3 чыгарылыш.—Казан, 1958.—47 б.).* Бүгенге көндә ул кулъязмалар Казан дәүләт университетының Н. И. Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә саклана. Шулай ук археограф Альберт Фәтхиев тә язучы Ф. Халидинең кулъязма календарьларын тасвирлый *(Фәтхиев А. Н. И. Лобачевский исемендәге Фәнни китапханә кулъязмаларының тасвирламасы. 5 чыгарылыш. Татар әдипләре һәм галимнәренең кулъязмалары. Беренче бүлек.—Казан, 1960.—49—55 бб.).* Соңгы елларда Ф. Халидинең тормышын һәм иҗади мирасын өйрәнүче, әдәбият белгече З. Мөхәммәтшин язучыбызның календарьларына да күзәтү ясый. Татар басма календарьларын өйрәнүдә академик Ә. Кәримуллинның хезмәтләре аерым урын алып тора. Галим гомерен татар басма китапларын өйрәнүгә багышлаганлыктан, күп кенә китапханә һәм архив фондларын энә күзеннән үткәрә. Бүгенге көндә билгеле булган беренче басма календаре хакында ул 1961 елда ук фәнни әдәбиятта язып чыга *(Кәримуллин Ә. Г. 90 түгел, ә 120 ел // Совет әдәбияты.—1961.—N 3.—Б. 154-155.; Кәримуллин Ә. Г. Беренче басма календарь // Социалистик Татарстан.—1981.—30 гыйнвар).* Соңрак Каюм Насыйриның басма календарьларын җентекләп өйрәнә *(Кәримуллин Ә. Г. Каюм Насыйри календарьлары // Әйдә халыкка хезмәткә!—Казан, 1985.—11—26 бб.).* Шулай ук журналист, язучы Исмәгыйль Рәмиевнең «Истәлекләр: Татарча басма сүз» исемле китабында да әлегә беренче булып санала торган календарь һәм аның төзүчесе турында кайбер мәгълүматлар урын алган. Календарьларны өйрәнү күп аспектлы темаларның берсе. Вакыт үлчәү берәмлекләрен тикшерү мәсьәләнең бер ягы булып тора. Бу юнәлештә эшләгән галим В. М. Беркутов хезмәтләре фән өчен мөһим роль уйный *(Беркутов В. М. Народный календарь и метрология булгаро-татар.—Казань, 1987.—С. 95).*

Бүгенге көннәрдә дә татар календарьлары тарихы вакытлы матбугат битләрендә дә, аерым хезмәтләрдә дә чагылыш таба. Мәсәлән, М. Әхмәтҗанов татар кулъязма календарьларын өйрәнүгә аерым мәкалә багышлаган. Күптән түгел авторның «Татар кулъязма китабы» исемле хезмәте дә дөнья күрде (Әхмәтҗанов М. Татар кулъязма китабы.—Казан; Татар. китап нәшр., 2000.—141-164 бб.). Анда сүз төрле характердагы татар кулъязмалары, шул исәптән календарьлар хакында да бара. Төрки-татар рухи мәдәниятен өйрәнүче Г. Дәүләтшин хезмәтендә дә халык арасында кулланышта йөргән вакыт үлчәү берәмлекләре тикшерелә *(Дәүләтшин Г. Төрки-татар рухи мәдәнияте тарихы.—Казан, 1999.— 169—180 бб.).*

Әмма, татарда календарь төзү һәм бастырып тарату тарихы әлегә кадәр комплекслы рәвештә тикшерелмәгән. Барысы күпме календарь, нинди тираж белән нәшер ителгән, аларның нинди төрләре булган, полиграфик эшләнеше, эчтәлеге, күпме вакытка хисапланганы ягыннан нинди төркемнәргә бүләргә була—бу сорауларга әлегә кадәр төгәл җавап бирелмәгән.

XX йөз башында татарлар арасында гына түгел, русларда да календарьларның тоткан урыны шактый югары булган. Үз чорының күренекле рус нашире И. Д. Сытин (1851—1934) әйткән сүзләр дә шуны раслый *(Книга в России (1881—1895) / Под общей ред. И. И. Фроловой.—Санкт-Петербург: Российская национальная библиотека, 1997.—С. 83).* Русларда беренче басма календарь 1709 елда Яков Вилимович Брюс (1670—1735) тарафыннан төзелеп бастырылган *(Всемирный биографический энциклопедический словарь / Ред. кол.: В. И. Бородулин, Н. М. Кузнецов, Н. М. Лонда и др.—М.: Большая Российская энциклопедия, 2000.—С. 109.; Автор первого русского календаря // Вечерняя Казань.—1980.—2 января).* Ул чыгышы белән шотландияле, генерал-фельдмаршал, XVII-XVIII гасырларда Кырым һәм Азов походларында, Төньяк сугышында катнашкан. Мәскәү басмаханәсе белән җитәкчелек итә, математика, физика, астрономия, картография белән шөгыльләнә. Аның тарафыннан төзелгән «Календарь или месяцеслов» яңа граждан шрифты белән басылган беренче рус китапларыннан хисаплана. Ул, кеше гомеренең ел фасыллары алышуына бәйлелеген өйрәнеп,

аның үз закончалыкларын ачыкларга омтылган һәм шул хактагы күзәтүләрен календарь битләрендә чагылдырган.

Мәгълүм булганча, Русия төрки-мөселманнары арасында татарлар беренчеләрдән китап басу эшенә керешкән халык. Матбагачылык, китап басу берничә тармактан тора: дәреслекләр, дини басмалар, фәнни хезмәтләр, әдәби әсәрләр, авыл хуҗалыгы буенча китаплар һ. б. XIX йөзнең икенче яртысында формалашып җиткән календарьлар бастыру да татар басмачылыгының бер тармагына әверелә. Татар вакытлы матбугаты Русия хөкүмәте тарафыннан тыелганлыктан, халык өчен төп информация чыганагы булып китап тора. Ләкин китап никадәр генә мөһим информация чыганагы булмасын, гәзитә-журналларга булган ихтыяҗны тулысынча канәгатьләндереп бетерә алмый. Шуңа күрә, татар зыялылары, бу проблеманы хәл итүнең башка юлларын эзлиләр. Шундый юлларның берсе—ул календарь төзеп бастыру һәм тарату.

Татарда безгә билгеле булган беренче басма календарь 1841 елда дөнья күрә. Ул мәгърифәтче Рәхмәтулла Әмирханов тарафыннан 40 елга исәпләнеп төзелгән һәм «Горрәлек» дип атала. Бу басма хакында фәнни әдәбиятта 1961 елда ук билгеле була. Аны галим-академик Ә. Кәримуллин Казан дәүләт университетының Н. И. Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә таба һәм чыганак турында гәзитә битләрендә мәкалә бастырып киң җәмәгатьчелек игътибарына тәкъдим итә. 20 биттән торган календарьның һәр бите бер айга багышланган. Һәр айның европача һәм гарәпчә исемнәре, татарча көн исемнәре, һәр көннең озынлыгы күрсәтелә. «Көн озынлыгы», «көн туу», «көн бату» вакытлары, сәгатьләре һәм минутлары белән бирелгән. Шунсы игътибарга лаек, анда көн озынлыгы, кояш чыгу һәм кояш бату Казан вакыты белән генә түгел, Әстерхан һәм Тобол вакытлары белән дә күрсәтелә. Кызганыч, инде фәнни әдәбиятта беренче татар календаре 1841 елда басылганлыгы исбат ителгән булса да кайбер хезмәтләрдә, хәтта энциклопедик характердагы белешмәлекләрдә бу хакта ялгыш мәгълүматлар бирелә. Мәсәлән, Санкт-Петербургта нәшер ителгән «Ислам на территории бывшей Российской империи» исемле басмада профессор Ә. Б. Халидов беренче татар басма календареның чыгу елын дөрес билгеләми *(Ислам на территории бывшей Российской империи: Энциклопедический словарь. Вып. 1.—М.: Восточная лит-ра РАН, 1998.—С. 26).*



*1901 ел өчен календарь.*

Русиядәге төрки-мөселман халыкларыннан беренчеләрдән булып календарь төзеп бастыру эшенә керешкән бабаларыбыз башка төрки халыкларга да бу эштә әчкерсез ярдәм итәләр. Мәсәлән, үзбәкләрдә 1871 елда беренче басма китап булып, үзбәк телендә 1872 ел өчен календарь нәшер ителә. Календарь 187 битле 500 тиражлы булып дөнья күрә. Аның авторы- төзүчесе татар эшлеклесе, Төркестан генерал- губернаторының тәрҗемәчесе, мәгърифәтче Шаһимәрдан Ибраһимов(1841-1892) була. Ә кыргыз халкы үз телендә басма календарьлар булмаганлыктан татар басмаларыннан файдаланган. Беренче казакъ басма календаре бары тик 1923 елда гына дөнья күрә.

Календарь басуның мәркәзе, әлбәттә, Казан шәһәре. Монда XX йөз башында 15 басмаханә, 1905 елда— 21, 1910 елда— 26, ә 1916 елда 24 басмаханә эшләп килгән. Алар арасында иң зурлары һәм мәшһүрләре булып Казан университеты һәм бертуган

Кәримевләрнең басмаханәләре саналган. Шулай ук “Милләт”, “Өмет”, “Үрнәк” һ.б. матбагаларда да календарьлар бер-бер артлы дөнья күрә. Татар календарьларының кайберләре рус хосусый табыгъханәләрендә дә нәшер ителә: И.Харитонов, В.Еремеев һәм А.Шашабрин, Г.Вечеслав, Н.Чижова, М.Чиркова басмаханәләрендә.

Татар календарьларын бастыру белән Русиянең башка шәһәрләрендә дә шөгыльләнәләр. XX йөз башында Оренбург шундый үзәкләрнең берсенә әверелә. Биредәге иң зур басмаханәләрнең берсе күренекле мәгърифәтче, язучы, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе Фатыйх Кәрими җитәкчелегендә эшләп килгән. Ул берничә тапкыр исемен үзгәртеп, Ф.Кәрими басмаханәсе, “Кәримов, Хөсәенов һәм К”, “Хөсәенов һәм К” дип йөртелә. Шулай ук, XX йөзнең беренче чирегендә киң таралган һәм танылган “Заман” календаренең беренче өч саны Оренбургта урнашкан Бреслин матбагасында дөнья күрә. 1908 елда Уфа шәһәрендә “Кәримов, Хөсәенов һәм К” табыгъханәсенең “Шәрык матбагасы” исемле бүлекчәсе дә ачыла. Оренбург басмаханәләрендә өстәл һәм дивари өзмә календарьлар күп чыгарылган.

Империянең башкаласы Санкт- Петербургта да берничә календарь басмасы дөнья күргән. 1894 елда шәһәрдә гарәп шрифты белән китап нәшер итүче Ильяс Бораганский басмаханәсенә нигез салына. Биредә “Русия мөселманнарының сәүдә- санагый календаре” татар һәм рус телләрендә басылып чыга. 1906 елда Санкт- Петербургта гарәп шрифты белән китап бастыручы тагын бер матбага ачыла. Календарь «Өлфәт» гәзитәсе исемен йөртә. Басмаханә һәм гәзитә күренекле публицист, җәмәгать һәм дин эшлеклесе Гәбдерәшит Ибраһимов (1857—1944) кулында була. Бу матбагада нәшер ителгән «Кечек салнамә Өлфәт. 1907 елга» басмасының авторы да Рәшит казый. Шулай ук, бу матбагада Кәримов фамилияле кеше тарафыннан төзелгән һәм аның акчасына нәшер ителгән календарь да билгеле.

Мәскәү шәһәрендә җәмәгать һәм дин эшлекләләре, Агеевлар нәселеннән Мөхәммәдкәрим Агеев «Горрәи даими» (1895), ягъни мәңгелек календарь бастыра.

Шулай итеп, XX йөз башында татарча календарь бастыру эше Русиянең төрле шәһәрләрендә—Казан, Оренбург, Санкт-Петербург, Уфа, Мәскәү, Стәрлетамакта җәелә.

Календарьларның эчтәлегенә тукталганчы XIX йөз ахырында XX йөз башында бу өлкәдә кулланышта йөргән терминнарга күз салыйк. Татар календарьлары «горрәлек», «горрәнамә», «тәкъвим», «тәкъвимнамә», «салнамә» кебек гарәп-фарсы телләреннән кергән сүзләр белән аталган. «Календарь» сүзе латин теленнән «календа»—«айның беренче көне» дип тәрҗемә ителә, безнең мәгълүматларга караганда, бу терминны татар календарьчылары арасында беренчеләрдән булып Каюм Насыйри куллана. 1877 елга хәтле галим үзенең календарьларын «Казан календаре» дип, ә 1878 елдан «Календарь» дип кенә күрсәтә.

Полиграфик эшләнеше ягыннан календарьларны берничә төргә бүлеп карарга мөмкин: китап рәвешендәге, өстәл календаре; дивари өзмә календарь; дивари плакат-календарь; кесә календаре.

Иң беренче басма календарьлар юка гына, якынча 20 битлек китапчык рәвешендә нәшер ителгәннәр. Мәсәлән, Р. Әмирханов, К. Насыйри, Ф. Халиди, Ш. Рәхмәтуллин календарьлары. 1900 елдан 1917 елга кадәр иң танылган «Заман» һәм алты ел дәвамында нәшер ителгән «Мөшавәрәт» календарьлары исә күп битлек журнал рәвешен алганнар. XIX йөз ахырында татар календарьларының яңа төрләре барлыкка килә. 1898 елда билгеле татар журналисты, тел белгече һәм җәмәгать эшлеклесе Әхмәдһади Максуди (1868—1941) беренче дивари өзмә календарь төзеп нәшер итә. Басмаларның бу төрләрен кечкенә энциклопедиягә тиңләргә мөмкин. Шунысын искәртеп үтәргә кирәк, русларда дивари өзмә календарьлар 1865 елда нәшер ителә башлаган булса, казак телендә 1960 елдан, ә башкортларда исә бары тик 1986 елдан гына дөнья күрә. Календарьлар арасында кесәдә йөртә торган төрләре дә бар. Мәсәлән, Ш. Шәһидуллин (1909, 1910), Г. Ниязи (1909), Г.

Камалов (1911), «Иптәш» календаре (1913), З. Касыйминың «Куен дәфтәре» (1914, 1915) календарьлары әнә шундыйлардан. Алар арасында тел белгече Гыйбадулла Алпаров (1888—1936) тарафыннан төзелгән, кесәдә йөртә торган «Мәңгелек календарь» 1911 елда Стәрлетамак шәһәрендә дөнья күрә.

Әйтеп үткәнебезчә, календарьлар вакыт хисабын билгеләү өчен генә түгел, ә бәлки күп кенә кызыклы һәм мөһим мәгълүмат тарату чарасы да булып тора. Эчтәлеге ягыннан аларны берничә төргә бүлеп карарга мөмкин, мәсәлән: фәнни-санагый; әдәби; фәнни-әдәби; сәүдә; халык календаре.

Халкыбызның милли-мәдәни үзаңы үсү һәм иҗтимагый-сәяси мәсьәләләргә кызыксынуы арту нәтиҗәсендә әдәби һәм фәнни-әдәби басмаларга ихтыяҗ көннән-көн зурая. XIX йөз ахырында иҗат иткән күренекле язучыбыз Фатыйх Халиди календарьларында татар әдәбияты тарихына зур игътибар бирелә. Шулай ук дини-дидактик, тәрбияви-әхлакый мәсьәләләр дә яктыртыла. Татар халык иҗаты үрнәкләренең берсе— мәкальләргә, күңел ачкычлары-латифәләргә, ягъни мәзәкләргә аеруча игътибар зур була. Календарьларда татар зыялыларының тәрҗемәи хәлләре дә яктыртыла.

Календарьлар барлык төрки-мөселман басмалары шикелле үк рус цензура кысуын татыйлар. Мәсәлән, Фатыйх Халиди календарьларында бу күренеш күбрәк тарихка багышланган урыннарга яисә татар халкының аңбелемгә омтылышын тасвирлаган материалларга кагыла. Цензор В. Смирнов Шәрәфетдин Шәһидуллинның 1898 ел өчен төзелгән өстәл һәм өзмә календарьларын гомумән нәшер итүне тыя.

XX гасыр башында татар сәүдәгәрләре, эшкуарлары аерым социаль катлау буларак формалашып җитәләр. Аларның ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен махсус календарьлар да бастырыла. Шуларның берсе күренекле нашир, татар рекламасына нигез салучы Шәрәфетдин Шәһидуллинның «Сәүдәгәр календаре» 1911 елда татар һәм рус телләрендә чыга. Ә. Сәйдәшевнең «Мәгълүмат» исемле сәүдә-санагый адрес-календаре дә шундыйлардан. Бу календарьга охшаган бер басма хакында китап белгече Ә. Кәримуллин хезмәтендә телгә алына, ул татар һәм рус телләрендә Санкт-Петербург шәһәренең И. Бораганский табыгъханәсендә басылган. Татар календарьлары арасында «Годәм календаре» дигән басма да бар. Авторы-төзүчесе дин әһеле, тарихчы Касыйм Бикколов (1868—1937). Безнең уйлавыбызча, ул гомуми халык календаре, ягъни тормышның төрле өлкәләренә караган мәгълүматлар тупланган басма.

Календарьларны куллану вакытына карап түбәндәге төрләргә бүлеп була: даими, ягъни мәңгелек; 40 елга; 25 елга; 12 елга; 1 елга; 1 айга.

Белгәнебезчә, беренче татар басма календаре 40 елга төзелгән була. Язучы Фатыйх Халидинең күп санлы календарьлары арасында 25 елга исәпләнгәне дә бар. Ә 1888 елда тел белгече, фольклорчы Мөхәммәтшакир Салихов (?—1929) 12 еллык календарь бастыра. Календарьларның иң киң таралганнары бер елга исәпләп төзелгәннәр. Мәсәлән, Ш. Рәхмәтуллин 1891—1900 елларда, Х. Зәбири 1905 ел өчен календарь бастыралар. 1907 елга Г. Ибраһимов, К. Бикколов басмалары нәшер ителә, Ф. Әмирханов 1909 елга, М. Идрисов, 1910 елга төзеп бастыра һ. б. Мәңгелек календарьлар, элеккегечә әйткәндә «горрәи даими»ләр дә халык арасында кулланышта була. Безгә билгеле булган, беренче «Горрәи даими» 1895 елда Мәскәүдә Мөхәммәдкәрим Агеев тарафыннан нәшер ителә. Шулай ук 1903 елда борадарән Кәримиләрнең матбагасында бер «Горрәи даими» дөнья күрә. Казанда гына түгел, Оренбург шәһәрендә дә «Тәкъвим даими» (1907) бастырыла. Киң кырлы җәмәгать эшлеклесе Ш. Хәмидинең «Мәңгелек календаре»ндә вакыт хисабын күрсәтүче җәдвәлдән тыш, төрле мәгълүматлар урнаштырылган: ярминкәләр вакыты һәм урыны, бәйрәмнәр һ. б.

2001 елда татар календарьлары басыла башлауга 160 ел тулды. Татар календарьлары тарихын өйрәнү киләчәктә дә дәвам итәр дип ышанасы килә.

Ләйсән **МИҢНУЛЛИНА**

*Әдәбият тарихына*

**Гаяз Исхакый**

# ШАГЫЙРЬ ГАБДУЛЛА ТУКАЙ

Халык шагыйребез Габдулла Тукайның үлүенә егерме биш ел тулу истәлекләрен үткәрергә хәзерләнгәндә без Тукайның иҗады хакында Җамалетдин Вәлидинең әсәренә башка күз унымызда һичбер житди бер әсәр күрә алмыйбыз.

Аның үлүенә егерме биш ел тулып үткән булса да анын бүгенге истәлеге белән үлгәндән соңгы беренче-икенче еллары кебек мәгънәви бер бушлык белән каршыланабыз. Бу егерме биш ел бик житәрлек мәдәт (вакыт, заман) булса да, Тукайның иҗады хакында бүгенге көнгә кадәр нә бер жентекләмә, нә бер тәнкыйть китабы язылганны без белмибез, күрмибез.

Халыкның бу кадәр сөйгән, хәятының, мәгънәви тормышының эченә кереп милләт белән бергә үреп, берләшеп киткән бер шагыйрьгә каршы эшләнгән бу хәрәкәтнең мәгънәсе нәрсә? Әгәр бу голәкасезлек (бер-берсенә бәйле булмаган) кебек күренгән әхвәлнең артында бик күп зур вакыйгалар булмаса иде, шөбһәсез бу эш һәммәбезнең йөзене кызартачак, һичбер вакыт гафу ителмәячәк милли бер гөнаһ булыр иде. Ләкин илебездә булып үткән вакыйгалар Тукайның хыялына керә алмаган, халкыбыздагы кайгы-хәсрәт, андагы бөтен милләтчеләргә каршы жисмәви вә мәгънәви ясалган каты гамәлләр, милләтебезнең бу эшлекле өлешене милли вазифасын үтәүдән тыеп калды. Андагы яшьлегебез, Тукайның «И туган тел, и матур тел» белән авызы ачылган яшьлегебез ник соң моны эшләмәде?

Илебездәге хаким большевик агымы бу яшьлегебезне милләтчелегеннән яздырыр, аның «И туган тел»ене оныттырыр өчен аны махсус ялган юлларга өстерәп үзенең халкының мәгънәви юлдан адаштырып калдырганга, ул да исерек кеше кебек мәлжерәп калып, көнне төннән аера алмаенча, кирәкне дә, кирәкмәсне дә онытты. Ул да табигый рәвештә үзенең вазифасыны үтәрлек дәрәҗәгә үсә алмады.

Мөһаҗрәткә чыккан яшьләребезнең, хосусән, Төркия дәрелфөнүнендә әдәбият төркиятчелекне укучылары үзе кызык, үзе мәгънәле шул юлда бер эш эшләмәде? Ник шуларның берсе генә дә үзенең докторлык тикшерүене Тукайга хәср итмәде (бер генә эшкә махсус тукталу) вә безгә Тукай хакында гыйльми үлчәүләр белән үлчәнгән бер гыйльми китап бирә алмады?

Украина мөһажрәте Шевченконың шигырьләре хакында бөтен Аурупа телләрендә докторлары өчен китаплар язганда, гөрҗиләр (грузиннар), мөселман булса да гөрҗичә язган Руставелине бөтен дөньяга, шагыйребез, дип танытканда, ник безнең мөһажрәт яшьләребездән берсе генә дә Тукай белән мәшгуль булмады?

Монысына гөнаһны большевикларга сылтап кына үтәргә мөмкин түгелдер. Үзебезнең мөһажрәтебезнең житешсезлегеннән килеп чыккан үз кимчелегебездер. Ләкин монда да большевикларның роле юк түгелдер. Төркиянең яшьлеге, большевик шаукымы кагылып, милли мәсьәләләрдә икеләнү дәверендәдер. Анда мөхәлтәәссеф (үкенечле хәл) милләт, милли барлыкка иман гранит ташы кебек

Бу мәкалә Берлинда чыккан «Яңа милли юл» (1928—1939) журналында 1938 елда басылган. Аны матбугатка филология фәннәре кандидаты **Розалина НУРУЛЛИНА** әзерләде.

каты булып жирләшмәгәнгә, төрек яшьлеге жил кайдан килсә, шуннан ага торган, мода нинди булса, шуңарга иярә торган мескен бер хәлдәдер. Вә бу хаста мөхаят безнең мөһажир балаларыбызны да зәһәрләп, аларны да үзенең тугъры юлыннан яздырырга житә каладыр. Безнең милләтче булырга тиеш гәнежлегебезне (яшь егетләребезне) дә бу халәт төрле хата юлларга саптырып милләттән, милләтеннән озаклаштырырга (ераклаштырырга мәгънәсендә—Р. Н.) сәбәп булып киләдер. Шундый черек мохитта зәһәрләнгән (агуланган мәгънәсендә—Р. Н.) милләтче бер милләтебезнең баласы—бер жегетебез үзенең музыкага булган кабилиятене үзенең табигый юлына куярга урын таба алмаенча, милләттәшләрнең милли музыкага ихтыяжларын үтәшүне үзенә ваклык санап, Алманиядә нимесләрнең чиркәүләрендә бушлай музыка уйнап йөридер. Бу жегет үзенең урманга утын ташуыны никадәр көлкелегене аңламас дәрәжәдә ахмакмы? Милли музыкасына сусаган милләттәшләренә бары-югы белән ярдәмгә килүнең ваклык түгел, кешелек икәнлеген аңламас дәрәжәдә әхлакый төшкәнме? Юк, түгел, үзенең ялган тәрбия, ялгыш мохитында үзенең милли арадасыны (фикерләрен) югалткан, су өстендәге чүп кебек дулкын кайдан килсә, шунда ага торган бер бәхетсез генәдер. Менә шундый черек мохит, монда бер жегетебезнең кабыйлиәте, милли музыкасы нигезендә эшләргә бирелеп шул юлда беренчелек шәрифене казануны Алманиянең бүген чиркәвендә, иртәгә кабагында, өченче көн урам почмагында уйнауга корбан иттерәдер. Икенче бер жирдә берсене Тукайның шигыре, ижады хакында эшләүдән бүгенге модадагы бер шарлатан футуристның шарлатанлыгыны «ижад» дип газиз вакытыны әрәм иттерәдер.

Нәтижәдә милли әдәбият, милли музыка халык әдәбияты мәйданларыбыз буш калып, Тукай кебек Тукайга бу көнгә кадәр бер жентекләмә язылмыйдыр. Ләкин бу үтешле, йогышлы чир белән яшь жилкенчәгебез аураганга карап безнең милли музыкабызның дәрәжәсе төшәме? Тукай тукайлыгын югалтамы, югалтачакмы? Хәер, Тукайның бәхете шунда ки, ул үзенең бөтен үсүене, күтәрелүене халкыбызның үсүе, күтәрелүе белән бергә баглап алып барган. Ул үзенең бөтен ижадынын көч-куәтене халыкнын көченнән алып, халыкның кайгы-хәсрәтене, сөенечене халкыбыз белән бергә жырлап, бергә көйләп халкыбыз эчендә үзенең ижад куәтен эретеп жибәреп халык белән берләшкән, үзенең бөтен ижадиятенең тамырларын халыкның бу көненә генә түгел, кичәгесенә дә, аннан элеккесенә таба жибәреп, халыкның барлыгы белән бергә тамырланган, төпләнгән. Халыкның баруы, яшәве белән Тукайның яшәве табигый рәвештә берләшдерелгән.

Тукайның исән вакытында ижадының иң куәтле чакларында һәм дә Тукай чын мәгънәсендә халык шагыйре булып житкәннең суңында, унберенче елларда, Тукайга каршы бер хәрәкәт башлана.

Бу хәрәкәтнең бер канатында ихтилал дәверендә беренче кыручы-ватучы булса да, бүгенге көндә большевиклардан сөрелгән мөхәррир Галимжан Ибраһимов торса, икенче канатында ул вакытта рус әдәбияты тәэсире астындагы большевик Хөсәен Ямашев янындагы бер груп (группа—Р. Н.) урын ала.

Галимжан Ибраһим Габдулла Тукайның үзен танымавыннан бераз үпкәләп, тиз көндә шул кадәр сөелүвеннән бер көнчеләп, Тукайны үзенең дәрәжәсеннән төшерергә маташа. Ул вакытның мәшһүр тәрәккыйпәрвәр байларыннан булган «Дәрдмәнд»нең күнелене алыр өчен аны беренче дәрәжәгә күтәрергә тырыша.

Икенче канат, андый вак мәнфәгатьләрдән озак торып, Тукайның ижадына каршы кулланачак үлчәүне алуда хата ясый. Бу груһ (төркем) үзенең рус зыялы мохитыннан алган, рус тормышына мөнасыйп булган, «сәнгать—сәнгать өчендер» дигән аршин белән Тукайга каршы чыга. Вә бу үлчәү белән ул вакытның шагыйрьләре Сәгыйть Рәми белән Габдулла Тукай арасында чагыштырма ясый. Вә Сәгыйть Рәминең мәшһүр «Мин» шигыре белән Тукайның шигырьләрен үлчәүдән кичереп, Сәгыйть Рәми файдасына хөкемне чыгара. Тукайны такмакчы дәрәжәсенә төшерергә маташа иде. Шунысы гаҗәп ки, бу груп ул вакытның төрек-татар матбугатында Тукайга гыйльми генә булса да каршы чыга беләчәк бер зәмин табыла алмыйча, үзенең бу фикерен рус матбугаты аша мәйданга ата. Русча укый белә торган яшьләрне мөхатиб (сүз сөйләрлек кеше) итеп ала вә алар арасыннан үзенә якын бер груп да

ясый иде[1]. Тукай боларга үзенең «Мөнтәкыйть» дигән шигыре белән җавап бирәдер[2].

Без монда боларның күтәргән мәсьәләләрен янадан мәйданга куярга теләмибез, ул вакытда бик күп сөйләнелгән, моназара ителгән Сәгыйть Рәми зур шагыйрьме, Габдулла Тукаймы зур икәнен янартырга уйламыйбыз. Ул вакытда да, хәзер дә бу мәсьәләнең болай куелуы хатадыр. Ул вакытта Сәгыйть Рәми вә Габдулла Тукай тарафдарларының бу сөалгә биргән җаваплары да хатадыр. Сәгыйть Рәми белән Габдулла Тукай һич бер-берсе белән чагыштырылмый торган, чагыштырыла алмый торган ике мәктәбнең, ике мәсләкнең шәкертләредер. Вә икесе дә үзләренең мәктәбләрендә, мәсләкләрендә, үз урыннарында зурлардыр.

Сәгыйть Рәми, «сәнгать—сәнгать өчен» мәктәбенең шәкерте булып, үзенең тирә-юнендән, үзенең мохитындан тәмамә читдә калып, үзенең үзлегенә фәнафи алла дәрәҗәсенә етешә торган индивидуалист бер шагыйрьдер. Ул үзен мохиттан тәмамә таҗрд итеп (аерылып):

«Мин» димен мин, «мин» дисәм мин,
Мина бер зур көч кирә,
Аллалар, шаһлар, канунлар
Булалар бер чүп кенә...—

дип яза алганга түгел, шул вакытда, шул игътикадда (күңел биреп эшләү) була аладыр. Вә бонын шигърияте нә безнең милләт белән, нә халкыбызның тормышы белән багланган түгелдер. Монда татарлык фәкать телдә генәдер. Шунын өчен Сәгыйть Рәми бу шигырендә татарча язган космополит бер шагыйрьдер.

Габдулла Тукай үзенең тойгыларын, фикерләрен, ыңгырашларын, үзенең тирә юнендән, бу көнге яшәдеге генә түгел, бабаларының бабалары яшәгән мохитдан аладыр. Алай гына да түгел, ул шул мохитның бер кисәге, шул тирә-юньнең күңеленең сыкравы белән генә сыкранучы, шунын моңын гына көйләүче бер җырчыдыр. Шул мохитның эченә, минлегене эретеп үзлегене оныткан бер шагыйрьдер. Анарда «Мин» юк, ул гомере буе тырышса да, Сәгыйть Рәминең «Мин» шигырене яза алачак түгелдер. Анарда «Мин»лек «без» эченә кереп киткән вә шунда эрегән, беткәндер. Ул «без»чедер, безне генә язадыр. Вә һичбер вакыт тирә-юньдәге «без» дән югары да чыга алмыйдыр, түбән дә төшә алмыйдыр, таҗрәд дә итә алмыйдыр. Ул җаны-тәне, төбе-тамыры белән үз мохитына, үз халкына гына багланганды, шул халыкның моңыны җырлыйдыр, дәрдене көйлидер, шул халыкның үз шагыйре, үзәк шагыйредер.

Менә шуның өчендер ки гыйльми хәзерлеге урта, ятим, фәкыйрь егерме биш яшьлек Габдулла Тукай һичбер кемнең өндәве, димләвендән башка халкы тарафыннан сөелеп житеп киң халык катлавының эченә, рухына сенеп, халык шагыйре булып өлгергәндер. Менә шул милләтнең күңеленә манчып кына каләмене тибрәткән өчендер ки Тукайның шигыре зыялыларыбыз мохитында гына булып калмаенча, авылга җитеп, урамга, кырга, басуга чыгып киң халык катлавыбызның малы булып өлгергәндер. Вә бик кыска еллар эчендә анын

---

[1]Сүз 1908 елда рус матбугатында, төгәлрәге «Волжско-Камская речь» газетасында А. П. Пинкевичның «Очерки новейшей татарской литературы» исемле мәкаләсе белән башланып киткән бәхәс турында бара. Бәхәстә тагын Касим Уралец, «Татарин», Фатих Әмирхан катнаша.

[2]«Мөнтәкыйть» 1912 елда басыла. Тукайның академик басмасын чыгаручылар аңа мондый искәрмә бирәләр: «Шигырь Тукай әсәрләрен урынсыз һәм буржуача тәнкыйть итүче Г. Ибраһимовка каршы юнәлдерелгән. «Ялт-Йолт» журналының (1913, № 53) тышлыгында ат коерыгын тотып торучы берәүнең рәсеме төшерелә, рәсем эчендә «Габди» дип куела (Габди - Г. Ибраһимовның псевдонимы), рәсем астына «Мөнтәкыйть» шигыренең:

Ул тота да ат коерыгын да, бу—озын сач дип куя.
Тик нигә башта түгел, тәнкыйтькә мохтаҗ дип куя,

—дигән юллары басыла.

шигырьләре көйләп-көйләп, халык җырларыбыз белән ярышып, аларның урыннарын тота башлагандыр. Аның шигырьләренең зур бер өлеше мәдәниләшкән, әдәбиләшкән халык җырлары булып кына алынгандыр, мәдрәсәдән башлап шәһәрләрнең чәйханәсендә дәвам итдергән шигырьләренең бу кадәр кыска мадатдә (вакытта) киң халык арасына җәелеп, анда үзләшеп китүе, халыкның барлыгы эченә җирләшүе—бу бик күп шагыйрьгә насыйп булган бәхет түгелдер. Моның кыйммәте дә бик шәп иттереп энҗе төсле тутыкмый торган берничә шигырь язып та кечкенә бер зыялы мохитда булып калырга мәхкүм шагыйрьләрдән юксәкдер, киң катлаучылык өчен, бер милләт өчен беренчесе, мең мәртәбә файдалыдыр.

Шул ук халыкчылык, халыкка файда итү, яшьлегенә тәрбия бирү ягындан караганда да Тукайның мөхалефтләренең (каршылары, дошманнары) күкләргә күтәргән Сәгыйть Рәми, Дәрдмәнднең шигырьләренең халык күз алдында кыйммәте ни кадәрдер? Монарга да төрле зыялыларның сүз көрәштерүләренә карамаенча халык үзе кыйммәт биреп өлгергәндер. Бу ике шагыйрьнең шигырьләреннән фәкать берәрсене генә Сәгыйть Рәмидән «сызла, сызла, сызла күңелем»не, Дәрдемәнддән «Сәлим бабай»ны (кая ул көнләргә) үзләштергәндер, үз итеп үзенең йөрәк малы амбарына салып, үзенең күңел җимешләре арасына кушкандыр. Ләкин, шуны да онытмаска кирәк, бу ике шагыйрьнең бу ике шигырьләре үзләре дә мохитның тәэсиренә бирелеп, халыкның аһ вә зарын көйләү парчаларыдыр. Нә Сәгыйтьнең «Мин»ене, нә Дәрдмәнднең «Кораб»ыны халык нә таныйдыр, нә аңлыйдыр, нә аны көйлидер, нә җырлыйдыр.

Тукайның шигырьләре белән бу көндә төрек-татар халкы һәм еглыйдыр, һәм көләдер, һәм моңаядыр, һәм уйныйдыр, киләчәкдә дә төрек-татар халкының киң катлавы бу шигырьләрдән әллә никадәр тәм табып, ләззәт алып аны укыячакдыр, җырлаячакдыр, аның көлкесеннән көләчәкдер, кайгысыннан күз яше агызачакдыр. Менә шуның өчен дә Тукай халык шагыйре булып өлгергәндер. Үзенең җиде-сигез еллык шагыйрьлек тормышында ни кадәре фәкыйрьлек, авырлыкда яшәсә дә үзенең халкының тәхетенә менеп җирләшә алгандыр вә аны анда кысырыклый торган әле мәйданда бер көндәш дә юкдыр.

Тукайның шул җиде-сигез елда баскыч-баскыч ничек үсүене, ниләр язганыны күзебез белән күреп торабыз. Ул үзенең беренче шагыйрьлек баскычыны Мөхәммәдиядән вә иске чыгатай әдәбиятыннан өлге алып язу дәверен бик тиз үтеп китде вә бу үтеше аның форма ягындан гына булмаенча, аның теленең җирләшүе, шигырьләренең халык җырларына якынлашуы җәһәтендән дә, мәгънәнең үзгәрүе ягыннан да зур бер үсү төсен аладыр. Ул, тарыйкатче (төрле рәвештәге) мистик диваналарның тәэсиреннән котылып, зәмин, заманның кушканынча халыкчылык, милләтчелек аның шигъриятенең үзәк урынын тотадыр. Шул мохит, шул ук мохитның эчке сәбекендә (узу, алга китешендә) бик зур урын тоткан үзебезнең хәлебезне тәнкыйдь, аның искергән, черегән формаларыннан көлү, аның белән көлә-көлә шикакъ (аерылышу) итү Тукайны бик тиз һөҗүчелеккә (көлү, юмор-сатира) таба үстерәдер. Ул да бу юлда зур уңышлык күрсәтеп бик мәгънәле һөҗү шигырьләрене мәйданга китерәдер. Идел буе матбугатының ул вакытта иң мөһим урынын тоткан көлке журналында[1] Тукай тиндәшсез бер һөҗүче—сатир язучы булып өлгерәдер. Ба Сахәдә (мәйданда) аның белән әзәрбәйҗанның Сабиры гына буй үлчәшә аладыр. Идел буе матбугатында Тукайдан соң бу урын бик озакка кадәр буш каладыр. Большевик дәверенең башларында бу урынны Бөдәйле бер тоташ башласа да, милләтчелек сылтавы белән ул да юк ителәдер. Бу урын бу көнгә кадәр бушлыкда каладыр.

Тукай—мулла баласы. Ул Кушлавыч авылының Гариф мулла белән Өчиле хәзрәтенең кызы Мәмдүдә остазбикә балалары гына түгелдер, ул халыкына хезмәт итеп килүне үзенең милли, дини бурычы дип уйлаган, Идел буеның гасырлар буе бик күп ауырлык күреп, шул вазифасы башында булынган муллалык, остазбикәлекнең шәргый (шәригатьчә) баласыдыр. Шул муллалык, остазбикәлек хакыны тәрбия итү, яшь буынга тугъры юл күрсәтү, начарлыкдан саклау, үзенең зур бурычы дип ышанган, ул ышану Тукайның тамырына ук сеңгәнгә ул Казанга килеп мәктәп-мәдрәсә мәсьәләсенә якынлашкач да тәрбияче булып китәдер. Корьән китапларына, балалар якчысына (яклаучысы—Р. Н.)

[1] «Ялт-йолт», «Яшен» журналлары булырга тиеш.

кирәкле әллә никадәр тәрбияви шигырьләр яза, дөньяга җәелгән әллә никадәр баснялар (мәсәлләр)не Идел буенча итдереп, бик тәмамиләндереп әйтеп бирә. Вә бу юлда ул вакытның сусавын бастырырлык тәрбияви шигырьләр мохиты хәзерләп чыгадыр. Бу эшдә дә Тукай беренче җиргә бик тиз менә вә шул беренчелекне гомер буе саклап киләдер.

Тукайның үзенең шәхси тормышы юклык, ятимлектә үсүе, Казан куллан киткәндән бирле юксыллык, үксезлеккә баткан милләтенең кайгысы, моны аның үзенең шәхси кайгы-хәсрәте төсене ала вә Тукай милләт моңыны көйли торган, милләт бәхетсезлегене җылый торган әллә никадәр шигырьләр мәйданга китерә, милли моңны шигыренең эченә ташлый. Ләкин ул мескен булып моңланмый, өмидсезләнеп зарланмый. Халыкның җырлаганын сөйләгән вә тагы җылатканнын соңында киләчәктә тагы безнең урамда да бәйрәм булачакны, безгә дә кояш чыгачакны белдереп, зур өмид биреп зафәрле (җиңеп чыгу, теләккә ирешү) киләчәкне булганы кебек күрсәтә. Вә зур бер өмидчеллек уятып яшь буынның алдында киләчәктәге бай, мул үзлек эчендә үз тормышыны үз иленең үзенә кайтачагыны җанландырып, гәүдәләндереп бирә.

Тукай тормышының иң бәрәкәтле чагында, үзенең кабилияте ачылып чәчәк атып өлгергән көннәрендә үзенең ярлы, ятим мохитындан алган үпкә авыруының әскәнҗәләре (авырлыклары) арасында кысыла башлый. Табгый шад, өмидле бу җегеткә бу авыру иң гайре табигый төсдә ангкас (кире дүнү, бер нәрсәгә бәрелеп кире кайту) итеп, аның үзендә үз-үзенә каршы өмиден киметә, аңарда үзенең тормышына каршы, үзенең теләкләренә каршы бер анксар (ватылу, сыну) хыял уята. Ул «Өзелгән өмид» рухында шигырьләр язарга тотына. Ләкин шәхси өмидсезлек аның шигъри кояшын зәгыйфьләндерми, билгакес (киресенчә) аның шигырьләренә моңанчы сизелмәгән яңа бер аһәң биреп, аның мәгънәсене тирәнләндерә, аның хасиятләрене нечкәләндерә. Мохитның бик чуалчык булуы меңләр, меңләр мөридләр ясап өлгергән Тукайга вакытында үзен каратырлык, вакытында үзен дәруландырырлык мадди имкян тудыра алмый. Аның фәкыйрьлек, ятим-үксезлекдән килеп чыккан сабырсызлыгы да моңарга кушыла да безнең әдәбиятыбызга бик яңа җимешләр бирәчәк бу дәвере дә кыска дәвам итеп Тукайга:

И мөкатдәс моңлы сазым,
уйнадың син ник бик аз?
Син сынасың, мин сүнәмен—аерылабыз
ахрысы...—

ны җырлата. Вә бик тиз вакытта хакыйкатә Тукай сүнә. Аның бу кадәр бәрәкәтле уйнаган сазы сына. Тукайның иҗадының бу яңа дәвере, үзенең сазының нечкә кылларында туйганчы уйнамаенча киселә... Тукай вафат итә.

Шуның өчен, Тукайның калдырган мирасы—«Тукай мәҗмугасы» Тукайның халкына бирергә теләгән вә бирә беләчәк бүләкләренең бөтене түгелдер. Алар табигый рәвешдә үсеп, киңәеп бара торган, аның иҗадларының ахырына килмәенчә, чишмәсенең суы бетмәенчә урта бер җирендә соңгый (ясалма рәвештә) киселеп калган өлеше генәдер. Тукайның тагы никадәр тирән мәгънәле әсәрләр бирә беләчәгенә җанлы шаһидлар гынадыр. Бу әсәрләр нәрсәләр булыр иде, без аны белә алмасак да, боларның ни төсдә, нинди тирәнлекдә булуын без әйтә алабыз. Болар да һаман шул халкыбызның моңы, дәрде белән халкының киләчәккә өмиденнән торган әсәрләр булачак иде. Боларны күрергә, боларны укырга язмыш безгә ирек бирмәде. Тукай аларны авырлык көенчә, күңелендәге нур көенчә үзе белән алып китте.

Шуңарга халкыбызның киң катлавы Тукай үлү көннәрендә матәм тотканда Тукайның ачы язмышы өчен генә җыламыйдыр. Аның күңел сыныклыгының ярты җыры җырланса да, яртысы җырланып бетмәенчә өзелеп калганы өчен дә хәсрәт чигәдер, күз яше түгәдер. Тукайга милли вазифасыны тулы көенчә үтәргә имкян бирмәгән мохитка рәнҗидер, сыкрыйдыр.

И мөкатдәс моңлы сазым,
уйнадың син ник бик аз...—

ны күз яше белән кабатлыйдыр.

*Варшава*





# 11—ҺУД (ҺУД) СҮРӘСЕ

**(Һуд сүрәсе 123 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән. Бер өлеше Мәдинәдә иңгән, дип фаразлана.)**

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Әлиф. Ләм. Ра. Бу шундый бер Китаптыр ки, аның аятьләре иң катгый дәлилләр белән расланган, ап-ачык аңлатылган, *(ул Китап)* хөкем иясе, бар нәрсәне белеп торучы тарафыннан камил рәвештә тәртипләнгән.

**2.** Әйт:

—Аллаһтан башка затка табынмасыннар, дип иңдерелде. Шик юк ки, мин Аның тарафыннан җибәрелгән бер кисәтүче һәм сөенче алучы кеше. **(3)** Һәм Аллаһтан ярлыкау сорагыз, тәүбә итегез, дип иңдерелде. *(Әгәр шушы әмерләрне җиренә җиткезеп үтәсәгез)* Аллаһ сезне тәгаенләнгән бер вакытка чаклы муллыкта яшәтер, артыгы белән игелек кылган һәркемгә артыгы белән игелек бирер. Әгәр дә йөз чөерсәгез, хәтәр Көндә башыгызга киләчәк җәза турында уйлап куркам,—диген.

**4.** Сез бары тик Аллаһ хозурына кайтачаксыз. Ул бөтен нәрсәгә кодрәтле.

**5.** Аң булыгыз, алар *(мөшрикләр)* күңелләрендә булган дошманлыкны яшерер өчен ниләр генә кыланмыйлар. Аң булыгыз, алар кат-кат киемнәргә уранып, яшерергә тырышкан нәрсәләрен дә, күз алдына кылганнарын да Аллаһ үтәли күреп тора. Ул күңелгә яшерелгәннәрне дә белеп торучы.

**6.** Җир йөзендә яшәүче һәр җан иясенең ризыгы бары тик Аллаһ ихтыярында. Аллаһ ул җан иләренен торган урынын да, соңыннан кая урнаштырылачагын да белә. Боларның барысы турында да Китапта ап-ачык язылган.

**7.** Аның тәхете идарәсе су өстендә иде. Яхшы эшләр башкарганыгызны сынар өчен Ул күкләрне, Җирне алты көндә яралтты.

Әгәр син:

—Үлемнән соң янадан тереләчәксез,—дип әйтсән, кяферләр, һичшиксез:

—Бу күз буудан *(сихердән)* башка нәрсә түгел,—диячәкләр.

*(«Аның тәхете су өстендә иде» җөмләсе турында бәхәсләр күп. Хәсән Басри Чантай язуына күрә, мәшһүр тәфсирчеләрдән Бәйзави бу фикерне кире кага. Күк белән Җир яралтылганга чаклы галәмдә Гареш һәм су гына була. «Гарше көрси»нең сүзлек мәгънәсе—тугызынчы кат күктә урнашкан тәхет. Әмма бәгъзеләре аны Бөтен Галәм, дип аңлата.*

Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге.

*«Гареш: галәмдәге бөтен җисемнәрне чолгап алган вә без күз алдына китерә алмаган нәрсәдер. Тәфсирчеләрнең бу аятькә кагылышлы аңлатмаларына күрә, Аллаһы Тәгалә башта Гарешне, аннан соң суны, аннан соң күкләрне вә Җирне яралткан».*

Садретдин Гүмүш тәфсиреннән.)

---

Журнал өчен **Рабит БАТУЛЛА** әзерләде.

**8.** Әгәр дә Без аларга бирелачәк жәзаны санаулы көннәргә кичектереп торсак, һичшиксез:—Бу кичектерүнең сәбәбе ни? *(Ни өчен газапны бүген үк бирми?)*—дип сораячаклар. Аң булыгыз, ул жәза килгәч, алар өстеннән жәза алынмас. Алар көлкегә санап килгән ул газаплар үзләрен үк уратып алачак.

**9.** Кешегә рәхим-рәхмәтләр биреп тә соңыннан ул рәхим-рәхмәтләребезне аннан алсак, багыгыз, ул кеше тәмам өметсезлеккә төшә һәм шөкерсез була.

**10.** Башына төшкән бәладән соң аңа нигъмәтләр бирсәк, әлбәттә, ул:
—Яманлыклар миннән китте,—дияр.

Ул чакта адәм *(мөшкел хәлен онытып)* куаныр һәм борынын чөяр. **(11)** Авырлыкларга чыдап, сабыр итеп, игелек кылганнар алай түгел. Алар өчен ярлыкау һәм әжерләр булыр.

**12.** *(Мөшрикләр)*:
—Ул *(Аллаһың)* Күктән безгә хәзинә яудырсын иде яки берәр фәрештәсен төшерсен,—дигәч, бәлки син аятьләребезнең кайберләрен аларга анлатудан баш тартырсың вә шунын аркасында жаның кысылыр. Аң бул, син бары тик кисәтүче генә. Аллаһ кына бөтен нәрсәнең хужасы.
*(Мөшрикләр хәзрәти Мөхәммәдтән сынамнарына-потларына тимәвен үтенделәр. Мөхәммәд Пәйгамбәр аларга кагылмады, ягъни аятьләрнең барысын да хәбәр итмәде. Бу эше өчен Аллаһ Тәгалә хәзрәти Мөхәммәдкә шелтә белдерде.)*

**13.**—Аны *(Корьәнне)* әллә үзеңнән чыгарып яздыңмы?—дип сорарлар мөшрикләр.
Син әйт:
—Алайса, әйдәгез, сез дә шунын кебек, һич югында ун сүрә чыгарып, язып карагыз. Аллаһтан башка табынганнарыгызны да чакырыгыз, *(ул уйдырма илаһларыгыз да берәр сүрә язып карасын)* әгәр дә сезнең сүзегез дөреска чыкса,—диген.

**14.** Әгәр дә шуннан соң алар *(мөшрикләр һәм сыннар-потлар җавап бирмәсә)* бу эшне *(аять язуны)* башкара алмасалар, хактыр ки, ул *(Корьән)* Аллаһнын гыйлеме белән иңдерелгән булып кала. Хакыйкатән, Аллаһтан башка тәнре юк. Инде шуннан соң да сез мөселман булмассызмы икән?

**15.** Фани дөньяда муллык эчендә яшәргә теләгәннәргә, башкарган эшләренен гүзәл әжере буларак, мул түләп бетерербез вә алар һичбер зыян күрмәс.

**16.** Фани дөньяда кылганнары юкка чыкты. Аларның кылганы да яман эш иде. Менә шулар инде Ахирәттә уттан башка нәрсә алмаячак бәндәләр.

**17.** Аллаһтан аятьләр кабул итеп, артларыннан шаһит килсә, әгәр алларында яхшы юлга өндәүче, рәхмәтле Мусага бирелгән Китап ятса, алар иман китерерләр. Аны танымаган һәртөрле өердәгеләргә алдан вәгъдә ителгән тәмуг булачак. Син дә бу мәсьәләдә икеләнеп калма. Чөнки, хактыр, боларның барысы да Раббыңнандыр. Ләкин инсаннарның *(мөшрикләрнең)* күбесе иман китерми.

**18.** Аллаһка каршы ялганнар уйлап чыгарганнан да яманрак кем бар? Алар Аллаһ хөкеменә китереләчәк, шаһитләр дә:
—Менә болар Раббыга каршы ялган сөйләүчеләр,—дип әйтәчәк.
Аң булыгыз, Аллаһның ләгънәте залимнәр башына булачак.

**19.** Алар шундый *(залимнәр ки, кешеләрне)* Аллаһ юлыннан яздырырга, аны *(тугры юлны)* кәкре итеп күрсәтергә маташалар. Ахирәтне инкарь итүчеләр дә шулар булыр.

**20.** Алар Жир йөзендә *(Аллаһны)* бичара хәлдә калдырырлык кодрәткә ия түгел. Үзләрен Аллаһтан *(җәзасыннан)* коткара алырлык бер генә химаячеләре дә юк. Аларга кат-кат жәза биреләчәк. Алар Хакыйкатьне ишетмәмешкә, күрмәмешкә салышалар. **(21)** Алар үзләренә үзләре зыян эшләде. Уйлап чыгарганнары *(потлары)* да үзләреннән качып китеп юкка чыкты. **(22)** Шик юк ки, Ахирәттә иң күп зыян күрүчеләр дә шулар булыр.

**23.** Иман китереп, игелекле эшләр эшләгән кешеләр, Аллаһка буйсынып, итагать иткәннәр җәннәт әһелләре булып, анда мәңгегә калачак.

**24.** Бу ике халыкның *(кяферләр белән мөселманнарның)* хәле сукыр белән күзле, саңгырау белән ишетүче кешенеке кебек. Алар бер-беренә тиң булырмы? Әле һаман гыйбрәт алмыйсызмыни?

**25.** Менә Без Нухны үз халкына пәйгамбәр итеп күндергән идек. *(Ул әйтте)*:

—Әлбәттә, мин Аллаһның газабы турында сезне кисәтүче кешемен. **(26)** Аллаһтан башкага гыйбадәт кылмагыз. Хактыр ки, мин сезнең өстегезгә хәтәр җәза килер, дип куркамын,—диде. **(27)** *(Нух)* кавеменең имансыз житәкчеләре әйтте:

—Син дә безнең кебек үк бер кеше. Синең арттан бары тик үз башы булмаган түбән катлам бәндәләре генә ияргәнен күрәбез. Бездән өстен һичбер сыйфат синдә юк. Күреп торабыз, сезнең барыгыз да ялганчы. **(28)** *(Нух)* әйтте:

—Әй, кардәшләрем, әгәр Раббым тарафыннан миңа җибәрелгән ачык исбатка ия булсам, вә Ул миңа үз катыннан бер рәхмәт иңдергән булса, сездән яшереп тотылган булса, моңа ни әйтерсез? Сез аны кабул итәргә теләмәсәгез, без аны сезгә ирексезләп такмаячакбыз. **(29)** Әй, халкым, Аллаһның әмерләрен сезгә җиткезгәнем өчен мин сездән һичбер мал *(түләү)* сорамыймын. Миңа тиешле әҗер бары тик Аллаһ ихтыярында гына. Мин иман китергәннәрне янымнан кумаячакмын. Алар Аллаһ белән кавышачак. Фәкать мин сезне билгесезлек эчендә адашкан бер халык буларак күрәмен.

*(«Хәзрәти Нух халкының өстен катлам кешеләре иман китергән фәкыйрьләр белән рәттән торасы килмичә: аларны яныңнан ку, диделәр. Ләкин Нух пәйгамбәр иманлы фәкыйрьләрне үз яныннан кумады».*

Садретдин Гүмүш тәфсиреннән.)

**30.** ... Әй, халкым, аларны кусам, мине Аллаһтан *(аның җәзасыннан)* кем килеп коткарыр? Шуны да аңламыйсызмыни соң сез? **(31)** Мин сезгә:

—Аллаһның бөтен хәзинәсе минем кулда, димим. Ләкин мин яшерен нәрсәләрне дә белмимен. «Мин—фәрештә»,—дип тә әйтмимен. Сезгә нәфрәт белән багучыларга да мин: «Аллаһ аларга беркайчан да игелек кылачак түгел»,—дип әйтә алмыймын. Аларның күңелендә ниләр барын бары тик Аллаһ кына белә. Иман китергән *(фәкыйрьләрне)* янымнан куган хәлдә мин дә залимгә әвереләчәкмен,—диде. **(32)** Тегеләр әйтте:

—Әй, Нух, син безнең белән озак карулаштың, гауганы арттырдың гына. Әгәр дә син дөрес сүз сөйли торган булсаң, безне куркыта торган җәзаны хәзер үк китер,—диделәр. **(33)** *(Нух)* әйтте:

—Аны бары тик Аллаһ кына китерә ала *(җәза бирү бары тик Аллаһ ихтыярында гына)*. Һәм сез Аллаһны гаҗиз итә алмаячаксыз *(сез хаклы булып, Аллаһны бичара хәлдә, көлкегә калдыра алмаячаксыз)*. **(34)** Әгәр Аллаһ сезне адаштырырга теләсә, мин сезне никадәр генә үгетләсәм дә, сезгә файда булмас *(иманга килмәячәксез)*. Ул сезнең Раббыгыз. Һәм, ниһаять, сез Аның янына китереләчәксез. **(35)** *(Алар—мөшрикләр)*:

—Ул *(Мөхәммәд)* моны *(Коръәнне)* үзе уйлап чыгарган,—дип әйтерләр.
*(Ий, Мөхәммәд)* әйт:

—Әгәр дә мин аны үзем уйлап чыгарган булсам, гөнаһысы үземә булыр. Ләкин мин сез кылган гөнаһтан ерак торачакмын,—диген. **(36)** Нухка вәхий ителде ки:

—Халкың эченнән иман китергәннәрдән башкасы иман китермәячәк. Шулай булгач, алар кылган *(гөнаһлар)* өчен борчылма. **(37)** Мин күреп торганда, әмеребез килгәч, көймә эшлә һәм көфер иткәннәр турында минем белән бер сүз дә сөйләшмә *(ягъни, алар өчен гафу сорама, дога кылма)*. Алар, һичшиксез, батып үләчәк. **(38)** Нух көймә ясый башлагач, халыкның бай житәкчеләре аның яныннан үтеп-сүтеп йөргәндә мыскыллы сүзләр әйтеп узалар иде. Ул *(аларга)* әйтте:

—Әгәр дә бездән көләсез икән, шуны яхшы белеп торыгыз ки, сез бездән көлгән кебек, килер вакыт, без дә сездән көләрбез. **(39)** Хурлыклы җәзаның кем өстенә киләчәге вә бетмәс-төкәнмәс газапның кем башына төшәчәген озакламый күрербез,—диде. **(40)** Ниһаять, әмеребездән соң учак *(кебек су)* кайный башлагач, Нухка әйттек:

—Исемнәре телгә алынганнардан тыш *(кяферләрдән, бер хатыныңнан, бер улыңнан башка җан ияләренең)* һәрберсеннән берәр пар, гаиләнне һәи иман китергәннәрне көймәңә ал.

*(«**Т. Кочигиттә:** мич кайный башлагач. **Х. Карамандa:** сулар кайнап, күбәя башлагач. Х. Чантайда: мич кайнадыгы заман. **И.Крачковскийда:** закипела печь. **И. Пороховада:** печь низринула потоки вод. **Ш. Ногманида:** җирдән су кайнап чыга башлагач, дип бирелә. Ләкин гасырыбызның галимнәреннән **Хәмди Языр** исә хәзрәти Нух көймәсенең җилкәнле булмыйча, пар машинасында йөргәнлеге турында фараз кыла. Ягъни, пар казанының кайный башлавына ишарә итә. Мәүланә **М. Алидә** исә: үзәннән ургылып су ага башлагач, диелгән».*

Садретдин Гүмүш тәфсиреннән.)

**41.** *(Нух)* әйтте:

—Көймәгә менегез. Аның йөзеп китүе дә, туктавы да Аллаһ исеме белән башкарыла. Шик юк ки, Раббым ярлыкаучы, гафу итүчедер,—диде. **(42)** Көймә тау кебек дулкыннар арасында аларны алып йөзә иде. Нух көймәдән еракта калган углына:

—Балакаем, син дә безнең белән бергә көймәгә утыр, кяферләр белән бергә булма,—дип кычкырды.

*(Хәзрәти Нухның иман китергән өч углы көймәдә иде: Хам, Сам белән Яфәс атлылары. Төркиләр, безнең борынгы балаларыбыз Яфәстән туган ир баладан килә дип риваять ителә. Төрек исемле һәм Алып исемле ике углы Идел буена күчеп киләләр. Идел буе төркиләре, имеш, әнә шул Алыптан таралган.)*

**43.** *(Ярда калган)* углы:

—Мин су житмәслек тау түбәсенә менеп котылачакмын,—диде. *(Нух)*:

—Бүген Аллаһның әмереннән мәрхәмәтле Аллаһтан башка берәү дә коткара алмаячак,—диде. Шулчак алар арасына дулкын бәреп керде һәм шулай итеп, *(Нухның углы)* батып үлде. **(44)** Һәм әйтелде *(Аллаһ тарафыннан)*:

—Әй, Жир, суыңны йот. Әй, Күк, суыңны туктат,—диелде. Су кими башлады. Эш тәмам булды. Көймә дә Җуди тавына килеп сыенды. Һәм:

—Тончыксын шул залимнәрнең токымы,—диелде. (45) Раббысына дога итеп, Нух әйтте:

—Йа, Раббым, шөбһәсез ки, углым да минем токымым иде бит. Синең вәгъдәң тормышка ашты. Син хакимнәр хакиме,—диде. **(46)** Аллаһ әйтте ки:

—Әй, Нух, ул асылында синең токымың түгел иде. Чөнки ул—яманлык кылган кеше. Шулай булгач, белмәгәнең турында Миннән үтенмә. Җаһилләрдән *(наданлыгы аркасында гөнаһ кылучы)* булмасын, дип кисәтәм Мин сине. **(47)** Нух әйтте:

—Йа, Раббым, киләчәктә белмәгәнем турында ялвармас өчен, Сиңа сыенамын. Мине ярлыкамасаң, гафу итмәсәң, мин зыян күрүчеләрдән саналырмын. **(48)** *(Аллаһ)* әйтте:

—Әй, Нух, сиңа һәм синең белән бергә булган өммәтеңә Бездән сәлам, бәрәкәтләр белән *(көймәдән)* төшегез. Аларны Без дөньяда рәхәт яшәтәчәкбез. Соңыннан Бездән хәтәр җәза алачак өммәтләр дә булачак.

**49.** *(Мөхәммәд)* сиңа иңдерелгән яшерен хәбәрләр шушы булыр. Моннан алда бу хәбәрләрне син дә, халкың да белми иде. Шуңа күрә, син сабыр ит. Чөнки соңгы нәтиҗә *(әҗер сабыр итеп, кыенлыкларга чыдап, гөнаһ кылудан)* сакланганнарныкы булыр.

**50.** Гад кавеменә дә Һудны күндердек. Әйт:

—Әй, кавемем, Аллаһка буйсыныгыз. Аннан башка тәңрегез юк. Башкасын сез бары тик уйлап кына чыгардыгыз,—диген. **(51)**

—Әй, кавемем, мин сездән түләү өмет итмимен. Минем әҗерем бары тик мине яраткан *(Аллаһ)* ихтыярында гына. Әле һаман шул турыда уйлап караганыгыз булмадымыни?—диген. **(52)**

—Әй, кавемем, Раббыгыздан ярлыкау теләгез. Сонра тәүбәгә килегез. Өстегезгә мул яңгырлар яудырсын вә куәтегезгә куәт өстәсен. Гөнаһ кылып *(Аллаһтан)* йөз чөермәгез,—диген. **(53)** Алар әйтте:

—Әй, Һуд, син безгә ачык бер могҗиза күрсәтмәдең, синең сүзеңә карап, без дә тәңреләребезне ташламаячакбыз. Һәм без сиңа ышанып, иман китерәчәк түгелбез,—диделәр. **(54)**—Без: тәңреләребезнең берәрсе сиңа зыян-зәхмәт салгандыр,—дип кенә әйтә алабыз. *(Ягъни шул зәхмәттән соң син акылдан язгансыңдыр, юкны сөйләп йөрисең.)* **(Һуд)** әйтте:

—Мин Аллаһны шаһит итәмен. Сез дә шаһит булыгыз, мин сез табынганнардан ерак торамын,—диде. **(55)**—Аннан башка *(табынган сыннарыгыз)* белән бергә барыгыз да миңа каршы, тын алырга да ирек бирмәстәй, мәкер корыгыз. **(56)** Мин, Раббым, сезнең Тәңрегез булган Аллаһка сыендым, Ул мөгезеннән, ялыннан тотмаган бер генә җанвар да дөньяда юк. *(Ул башкара алмаган, аның кодрәте җитмәгән нәрсә юк.)* Шөбһәсез ки, Аллаһым минем тугры юлның хуҗасыдыр. **(57)** Әгәр йөз чөерсәгез *(аңысы сезнең эш, теләсәгез нишләгез, әмма үземә тигән бурычны мин үтәдем)* күндерелгән хәбәрне мин сезгә белдердем. Раббым *(ихтыяр итсә)* сезнең урынга башка бер халыкны китерер, ләкин сез Аңа бернинди дә яманлык кыла алмассыз.

**58.** Бездән әмер килгәч, Һудны вә аның белән бергә иман китергәннәрне рәхмәтебез белән коткардык, аларны авыр җәзадан алып калдык.

**59.** Менә Гад кавеме шул булыр. Раббының аятьләрен инкарь иттеләр. Аның пәйгамбәрләренә буйсынмадылар вә киребеткән үҗәт хакимнең әмеренә буйсындылар. **(60)** Алар һәм бу дөньяда, һәм дә Кыямәт көнендә ләгънәткә хөкем ителде. Аң булыгыз, Гад халкы Раббыны инкарь итте. Аннан соң тагын белеп торыгыз, Һудның халкы Аллаһның рәхмәтеннән еракка *(һәлакәткә)* куылды.

**61.** Сәмуд кавеменә дә үз кардәшләре Салихны күндердек. Әйтте:

—Әй, халкым, Аллаһка гыйбадәт кылыгыз. Сезнең аннан башка тәңрегез юк. Ул сезне җирдән *(туфрактан)* яралтты. Ул сезне шунда яшәтте. Шуңа күрә, сез аннан ярлыкау сорагыз. Аннан соң тәүбә итегез. Раббым *(дога укыган)* бәндәләренә киң рәхмәтледер, якындыр *(догаларыгызны)* кабул итәр. **(62)** Әйттеләр:

—Әй, Салих, син безнең арада яшәгәндә өметле генә егет идең. *(Хәзер)* бабаларыбыз табынганнарга табынырга комачаулыйсың. Дөресен генә әйткәндә, без син гыйбадәт кылырга чакырган ул заттан нык шикләнәбез,—диделәр. **(63)** *(Салих)* әйтте:

—Әй, халкым, әгәр мин Раббымнан *(бирелгән)* ап-ачык аятьләр иясе булсам вә Ул миңа бер рәхмәтле булып *(пәйгамбәрлек)* биргән булса, моңа ни әйтерсез? Әгәр дә мин Аңа буйсынмасам, Аллаһтан *(аның җәзасыннан)* кем мине коткарып калыр? Ул вакытта сез дә миңа зыян эшләүдән ары берни дә кыла алмаган булыр идегез. **(64)** Әй, кавемем, менә сезгә Аллаһның могҗизасы буларак дөя күрсәтәм. Аны иреккә җибәрегез, Аллаһның җирендә ул ашасын-эчсен. Аңа яманлык кылдыртмагыз. *(Юкса)* соңыннан сезне озакламастан бер газап тотачак.

*(«Үз халкы Салихка: әгәр син чын пәйгамбәр икәнсең, кыя-таштан дөя чыгар, диде. Салих Аллаһка ялварды, гыйбадәт кылды. Кыядан дөя килеп чыкты. Ләкин халыкның күбесе барыбер иман китермәде».*

Садретдин Гүмүш тәфсиреннән.)

**65.** Салихны тыңламадылар, дөяне *(балтырларын кисеп)* үтерделәр. Салих әйтте:

—Өегездә өч көн *(бәйрәм ясап)* торыгыз, *(соңра һәлак булачаксыз)*,—диде. Бу кисәтү һич тә буш сүз түгел иде. **(66)** Гозерем белән Салихны вә аның белән бергә иман китергәннәрне, Безнең рәхмәтебез буларак, *(җәзадан)* вә мәсхәрәдән коткардык. Шөбһәсез ки, Раббың куәтледер, җиңүчедер. **(67)** Золым итүчеләрне дә куркыныч тавыш *(гарасат гөрелтесе)* тотты вә йортларында *(җансыз)* йөзтүбән капланган килеш калдылар. **(68)** Әйтерсең лә, алар анда яшәмәгән дә кебек. Аң булыгыз, Сәмуд кавеме, чыннан да, Раббыны инкарь итте. Янә белеп торыгыз, Сәмуд халкы *(Аллаһның рәхмәтеннән)* мәхрүм калды.

**69.** Ниһаять, илчеләребез *(фәрештәләр)* Ибраһимга сөенче китерделәр:
—Сәлам сина,—диделәр.
Ул да:
—Сезгә дә сәлам,—диде дә тиз генә табынга кыздырылган бозау ите алып килде. **(70)** Аларның ризыкка сузылмаганнарын күреп, ул *(Ибраһим)* читенсенде һәм аның күңеленә шик-курку төште. Әйттеләр:
—Курыкма син, без Лут кавеме тарафына җибәрелгәнбез,—диделәр. **(71)** Ибраһимның хатыны шунда ук өягесте басып тора иде, без аңа Исхак белән Ягъкуб турында сөенечле хәбәр бирдек, ул көлде.
*(Хатынның Исхак исемле бәбәй табачагы, Исхак Ягъкубның атасы булачагы турындагы хәбәр.)*

**72.**—Бу—кеше ышанмаслык эш. Мин бит карчык инде, ирем дә карт кеше, каян килеп безнең балабыз булсын? Бу—гайре табигый хәл,—диде хатын. **(73)** *(Фәрештәләр)* әйтте:
—Аллаһның әмеренә гаҗәпләнәсезме? Әй, йортлы халык, Аллаһның рәхмәте вә бәрәкәте сезгәдер. Шөбһәсез ки, Ул мактауга лаек, Аның игелеге киңдер.

**74.** Ибраһимның куркуы беткәч, *(баласы булачагы турында)* сөенечле хәбәр алганнан соң, ул Лут халкы турында *(аларны яклап)* илчеләребез белән сөйләшә башлады. **(75)** Чыннан да, Ибраһим йомшак холыклы, кече күңелле, Аллаһ юлына бирелгән бер кеше иде. **(76)** *(Фәрештәләр әйтте):*
—Әй, Ибраһим, бу эштән *(Лут кяферләрен яклаудан)* баш тарт. Чөнки Раббының әмере *(газабы)* килде инде. Вә аларга кире алынмас җәза әзер. **(77)** Илчеләребез Лут янына килгәч, аларны күреп, хәсрәткә калды, аның хәле китте. Ул әйтте:
—Ай-һай авыр килде бу көн,—диде.
*(Лутның хатыны ире Лут янына килгән фәрештәләрне чибәр егетләр, дип белеп, башка ирләргә барып: «Аларны файдаланыгыз»,—ди. Лут бу яшь егетләрне тегеләрдән ничек якларамын, ничек саклармын, дип кайгырды, хәлсез булды. Лут халкында ирләр белән ирләр арасындагы җенси азгынлык киң таралган була. Кара: с. 7:80, 81.)*

**78.** Лут кавеменең ирләре *(яшь егетләрне теләүчеләр)* йөгерә-йөгерә аның өенә килделәр. Алар моннан алда да *(шундый ук)* яманлыклар кылган халык иде.
—Ий, кардәшләрем,—диде Лут.—Менә болары—минем кызларым, алар сезнең өчен саф *(ягъни, кунак егетләргә кагылмагыз, алар урынына кызларымны файдаланыгыз)*. Аллаһтан куркыгыз вә кунак егетләр алдында мине мәсхәрәгә калдырмагыз. Арагызда, ичмасам, бер генә тугры кеше дә юкмыни соң? **(79)** Әйттеләр:
—Үзең беләсең, синең кызларың безне кызыксындырмый. Һәм син безнең ни теләгәнебезне дә яхшы беләсең.
**(80)**—Их, сезгә каршы торырлык куәтем булса иде минем яки миңа ярдәм итәрлек таянычым булса иде, яки кереп качарлык ныгытылган шәһәрдә булса идем,—диде Лут. **(81)** *(Фәрештәләр)* әйттеләр:
—Әй, Лут, без—Раббының илчеләре. Алар сиңа кагыла алмас. Син төннең бер унай вакытында гаиләңне алып юлга чык. Артка борылып карамыйча качыгыз. Хатыныңнан башка һичкем өйдә калмасын. Аларга киләсе җәза, шөбһәсез, хатыныңа да кагылачак. Вәгъдә ителгән җәза иртәнге якта булачак. Таң атарга күп калмады бит инде.

**82.** Әмеребез килгәч, ул җирләрнең *(шәһәрләрнең)* астын өскә китердек вә аларның өстенә яндырылган балчыктан ясалган ташлар яудырдык. **(83)** Ул ташлар Раббы тарафыннан тамгаланган иде. Алар залимнәрдән ерак түгел.

**84.** Мәдьян халкына үз араларыннан чыккан Шөгаебны күндердек.
Әйтте:
—Әй, халкым, Аллаһка буйсыныгыз. Сезнең өчен Аннан башка тәңре юк. Үлчәгәндә авырлыкны да, *(кискәндә)* озынлык үлчәмен дә киметмәгез. Күреп торамын, сез муллык эчендә *(яшисез)*. *(Сез гөнаһка батып, шул гөнаһларыгыз өчен)* сезне бер көнне газаплар чорнап алыр, дип куркамын,—диде. **(85)**
—Әй, халкым, *(авырлык һәм озынлык)* үлчәгәндә гадел булыгыз. Кешеләргә

әйберләрен *(өлешләрен)* киметеп бирмәгез. Җир йөзендә бозыклык таратып йөрмәгез. **(86)** Әгәр дә мөселман икәнсез, Аллаһ калдырган сезгә хәерлерәк. Мин сезнең янга куелган сакчы түгелмен.

*(Соңгы җөмлә тәфсирчеләр тарафыннан төрлечә шәрехләнә. Әйтик, И. Крачковскийда ул болай язылган: я для вас не хранитель. В. Пороховада ул җөмлә бөтенләй юк. Ш. Ногманида, Нурулла хәзрәт җитәкчелегендә чыккан нөсхәсендә исә: мин сезгә сакчы түгелмен, һәр эшегезне күзәтеп бетерә алмам, үз эшегезне үзегез карагыз!—диелгән. Т. Кочигит тәрҗемәсендә ул менә мондый мәгънә ала: әгәр дә сез иманлы кешеләр икәнсез, сату-алудан Аллаһ сезгә файда буларак калдырган керем сезнең өчен тагын да хәерлерәк. Чөнки мин һәр яман гамәлләрдән сезне тыеп торучы түгел. Ягъни, кылган гамәлләрегез өчен мин түгел, үзегез җаваплы.)*

**87.** Әйттеләр:

—Әй, Шөгаеб, аталарыбыз табынган сыннар-потлардан баш тартырга, байлыгыбызны үзебез теләгәнчә тотмаска сиңа намазың әмер итәме? Юкса, син йомшак холыклы һәм дә тугры кеше идең, дип беләбез. **(88)** *(Шөгаеб әйтте)*:

—Һәй, халкым, уйлап караганыгыз булдымы икән, әгәр дә Раббымнан миңа ап-ачык аятьләр килсә, затлы ризыклар да бирелгән булса, ни әйтерсез? Рөхсәт ителмәгәннәрне эшләгәнегезне мин хуплый алмыйм бит инде. Көчем җиткәнчә, мин сезне үзгәртеп, тугры юлга чыгарырга тырышачакмын. Моны мин фәкать Аллаһның ярдәме белән генә башкара алам. Бары тик Аңа тәвәккәл иттем, бары тик Аңа кайтачакмын. **(89)**—Әй, халкым, сак булыгыз, миңа каршы бармагыз, Нух халкы яки Һуд халкы яки Салих халкының башына килгән *(җәзалар)* сезнең башка да төшмәсен иде. Лут халкы сездән ерак түгел. *(Андый җәза сездән дә ерак йөрмәс.)* **(90)**—Раббыгыздан ярлыкау теләгез, аннан соң тәүбәгә килегез. Шөбһәсез ки, Раббым кин миһербан иясе, чиксез мәрхәмәтле. **(91)** Алар әйтте:

—Әй, Шөгаеб, син сөйләгәннәрнең күбесен аңламыйбыз, сине зәгыйфь бер бәндә дип уйлыйбыз, кардәшләрең булмаса иде, сине, һичшиксез, таш атып үтерәчәк идек. Син бездән өстен түгелсең. **(92)** Әй, минем кардәшләрем сезгә Аллаһтан да кадерлерәкмени? Аллаһны онытып, артта калдырдыгыз. Шөбһәсез ки, Раббым сез кылганнарның барысын да уратып алучы. **(93)**—Әй, халкым, кулыгыздан килгәнне эшләгез. Мин дә эшләячәкмен. Үз-үзенә рисвай итәчәк җәзаның киләчәге, кемнең кем икәнен, ялганчыларның кем икәнлеген озакламый күрәчәксез. Көтегез. Мин дә сезнең белән бергә көтәм.

**94.** Боерыгыбыз килеп җиткәч, Шөгаебне вә аның белән бергә иман китергәннәрне рәхмәтебез белән коткардык; золым итүчеләрне исә куркыныч бер гөрелте тотты да, йортларында йөзтүбән *(һәлак булып)* калдылар. **(95)** Әйтерсең лә, алар анда яшәмәгәннәр дә кебек. Белеп торыгыз, Сәмуд халкы *(Аллаһның рәхмәтеннән ерак булганы кебек)* Мәдьян халкы да ераклашып, юкка чыкты.

**96.** Хактыр ки, Мусаны да могҗизаларыбыз белән, ап-ачык аятьләребез белән **(97)** Фиргавенгә һәм аның яраннары янына җибәрдек. Ләкин алар Фиргавен боерыгына буйсынды. Юкса, Фиргавеннең боерыгы гадел түгел иде. **(98)** Фиргавен Кыямәт көнендә үз халкының алгы сафында булачак, *(су эчәргә алып барган кебек)* аларны ияртеп, утка егылачак. Ул урын нинди хәтәр. **(99)** Алар бу дөньяда да, Кыямәт көнендә дә ләгънәткә хөкем ителгән инде. Аларга бирелгән «бүләк» *(җәза)* бик тә хәтәр «бүләк» булыр. **(100)** *(Ий, Мөхәммәд, халыклары һәлак булган)* илләр турындагы хәбәрләр шушы булыр. Без аларны сиңа аңлатабыз, аларның нәселеннән хәзер дә исәннәре бар, чабып ташланган печән шикелле кырылып юкка чыкканнары да бар. **(101)** Без аларга золым итмәдек. Алар бары тик үзләренә үзләре золым китерде. Раббының җәза әмере килгәндә, Аллаһны инкарь итеп, табына торган сыннары аларга һич тә ярдәм итмәде, җәзаларын арттырудан башка бернигә дә ярамадылар. **(102)** Раббың гаделсез шәһәрләрнең халыкларын әнә шулай җәзалады. Шөбһәсез ки, Аның җәзасы шундый хәтәр, интектергеч һәм әрнетүледер. **(103)** Менә боларның барысы да Ахирәт җәзасыннан курыкканнар өчен бер гыйбрәттер. Ул Көн барча кешеләрнең бер урынга җыелган көндер ки, ул Көн бөтен мәхлукатның *(җанлыларның Аллаһ каршысында)* җавап тотарга хәзерләнгән көнедер. **(104)** Без

аны *(Кыямәт көнен)* бары тик санаулы бер вакытка гына кичектереп торабыз. **(105)** Ул Көн килгәч, Аллаһның рөхсәтеннән башка һичкем сөйләшә алмас. Аларның кайсысыдыр бик бәхетсез булачак, кемнәрдер бәхеткә ирешәчәк. **(106)** Бәхетсезләр утта яначак, анда алар акырыш, ынгырашу *(сызлану)* эчендә калачак. **(107)** Алар шунда яначак. Җир белән Күк дәвам иткәнгә һәм Аллаһ башкача хөкем чыгарганга чаклы. Аллаһ үз ихтыярынча хөкем итүче.

*(«Аз гөнаһлылар тәмугта бераз вакыт янганнан соң, Аллаһ әмере белән оҗмахка кайтарыла».*

Хәсән Чантай тәфсиреннән. Ул Бәйзавидан алган.)

**108.** Бәхетлеләр исә җәннәткә керер. Алар анда мәңгегә калачак. Җир белән Күк дәвам иткәнчегә чаклы. Аллаһ башка хөкем чыгарганга чаклы. Бу нигъмәтләр бетмәс-төкәнмәс бәрәкәттер.

*(«Җир белән Күкнең дәвамы» турындагы тәгъбирдә фани дөньядагы Җир белән Күк түгел, Ахирәт дөньясының Җире, Күге турында сөйләнә. Идраһим сүрәсенең 48 нче аятендә: ул Көн җиткәч, Җир башка Җир белән, Күк исә башка бер Күк белән алыштырылыр, диелә».*

Садретдин Гүмүш тәфсиреннән.)

**109.** Алар аталары ничек итеп сыннарга табынган булса, шулай табына. Моның яман гамәл икәнлегендә шик тотма. Аларга тиешле җәзаны һич киметмәбез.

**110.** Хактыр ки, Без Мусага китап бирдек. Ләкин араларында гауга купты *(кемдер аңа ышанды, кемдер: ялган, диде).* Әгәр дә Аллаһның алдагы вәгъдәсе булмаса иде, алар арасындагы бәхәс киселгән булыр иде *(эшләре беткән булыр иде).* Шик юк ки, алар да *(мөшрикләр дә)* Корьән*(нең Аллаһтан иңгәнлеге)* хакында шик белдерде. **(111)** Шик юк ки, Раббың аларның һәрберсенә дә кылган гамәлләренә күрә төгәл әҗер *(җәза)* бирәчәк. Раббың аларның ни кылганын белеп тора. **(112)** Шуңа күрә, синең белән бергә тәүбә иткәннәр, сезгә боерылганча, туры юлда калыгыз. Хәттин ашмагыз. Ул сезнең ни кылганнарыгызны бик яхшы белеп тора. **(113)** Золым итүчеләргә таянмагыз. Соңыннан сезгә дә ут кабар *(җәһәннәмдә янарсыз).* Аллаһтан башка сезнең химаячегез юк. Ахырда *(гөнаһларыгыз булса)* Аннан дә ярдәм күрмәссез. **(114)** Көн башында да, азагында да намаз укыгыз. Игелекләр әшәке гамәлләрне каплар. Болар вәгазь алырга теләүчеләр өчен бер кисәтүдер. **(115)** *(Ий, Мөхәммәд)* сабыр-чыдам бул, Аллаһ игелек кылганнарның игелеген заяга чыгармас. **(116)** Сездән әүвәл яшәгән буыннар арасында, котылуга ирешкән берничә кешедән башка, Җир йөзендә яшәүче кешеләрне азгынлыктан тыярга алынучы кеше булмады, ни сәбәпле? Золым итүчеләр исә үзләренә бирелгән дөнья байлыгына алдандылар һәм гөнаһкяр булып киттеләр. **(117)** Халыклары игелекле булган шәһәрләрне Аллаһ хаксызга һәлак итмәс.

**118.** Раббың ихтыяр итсә иде: бөтен кешеләрне дә бер өммәттән ясаган булыр иде. Ләкин алар гауга чыгарудан туктамыйлар. **(119)** Аллаһның мәрхәмәтенә юлыкканнарыннан тыш. Шуңа күрә, Аллаһ аларны бер җәмгыять итеп яралтты *(бар итте).* Раббының:

—Җәһәннәмне кешеләр һәм җеннәр белән дыңгычлап тутырачакмын,— дигәне расланды.

**120.** Рәсүлләрем турындагы хикәяләр белән Мин синең күңелеңне *(ихтыяр көчеңне)* ныгытмак буламын. Аларда синең өчен Хакыйкать, кешеләр өчен кисәтү вәгазе бар. **(121)** Имансызларга әйт:

—Кулыгыздан килгәннәрне эшләгез. Без дә булдыра алганыбызча гамәл кылырбыз,—диген. **(122)**—Көтегез! Хактыр ки, без дә көтәчәкбез. **(123)** Күкләр вә Җирдәге серләргә бары тик Аллаһ кына хуҗа. Һәр гамәл Аңа кайта. Бәс, Аңа буйсыныгыз *(гыйбадәт кылыгыз)*, Аңа гына сыеныгыз. Раббыгыз сез кылганнарны белеп тора.

صدق الله العظيم

## ҖЫРНЫҢ ЕРТЫГЫ ЮК...

Татар жыры хәзинәсенен бер өлешен тәшкил иткән тарихи жырлар арасында халыкнын зур этник төркемнәреннән берсе—мишәрләр яшәгән төбәкләрдән язып алынганнары да шактый[1]. Бу жырлар башлыча XIX гасырга карыйлар һәм тематикалары, эчтәлекләре ягыннан да охшаш социаль жирлеккә нигезләнгәннәр. Тарихи жырларнын күбесенә хас булганча, алар кайсы да булса бер шәхескә багышлап ижат ителгәннәр. Солдат хезмәтенә алынган, әсир төшкән, качкынлыкта йөргән, сөргенгә сөрелгән кешеләрнен ачы язмышына борчылу, аларга теләктәшлек хисләре белдерү белән сугарылган мондый әсәрләрдә халык реаль шәхеснен исемен жырларга күчергән һәм буыннан-буынга тапшыра килгән. Кайбер жырларда анын герое үз исеменнән дә сөйли. Кем турында сүз барганлыгы күп кенә жырларнын исемнәреннән үк күренеп тора, мәсәлән: Шәрүк беглый, Хәмидулла качкын, Ташкай, Лачын Хәсән һ. б. әнә шундыйлардан.

Мишәр диалекты вәкилләре яшәгән төбәкләрдән—Түбән Новгород, Ульяновск, Пенза, Саратов өлкәләреннән, Мордва Республикасыннан язып алынган жырларны тикшергәндә, аларда борынгы тел күренешләренен саклануына да, рус алынмаларынын шактый күп кулланылуына да, әлеге диалектка хас булган лингвистик үзенчәлекләрнен кин урын алуына да игътибар итмичә мөмкин түгел. Хәер, шулай булуы табигый дә: фольклор әсәрләренә традицияле лек, мәгълүм бер кануннарны саклап ижат итү хас. Икенчедән, тарихи жыр геройларынын тормышы һәм язмышы ул үзе яшәгән чор вакыйгалары белән, туган халкынын социаль һәм рухи халәте белән аерылгысыз бәйләнгән. Аерым бер шәхеснен язмышын күнеленә якын алып бәян иткәндә, халык шушы төбәккә хас тел үзенчәлекләреннән дә уңышлы файдаланган.

Элегрәк актив кулланылышта булып та, хәзерге телебездә искергән сүзләргә әйләнгән берничә мисалга тукталыйк. Самара, Ульяновск, Түбән Новгород өлкәләрендә, Мордовиядә кин таралган «Шәрүк беглый» жырында түбәндәге юллар бар:

Кара урманнарда, әй, утларда
Шәрүк Беглый атын үйната.

Мәгълүм булганча, **ут** сүзе борынгы төрки телдә үлән мәгънәсен белдергән. Татар телендә ул утлык, утлау, сарут кебек сүзләрдә сакланган.

Мишәр диалектынын аерым сөйләшләрендә ут әле хәзер дә үлән, чүп үләне мәгънәсендә кулланыла. Удмуртиядә яшәүче татарлар сөйләшендә ут сүзе көтүлекне анлата[2].

Яки булмаса, Түбән Новгород өлкәсендә язып алынган «Ташкай» исемле жырдан бер өзек китерик:

Сугышыр да идем солдат белән,
Баксам, кистән бавым өзелгән.

Биредә кулланылган **кистән** сүзе борынгы сугыш коралы исемен белдерә. Кистән тимер шар, гер кебек әйберләрне кыска таякка бау, чылбыр яки каеш белән беркетеп ясалган. Бу сүз тарихи әсәрләрдә, жыр-бәетләрдә генә очрый.

Жыр текстларында борынгылык күренешләре авазлар куллану өлкәсендә дә чагылыш таба. Мәсәлән, хәзерге телебездәге кайбер сүзләрдә төшеп калган **г** авазын шул ук сүзләрдә борынгы традицияләрне саклап куллану очраклары бар. Мона мисаллар «Качкыннын михнәте бигрәк зур» жырында күп:

---

[1]Татар халык ижаты. Тарихи һәм лирик жырлар.—Казан, 1998,— Б. 488.
[2]Татар теленен диалектологик сүзлеге. —Казан, 1993.—Б.332.

Агай, бер **угълынны** солдатка бир...
Бармагымны киссәм, **агырта**...
**Егълама**, анай кәбәм... һ. б.

Пенза өлкәсенең Кикин авылында язып алынган «Әнием, бирәсен мине солдатка» жырында **кавырсын** сүзе **кагырчын** әйтелешендә теркәлгән:

Аваларда очкан асыл кошнын
Кагырчынын алдым каләмгә.

Галимнәр күрсәтүенчә, язма телдә **г** авазы урынына **w** куллану яки **г** тартыгынын бөтенләй төшеп калуы XIX гасыр ахыры—XX гасыр башларында гомуми күренешкә әйләнә. Әмма кайбер әдәби әсәрләрдә элеккеге традицион кулланылыш та очрый[1].

Борынгы әйтелеш үзенчәлекләреннән тагын берсе—**мин** алмашлыгында **м** авазы урынына **б** куллану (Бу сүздә хәзер сузык аваз көчеше дә барлыкка килгән):

Агай, бер угълынны солдатка бир,
Шунда **бән** төшәрмен исенә.
*(«Качкыннын михнәте бигрәк зур»)*

Халыкнын тарихи жырларында аерым грамматик формаларда электән үк килгән әйтелеш нормалары сакланганнар. Мәсәлән, хәзерге телдәге чыгыш килешнен кушымчасы урынына **дән-дин** кушымчасын әйтеп жырлаганнар:

**Себерләрдин** алган ак күлмәгем,
**Итәгендин** озын жинләрем.
*(«Качкыннын михнәте бигрәк зур»)*

Бу—XIX гасыр әдәби телендә дә очрый торган күренеш. В. Хаков язуынча, «борынгы уйгыр һәм иске үзбәк телендә чыгыш килешенә ялганып килгән—**дыйн,—дин,—тыйн,—тин** кушымчалары ул чордагы татар әдәби теле өчен ят түгел»[1]. Әле шунысын да әйтергә кирәк, татар халкынын мәҗлес жырларында бу форманы өлкәннәрдән бүген дә ишетергә мөмкин.

Мишәрләрдән язып алынган тарихи жырларда боерык фигыльнен—**гыл/-гел, кыл/-кел** кушымчаларын куллану да очрый. Бу форма турында күренекле галим Л. Җәләй болай дип язган иде: «Татарнын борынгы әдәби телендә, гомуми төрки элементы буларак, боерык фигыльгә—**гыл/-гел (-кыл/-кел)** формалы кушымча ялгау шактый озак заманнар, әйтергә мөмкин, Мәҗит Гафури һәм Тукайларга чаклы дәвам итә.» Әлеге кушымча,—**гын/-ген** вариантларына да күчеп, көнбатыш һәм көнчыгыш диалектларнын сөйләшләрендә бүгенге көндә дә кулланылышта йөри. Безнен тикшеренү объекты булган жырлардан әлеге боерык фигыль формасына түбәндәге мисалларны китерергә мөмкин:

Тимәгел, Бикзәнтәй, ятимнәргә...
*(«Дашкай»)*

Еглама, анай, кәбәм, бетмәгел,
Якын жирдә түгел, көтмәгел!
*(«Качкыннын михнәте бигрәк зур»)*

XIX гасырга караган тарихи жырларда, аерым борынгы үзенчәлекләр саклану белән бергә, яна күренешләр дә урын ала. Шундыйлардан рус сүзләренен шактый актив кулланылуын күрсәтергә кирәк. Халыкнын төрле социаль катлауларга бүленүе, административ төзелешкә караган титул-дәрәжәләрнен барлыкка килүе сөйләм телендә дә чагылыш табалар. Шулай ук һөнәр, кәсеп исемнәрен, тоткынлыкны, качкын булып йөрүне белдергән рус алынмалары да кулланыла башлый. Алар жыр исемнәрендә дә күчәләр: Шәрүк **беглый** (качкын), Староста кызы, Әхсән **голова** (башлык, түрә мәгънәсендә), Әбделмән **купис** (купец, сәүдәгәр), **Наемщик** (башка бирәү урынына солдат хезмәтенә ялланган кеше) һ. б. Жыр текстларында шулай ук халыкнын көндәлек тормышына турыдан-туры караган, мәгънәви яктан төрле лексик-семантик төркемнәргә кергән рус сүзләре күп. Аларнын кайберләре рус теленнәгечә үк алынганнар. Мәсәлән:

Кара урманнарда йөргән чакта
Очырадым куйлар гуртына.
*(«Дашкай»)*

[1]Хаков В. Х. Татар әдәби теле тарихы.—Казан, 1993.—Б. 112.

Бу сүз мәләкәс сөйләшендә (Ульяновск өлкәсе) хәзер дә кош-корт төркеме, көтүе мәгънәсендә кулланыла.

Хвалын садларын ни куркәйтә...
*(«Аким качкын жырлары»)*

**Сад** сүзе мишәр диалекты сөйләмнәрендә бакча мәгънәсендә әле дә кин кулланылышка ия.

Рус алынмаларының күбесе исә татар теленен үз фонетик-грамматик закончалыкларына яраклаштырылып кабул ителгәннәр. Алынмаларда күп кенә авазлар алмашынган, төшеп калган яки өстәлгән:

Өстемә казаки мин тектердем,
Алдым аглийский пуставын.
*(«Хәмидулла качкын»)*

Әтиемәсен сивай аты
Таймас микән көченнән?
*(«Староста кызы»)*

**Сивай**—русча сивый сүзеннән ясалган. Әйтик, мишәр диалектының ләмбрә сөйләшендә сибай сүзе күк төстәге атны белдерә *(Татар диалектологик сүзлеге.—Казан, 1993.—Б. 80.)*. Ә мондый мисалларны күпләп, хәтта бик күпләп китерергә мөмкин.

Халык жырларының сүзлек хәзинәсен тикшергәндә, андагы диалекталь үзенчәлекләргә дә аерым игътибар бирми мөмкин түгел. Жирле сөйләшләргә хас кайбер сүзләрнен мәгънәләрен махсус тикшереп кенә анлап була.

Мишәр жырларында **кәбәм** сүзенен еш кулланылуы күзгә ташлана. Мәсәлән:

Яшь вакытта үстем авылымда,
Әти-әни кәбәм кулында.
*(«Шәрук беглый»)*

«Качкыннын михнәте бигрәк зур» жырында кәбәм сүзе ун тапкыр, «Әнәй кәбәм» жырында биш тапкыр кабатлана, шулай ук «Бәхетсез солдатын киләэ», «Дашкай» һ. б. жырларда еш очрый. Кәбәм сүзе мишәр диалектында—яратып, иркәләп эндәшү сүзе. Мәләкәс сөйләшендә **эни** мәгънәсендә дә йөри.

Тарихи жырларда мишәр һәм Себер диалектларында кулланыла торган **куй** сүзе дә урын алган (ул **сарык** мәгънәсен белдерә). Мәсәлән:

Бәйләп салдылар ла куй кебек...
*(«Качкыннын михнәте бигрәк зур»)*

**Кизләү** сүзе мишәр диалектына караган күп кенә сөйләшләрдә **чишмә** мәгънәсендә йөри. «Качкыннын михнәте бигрәк зур» исемле жырда бу сүз шул ук мәгънәдә кулланылышын тапкан:

Суык та гына кизләү өсләрендә
Ашап йөри Тали атлары.

«Ташкай» жырында мишәр диалектына хас булган багу сүзе **карау** мәгънәсен белдерә:

**Баксам**, кистән бавым өзелгән.

Диалекталь үзенчәлекле шушы жырлар язып алынган төбәкләрдә—Мордовиядә, Пенза, Ульяновск, Түбән Новгород өлкәләрендә бүгенге көндә дә кулланыла торган тагын берничә сүзгә тукталыйк. Мәсәлән, **сыр** сүзенен мишәр диалектында бизәк һәм буяу мәгънәләре бар. Түбән Новгород өлкәсендә кин таралган «Ташкай»да ул нәкъ шул мәгънәләрне белдерә дә:

Биек тау башына йорт салдырдым,
Нинди **сырлар** белән **сырлатыйм**?

Багалма сүзе аерым мишәр сөйләшләрендә **алма** мәгънәсендә кулланыла. Самара өлкәсенен Зөя авылында язып алынган «Әбделмән Купис» жырында да анын алма мәгънәсен анлатканлыгы күренә:

Әбделмән кулисның багалма садында
Аралаш кына утырткан карама.

Түбәндәге өзекләрдә китерелгән диалекталь лексика да, нигездә, көнбатыш диалект сөйләшләре өчен генә хас булып тора.

Әхсән голованың чемоданы,
Унике икән аның **бүлкәсе**.
*(«Әхсән голова»)*

**Бүлкә**—бүлек, бүлем мәгънәсен белдерә.

Акча суккан алтын станокны
Идел **тобасына** ташладым.
*(«Әбделмән кулис»)*

**Тоба**—елганың тирән, кин, тынычрак аккан урыны; упкын.
**Кыю**—кыйгачлап кисү.

Кайбер сүзләр җырларда кулланылган мәгънәдә диалектологик сүзлекләрдә дә теркәлмәгән. Әмма аларның этимологик нигезе башка сүзләрдә чагылыш тапкан һәм мәгънәне билгеләргә мөмкинлек бирә.

Донской кырларыннан узган чакта,
Мангай чәч кенәем велелди.
*(«Хәмидулла качкын»)*

**Вел-вел итү** карсун сөйләшендә—**җем-җем** итү; димәк, бу урында **велелдәү** сүзен җемелдәү, ялтырау мәгънәсендә карарга кирәк.

Шушы ук җырда **кыстау** сүзе дә кулланылган:

Мал гынам кала дип әйтәсез,
Белмисез җанымның **кыставын**.

Карсун сөйләшендә **кыстаныч, кыстанычлык** сүзләре **авыр, кыен** мәгънәсендә сакланган. Күренә ки, **җан кыставы** бу җыр юлларында—җанымның авыр хәле, җан газабы дип аңлашыла ала.

Мишәр диалектына караган төбәкләрдән язып алынган тарихи җырларда әлеге диалект өчен типик булган аваз закончалыклары да билгеле бер дәрәҗәдә чагылыш таба. Әйтик, кайбер авазларның төшеп калуы җыр текстларында берничә урында күзәтелә, тартыкларның төшеп калу очраклары исә гарәп-фарсы алынмаларына карый.

Билгеле булганча, калын (увуляр) **г** авазы мишәр диалекты сөйләшләрендә кулланылмый, ул яки нечкә **г** белән алмашына яки төшеп кала. Йоткылык тартыгы **h** шулай ук татар сөйләменә хас аваз түгел, ул алынмалар белән килеп кергән. Җирле халык сөйләмендә бу аваз, димәк, үзләшеп җитмәгән:

Җома көн мәчеткә хәер куйдым...
*(«Дашкай»)*

Сүз башында **о, ө, у** авазларының төшеп калуы күзәтелә. Мәсәлән:

Озын гына көнне, кыска төнне
Кортлар бал ташыйлар **муртага.**
*(«Шәрук беглый»)*

**Муртага**—умартага.
Умарта сүзенең бу формада кыскартылып әйтелүе (бирелә **а—у** күчеше дә бар) мишәр диалектында кин таралган.

Казаннардан алган иyремнең
Зәнгеләрен ничек ачармын.
*(«Качкынның михнәте бигрәк зур»)*

**Зәңге**—өзәнге.

Кара урманнарда йоклаганда
Иyремне куйдым **башчыма**.
*(«Ташкай»)*

**Башчыма**—баш очыма.

Аерым сүзләрдә, авазлар үзгәреше белән бергә, иҗекләр кыскаруы да күзәтелә:

Уникe иде минем **тирмәнем**,
Акчам кая киткәнен белмәдем.
*(«Әбделмән купис»)*

**Тирмән**—тегермән.

Түбәндәге җыр юлларындагы сүзләрдә исә мишәр диалектына хас тартык аваз тәңгәллекләре күренә.

**Каста** идем, хәлем юк иде.
*(«Ташкай»)*

**Каста**—хаста (**х-к** тәңгәллеге).

Аеракай нөгез, болан диган,
Ашап кына туймый **нүектән**.
*(«Качкынның михнәте бигрәк зур»)*

**Нөгез**—мөгез, **нүек**—мүк (**м-н** тәңгәллеге).

Кайбер тартык авазлар, мишәр сөйләшләрендәгечә, бик нечкә вариантта килгәннәр һәм язып алучылар тарафыннан шулай теркәлгәннәр дә. Мәсәлән:

Ташлама, **каньәтекәем**, Алла өчен.
*(«Абушай»)*

Мондый күренеш, ягъни **н**, **т**, **р** кебек тартыкларның бик нечкә вариантларда әйтелүе мишәр диалектын урта һәм Себер диалектларыннан аеручы дифференциаль билге булып тора.

«Качкынның михнәте бигрәк зур» җырында **уята** сүзенә **г** тартыгы өстәп әйтелгән:

Кеше күрсә, атым **уйгата**.

Мишәр диалектына хас булган сузык аваз закончалыкларыннан җыр текстларында чагылган ин характерлы күренешләрнең берсе—дифтонгларның монофтонглашуы, ягъни кыскартылып, бер авазга гына калуы:

Асла чыга алмадым **күектән**.
*(«Качкынның михнәте бигрәк зур»)*

**Күек**—көек (кайгы, борчу мәгънәсендә).

Зариф абзый килгән, елап **сүли**...
*(«Хәмидулла качкын»)*

**Сүли**—сөйли.

Үссә, Биктимергә сүләрсен.
*(«Дашкай»)*

**Сүләрсең**—сөйләрсен.

**Ө—ү** күчеше дә мишәр сөйләшләрендә шактый кин таралган күренеш. Түбәндәге җыр юлында бу күренешкә мисал бар:

Туры аткынамда ияр, йүгән...
*(«Дашкай»)*

**Йүгән**—йөгән.

Фонетик үзенчәлекләрне анализлаганда, тагын бер күренешнең игътибарга лаек булуын әйтми мөмкин түгел. Ул да булса—**ж—й** мәсьәләсе. Мишәр диалекты **й**—ләштерүче диалект булып санала, ягъни анда әдәби телдәге һәм урта диалект сөйләшләрендәге **ж** урынына күбрәк **й** (орфографиядә **е, я, ю**) кулланыла. Төрле авыллардан төрле авторлар язып алган бер үк җыр вариантларында исә **ж** һәм **й** кулланылышында төрлелек күренә. Мәсәлән, «Ташкай» җырында (Түбән Новгород өлкәсенен Калина авылында, Х. Ярми язып алган) **жырладым, жырлыйлар** әйтелешләре теркәлгән. Бу җырның «Дашкай» вариантында исә (Түбән Новгород өлкәсенен Митрявыл авылында И. Надиров язып алган) **ерымны, ерлыйлар, ертыла, йибәр** кебек әйтелеш чагылган. Күренә ки, мондый күренешләр халык авыз иҗатында әдәби тел белән җирле сөйләм үзенчәлекләре арасындагы мөнәсәбәтнен катгый формада булмавын дәлилилләр.

Инде югарыда исемнәре телгә алынган җырларның грамматик үзенчәлекләренә килсәк, бу өлкәдә дә тарихи шәхесләрнен туган төбәгенә хас булган кайбер

формаларны күрәбез. Ин элек төрле сүз төркемнәренә караган сүзләрнең уртасына яки ахырына кушымчалар өстәп куллануны әйтергә кирәк. Мондый күренеш татар сөйләшләрендә кин таралган:

Бүгенгесе авыр көннәремне...
*(«Дашкай»)*

**Бүгенгесе**—бүгенге.

Әни, кәбәм, килмә син каршыма,
**Куркынырсың** богау тавышына.
*(«Абушай»)*

**Куркынырсың**—куркырсың.

Кара урман ашалый карадым...
*(«Аким качкын жырлары»)*

**Ашалый**—аша.

Мишәр сөйләшләрендәгечә, бу жырларда да—**мы/-ме** сорау кисәкчәсенең затсан кушымчалары алдыннан кулланылуы урын ала. Мәсәлән:

**Беләмесең**, жаным, **белмимесең**
Сиксән солдат алдылар уртага.
*(«Хәмидулла качкын»)*

«Егерме ел солдат булып йөрдем» жырында, әдәби телдән һәм башка татар диалектларындагы үзенчәлекләрдән аермалы буларак,—**ме**, сорау кисәкчәсе фигыльгә ялгану урынына алдан килгән **дә** кисәкчәсенә кушылган:

Аш янына утырганда
Мине **дәме** сагынасың?

Мордовиянең Татар Пешләсе авылында язып алынган «Никрутлар жыры»нда түбәндәге юллар бар:

Киендермә, әнием, киенмим,
Мин бармыймын кияү **егетли**.

Биредәге **кияү егетли** тезмәсе бик үзенчәлекле. *Л.* Жәләй үзенең «татар диалектологиясе» китабында мондый форманың Әтнә төбәгендә кин таралганлыгын әйтә. Ул язганча, бу төбәк татарлары «Мин Казанга **кунаклый барам**» формаларын систематик рәвештә кулланалар.

Күренә ки, **мин бармыйм кияү егетли** жөмләсен **мин кияү егете булып (буларак) бармыйм** дип анларга кирәк.

Тарихи жыр текстларында—**а (-ә,—й)** формалы хәл фигыльнең, хәрәкәтне белдерүче фигыль тезмәсендә килеп, төп фигыль белән бер үк вакытта башкарылган эш-хәлне белдерү очрагы да бар:

Ике өй арасында елаша йөри
Шул Әбделмән күпис кызлары.
*(«Әбделмән күпис»)*

«Ташкай» жырындагы **Артыман пагун житкенчә** диган жыр юлында—ганчы формалы хәл фигыльнең мишәр диалектына хас булган фонетик варианты кулланылган.

Күренгәнчә, халык күңеленең көзгесе, аның жан авазы булган фольклор әсәрләрендә, аерым алганда тарихи жырларда, гомуммилли характердагы тел чаралары белән бергә, кабатланмас рухи байлык булган жирле сөйләм үзенчәлекләре дә матур бизәк булып чигелеп бара. Алар үткән тарихыбызны, милли байлыгыбыз булган тел үсешен, мәдәниятебезне тирәнрәк анларга ярдәм итәләр.

**Ким МИҢНУЛЛИН,**
*филология фәннәре кандидаты*
**Гафур СӨНГАТОВ,**
*КДУ укытучысы*

## БЕР СОРАУГА—БЕР ҖАВАП

*—Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты (ТӘҺСИ) латинга кайту җәһәтеннән нинди эшләр башкара?*

Институт директоры, филология фәннәре докторы, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, халыкара төрки академия академигы, язучы **Нурмөхәммәт ХИСАМОВ:**

—ТӘҺСИ—татар халкын төрле яклап: тарихи, этнографик, мәдәни, әдәби яктан, тел һәм сәнгать җәһәтеннән өйрәнә торган гыйльми үзәк. Ниһаять, без соңгы 10-15 елда милли мирасыбызны бүгенге чор шартларында өйрәнә башладык. Иң мөһиме: татар халкы үзенең никадәрле зур байлыкка ия икәнлеген аңлады. Бәйсезлек өчен көрәш чорында безнең өчен бу бик тә көчле стимул иде. Милләт үз зурлыгына, башкалар белән тиң булуына төшенде.

ТӘҺСИ дә ике тел бүлеге—тел белеме һәм лексикография (сүзлекләр эшләү) бүлекләре әһәмиятле урын алып тора. Республика тормышындагы яңа вәзгыять бу ике бүлекнең дә эшчәнлеген бик нык активлаштырды. Татар теленең дәүләт теле дип игълан ителүе сүзлекләргә ихтыяҗ тудырды. Соңгы берничә елда гына да бик күп сүзлекләр дөнья күрде, яңалары төзелә тора, чыга тора.

Татар теленең теоретик мәсьәләләрен яктыртуда да яңа төсмерләр бар. Латинга кайту теоретик һәм гамәли планда яңа проблемалар тудыра. Шунлыктан, орфография латин әлифбасы шартларында янача эшләнә. Гомумән, латинга кайту җәһәтеннән җиренә җиткереп башкарасы гамәлләребез, уй-ниятләребез хәттин ашкан. ТӘҺСИ аларны эзлекле рәвештә тормышка ашырырга тырыша.

Телнең үз табигатен камилрәк чагылдыру юнәлешендә, тел тарихын яктыртуда да яңа үзенчәлекләр бар. Мисал өчен бер генә юнәлештармак: татар теле иске Русия шартларында XVI гасырдан XIX гасырның беренче яртысына кадәр империядә икенче дәүләт теле, дипломатия теле булып торган. Урыс дәүләте көнчыгыш илләре белән татар телендә язышкан. Татар яшәгән төбәкләрдә суд-хөкем, канцелярия эшләре татар телендә башкарылган. Бу тәҗрибәне хәзерге терминнарыбыз өлкәсендә нигез итеп кулланырга була лабаса! Сер түгел ки, терминнарны кирәксәкирәкмәсә дә бер генә телдән алу телнең аһәңлегенә шактый зыян сала. Борын-борыннан теркәлеп килгән иҗтимагый-сәяси терминнарыбыз исә бүгенге тел үсеше өчен бәрәкәтле мая булып тора. Элегрәк без тел үсешен, алгарышын диалектларның юкка чыгуы итеп кенә күзаллый идек. Хәлбуки, диалектлар (шивәләр)—теләсә кайсы телнең искиткеч зур байлыгы. Бездә хәзер диалектларны тирәнрәк өйрәнү ихтыяҗы туды. Андагы сүзлек маясы, фразеологик байлык әдәби телне тулаем баетуда бик тә мөһим чыганак булып тора. Бу—институт эшчәнлегенең бер генә тармагы.

# Ictimagi-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## ПАРИЖДА ТАТАРСТАН КӨННӘРЕ

6-7 июньдә Парижда—ЮНЕСКОның штаб-квартирасында Казанның 1000 еллыгы уңаеннан Татарстан Республикасы көннәре булып үтте. Бу тантанада Президент **Минтимер Шәймиев** житәкчелегендә рәсми делегация катнашты. Делегация составында Казан мэры **К. Исхаков**, ТР Фәннәр академиясе президенты **М. Хәсәнов**, ТР мәдәният министры **И. Тарханов** һ. б. бар иде.

Татарстан делегациясе Парижда күп кенә очрашулар үткәрде, анда Казанның меңъеллыгын бәйрәм итүгә багышланган мәсьәләләр тикшерелде.

Татарстан Президенты ЮНЕСКО Генераль директоры **Коитиро Мацууро** белән очрашты.

Татарстан дөньякүләм әһәмияткә ия тарихи һәйкәлләр тупланган төбәкләр исәбенә керә. Кимендә өч типтагы мәдәниятнең (төрки, фин-угор һәм славян-урыс), ике диннең (ислам һәм христиан диннәре) бер-берсенә йогынты ясавы бу төбәкнең уникаль, мәдәни-тарихи кыйммәтләрнең үзенчәлекле булуын тәэмин итә. 1998 елда өч объект—Казан Кремле тарих-архитектура комплексы, Болгар тарих-архитектура комплексы һәм элекке Свияжски шәһәренең шәһәр корылмалары ансамбле ЮНЕСКОның Бөтендөнья мәдәни һәм табигать мирасы комитетына тапшырылды һәм Россия Федерациясе буенча Бөтендөнья мәдәни мирасның башлангыч исемлегенә, ә 2000 елның 30 ноябрендә ЮНЕСКОның хөкүмәтара комитеты сессиясендә Казан Кремле тарих-архитектура комплексы ЮНЕСКОның Бөтендөнья мәдәни һәм табигать мирасы исемлегенә кертелде.

Шулай ук ЮНЕСКО карамагында Ф. Шаляпин исемендәге опера фестивален һәм Р. Нуриев исемендәге балет фестивален үткәрү мәсьәләләре тикшерелде.

2001 елда Казанда «Бөек Идел юлы» дигән халыкара конференция үткәрү турында килешүгә ирешелде.

Мәдәни-тарихи кыйммәтләрне саклауга зур өлеш керткәне өчен Коитиро Мацууро Минтимер Шәймиевкә Әбүгалисина исемендәге көмеш медаль тапшырды.

## КАЛӘМДӘШЛӘРГӘ—«БӘЛЛҮР КАЛӘМ»

Камал театрында ел саен үткәрелә торган «Бәллүр каләм» дигән журналистлар конкурсына йомгак ясалды.

Каләмдәшләребезне һөнәри бәйрәмнәре уңаеннан Президент Минтимер Шәймиев исеменнән ТР вице-премьеры **Зилә Вәлиева** котлады.

Республикабыз икмәк үстерү, самолетлар житештерү һәм нефть чыгару белән берләттән, медиаинфраструктураны да актив рәвештә үстереп килә, дип искәртте Зилә Вәлиева. Татарстан журналистлары Россия күләмендәге төрледән-төрле конкурсларда күпсанлы призлар яулады. «Бәллүр каләм» дигән республика конкурсы үткәрелү исә моңа бер дәлил булып тора.

Аннары «Бәллүр каләм» конкурсы жиңүчеләрен котлау булды. «Мактау һәм хөрмәт» номинациясендә **Ринә Зарипова** *(«Татарстан яшьләре»)* һәм **Рафаэль Мостафин** *(«Казанские ведомости»)* лауреат исеменә лаек булды.

«Елның иң яхшы язмасы» номинациясендә «Бәллүр каләм»гә **Илсөяр Хәйруллина** *(«Ватаным Татарстан»)*, **Венера Якупова** *(«Казанские ведомости»)*, **Флера Низамова** *(«Татарстан яшьләре»)* лаек дип табылды.

Район газеталары арасында Түбән Каманың **«Туган як»** газетасы иң яхшы буларак аталды. **«Новый Зай»** (Зәй шәһәре) елның иң яхшы шәһәр газетасы дип табылды. Республиканың ел газетасы исеменә менә инде дүртенче тапкыр **«Татарстан яшьләре»** лаек булды. **«Сөембикә»** исә ел журналы буларак танылды.

## ХАЛЫК ШАГЫЙРЕ БӘЙРӘМЕ

Инде мәгълүм булганча, шушы елның май аенда Татарстанның халык шагыйре **Гамил Афзалга 80 яшь** тулды. Шул уңай белән 23-25 майда Әлмәттә һәм Актанышта тантаналы төстә әдәби бәйрәмнәр уздырылды. Әлмәттә узган әдәби кичәдә Татарстан Дәүләт Советы рәисе Ф. Мөхәммәтшин, мәдәният министры И. Тарханов, Язучылар берлеге рәисе Ф. Галимуллин, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Р. Фәйзуллин, Әлмәт шәһәре хакимият башлыгы Ф. Комаров, Актаныш

районы хакимият башлыгы Э. Фәттахов, «Татнефть» АҖ генераль директоры урынбасары Р. Әбүбәкеров һ. б. катнашты һәм чыгыш ясады. Кичә ахырында юбиляр шагыйрь Гамил Афзал чыгыш ясады, халыкка рәхмәт хисләрен белдерде.

24-25 майда Актанышта үткәрелгән татар әдәбияты көннәре дә, нигездә, Г. Афзалның 80 еллык юбилеена багышланган иде. Актаныштагы тантаналарга Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин, Язучылар берлеге рәисе Ф. Галимуллин; бу төбәктә туып-үскән әдипләр Ләбиб Лерон, Эльмира Закирова, Фәйрүзә Мөслимова, Данил Салихов, Вахит Имамов, профессор Фәрит Хатыйпов, иҗат командировкасы рәвешендә Җәүдәт Дәрзаманов, Галимҗан Гыйльманов, Рөстәм Мингалим, Рәдиф Сәгъди килделәр. Әдәби чараларда Актаныш районында яшәп иҗат итүче язучылар Әмирҗан Моталлапов, Мөхәммәт Мирза, Фәнәвис Дәүләтбаев катнашты.

Казаннан килгән язучылар Актаныштагы «Агыйдел дулкыннары» иҗат берләшмәсе әгъзалары белән очраштылар. Әдәби очрашулар, шулай ук, районның Пучы һәм Әнәк авылларында да уңышлы үтте.

## КИРӘКЛЕ БОЕРЫК

Мәдәният министрлыгы Баш архив идарәсе белән берлектә мәдәният учреждениеләрендә документларның сакланышын тәэмин итүче чаралар турында боерык чыгарды.

Анда тарихи кыйммәткә ия документларны югалтуга юл куймау, саклау шартлары, вакытында һәм сыйфатлы итеп дәүләт архивларына тапшыру мөһимлеге күрсәтелгән. Документларның сакланышына урындагы житәкчеләр җаваплы, ә методик ярдәмне архив учреждениеләре күрсәтергә тиеш.

## МӘГЪРИФӘТЛЕ МИНИСТР

Әле үткән ел гына Татарстан мәгариф министры **Фарис Харисов** педагогия фәннәре докторы булган иде һәм менә хәзер Россия мәгариф академиясенең әгъза-корреспонденты итеп сайланды.

## ПЕРМЬ ЯКЛАРЫНДА

14-19 майда Пермь өлкәсенең Барда районында Татар әдәбияты көннәре булып үтте. Язучылар Әхмәт Рәшит, Резеда Вәлиева, Ләбиб Лерон, Рәдиф Сәгъди, Рәшит Ягъфәров һәм Идият Әширов составындагы язучылар төркеме районның егермеләп авылында чыгыш ясады. Шулай ук, район газетасы каршындагы «Таң йолдызы» әдәби берләшмәсе әгъзалары, район зыялылары, Оса педагогия училищесының татар бүлеге студентлары белән дә очраштылар.

Барда районы хакимиятендәге өңгәмә вакытында алга таба мондый әдәби очрашуларның ел саен һәм өлкә күләмендә оештырылачагы турында килешенде.

## ЯКТАШЛАР КОТЛАДЫ

Май аенда «Буа» якташлык җәмгыяте, район үзәгенә җыелып, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстан халык депутаты шагыйрь **Ренат Хариска 60 яшь** тулу уңаеннан тантана уздырды. Юбилярның хезмәттәшләре, каләмдәшләре, укытучылары, сабакташлары, Ульяновск районының ул туган авылдан килгән җәмәгатьчелек вәкилләре тәбрикләү сүзләре әйтте, бүләкләр тапшырдылар. Һәвәскәрләр аның җырларын башкарды, шигырьләрен укыды.

Район мәдәният йортында Р. Харис рәсемнәреннән күргәзмә дә оештырылган иде. Андагы 50 дән артык әсәрне шагыйрь үзе укыган Луначарский исемендәге мәктәпкә бүләк итте.

## АФЗАЛ ШАМОВКА БАГЫШЛАП

16 майда Казанның Актерлар йортында күренекле прозаик, тәрҗемәче һәм җәмәгать эшлеклесе **Афзал Шамовның** тууына 100 ел тулуга багышланган искә алу кичәсе булды.

Аны кереш сүз белән Татарстан Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин ачты. Әдип турында истәлекләр белән Афзал Шамовның туган авылы—Яшел Үзән районының Татар Танае авылы күмәк хуҗалык рәисе Хәлим Идиатуллин, язучылар Кави Латыйп, Лирон Хәмидуллин, Мөсәгыйт Хәбибуллин, язучының энесе Салих Шамов чыгыш ясадылар.

Кичәдә Афзал Шамов әсәрләре буенча эшләнгән инсценировкалар уйналды, өзекләр укылды, җырлар җырланды.

## ЯҢА УРАМГА—ЯЗУЧЫ ИСЕМЕ

Яңа Савин районында Казансу елгасы ярыннан Ямашев проспектына хәтле төзелгән яңа урамга күренекле язучы, күпсанлы популяр романнар авторы, Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, **Габдрахман Сафа улы Әпсәләмов** исеме бирелде.

*Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** «Өч ай»—рәссам Зөфәр Гыймаев эше.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** шагыйрә Резеда Вәлиева.

# ЯҢА КИТАПЛАР




**Гайнетдин Әхмәров**: тарихи-документаль җыентык. Казан: «Хәтер» нәшрияты.—2000. 384 б. Тиражы—2000 данә.

Китапка күренекле татар тарихчысы, педагог һәм җәмәгать эшлеклесе Гайнетдин Әхмәровның Болгар дәүләте һәм Казан ханлыгы тарихларын өйрәнүгә багышланган гыйльми хезмәтләре, милли тарихыбызның башка өлкәләренә дә караган мәкаләләре тупланды. Җыентыкта, шулай ук, галимнең тормыш юлын һәм эшчәнлеген тулырак ача торган документаль чыганаклар урын алды.

Китап тарихыбыз белән кызыксынучы киң катлау укучыларга тәкъдим ителә.

ТАНЧУЛПАН (Чулпан Әхмәтова). **Кыргый чәчәк.**—Казан: Татарстан китап нәшрияты.—2000. 112 б. Тиражы—2000 данә.




Шагыйрәнең беренче китабына язган керешендә мондый юллар бар: «Мин—Актаныш кызы. Туган авылым Бишкүмәч хәзер юк инде. Авылларны эреләндерү чорында авылым балалары кайсы кай якка сибелеп, таралып беттеләр. Хәзер ул урында берән-сәрән калган агачлар гына моңаеп утыра бирәләр. Бишкүмәчнең бәпкә үләнле ямь-яшел урамы еш кына төшемә керә.

Була шундый мизгелләр—җанны бушатасым килә. Кулыма кәгазь, каләм алам һәм дөньяга шигырь туа.»

Яшь шагыйрәнең бу җыентыгына лирик характердагы йөзгә якын шигыре тупланган. Китапның мөхәррире—Р. Корбанов, рәссамы—Д. Җәләлетдинов.

Индекс 73210



Резеда Валиева

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)